www.kazanutlary.ru

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ
ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН
БАШЛАП ЧЫГА

Бу санда

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Нур ӘХМӘДИЕВ. Офык артларында офык бар. *Шигырьләр.* .... 3
Марсель ГАЛИЕВ. Тимә, яшәсен! *Роман-новелла.* .... 8
Гөлзадә ӘХТӘМОВА. Бирешмәс көчләр табам. *Шигырьләр.* .... 53
Данил САЛИХОВ. Чукрак. *Роман.* .... 57
ТАҢЧУЛПАН. Гомер үтә шулай тоташтан. *Шигырьләр.* .... 97
Гәүһәр ХӘСӘНОВА. *Хикәяләр.* .... 102

*100нче бит:* Рәфикъ ЮНЫС. Явызлыкка һәйкәл кирәкме? ....100

ЯҢА ИСЕМНӘР

Лилия ФӘТТАХОВА. Җанымда илаһи тылсым. ....109

ЮБИЛЕЙЛАР

Рәфыйк ШӘРӘФИЕВ. Мәҗнүнгә дә үз дәүләте кирәк. *(Нур Әхмәдиевкә 70 яшь).* ....114
Камил КӘРИМОВ. Батырларча иҗат. *(Рауль Мир-Хәйдәровка 75 яшь).* ....118
Лирон ХӘМИДУЛЛИН. Күңел дәрьялары киң аның *(Равил Шәфигуллинга 75 яшь).* ....119
Гөлзадә БӘЙРӘМОВА. Чын безнеңчә – милли. *(Рушан Шәмсетдиновка 70 яшь).* ....120
Рамил ХАННАНОВ. Туганкай *(Фирдәвес Гарипованың туууына 75 ел).* ....121

ТУКАЙ ҺӘМ ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ

Рифә РАХМАН. Тукай эзләреннән йөргән галим: Мөхәммәт Гали. ....125

ӘДӘБИ ХӘЗИНӘЛӘРЕБЕЗ

Әнвәр ШӘРИПОВ. Сирин Батыршинның тууына 120 ел. ....128
Сирин БАТЫРШИН. Тормыш хатирәләре. *Автобиографик бәян-истәлек.* ....130

ТАТАР ТЕАТР СӘНГАТЕНӘ 110 ЕЛ

«Халыкка дәрсе гыйбрәттер театр». ....161
Рамил ХАННАНОВ. Җилкәннәрне сыный чор җилләре. .... 162
Миләүшә ХӘБЕТДИНОВА. Синең ничә нигезең бар? ....166
Ильтани ИЛЯЛОВА. Театр – җәмгыятьнең барометры ул. ....173

ЮМОР

Әхәт САФИУЛЛИН. Шаян монологлар. ....176

2017 елда дини бәйрәмнәр һәм истәлекле көннәр. *(Абдулла ДУБИН әзерләде).* ....183
2016 елда журналда басылган әсәрләр исемлеге. ....184
«Казан утлары» архивыннан. ....112
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ....190

Гамәлгә куючы –
«Татмедиа»
акционерлык
җәмгыяте

*БАШ МӨХӘРРИР –*
**Илфак Мирза улы**
**ИБРАҺИМОВ**

*ИДАРӘ:*

**Рабит Батулла**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Разил Вәлиев**
**Рәдиф Гаташ**
**Рәдиф Җамалетдинов**
**Айрат Зарипов**
**Дания Заһидуллина**
**Дамир Исхаков**
**Зиннур Мансуров**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Вакыйф Нуриев**
*(җаваплы сәркатип)*
**Данил Салихов**
**Айрат Сибагатуллин**
**Энгель Фәттахов**
**Равил Фәйзуллин**
**Рамил Ханнанов**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Рәфикъ Юныс**

---

*Мөхәррирләр:* **Айгөл Әхмәтгалиева, Гөлзадә Бәйрәмова, Фәнил Гыйләҗев, Камил Кәримов, Рәфикъ Юныс.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Рәзилә Хәйретдинова, Наил Кадыйров.**

*Исәп-хисап бүлеге:* **Эльвира Камалова** (баш бухгалтер).

---

✉✉: Редакция һәм нәшер адресы: *420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
☎☎: *Баш мөхәррир – 222-05-50 (өст. 1618).*
*Баш мөхәррир урынбасары – 222-09-83 (өст.1612).*
*Шигърият, сәнгать һәм хатлар бүлеге – 222-09-83 (өст.1616).*
*Исәп-хисап бүлеге – 222-09-80 (өст.1268).*
: **Факс** – (843) *222-09-83 (өст.1612).*

💻: **E-mail:** kazanutlari@yandex.ru

---

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кульъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

---

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды. Айга бер тапкыр чыга.
Басарга кул куелды 30.11.2016, график буенча 30.11.2016.
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108 $^{1}/_{16}$.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ М-3134. Тираж 4016.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы идарәсендә 2011 елның 23 мартында теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-44362.
Индекслар: 73210, П2365 (физик затлар өчен), 16262, П2368 (юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

---

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2016 ел



Нур
Әхмәдиев

# ОФЫК АРТЛАРЫНДА ОФЫК БАР

## Пәйгамбәрләр турында кыйсса

Пәйгамбәрләр җиргә килгән, киткән,
Үз дигәнчә һәркем көн иткән.
Пәйгамбәр дә судан яралмаган,
Кендекләре җиргә береккән.
Пәйгамбәрләр җиргә килгән, киткән,
Ничәү алар – төгәл кем белгән.
Пәйгамбәр дә Адәм баласы бит,
Сәгатьләре суккач, бер үлгән.
Пәйгамбәрләр җиргә килгән, киткән,
Күктә шулай кирәк тапканнар.
Хак илчесе диеп тормаганнар,
Аларга да ташлар атканнар.
Нух пәйгамбәр, Гайсә, Ибраһиммы,
Сөләйманмы – кайсы көчлерәк?
Кавемнәрне тугры, изге юлга
Бастырырга күпме көч кирәк?
Һәр пәйгамбәр утны-суны кичә,
Абруй ала, шөһрәт, дан ала.
Ахырзаман пәйгамбәре булып,
Тик Мөхәммәд кенә санала.
Шигырьнең дә бар үз нәбиләре*:
Кол Галиләр, Тукай кебекләр.
Пушкин белән Лермонтов та даһи,
Буй җитмәстәй биек, бөекләр.

*Нәби – пәйгамбәр.

Нур ӘХМӘДИЕВ (1946) – *шагыйрь, прозаик; «Аһәң», «Амбирак», «Абага чәчәге» һ.б. китаплар, шул исәптән дүрт томлык «Сайланма әсәрләр» авторы. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, С.Сөләйманова исемендәге әдәби премия лауреаты. Әлмәттә яши.*

Мин дә шагыйрь, халкым белән бергә
Күпме шатлык, моң-зар кичергән.
Мин дә шагыйрь, изге бу исемгә
Кер кундырмам, тап та төшермәм.
Мин дә шагыйрь, тел сагында торам,
Фикерем бар, баймын хискә дә.
Шигърияттә бер пәйгамбәр булу
Кереп карамый тик төшкә дә.
Пәйгамбәрләр җиргә килгән, киткән,
Пәйгамбәрләр – халык бәгыре.
Кемне гади һәм пәйгамбәр итү –
Бусы инде күкләр әмере.

## Тауга менсәм

Тау башында бөдрә җилләр уйный,
Үзәннәргә таман таралган.
Таулар горур, алар кешеләрдән
Күпкә алданрак яралган.

Тауга менсәм, сулыш иркенәя,
Юкка чыга әрнү, борчулар.
Әрем исләреннән исерәм мин,
Кылганнары шундый ярсулар.

Җай чыкканда, шушы тауга менеп,
Укып төшәм белгән догамны.
Фәрештәләр, дәшми-тынмый гына,
Язып бара минем кылганны.

Гади үрләр генә түгел таулар,
Язмыш бүләк иткән тәхет ул.
Шул тәхеткә басып, туган җирне
Данга күмү – үзе бәхет ул.

## Әйләнүдән җирем туктамый

Басып торам җирнең уртасында,
Кыйбла яктан җылы җил исә.
Өздерепләр күктә тургай сайрый,
Март бетмәгән әле югыйсә.

Сыерчыклар килеп өлгермәгән,
Карга кайтуына атна юк.
Кая карасам да, офык ачык,
Офыкларда бикле капка юк.

Бар тереклек гүя хәрәкәттә,
Кар суында коена чыпчыклар.

Бу офыклар соңгы офык түгел,
Офык артларында офык бар.

Җан иясе язгы мәшәкатьтә,
Хәрәкәттә бар да, йокламый.
Мин сокланып басып тора диеп,
Әйләнүдән җирем туктамый.

## Кем гаепле?

Кем гаепле?
Җавап табалмагач,
Өмет белән багам күкләргә.
Безнең сөю – ул гөнаһсыз сөю,
Үрнәк иде, үрнәк күпләргә.

Кем гаепле?
Нигә аерылыштык,
Кайсыбызда гаеп күб(е)рәк?
Айлар, еллар узды, тынычланмый,
Газаплана йөрәк көчлерәк.

Кем гаепле?
Әллә гайбәт сүзләр
Сиздермичә керде арага?
И Ходаем, башка гашыйкларны
Гайбәт сүзләреннән арала.

Кем гаепле?
Дөрес итеп моңа
Еллар гына җавап бирерләр.
Кем гаепле?
Синме, әллә минме –
Сак белән Сок кебек гомерләр.

## Фәрештәләр белән бәхәсләшмим

Ничә тапкыр авыз пешкәне бар,
Нигә кеше шулай ашыга?
Ничә тапкыр иткән изгелегем
Гөрзи булып төште башыма.

Аңа карап бер дә бирешмәдем –
Шундый итеп Ходай яраткан.
Юлың дөрес, диеп, фәрештәләр
Пышылдыйлар төрле тарафтан.

Фәрештәләр әйткәч, хактыр ла ул,
Шик-шөбһәгә алу килешми.
Кул-аякта егәр китеп бара,
Ә рухым сау, рухым бирешми.

## Безнең як

Болыннарда, уйсу урыннарда
Сыек томан ята кич-иртә.
Болыннарга чыгып, бер суласаң,
Чыклы үләне дә исертә.

Дөрес, безнең Идел-Камабыз юк,
Эстәрле ул башка төрлерәк.
Су буеның куе таллыклары
Кырлай урманыннан серлерәк.

Һималайлар белән чагыштырсаң,
Безнең таулар гади үр генә.
Тик гомергә хәтереңдә калыр,
Берәр тапкыр аны күр генә!

И туган як, газиз бишегем син,
Шулкадәрле ник син кадерле?
Хәтта котыпта да сине уйлау
Гел җылытып тора бәгырьне.

## Кеше җаны

*Йолдыз атылуны халыкта*
*яңа кеше туу билгесе, диләр.*

Әйтәләр бит: кеше үлгәннән соң,
Җаны күчә икән бүтәнгә.
Хакка рәхмәт, бер хәшәрәт итми,
Миңа кеше җаны керткәнгә.

Суалчан йә бөҗәк итәр иде,
Йә булмаса, ерткыч арыслан...
Нишләр идем, юлбарыслар белән
Җан кыюда әгәр ярышсам?

Үләксәләр белән туенырга
Чүл бүресе, ярый, итмәгән.
Кеше – горур (гәрчә кайберләре
Хайваннардан ерак китмәгән).

Кеше – горур, хыял канатлары
Вакытыннан алда сынмасын.
Бар гомере узсын сихәтлектә,
Ышанычы аның сүнмәсен!

Газиз Аллам! Миңа иңдергәнсең
Бер гөнаһсыз җанын төркинең.
Рәхмәт Сиңа, Синең кәнсәләрдә
Булмаса да таныш беркемем.

Хәер, коррупция дигән сүзне
Сезнекеләр хәтта белмидер.
Күк кәнсәсе, кайдан карасаң да,
Җирдәгеләр өчен өлгедер.

Миннән алда шушы җанны йөрткән
Инсан, бәлки, шагыйрь булгандыр.
«Карурман»нар мескеннәрдән түгел,
Нечкә күңелләрдән тугандыр.

«Карурман»нар кайчан язылган да,
Кемнәр язуы да – билгесез.
Алар туган халык бәгыреннән,
Шуңа күрә дә бит үлемсез!

Адәм балалары туалар да
Мәңгелеккә китеп баралар.
Яңа хуҗа эзләп гаҗизләнгән
Запас җаннар бардыр, бар алар!

Бер сәбәпсез күкләр күк(е)рәми,
Запасларның чыга кирәге.
Белсәң иде: кайсы асыл затта
Бәргәләнә Тукай йөрәге?

Кол Галинең вафатыннан бирле,
Күпме җилләр исте, су акты.
Нәфис затлар йөккә уза торды,
Малайлары туды, кыз тапты.

Шулар арасында татарымны
Данга күмгән тагын кемнәр бар?
Шигърияттнең асыл бакчасында
Күзнең явын алыр гөлләр бар.

Зәңгәр күктә йолдыз атылуны,
Әй кардәшем, нәрсә диярсең?
– Яңа кеше туды, котлы булсын,
Иясез җан тапты иясен!

***Редакциядән:***

*Каләмдәшебез бу айда үзенең юбилеен билгеләп үтә. Аңа исәнлек-саулык, иҗат уңышлары телибез.*

Марсель
Галиев

# ТИМӘ, ЯШӘСЕН!

РОМАН-НОВЕЛЛА

**Никрут**

Язмыш – гомер йомгагы.

Гайре табигый хәлгә юлыкканда, без «Көтмәгәндә... Уйламаганда... Очраклы рәвештә...» дияргә яратабыз. Бәлки язмыш челтәренең һәрбер үреме алдан уйланылгандыр, без аның бер генә бизәк-күзәнәген дә үзгәртә алмыйбыздыр. Шулай булган. Шулай була. Шулай булачак... Бу – яшәү асылының һәркемгә тәгаенләп язылган астыртын кагыйдәсе түгел микән әле?..

Менә мин – унсигез яшьлек никрут, табиблар каршында анадан тума килеш басып торам. (Рекрут – алман-француз сүзе, руска некрут булып кергән. Солдатка алынган, әмма солдат булып җитмәгән дигәнне аңлата.) Ярый әле үзем генә түгел, унбишләп егетне галәмәт зур бүлмәгә шулай төркемләп-төркемләп кертеп торалар. Бетсәк – бергә бетәбез, калсак – бергә калабыз, дигән янәшәлекне тою шыр ялангач халәттә, чарасыз икәнлегеңне оныттырып, юаш кына кыюлык өсти. Монда өстәлләр дә күп, ак халатлы табиб-медсестралар да шактый күренә. Менә шул күркәм генә ханымнар нинди боерык бирә инде: ятаргамы-торыргамы, бөгелергәме, тезләнергәме – оялу-кыенсынуыңны эчкә йотып, барын да карусыз үтисең. Табибларның күз карашлары иләсләнгән, бит очлары алланып чыккан шикелле, әмма тыштан кырыс-җитди күренәләр. Армиягә нинди мал озатасын кәгазьгә латин атамалары белән терки торалар. Язуы бер хәл, тән күзәнәкләреңне нәзберек салкын бармаклары белән тотып-капшап, бөтен гәүдәңне сындырып-сынап та карыйлар шикелле. Ике күзең дә үзара килешеп ачыла-ябыламы, уңы мәгърипкә төбәлгәндә, сулы мәшрикъка тайпылмыймы? Кирәкмәгән чыш-пыш хәбәрне дә, бер-берсеннән көнләшмичә, ике колагың да тигез ишетәме? Борын тишекләреңнән һава ургылып керәчыгамы? Авыз куышлыгың үз урынындамы, кыбырсык телеңне тигез-сәламәт тешләр коймасы тыеп тора аламы? Менә шундый четерекле сорауларга җавап эзли һәм хәлиткеч мөһерне суга башкалабыз Казанның таләпчән табиблары.

Якташым Ислам белән табибтан-табибка бергәрәк йөрибез. Ишелеп маңгаена төшкән куе кара чәчле бу үтә дә чибәр егет бик ипле, итагатьле күренә иде, Азнакайдан кузгаласы мизгелдә әллә нишләде; хәмер тәэсиреннән алай ук йомшап

---

*Дәвамы. Башы 10, 11нче саннарда.*

та төшмәгән кебек иде югыйсә, бүтәннәр кебек үк, якыннары белән кочаклашып хушлашты да... Бөгелмә вокзалына алып китәсе автобуска утырышып беткән генә идек, Ислам, урыныннан җәһәт купты да, ыргылып килеп, ачык ишек яңагына тотынып басты, әле бер, әле икенче аягын ачу белән селтәп, тибепме тибә бу озатучы халыкка. Көчкә тыеп, урынына утырттык малайны.

– Сиңа бәйләнүче юк бит, нигә тибенәсең?! – дигәч, «Алар – кала, мине алып китәләр бит!» – дип, инәлеп, җыларга тотынды.

Шул гаебен оныта алмыйча, ул поездда барганда да, үз эченә йомылып, Казанга җиткәнче гасаби халәттән чыга алмады. Менә хәзер, хәлиткеч медкомиссия үткәндә, киеме белән бергә борчуларын да салып ташлады бугай, бераз ачылып сөйләшә башлады:

– Әнә теге тинтәкне күр әле, – дип иңемә төртте. Мин түр почмакта басып торган егеткә карагач, имәнеп киттем: маймыл кебек йонлач гәүдә, тар җилкә, гадәттән тыш киң бәдән, алагаем зур башы иңенә чумып тора, сөзәк маңгае йөнтәс каш турына җитәрәк эчтән күпереп, шешеп чыккан шикелле. Шул «түбә» астында бер-берсенә елышып поскан кечкенә-төссез күзләре бер ноктага төбәлеп тасрайган. Ирен читендә сәер елмаю оеп калган.

– Чыраеи үтмәс балта белән ясаганнар моның, – диде Ислам. – Бу тинтәккә дә мылтык тоттырырлар микәнни?!

– Үзеннән көлгәнне сизә күрмәсен. Йодрыгы бер потлы гер чаклы, – дидем мин.

– Йодрыгы гына түгел... – диде Ислам.

Бераздан ул, икенче өстәл янына килеп чиратка баскач, ярым пышылдап болай диде:

– Унҗиденче елгы революциядән соң Казанда татар полклары оеша. Татар булгач, командалар да татарча булырга тиеш бит инде. Тәрҗемәсен эшлиләр. Менә син «Смирно!» командасын ничек әйтер идең? Белмисең. «Смирно!» – «Үрә кат!» була. «Вольно!» дигәне – «Шәлперәй!» Кызык бит, ә! Моны сиңа нигә дип сөйлим, теге тинтәккә кара әле, «ташкенты» беренче командага буйсынган түгелме!

Шәһәр кабагы сыман гәүдәсе өстән аска иләмсез киңәеп төшкән баягы егет берни булмагандай елмаеп тора, янәшәсендә битенә ут капкан табибә кыз – чарасыз... Шул мәлдә икенче өстәл артыннан торып, ябык-курач гәүдәле, гадәттән тыш ак йөзле, усаллыгын юка иреннәренә кыскан өлкәнрәк яшьтәге табибә ханым килде дә, кулындагы линейкасын бөгеп китереп, шундый итеп чартлатып чирттерде ки, теге егетнең «кызыл фәсле малае» «Шәлперәй!» командасына буйсынып, бөгелеп кенә төште. Бу мәлнең шаһиты булган никрутларның дәррәү көләргә бөтен хуты бар иде югыйсә, әмма шыр ялангач килеш көлү дә килешеп бетми икән шул...

Без – Азнакайдан ракетчиклар командасына дип тәгаенләнгән унбер егет идек. Иңгә-иң килеп, дус булып йөрмәсәк тә, бер-беребезне ерактан булса да күргәләгән бар иде. Төрле мәктәпләрдә укып, унбер классны тәмамлап чыккан берсеннән-берсе чибәр егетләр. Барысы да бүгенгедәй күз алдында...

Хәзер инде безне уртак максат берләштерә. Ук белән җәядән башлап, меңмең еллар буена камилләшә барган сугыш кораллары арасыннан моңарчы күрелмәгән иң куәтле, иң заманча саналган дәһшәтле ракеталарны иярләргә дип җибәрәләр бит безне. Күңелдә – чынбарлыкның асылына төшенеп тә җитмәгән горурлык баш калкыта. Иткәч инде шундый гаскәрдә хезмәт ит – күпне күрдек дип йөргән авыл агайлары без сөйләгәнне тел шартлатып тыңларлык булсын.

Нинди төрләре генә юк бит солдат хезмәтенең. Пехота әнә гомер-гомергә

җирдә казына.Ташбака кебек үрмәләгән танк йөртү дә әллә ни кызыктырмый. Ә безнеке – ракета! Җир тарту көчен җиңеп, галәм киңлекләренә дә ыргыла ала торган, кеше акылы тудырган хикмәтле тимер кош! Тайпылыгыз безнең яннан чернота – кара погонлылар! Безнең иңдәге погоннарга аяз күк төсе кунаклаячак...

Әмма минем эчке горурлыгымны үсендереп торган беркатлы хыялларым озакламый челпәрәмә килде: күз табибында шактый озак тоткарландым. Олылар әйтмешли, күзләрем пичәт кебек, шәп күрә, дип йөри идем, аерым-аерым караганда алай түгел икән бит. Уң күзем эреле-ваклы бөтен хәрефләрне дә наят күрә, ә сулы... юл-юл хәрефләр вагая-метекләнә барган саен, күз карасын үчекләгәндәй, тоташ бер җепкә тезелеп, хәреф булудан туктый. Шулай итеп, үткенлеге ягыннан ике күзем ике төрле булып чыкты (медицина теле белән әйткәндә: уңы – 1, сулы – 0,5). Төрле калынлыктагы линзалар да куеп карыйлар, юк кына бит, сул күзем киреләнә инде, вак хәрефләр белән вакланмый. Бернинди күзлек тә ярамаячак икән миңа. Табиблар аптыраштa. Бәләкәй чакта бер-бер нәрсә төртелмәдеме, күзең авыртмадымы, дип сорыйлар, мин берни дә әйтә алмыйм. Капылт кына хәтергә төшереп тә булмый...

Шулай итеп, мондый күз белән авиациядә генә хезмәт итә аласың, дигән нәтиҗә чыгарып куйдылар. Аргамак биленнән селтәп төшереп, ишәккә атландырып куйган кебегрәк кимсетү булды бу. Азнакайдан ракетчик буласыз дип озатканнар иде бит югыйсә. Казан иләге нечкәрәк булып чыкты. Төшеп калдым менә, оят бит, бергә килгән якташларым күзенә ничек күренергә? Без – ракетчиклар, дип масаеп йөрдек тә...

Кәефсезлек, ямансу халәт тымызык болытлы ноябрь күгеннән берьюлы убылып төште. Биек йортлар, таш диварлар каймалаган ишегалды мәйданында (Татвоенкоматның төп туплану пункты) төрле тарафтан җыелган егет-җилән – чуар халык кайный. Хәрби кысаларга керер алдыннан бер кыргыйланып аласы килгән яшьләр көтүе. Күбесе – иске, таушалган, алама киемнән. Бигрәк тә авылныкылар. Әнә берәү такыр итеп кырылган башына чалма итеп тастымал ураган, берсе – башына сыңар колакчыны өзелгән бүрек калдыгын чәпәгән. Күзеңне аска «исәң», никрут модасының чуарлыгына исең китәрлек: авызын ачып, кадак тешләрен ыржайткан ямьшек ботинкалар, кыршылып, төсен җуйган тирән кунычлы галошлар, Хаттабыч картның чүәге сыман, баш-башлары өскә чөелгән иске, калҗайган күн итек, кат-кат бөкләп, кунычы кыска калдырылган олтанлы киез итекләр дисеңме (ун еллар элек кенә моданы чабата тоткандыр) – бар да буталган монда, авылныкылар да, шәһәрнекеләр дә... Арада ыспайлар да күренә: муенга Остап Бендерча уралган озын шарф, «канадка» итеп алдырылган чәч учмасы маңгайны сыйпап-сыйпап алсын өчен башны һәм гәүдәне селкенчәк көй ритмына тирбәтеп тору, ирен читенә кыстырылган тәмәкене «онытып» сөйләшү, яканың арткы өлешен күтәртеп, ике кулның да очын кесәгә тыгып, башны иңгә чумырыбрак тору рәвеше – бу инде алтмышынчы елларның «стиляга» дигән кызыктыргыч шаукымын җуясы килмәгән яшьләр. Күбесенең бүген-иртәгә такыр каласы башын чәчле чагында дөньяга күрсәтеп каласы килә.

Әнә бер өер, үзенә бер өермә булып, «Братья, славяне!» дип, шом салып, бугаз ертып килә. Хәмер тәэсиреннән калайланган күзләрен кан баскан. Фуфайкаларының арка өлешен мамыгынача кисеп, ак тәре сурәте ясаганнар. Боларның атлау рәвешендә – кайда тереклек бар, без шунда хуҗа булырга тиеш, дигән чамасыз мин-минлек чагыла.

Ничә еллар шулай солдатка алынганнарны барлап тора микән бу мәйдан?

Бәләкәй чактан ук хәтерлим, үзебезнең очта яше җиткән егетнең солдатка китүе онытылмас бәйрәм була иде. Шатлык та, күз яше дә бергә. Кул арасына керә башлагач кына, дип ата-ана бер яктан нәүмизләнсә, икенче яктан, улым чыныгып, дөнья күреп, кеше булып кайтыр дигән горурлык та кичергәндер.

Никрут егет үзе дә канәгать. Чөнки ул «кәҗә билеты» тотып калмаган. Хәрби хезмәткә яраклы, сау-сәламәт, нәселенә кызыллык китермәгән. Ул – үз тирәсендә чыркылдашкан кыз-кыркынга еракка очасы бөркет вәкарьлеге белән карап куя. Ул – никрут. Карашында, торышында – күз күрмәгән дөньялар иләслеге...

*(И бу – татарның буыннан-буынга күчә килгән карусыз беркатлылыгы. Бик борынгы заманнардан калган, үз иле, дәүләте бар чагында яу-дауларда чыныккан яугирлек, уклы, утлы корал тотуга хирыслык, сугышчан рухның канда типкән үкенечле кайтавазыдыр бу... Ничә гасырлар буена империя алып барган сугышларда, алгы рәтләрдә булып, утка кергән, кырылган, гарипләнгән, чит тарафларда гаип булган. Билгән җирләр дә, таланган байлыклар да үзенә тәтемәгән. Сугыш тынгач, исемен дә оныттырып, кылган батырлыгын да, данын да тартып алып, империя тотучы милләткә ягып куйганнар.)*

Безнең очта Фәрит абый бар иде. Тән-мускулларын тимер кебек чыныктырган. Кыш чилләсендә дә юка гына киенә. Апрель кояшы карый башлауга ук, ул майкачан яисә билдән чишенеп йөри башлый. Каралып бетә. Калын иренле, шакмаклы йөзле – тач негрга әйләнә дә куя. Шуңа күрә аны Кара Фәрит дип йөртәләр дә. Бу кушаматка тагын да көч өстәр өчен, рус телендәге сүзне тартып китереп, «Чёрный» дип тә җибәрәләр. (Бәләкәй чагымда ул бик ямьсез булып күренә иде миңа, хәзер инде аңлыйм: хатын-кызларны тәкатьсез калдыра торган ирләрчә кырыс чибәрлек булган икән аңарда.) Менә шул Кара Фәритнең солдатка алынуы турында үзе сөйләгән кыйсса хәтеремдә калган:

«...Мал ташый торган калтырча вагонда, бер поездан икенчесенә күчә-күчә айдан артык бардык. Иксез-чиксез далалар үтеп, чүлләр кичеп. Сусызлыктан кибенеп, җүнле ризык күрмичә... Каралып бетеп... Менә минем хәзерге каралыкка тагын да куерак корым яксаң, күз алдыңа килер... Шулай талкынып бара торгач, чабатам да, болай да сизерәп беткән өс-башым да бөтенләй тетелеп бетте. Сугыштан соңгы фәкыйрь еллар бит ул. Ниһаять, ил чигенең Көньяктагы иң ерак ноктасына – Кушка шәһәренә барып иләктем. Хәрби гарнизонга китереп, плацка тезделәр безне. Азиатлардан да карарак булып чыктым мин. Арада – бер! Ярымшәрә хәлдә, киемне хәтерләткән алам-салам почкаклары белән җан җирне каплаштырган булып басып торам инде... Саф алдыннан берәм-берәм һәр никрут каршында тукталып, төрле сораулар биреп килгән командир, минем турыга җиткәч, артка чигенеп, шаккатып бер мәл карап торды. Минем кыяфәт... Ныграк төчкерсәң дә таралып төшәсе кием аламасы бер хәл әле, ялантәпигә киндер җеп белән бәйләштереп куйган такта кисәкләреннән әтмәлләгән штиблетны күрсәң син!.. Командир, хәйраннар калып, башын чайкап куйды да:

– Что за чучело, откуда?! – диде.

Мин, киноларда күргәнчә, такта үкчәмне такта үкчәгә шап итеп бәреп куйдым да, күкрәкне киереп:

– Из солнечной Татарии! – дип ярып салдым.

– Шуннан соң: «Ике адым алга!» – дигән команда яңгырады. Мин саф алдына чыгып баскач, командир иңемә кулын салды да:

– Вот из этого чучело надо сделать советского солдата. И мы это сделаем! – диде...»

Беренче көнне мин шыксыз казармада, өч яруслы нарларның иң түбән катында, күпме кешеләрнең аркасын каезлаган агач сәкедә, спорт сумкасын баш астына салып, бәхетсезлек катында аунап чыктым. Күзгә йокы эленә алмады шикелле. Казарма эче анасын җуйган корт күче кебек болгавыр гөжелдәүдән тетрәп тора. Кортлар өммәтеннән аермалы буларак, бу гөжелдәү – бугаз ертып акырышу, катлы-катлы сүгенү, дөпе-дөпе чәкәләшеп алу, әче итеп сызгыру һәм тагын шуның ише кыргый авазлар куелыгы белән баетылган иде. Инде керфекләр авыраеп йомылам дигәндә, нарларны дер селкетеп, өске каттан гөрс-гөрс итеп сикерә, йөгерешә башладылар. Әткә-әнкә куенында иркә ялгызлыкта яшәгән малай өчен чирканыч тетрәнү иде бу...

Йокысызлык белән генә кәефкә көя төшерә алмыйсың – яшьлек үзенекен итә. Иртән мин көтелмәгән яңалыкларга әзер булып дөньяга чыктым. Ә дөньям шундый тар, таш диварлар белән кысылган, түбәсе – кургашын болытлар белән ябылган. Мин бар да, мин юк та...

Үз уйларымны таптап, кешеләр төркеменә ияреп барам. Тамагым ачмаса да, ашханәгә керәм, озын өстәл тирәли тезелешеп утырабыз. Калай савытта тары боткасы, чиле-пешле кара ипи кисәге, калай кружкада әчкелтем алма компоты. Ашаттык боларны, дип каяндыр, кемдер мыскыллап көләдер сыман...

Нишләп соң әле мин йомычка хәлендә агымга ияреп барам? Болай барса, күндәмлеккә күнегәчәксең бит... Кая синең һәммә нәрсәне үзеңчә эшләргә адарынган үҗәт кирелегең? Киттем! Бу калын таш диварларны киереп ирекка чыгарга кирәк. Мине ят, кызыктыргыч, бераз шомлы да Казан шавы үзенә кыстый..

Ике якка ачылмалы киң тимер капка янәшәсендә флигель. Тар коридор. Әйләнмәле тимер киртә. Үткер күзле сакчы солдатлар минем документны да сорап тормыйча, аркадан этеп диярлек чыгарып җибәрделәр. Әнигә рәхмәт инде. «Кеше алдында матур киенеп йөр, улым», дип гел искәртә торган иде. Мәктәптән соңгы бер ел эчендә алган әйбәт киемнәремне киеп китәремә дә сүз әйтмәде. Менә бит, ярдәме тиде бүген. Шундый никрут була димени – өстемдә куе яшел төстәге драп пәлтә (сәкедә, Тукай әйтмешли, буш шешә кебек аунап чыксам да таушалмаган), куе чәч учмасы бөдрәләнеп, бүрек астыннан ташып чыккан. Муенда куе кызылга ак сызыклар төшкән шарф. Чалбар балагының эчтән сабын сылап үтүкләнгән кылыч йөзе дә «үтмәсләнмәгән». Аякта да өр-яңа кышкы ботинкалар. Хәрбиләр коллыгыннан күз буяп котылырга шул рәвеш җитмәгәнмени!

Киттем Казан урамнары буйлап. Берни аңышмаган сарык бәрәне сыман чумдым башкала шавына. Еракнан ук күреп киләм: гаҗәеп биек бер манара якынайган саен отыры калка, чакырып кул изи, ниндидер сихере белән мине үзенә суыра шикелле. Әйләнә-тирәдәге биналарга күз дә салмыйм, алар бөтенләй кирәксез булып чүгеп калды. Бауман урамы икән бу. Тротуардан агылучы кешеләр елгасын ерып ашыгам. Көмеш гөмбәзле мәһабәт манара каршымда бөтен буена калыккач, бер мәлгә сулышыма төелеп торам. Искиткеч! Мондый да биек, мондый да камил чигелешләр белән үрелгән манара күрермен дип башыма китерми идем. Гөмбәзләре очына хаҗ куелган булса да, мин аны дингә кагылышлы корылма дип уйламадым бугай (дөресен әйткәндә, минем «тере» чиркәү яисә «тере» мәчет биналарын якыннан бер дә күргәнем юк бит әле.)

Сокланудан сакланып булмый.

Муеным башымны тотып тора алмаслык хәлгә килгәнче йотылып өстән

аска, астан өскә карыйм да карыйм. Бу хикмәтле манара сурәте тәүге тапкыр кем зиһенендә ялралды икән, җеге-җеккә тезелгән кызыл кирпечләргә нинди оста куллары кагылды икән, күзне рәхәт сискәндерә торган бизәкләрен нинди әфсен өреп сырладылар икән, дип, гаҗиз булып, манара төбенең әле уң ягына, әле сул ягына чыгам, ераккарак китеп тә карыйм, тагын әйләнеп киләм. Шунысы гаҗәп: янымнан үтеп-сүтеп йөрүчеләргә игътибар итәм – ник берсе күтәрелеп карасын, болар өчен әллә манара бар, әллә юк... *(Еллар үткәч белдем: Богоявление чиркәве өчен ике миллион кирпечтән төзелгән бу колокольняны бизәүдә шул дәвергә хас орнаментлар, татар бизәкләре дә, яһүдләрнең алты почмаклы Давид йолдызы да кулланылган икән. Ничекләр күтәреп тора, дип хәйран калырга мөмкин: өске яруска күтәртеп асылган кыңгыравының авырлыгы гына да 9 тоннага җитсен әле.)*

Казанга кил дә Сөембикә манарасын күрмә, имеш. Бу бит Парижга барып та Эйфельне күрми кайту тинтәклегенә бәрабәр. Кешеләрдән сораша-сораша, Кремльгә барып чыктым. Рәсемнәрдә күреп белгән ак кирмән диварларына якын килгәч, бу тарихи олылык каршында бер мәлгә каушап калдым. Эчкә үтәргә ярыймы дигән икеләнү белән, милиционерларга сагаеп кына карап киләм. Әллә мин бар боларга, әллә юк. Маңгаена түгәрәк сәгать ябыштырылган Спасс манарасының бөкре капкасыннан, кыю булырга тырышып, эре-эре атлап, эчкә тәвәккәлләдем. Шәһәр шавы, миңа ияреп керә алмыйча, калын диварлар артында сөзелеп калды. Монда һава үзгә, рәхәт җиләслек. Берән-сәрән үткән машиналар да, җәяүлеләр дә затлы күренә. Монда – аңлатып булмый торган ниндидер бер тибрәнеш бар. Мин аны тоям, сизәм, бу халәт – минем акыл сүрүен киерә, тәнемә җиңелчә курку дулкыны йөгертә.

Әнә ул – Сөембикә манарасы!

Текә тауга якынайганда гына була торган дулкынлану кичереп, мин аңа тартылам. Якыннан караганда артык гади түгелме. Күпме җилләр, күпме гасырлар төсен уңдырган кызгылт кирпечтән төзелгән. Күз карашын чуалтырлык катмарлы бизәкләргә дә бай түгел кебек. Әмма бу – үзгә манара – ул авыр булып җир күкрәгенә басып тормый, ул гүя күк гөмбәзен тишеп чыгып очарга җыенган сәмави кодрәт чагылышы.

Әсәренеп, күпмедер күзәтеп торганнан соң гына искәреп алам: ерак та түгел бер төркем тупланган (туристлар ахрысы), якынрак килеп, аларны җитәкләп йөри торган чандыр гәүдәле кызның сөйләвенә колак салам. Русча бик кызу сөйләсә дә, чама тартып, аңларга була икән.

Сөембикә-ханбикәнең манарадан ташлануы хакындагы кыйссаны тын да алмыйча тыңлыйлар. Кызның «легенда» дигән сүзе генә аңлашылып бетмәде, унбер ел укып, бу сүзне бер дә ишетмәгәнмен, яисә ул сүз колак яныннан миңа кагылмыйча үтеп киткән...

Кызның теле-телгә йокмый:

– Һәммәгез дә әйтеп карагыз әле: нинди матур исем кушылган: Сө-ем-би-кә!.. Килешәсезме, сезгә дә ошады, шулай бит?! – Аннары ул: җитдиләнеп: – Бу манара – Шәрык архитектурасы үрнәгендә төзелгән, – диде. – Әнә ничек: һәр буыны өскә таба нәзегәя бара, җиде ярусны манара – ислам белеме өйрәткәнчә, күкнең җиде катлы булуына ишарә – символны белдерә...

Мин аңламаган «символ» дигән сүз дә, каты чикләвек булып, теш арасына керде. Кәефем төшеп, читкәрәк тартылыйм дигәндә, теге кызый манараның кояш чыгышы ягына авыша баруы турында сөйли башлады. Шунысы гаҗәп: авыш икәнен башта ук үзем дә искәргән идем бит югыйсә, болай булырга

тиеш түгел, болытлы көн булганга күземә генә күренәдер дип, чынлап та авышлыгына ышанасым килмәгәндер, бәлки.

Нигезеннән кубып, кинәт убыла башласа... Нигә турайтмыйлар икән аны? Бу сорауны кемгә бирим? Якында гына ике ир кеше татарча гәпләшеп тора. Берсе – кыршылган күнле саргылт портфель тоткан, икенчесе – култыгына күн папка кыстырган. Болар янына килеп тәвәккәлләдем. «Нигә турайтмыйлар бу манараны?» дип соравым дорфарак чыкты ахрысы. Тегеләр сүзсез калып, бер мәл миңа сынаулы карашып тордылар да башына юка кепка чәпәгән кара мыеклысы, серле елмаеп, манарага ишарәләде:

– Аның авыш булуы кирәк безгә, – диде. Һәр сүзне кәнфит кебек тәмләп суырып әйтүен өнәмичә, бу нинди дошман, дигән шикелле, маңгай астыннан сөзеп карап торуымны үзенчә бәяләп, аңлатып бирүне кирәк тапты ахрысы:

– Төз манаралар дөнья тулы, авышы – сирәк. Ә сирәк нәрсә кадерлерәк була, – диде. Минем шома баш миенә шул мәлдә нәни генә бер сыр өстәлде бугай. Белекле булып, икенче патронны чыгардым:

– Сөембикә әнә шул... иң биектәге тәрәзәдән ташланганмы?

Түгәрәк ырмаулы күзлек кигән икенче ир нидер әйтергә җыенган иде, кара мыеклы аны туктатты:

– Тимә, шулай уйласын, – диде. – Нишлисең бит... Тарих капкасы каршында без күзе ачылмаган песи баласы хәленә калдык...

Шул мәлдә бөтен тәнем кычытып куйгандай булды. Тизрәк моннан китәргә ашыктым. Үз-үземне сүгеп кайтып барам. Нинди сорау бирәм бит, мокыт, ә! Сөембикәнең кайсы тәрәзәдән ташлануы мөһиммени?!

Шуны белдең ди, җә! Син сүз катардай кешеләрме болар? Акыл иясе икәнлекләре йөзенә чыккан бит. Ә син кем? Өч елга бу тормыштан ыргытылган бәндә, сорау бирергә дә, уйланырга да, үз теләгең белән берни эшләргә дә хокукың юк – менә кем син! Кирза итек табаны астында каласы миңгерәү бөҗәк..

Үз-үземне шулай битәрләп кайтышлый, Сөембикәне көнләштермим дипме, Бауман урамында бая гына күреп тукталган манарага күз дә күтәрми үтеп киткәнмен...

Кичке эңгер төшкәч кенә кайтып җиттем. Хәрби билетны күрсәтеп, капкадан бер тоткарлыксыз үтеп кердем дә мәйданда кайнашкан халык арасыннан якташларымны эзләп таптым. Алар мине күргәч, бер командага буйсынгандай, башларыннан бүрекләрен йолкып алдылар. Кинәт дөнья яктырып китте. Йә Хода! Каршымда – ничә шар, ялап алынган ничә такыр баш. Чәч – кеше кыяфәтенең таҗы икән бит. Кара инде Исламны, маңгаена чәч учмасы төшеп тормагач, гүпчим дә мәзәк кыяфәткә кергән. Аның бүтән камырдан әвәләнгән ят-яңа кыяфәтенә ияләнергә дә вакыт калмаган шул инде. Иртәгә иртәнге сәгать тугызда ракетчиклар командасы – әллүр! Озатачаклар икән. Ул арада нининдидер күрсәтмә бирергәме – егетләрне тагын җыеп алдылар. Күкрәк турында кайнар бер нокта тибенеп куйды. Алар китә, мин калам...

Тынчу казармага кермәс өчен сәбәп эзләп, киләп-сарып йөри идем, багана башындагы репродуктордан, музыканы бүлеп, минем исем-фамилияне яңгыраттылар: «Комендатура янына килергә, туганнарың көтә...»

Кем чакырта икән мине дип барсам... Казанда яшәүче туганыбыз – Сәгыйрь абзый кызы Флёра, авылдагы күрше туганыбыз Рәшидәттәй кызы Кадәрия (ул медицина институтында укый иде) һәм тагын бик чибәр кыз («Альба Регия» дигән венгр фильмында уйнаган артисткага охшаган) басып торалар. Мин олы шәһәргә барып кергәч, төшеп югалмыйм тагын дип, алдан ук хат юллаган

идем. Менә бит, барып җитәрме дип, икеләнеп кенә юллаган кыюсыз авазым барып ирешкән, рәхмәт төшкере!

Мине кызлар медицина институтының тулай торагына алып кайтып чәй белән сыйладылар. Теге чибәр кызыбыз Хәния – мин ишетеп кенә белгән якташыбыз, актриса Нәҗибә Ихсанованың бертуган сеңлесе булып чыкты.

Студентлар кыюсызны да кыю итеп үсендерә белгән эчкерсез халык икән. Кызыгып карыйм үзләренә. Мин дә шулай студент булачакмын, дигән тәмле уемны артка чигереп, алда – томаннар аръягында өч елың бар әле, үзе бер гомер дигән уй тәмсезләп куя.

Кадәрия – авылда чакта ук үткен телле, суктырып сөйләшә белгән эчкерсез, зәңгәр күзле, хикмәтле кыз иде. Монда да ул – үзәктә икән. Күрше бүлмәләрдән дә кереп гел кузгатып торалар үзен. Аның сүзе – сүз.

– Баян абзый малае башың белән казармада кунып ятмассың бит инде. Монда, шушы кадәр кызлар арасына салу да куркыныч, – дигән булды ул, минем юк дәрәҗәне күтәреп. Шулай итеп, мине яшьтәш туганым Флёра белән култыклаштырып, Сәгыйрь абзыйларга озатып куйдылар. Анда мин казарманың тәнемә йогып калган сөрсегән өнен ваннада юып төшергәннән соң, ак җәймәле диванда, аккош мамыгыннан сырылган җиңел юрган астында җәннәт төне кичердем. Моннан соң, авыл агайлары әйтмешли, күкрәккә агач мылтык терәсәләр дә, казарма тәмугында кунып каласым юк.

Иртән чак соңга калмадым. Хәрби комиссариатның ике якка киереп ачып куелган капкасыннан килеп керсәм... трибунада офицерлар, мегафоннан яңгыраган тавышлар биек диварлар арасында өзек-өзек бәргәләнеп ишетелә. Ракетчикларны сафка тезгәннәр, ике йөзләп бардыр. Чуар киемле тарау халыкны сафка тезсәң дә, барыбер, чын солдат кавеме кебек кыл тәртипкә китереп булмыйдыр шул... Мин читтән-читтән генә үзебезнекеләрне эзләп барам. Тәкъдир җиле таратамы безне... Кайсылары белән бүтән беркайчан да күрешә алмаячагымны уема да китермим әле. Әнә алар – язмыш берничә көнгә генә янәшә китергән ун якташым. Аларга якынаю мөмкин түгел иде. Кул ишарәләре белән генә хушлашабыз. Ул арада оркестр дәртле көй уйный башлады. Командалар яңгырады. Зур барабанның дөпе-дөпе тавышы күкрәк читлеген аерып кереп, бөтен гәүдәне дер селкетеп тибә шикелле. Ракетчиклар сафы бераяктан атлап кузгалмаса да, шактый эзлекле дулкын булып, мәйданны тантаналы рәвештә бер урап чыкты да капкага таба юнәлде. Купты саубуллашу симфониясе – сызгыру, кычкыру, бүрек чөюләр... Күзгә яшь килде. Карыйм, рәтләрне аерып чыкты да Ислам миңа таба йөгерә. Кулыма нидер тоттырды да киредән үз дулкынына чумды. Киттеләр. Капка ябылды. Учыма сөяк саплы пәкене кысып басып калдым. Мин дә алар сафында китәргә тиеш идем бит. Көзләрен, киек казлар биектән очып узганда, канат очы киселгән йорт казларының, борын эченнән еламсырап, сагышлы карап калулары кебек хәлдә идем мин бу мизгелдә.

Кемгә үпкәләргә? Уйламаганда... көтмәгәндә... юктан гына... Күзне сәбәп иткән булып, кем бүтән якка борды минем язмышымны? «Тимә, яшәсен!» дигән Раббы ихтыярымы? Әнинең ышанып укыган бәгырь догасымы? Улыма юньле җир насыйп итсен, дигән әтинең эчке теләгеме? Кемгә рәхмәтле мин?

Хикмәт шунда: мин кызыгып, көнләшеп озатып калган якташларым Казакъстанның бик хәтәр төбәгенә – җир өстендә дә, җир астында да атом-төш коралын чама белмичә сыный торган, һавасы, суы, туфрагы зәһәр радиация агуына манчылган Семипалатинскига эләккәннәр. (Алар, хезмәтен тутырып, туган якка әйләнеп кайтсалар да, гомерләре кыска булды, бер-бер артлы сызып сүнделәр.)

*(Күзнең «хыянәте» аркасында ракета гаскәрләрендә хезмәт итә алмавыма кимсенеп (и, җүләр!) уйлануларым әкренләп юыла барса да, вакыт-вакыт искә төшеп, «чәнчеп» ала иде. Нигә болай? Кайчан, ни булды? дигән сораулар бимазалый торгач, мин балачакта калган хәтер йомгагының җебен-җепкә сүтә башладым. Күзем бер дә сызламагач, уңы хисабына дөньяның нәзберек төсләрен дә җете аера алгач, мин, тынычланып, фаҗига китереп чыгарырдай шуклык эшләгән көнемне әллә кая, хәтер аръягына ук чигереп куйганмын ахрысы. Хәтеремдә шәйләнә, төсмерләнә башлагач та, әле үз-үземә ышанып бетмәдем шикелле. Хәрби хезмәтнең бер елын үткәреп, ун көнлек ялга кайткач, әнидән бу хакта сорадым. Әни хәтерен җигеп тормады, кичә генә булган хәл кебек:*

*– Әйе, күзең авыртып йөрде шул, – диде. – Сул күзең турын, дару сөрткәннән соң, бинт белән баш аркылы урап җибәрә идем укырга. Лампага да, көн яктысына да карый алмыйча интектең. Икенче сыйныфта укыган чагыңда булды бугай... Күз алмаңа ручка белән кадаганнар иде бит...*

*Әни шаһитлыгында хәтер пәрдәсе ачылганнан-ачыла бара. Хатирәләр савылып искә төште. Мәктәп бинасы авылыбызда иң зур бина саналса да, әллә ни иркен булмагандыр инде. Бер бүлмәдә – беренче, өченче сыйныф, икенче бүлмәдә – икенче, дүртенче сыйныф дәрес сәгатьләрен уртак бүлешеп укый идек. Мәктәпнең ханәкәсе – матур киенгән, купшы бантик таккан Венера һәр көнне бер-бер хикмәт чыгарып, игътибар үзәгендә бер бөтерелеп ала иде... Кибетче Камилә апа кызы. Заемга егерме биш мең откач төзеткән гүрнәчә йортлары да әллә каян балкып тора. Авылда шулай бит ул: йортың нинди – башны тотуың да шундый... Йә, менә шул чибәр кызый, йокылы-иркә тавыш белән сөйләшә торган кыланчык Венера миннән алдагы партада гына утыра. Без – чиктәш, аның турында дүртенче сыйныф бетә, минем парта турыннан икенче сыйныф башлана. Венераның бер гадәте көн дә кабатлана: «икеле» йә «өчле» алдымы – кычкырына башлый, дәфтәрен рәхимсез умыргалап, мич янындагы почмакка ыргыта. Күпләрнең сулышы кысыла, дәфтәрнең, гомумән, кәгазьнең бик тә кадерле чоры бит бу. Ә миңа аның бит очларын алландырып тузынуы да, дәфтәрләреннән үч алуы да ошый, дәреснең кызыклыгы – Венераның шау кузгатуы белән бәяләнә иде.*

*Беркөнне, тыныч кына дәрес барганда, аның тәкәббер чибәрлегенә кагылып карарга теләпме, җөрьәт итеп, чәчен тартырга үрелдем бит!*

*Ул кырт борылды, үзеннән түбән сыйныфтагы чебешнең кул сузуына чирканган кебек чыраен чытты да кулындагы ручкасын селтәп җибәрде. Агач саплы ручканың нәзек очлы каләме күзгә килеп керде, чәнчүле авыртудан мин кычкырып җибәрдем, ручка шапылдап парта өстенә төште, шәмәхә караның әчкелтем исе бөтен тәнемне өтеп алды кебек, яшь тулган күз кабагын учыма кысып, партага капландым.*

*Ул арада укытучыбыз Мөхтәсим абыйның яныма йөгереп килгәнен хәтерлим. Аннары – медпункт. Укол. Әчкелтем дару исләре. Яраланган солдат сыман, сыңар күз турын маңгай буйлата ак бинт белән уралган хәлдә күргәч, әниниләр кичерде икән?..*

*Күпмедер вакыт узгач, бинтсыз гына йөри башладым. Класска кергәч, Мөхтәсим абый өстәл янына мине чакырып ала, ике битемнән тотып башымны яктыга бора-бора күзнең «кешесен» карый, «төзәлә инде, ярасы бетеп бара...» дип мине юата иде.*

*Шул хәлдән соң Венера дәфтәр ерту гадәтен ташлады. Икенче уку елында бишенче сыйныфка Азнакайга, рус мәктәбенә китеп барды. Нишләптер, аның белән бүтән беркайчан да очрашырга туры килмәде.*

*Малайчак шуклыгыннан килеп чыккан менә нинди очраклылык. Ә шуның алдагы язмышыңа тәэсир итәрлек көче һич көтмәгәндә калкып чыга икән. Ягъни, кече бәла – башыңа төшәсе олы бәладән йолып кала...)*

Хәрби комиссариатның капкасына һич тә тынгы юк, әле киерелеп ачыла, әле ябыла тора; солдат булып калыпланырга дип, илнең кайсыдыр тарафына тәгаенләп бер өер чыгып китүгә, икенче өер ургылып килеп керә.

Безнең авиаторлар командасы әле һаман тупланып бетә алмый. Бүген-иртәгә генә кузгалу булмаячагын белешкәч, мин, тынычланып, тагын шәһәргә чыгып китәргә булдым. Капка ягына таба кузгалуым булды, арттан исемемне әйтеп кычкырдылар. Тавышы авылдашым Ирекнекенә охшаган, кем кычкыра икән дип борылсам, ул чынлап та Ирек булып чыкты. Җиденче сыйныфтан «төшеп» калганнан соң, ул Бөгелмәдә ниндидер һөнәр мәктәбендә укый, сирәк күрешә идек. Мондый чит, соры кавем арасында авылдашыңны күрү туганыңны күрүгә тиң икән.

Менә бит ничек: югары оч егете белән түбән оч егете гомер буе якын дус булган кебек кул кысышты. Аны чик саклау гаскәренә билгеләгәннәр икән. Бүген медкомиссия үтүгә, иртәгә алып китәселәр ди. Рэкс та комиссия үткән, аны, төрлечә сынап карап, бик ошатканнар. Рэксның кем икәнен белмичә, аптыраулы карап торуымны сизенеп, ул аңлатуны кирәк тапты. Бөгелмәдә үз йорты белән яшәгән фатир хуҗасы Ирекка көчек бүләк иткән булган. Шуны ул төрле командаларны үтәргә өйрәтеп, гаярь итеп үстергән. Үз эте белән хәрби хезмәткә алынучылар без – бишәү, ди. Рэкс белән икебезгә бергә ике генә ел хезмәт итәргә, дигәндәге горурлыгын күрсәң, күз карашы рәхәт томанланып китте, ирен читләрендә энә күзе чаклы гына күбек елтырап куйды. Мин исә армия камытын аңа караганда тагын бер ел артык киясемне аңлап, көнләшүемне кесәдәге йодрыкка йомарладым.

Ирек үзе көнчел-эремле карашын беркайчан да яшерә алмый иде. Менә хәзер... калын, юеш иреннәннән шуып төшкән сүзе аңымны томалады: «Яратам, яратам, дип йөргән булдың... Син киткәнне генә көткән Фәниян! Икенче көнне үк... озата башлады үзен...» дип ул, җиденче класстан тибелеп чыгып, каядыр укыган сыман йөргән бер егетнең исемен атады. Бу мокытның исемен ишетү гарьлегеннән күз алларым караңгыланып китте. Акылыма ялкын капты. Мин үз-үземне белештермичә капкага таба ыргылдым. Дөньям кысылып килде. Яшәүнең бер мәгънәсе калмады. Иреннәрне канатырлык итеп тешләп пышылдыйм: нишләдең син, нишләдең?! Үз күзләрем белән күреп, тиз арада бу хәлне ачыклый алмасам, мәңге үкенечтә каласы хата ясалыр кебек. Нинди ачыклау, ди. Хыянәтне аклау юк. Икесен дә буып ташларга! Кайтырга, кайтырга, кичекмәстән кайтып төшәргә кирәк!

Биек йортлар. Шаулы урам. Мин беркемне белмим, күрмим. Дөньям сүнде... Кешеләр ташкынын ерып барам. Болар бар да – өнсез төш, ялган мираж, сурәтле төтен. Күз алдымда бары – Ул! Ул! Ул гына! Нишләдең син, нишләдең?! Әле кайчан гына Бөгелмә перронында эре-эре күз яшьләре белән озатып калган ЯР, синме ул? Төнге пышылдауларың – диңгез кабырчыгында сакланып калган дулкын пышылдавы кебек, мәңге хәтердә каласы иде бит. Харап иттеңме икәү генә белгән төннәр серен... Ай – безнең мәхәббәт калканы иде, көнчелектән өстен сүзсез шаһитыбыз иде. Моннан соң ничек карарсың Ай йөзенә?

Урамнан шулай, үзалдыма сөйләнеп барам икән, кемдер җиңемнән тартып туктаткач, айнып киттем, ак шәл бәйләгән татар әбисе, борчулы күз текәп, җиңемнән сыйпый-сыйпый:

– Төсең киткән, улым, бер-бер хәл булмагандыр бит? – диде. Аның шулай әнкә җылылыгы белән йомшак дәшүеннән күңелем түгелеп китте:

– Миңа бик тиз кайтырга кирәк, әби, Бөгелмәгә кадәр, – дидем. Бу мизгелдә ул миңа хәтта Шайтан канатына утыртып җибәрерлек әфсенгә ия бер коткаручым булып тоелды.

– Тиз кирәк булгач, аэропланга утырырга кирәк, улым. Әйдә, күрсәтәм, әнә теге тукталышта троллейбуска утырасың да, ун тукталыштан – аэропорт.

Ни хикмәт, ак әбинең һәр сүзе мине үз ихтыярына буйсындыра бара. Үз гомеремдә самолётка бер дә утырып карамагач, андый канатлы җәнлек барлыгы бөтенләй башка килмәгән. Өч йөз чакрым араны йөгереп кайтасы идеңмени, авыл гыйбады, үзең авиациядә хезмәт итәчәк никрут булып йөрисең!

Тукталышта, хушлашыр алдыннан, ак әби миңа болай диде:

– Ярсынган кебек күренәсең, улым. Ашыгычлык белән, вөҗданыңны җуеп, гөнаһ кыла күрмә.

– Нәрсә соң ул «вөҗдан», әби?

– Вөҗдан – тумыштан һәркемгә бирелә торган күңел кояшы. Яшәү рәвешенә карап, берәүләрнең ул отыры кечерәя, әнә күзе чаклы гына калып, бөтенләй сүнеп бетә. Берәүләрнең, киресенчә – торган саен олылана, яктыра бара. Аны изге аятьләр белән сугарып торырга кирәк...

Ак әбинең бу сүзләре зиһенемне читләбрәк узса да, мин аны хәтергә салып, хушлашырга ашыктым. Җиде тавышка шыгырдап ишеге ябылгач та, троллейбус бераз вакыт кузгала алмыйча торды. Тәрәзә аша ак әбигә карыйм. Сүз мәгънәсен аңлап та бетермәдем шикелле. Рәхмәт әйтергә дә оныттым бугай. Ул бу соры дөньяга вакытлы гына төшкән сәмави зат кебек нурланып басып тора, иреннәре сизелер-сизелмәс кенә дерелди, эчтән тыенкы гына дога укыйдыр, мөгаен.

Барам троллейбуста, үз эчемә йомылып. Бөтен ярсуым ярга бәрелгән дулкын кебек челпәрәмә килде. Очын очка ялгый алмыйча, чарасыз калып, күңелне баскан хәрабәләр арасыннан бары бер уйны күтәреп алам: тиз арада кайтып җитә алмасам, гомергә үкенечкә каласы фаҗига булыр кебек.

Үшән троллейбусның алдына чыгып йөгерәсе килә. Бар да гамьсез. Ничек барып җиткәнбездер инде, ниһаять, мин маңгаена эре хәрефләр белән «аэропорт» дип язылган бинаның колонналары арасыннан эчкә ыргылам. Репродуктордан «Бөгелмә...» дигән сүз колакка чалына. Мин аңышмыйча кассалар рәтенә юл сабам. Зәңгәр пәлтә, кокардалы зәңгәр пилотка кигән ханым гүя мине генә көткән, касса кырыенда «Бөгелмәгә түгелме?» дип каршы ала, «Бәхетең бар икән, соңгы урын... Тиз бул, документ, акчаларың!..» дип ул, бумажнигымны кулымнан тартып алып диярлек, кассир кызга суза. Ул арада тагын репродуктордан «Казан – Бөгелмә рейсына... Ике урын бар» дигән белдерү яңгырый. Менә булды да. Янәшәдә әзер билетын учына кыскан агайның да, минем дә кулдан эләктереп алып, кокардалы ханым безне җилтерәтеп алып чыгып китә. Очу кырына чыгасы тимер капка шаңлап ачыла. Йөгерәбез. Самолёт корсагындагы ишек бусагасыннан атлауга, аяк астыннан диярлек трапны тартып алалар. Эчкә узып урынга җайлашуга, моторы кабынды ахрысы, самолётның бөтен гәүдәсенә вак кына калтырау тарала башлады. Беренче тапкыр җирдән аерылу кебек хәтәр мизгелне дә кичерә алмадым.

Тагын ишелеп киләсе ярсу хис өермәсеннән тетрәнмәсен дипме, гүя тәнемнән җанны аердылар. Изрәп, йокы чоңгылына убылганымны сизми дә калдым...

Юк, бу гадәти йокы ваемсызлыгы түгел иде шул. Аңым сүнеп өлгергәнче үк, мине бүтән яссылыкка күчерелгән хәлләр, бер-берсенә бәйләнмәгән, берсен-берсе бүлеп агылган саташулы төш манзаралары күмеп китте.

...Янәшәмнән генә кара елан шуышып бара. Юк, шуышмый, нәкъ минем күз турыннан йөзеп бара. Шәмәхә төстәге күзе асылташ сыман җем-җем килә. Шом салып, үтәли чәнчеп карый. Минем аңыма агулы уклар җибәрә, имеш. Мин чарасыз калам. Күпмедер вакыт бер-беребезгә карашып торабыз. Аннары ул... бер мизгелгә күзен йома. Шул мәлдә мин, кинәт ыргылып, койрыгыннан эләктереп алам. Ул зәһәр ысылдый, бәргәләнә, ыңгырашкан сыман аваз чыгара, имеш. Бераздан карасам, елан үзе юк, кулымда кабыгы гына торып калган. Мин сөенәм икән. Минем дә, ниһаять, тирә-юньдә иң шәп чыбыркым булачак. Җидедән үрелгән, һәр буыны җиз сугылган чуклы, сабына кара елан кабыгы киертелгән... Әй, күрегез, дип кычкырам: кемдә шундый елан саплы чыбыркы бар?! Мин үзем бөтереләм, чыбыркыны баш очында әйләндерәм, менә хәзер кулымны кыеклатып селтәүгә галәмәт куәтле шартлау яңгыраячак!.. Шул мәлдә кемдер кулымнан тотып ала... Фәния! Ул минем карашымнан куркып тынсыз кала. Минем күзләргә кара елан агуы кереп оялаган, имеш, шул чатнап яна. Мин Фәниягә ераккарак китәргә кушам, озын чыбыркы белән якыннан сыдырып булмый, имеш. Ул бер карусыз тыңлый, сары комга яланаяклары белән бата-бата чигенә, күзләрендә яшь. Үзе һаман бер үк сүзне кабатлый: «Их, син!.. Их, син!.. Их, син!»

Бер мизгелгә уянган сыман булам. Авыртулы кысылган йодрыкларымны язып, иллюминаторга карыйм: якты, ак болыт кәрваннары иксез-чиксез ераклыкка китеп таралган. Моңа карап сокланырга минем дәхелем юк, имеш. Йокы чоңгылы тагын мине үзенә суырып ала.

...Икебез ике ярда басып торабыз. Ак мамык сыман ап-ак карлы текә ярлар. Уртада, бик тирәндә караеп аккан елга. Юк, аяк астында җир түгел, без биектә, яр-яр болытлар өстендә басып торабыз икән. Ә уртада упкынлы елга түгел, бик түбәндә, тымызыкланып Җир йөзе шәйләнә икән. Без шушы ике болыт арасындагы упкынга сикерергә тиешбез. Икебезгә бер парашют. Берочтан сикереп, кулга кул тотышкач, парашют ачылырга тиеш. Мин Фәниягә кул изим, ул – миңа. Сикерәбез! Куллар – кулда. Кочаклашабыз. Күңелләрдә Күк шатлыгы тибә. Күбек-күбек болыт кантарлары арасыннан очабыз. Болытлар сүрүен ерып чыгуга аста, бик тирәндә җир өсте күренде. Менә хәзер, менә хәзер парашют ачылачак. Шунда мине коточкыч уй урап ала: парашютны онытып калдырганмын ич! Ничек моны Фәниягә сиздермәскә? Ә ул сизгән икән бит, пәри зат! Берни булмагандай кинаяле елмая. Көчле җил чәчләрен туздырып битемә сибә. Куллар – кулда. Очабыз. Чәчләрен аралап, күзгә сынап карый:

– Әллә куркасыңмы? – дип шаркылдап көлә. – Их, син... Әле кайчан гына әйткән идең бит: бу безнең иң бәхетле мизгелебез, мәхәббәтнең иң биек ноктасында чакта бергә үлик, кулга-кул тотынышып, бергә үлик! – дигән идең.

– Ул чакта син карыштың бит. Мин моңа әзер түгел, – дидең.

– Бәхеттән үлгәннәр дисеннәр! Менә ул мизгел килде! Тик... Син – син түгел инде... Сизеп торам: куркасың бит, куркасың, үләсең килми!

– Соңга калдык шул... Бу – безнең ихтыярдан тыш, – дип нидер әйтергә тырышып акланырга телим, Фәния кулын кисәк тартып ала. Җил аның гәүдәсен бөтереп алып, әллә кай ераклыкка җилпеде. Аерым-аерым очабыз. Ә

тораташ калган җир котылгысыз тизлек белән якыная. Инде бәреләм дигәндә, гасабилы саташудан уянып, иллюминаторга төбәләм. Самолёт тәгәрмәчләре бетонга бәрелеп алды да гөжелдәп тәгәри башлады. Якында гына Бөгелмә аэропортының утлы язуы шәйләнеп калды. Кеше ышанмаслык әкият бу! Бер секунд элек кенә утырган идем, икенче секундта килеп тә җиткәнбез, бер хәвефсез, саташу шаукымын санамаганда...

Тискәре ният белән кайткангамы, бөтен нәрсә уңай килеп тора. Азнакай автобусы расписаниедән соңга калып булса да безнең самолёт төшкәнне көтеп торган. Тагын ике-өч кеше өстәлгәч, шофёрның күңеле булды. Кузгалдык. Таныш кешеләр була күрмәсен дип, мин, яканы күтәреп, бүрекне батырыбрак кидем. Минем кайтканны беркем күрергә, беркем белергә тиеш түгел. Әти-әнигә ишетелсә... дигән курку хәрби кысалардан хәтәррәк тоела шикелле.

Монда инде кыш үз көченә кереп бара икән. Төн куера. Юаш кына җәяүле буран шәйләнә. Яратам – зур тизлек белән барганда, асфальт өстеннән аркылыга кар төтеннәренең ак елан кебек бөгелә-бөгелә шуышуын. Әмма миндә хозурлану кайгысымыни?! Тагын эчтә ачу-ярсу кайный башлады. Әле – читлек тимерен чәйнәп өзеп, иреккә, үч алырга ташланган бүре мин, әле – яфрак кыштырдаганга да сискәнә торган куян мин.

Автобустан төшеп калгач, авылга кадәрге ике чакрым араны нәрсәдәндер үкенечле соңга калырмын кебек гел йөгереп уза идем. Бүген инде бигрәк тә... Клуб тавыннан төшүгә, тыкрык почмагында Фәнияләр өе. Сүрән генә утлары күренә. Утлары сүрән икән, димәк, Фәния өйдә түгел. Коймага елышып, юка кар өстендә таптанып торам. Җан кайный. Йөрәк тибешем койма такталарына бәрә шикелле. Клуб янында кайнашкан кешеләр күренә. Сәгать җидедә кино башланырга тиеш. Әле өч минут бар. Менә, өч елга киткән егет, бөтен кешедән яшеренеп, өч минутны үткәрә алмыйча торасыңмы? Кайнарланып кайтып төштең дә чарасыз калдыңмы?..

Клуб ишегеннән ялгызы гына чыгып болай таба килә башлаган таныш силуэтны күргәч, мин әле ышанып җитмәдем, күземә генә күренәдер, дип уйладым. Улмы? Ул! Фәния бозлавык карга сак кына басып килә. Әлбәттә, ул һәр адымы белән миңа таба якыная барганын башына да китермидер. Нигә ялгызы гына... дигән уемны, менә хәзер клуб ишегеннән... теге... исеме күңелемнән тыелган егет килеп чыгар да, аны куып җитеп, кочып алыр, дигән көнчел-шөбһәле уй күмеп китә. Тәнне вак кына калтыратып салкын үрмәли. Килә. Якыная. Чаттан борылды. Янәшәдә! Мин яшеренеп торган җиремнән кубарылып, аның шарфыннан бөтереп, кысып алам.

– Нишләп үзең генә! Кая озатучың!

Тавышым карлыгып, ысылдап чыга. Фәния күзләрен зур ачып катып калды. Кулымны бушатуга, карга сыгылып төште дә ютәлли башлады. Бер дә тавыш күтәрми, нинди хәлләрдә дә сабыр кала белгән, гадәттән тыш тыныч холкы белән кайчакларда ачуны да китерә торган кызый бу мәлдә дә минем ярсу учакка боз сибә түгелме! Мин аны күтәреп алып коймага сөядем.

– Буып үтерәсең бит... – диде ул, еш-еш сулу алып. – Нинди гаебем өчен?

Мин аның төнге, кара күзләренең гипнозына эләккәнче дип, бөтен уйлаган, ишеткәнемнән кайнарланып, ярсыган сүз хәнҗәрен тыя алмадым. Йөрәгенә кададым. Күңеленә кададым. Хәтеребезгә кададым... Аптырагач: «Ник дәшмисең, гаебеңне аклый алмыйсыңмы?!» – дип, иңеннән кысып тотып, селкетә башладым. Кинәт ул, җансыз калган шикелле, күкрәгемә капланды. Йөзен учыма алып күтәрәм – күзләрендә калтыраулы яшь пәрдәсе, берни

күрми, берни тоймый шикелле, сукыр кеше сыман капшанып, салкын учын битемә куйды да:

– Их, син... – диде. Бу аның көтелмәгән, тетрәнүле хәлгә калганда саркып чыга торган рәнҗүле бәгырь авазы иде. – Мин сине өч ел буе көтәргә әзер идем бит. Их, син!..

Кинәт миңа оят булып китте. Әмма мин-минлегем алай тиз генә бирешәсе килми иде әле. «Үзең бит!» дигәнемне сизми дә калдым. Аннары... юашланган сүз хәнҗәрен ачуым суына башлаган хәрабәләр арасына томырдым.

– Кем котыртты сине, Ирекме? Сизми идеңмени, аның һәрчак күз карашы ачуташлы иде бит. Кемнәр парлы – шулардан үлеп көнләшә иде. Син киткәч, җанымны кая куярга белмәгәнгә генә клубка чыктым мин. Ирек үзе бит ике кичтә дә яныма килеп сырпаланды, озатырга теләп нинди генә юха сүзләр сайрамады. Чирканам мин синнән, дигәч, тузынып китүен күрсәң... Бүген мин китапханәгә дип кенә чыккан идем...

Ирекнең аскы калын, юеш ирененнән тәгәрәп төшкән сүзләрнең мәкерен мин ничекләр сизмәдем икән. Югыйсә, күңелгә кагылышлы сүзнең, җебен-җепкә таркатып карап, уемны бер чияләндереп, бер төенен чишеп, шигемнән тәмам арынгач кына, инана торган идем. Анда – җаның кысылган мохиттә акылың да үтмәсләнәдер шул... Бигрәк кинәт ыргытты шул сөңгесен. Минем тумыштан ук иярә килгән беркатлы аңым саклану калканын куярга өлгерә алмый калды... Биек диварлар эчендә, сак астында яшәүгә күнеп барган акылым үтмәсләнә барадыр шул.

Фәния каршында акланыйммы, кичерүен сорыйммы, дуамал холкымны салып таптыйммы? Бөтен ачу касмагы чыгып беткәнче бер кычкырыйммы?

Кирәкми, диде күкләр. Ишелеп кар яварга тотынды. Күңел юшкыннарын күмәрлек юмартлык бу – кар тәңкәләре бер-берсенә бәрелешеп зеңгелдәрләр дә, тирә-юнь сихри моңга коеныр шикелле. Без гүя дөньядан аерылып, әкияти сүрү эчендә калдык. Мондый сүрү эченнән кулга-кул тотынышып барырга да барырга.

– Җүләр син, – дип, Фәния кулымны авырттырып кыса. – Качып кайттыңмы, дезертир? Утыртып куйсалар үзеңне.

– Мин чын солдат түгел әлегә, ант бирмәгән.

– Барыбер, военнообязанный саналасың.

Мин әле бу хакта утырып уйламаган идем. Күңелгә астыртын суык йөгерде. Дезертир... Ир-егет өчен иң хәвефле, иң бәхетсез кушамат. Ходай язмасын. Фронтка китүче эшелоннан төшеп калмаган. Үз мәхәббәтемне даулап кайттым. Тылда – сагынып көтүче ярың булмаса, нинди солдат инде син – канатсыз кош, гаярьлеген җуйган бүре. Мин бит киләчәгемне яклап, берничә генә сәгатькә үткәнемә кайттым. Кабул ит, рәсемең артына «Без мәңге бергә» дип язган Яринә! Барсына да син гаепле. Синең барлыгың – язмышым таянычы...

Вакыт бара. Кул аркасына кунган алты таҗлы кар чәчәкләрен суырып кабып кына сусынны баса алмыйсың. Фәния өйләренә кереп, кытай термосында чәй, өчпочмаклар төреп алып чыкты. Ишегалды түрендәге мунча ишеген шыгырдатмаска тырышып кына ачып кердек. Кипкән каен яфрагы, мәтрүшкәләр исе саркып торган алгы бүлмәсе артык салкын да, артык җылы да түгел. Көтелмәгән кунак өчен таман гына. Куыклы лампа теле яктысын җәймичә, йомылып, сүрән генә көйри. Термос капкачы – икебезгә бер тустаган. Чәй кайнарлыгы тәнгә йөгерә.

Авыл йоклый. Кар туктаган. Менә без түбән очта. Аяк астында яшь карның сусыл шыгырдавы. Төн икенче яртысына авышкан. Аяз күк йөзендә шыгрым

йолдызлар. Безнең өй каршында басып торабыз. Дөресрәге – әз генә арырак китеп тукталабыз. Тәрәзәләргә туп-турыдан карасам, әни уяныр да тәрәзәгә килер шикелле. Аның шундый мәҗүси сизгерлеге бар. Менә хәзер, ишекне ачтырып керсәм... Сискәнеп уяныррлар да... «Өч елга дип китеп, өч көннән качып кайттыңмы әллә, бизбашка!» дип кычкырмасмы әти, «Яраксызга чыгардыларммы әллә?» дип пошаманга калмасмы әни?.. Юк, ярамый, туган йортка миңа керергә ярамый. Аларны хафага саласым килми. Әти-әни, саубуллашып, язмышымны өч елга төйнәп куйдылар бит инде, вакыты җитмичә кабат чиштерү – кадерсезлек булыр иде. Чарасызлыктан күзгә яшь төелә. Фәниянең кулын учка кысам. Китик моннан, кузгалыйк. Минем монда дәхелем юк. Чакырма, Йорт иясе! Хушыгыз, тәрәзәләр! Сау бул, капка, тотканңа тотына алмадым, кичер мине, ачып керә алмыйм, шыгырдавыңны сагынырмын...

Авыл – гадел йокыда. Бөтен буема басып, бер кычкырып уятыйммы әллә?! Ярамый. Мәктәптән үк гел «я р а м ы й»лар чикләвендә үскән кеше мин. Бу халәтемдә бигрәк тә... Такташ әйтмешли: «Мин дезертир бугай, командир...»

Хокуксыз булсам да, барыбер рәхәт. Күктән, кызыгып, йолдыз атыла. Җирдә без – янәшә. Алда ни көтә? Артта – тыелган бәхет карына чигелгән эзләр...

Фәниягә сөйләп барам. Үсмер чакта шундый фәлсәфәгә бирелеп ала идек: әгәр, бер сәгатьтән дөнья бетәчәк, дисәләр, син нәрсә эшләр идең, дигән сорау куела һәм шуңа һәр малай җавап бирергә тиеш. Кайсы: әтигә барып әйтер идем, ди, кайсы: кибет басар идем, ди, кайсы: әни янына йөгереп кайтыр идем, ди. Боларның, димәк, борын асты кипмәгән әле, чаты ачылмаган. Башны артка ташлап, их, сусыллар сез, дип, болардан рәхәт чигеп, мыскыллы көләргә генә кала. Ә без, өч дус – Зөфәр, Фаварис, мин – күз кысышып, үзебез генә белгән серне уртага салабыз. Әгәр, бер сәгатьтән дөнья бетә, дисәләр, әлбәттә инде, без әниләр янына түгел, ә күз атып йөргән кызларыбыз янына томырылачакбыз. Андый чакта дөнья бетү дә куркытмый, чөнки син – яраткан кызың куенында...

Фәния мине туктатып, күземә сынап караган була:

– Кем иде соң ул дөнья бетүен бергә каршылаучы?

– Ул бүген дә минем каршыда тора. Бүген дә таң беленгәндә дөнья бетәчәк...

Ул куркынган кебек кочагыма тартыла. Сүздән сүз өзелә, күзгә күз ялгана, иренгә ирен кушыла.

Беркадәр вакыттан соң мин, берән-сәрән утлары кабынып, уяна башлаган авылыма тау өстеннән соңгы тапкыр борылып карыйм.

Фәния җылый, кайнар яше битемне пешерә. Асфальтка кадәр озата чыгып, тукталышта озатып каласы килә, мин карышам, икебезне бергә күрсәләр – таныячаклар бит. Безнең бу – кылыч йөзендә кавышу – моңлы бер төш кенә булып калсын.

– Әгәр каршы килмәсәң... Мин сиңа көн дә хат язып торырмын. Өч елга меңнән артык хат! Ышанасыңмы?!

Бу сорауда никадәр мәгънә, якынлык хисе, мин аны йөрәккә генә сыйдыра алмыйм.

– Ыша-нааам!!!

Тау өстеннән авылга карап бар көчемә кычкырам. Фәния минем авызны каплый.

– Җүләр, бөтен авылны уятасың бит!

– Хәзер кыйнап калдырам, аерылыша алмыйбыз ату.

Үпкәләгән атлы булып, ул кырт борыла да нык-нык адымнар белән китә башлый. Учыма кар йомарлап ыргытам, аркасына тия. Борылып, ул яңадан миңа таба йөгерә. Кочаклашып, карга егылабыз.

Межага җиткәнче исәнгерәдек шулай: ул борылып китәргә дип талпына, мин куып җитәм, мин борылып китәргә дип талпынам, ул куып җитә.

Әмма хушлашуны җиңеләйтү дәвасы юк, аны хушлашып кына җиңеп була...

Азнакайдан аэропортка йөрүче РАФ автобусы иртәнге алтыда кузгала, Балтач тукталышына ун-унбиш минуттан килеп җитә. Бәхеткә, Бөгелмә ягына баручылар күренми, посёлокка эшкә барырга чыкканнар барысы да тукталышның каршы ягында. Бәхеткә, төн караңгылыгын таң җиңә алмый әле. Автобуска утырыр алдыннан бер борылып карыйм, олы юлга чыгып килүче карамчыклар бар да күземә а н ы ң силуэты булып күренә... Ачык ишек яңагына тотынып, бер мәлгә икеләнеп торам: әллә калыргамы? Җүләр уемны шофёрның тупас тавышы кагып төшерә:

– Нәрсә терәлеп каттың!

Автобус Бөгелмә аэропортына җилдереп кенә китереп куйды.

Көлемсерәми генә көн башланды. Ноябрь күге – тотрыксыз. Болытлар тартылган, вак кына кар сибәли. Төнге аязлык авылым турындагы йолдызлар белән хушлашу өчен вакытлыча гына иңдерелгән илаһи бүләк булгандыр. Бар да әйбәт, дисәм... бу тормыш гел уйламаган катлаулылыкларын чыгара да куя. Кассир кыз минем хәрби билетны актарып карады да башын чайкый-чайкый каядыр кереп китте. Бераздан калын кашлы, кылыч борынлы кешене ияртеп килде. Калын каш, минем документны селки-селки, тавышын күтәрде:

– Син бит, энекәш, беркая да учётка басмагансың! Нинди частьтән?

Йөрәгем жу итеп китте. Нинди учёт, кемгә, кайчан, нигә? Мин бу турыда бөтенләй хәбәрдар түгел идем. Андый чакта минем башта фикерләр әллә ничә тармакка бүленә башлый, кайсының койрыгыннан эләктерергә икәнен секунд эчендә хәл итәргә кирәк. Ул арада Калын каш хәтәр сүз ычкындырды:

– Мужыт син армияне ташлап качкансыңдыр, ә!

Мин кесәмнән кичәге самолёт билетын чыгардым, каушавымны сиздермәскә тырышып:

– Нинди качу ди, мин бит Владивостокка билет сорамыйм. Менә, кичә кич Казаннан кайттым, бүген иртән Казанга китәм. Ашыгыч рәвештә, бик мөһим документ алып килергә җибәрделәр мине.

– Нинди документ?

– Анысы – хәрби сер... – дидем. Кайсы чакта шулай уйламыйча әйтелгән җилбәзәк сүзнең ышандыручан тәэсире көчле була.

Калын каш яңа күз белән сынап карап торды да, эшне зурга җибәрсәң, мәшәкать чыга инде, әйдә, миннән булсын яхшылык дип уйладымы, түрәлек вазифасының кырыслыгы иртүк уянып җитмәгән идеме, минем кызарып, юаш кына басып торуымны кызгандымы: «Владивостокка билет сорамыйм, диюең логично...» – дип, документымны кассир кызга сузды: «Бир, иртәнге рейска!» – дип, кулын селкеп китеп барды.

Кичә Казан аэропортыннан ничек җиңел үтелгән... Ашыктырдылар шул... Самолёт кузгалыр алдыннан гына... Димәк, кемгәдер файда булган. Бәлки әле... кесәдәге акчамны бөртекләп санап йөри белмәгәнемне чырайдан сизенеп, үзләренә дә бераз чигереп калганнардыр. Шулай уйлана-уйлана, бүгенге шатлыгымны сиздермәскә тырышып, кире чакырып алмагайлары дип, самолётка утырту башланганчы энә өстеннән йөрдем. Фәнияне янәшәмдә итеп тоеп, рәнҗемәдеңме миңа, рәнҗи күрмә берүк, югыйсә минем юлым уңмас, дип ялварам.

Язмыш, кисәтеп, бармак янады – бу юлы да: «Тимә, яшәсен!» – диде.

Бүген инде мин ИЛ-12 самолётына утыру белән саташулы йокы базына

төшеп китмәдем. Аулагөйләрдә дәртне почмакландырып, күпме төннәрне таңга ялгап чыныккан баш-гәүдәм – йокы сорамый, җиңел талгынлыкта тирбәлә. Түгәрәк тәрәзәдән йотылып карыйм. Болытларның җиргә караган ягы соры иде, ә биектә, кояшка караган ягы керсез яктылыкка манчылган. Офыккача җәелгән шушы бөдрә, актан-ак дала өстеннән йөгерергә дә йөгерергә иде.

Уйланып барам. Дөньяда йолдызнамә дигән фән барлыгын, туган көнеңә-аеңа карап, кайсы йолдызлык астында тууыңны белеп, шуннан холык-фигылеңне ачыклап була икәнне ишеткәнем дә юк. Мең еллар буена күзәтү, тәҗрибә туплап эшләнгән бу хикмәти фалда әйтелгәннәр тач туры килә икәнгә мин шактый еллар үткәч кенә инандым. Мин Үлчәү йолдызлыгы астында туып, әллә нинди күркәм сыйфатларга ирешәчәк икәнмен. Әмма үлчәүлеләрнең иң төп сыйфаты – катмарлы тормыш хәлләрендә үлчәү тәлинкәләрен гадел яссылыкта, тигез тотарга тырышу икән. Менә монысына мин юка башым белән дә, үз сизгерлегем белән төшенгәнмен. Адәми затларның акылын чагып, баш очыннан мәңге үлмәс бер яманлык йөри: ул – мәкерле, үрчемле, астыртын гайбәт. Әгәр күктә аллалар күп булса, алар арасында да гайбәт таралыр иде. Чыпчык борыны кебек кенә нахак сүздән дә илләр белән илләр чәкәләшкән, ирләр белән ирләр дуэльгә чыккан, күпме язмышлар челпәрәмә килгән. Нахак сүздән күңел рәнҗи, яшәүнең кызыгы бетә. Эчтән рәнҗеп йөрү – көчсезлек. Шуңа күрә мин хәлнең асылына, төбенә төшеп ачыкламыйча тынычлана алмыйм. Тәкәбберлегеңне җиңеп, үзара аңлашып, кул бирешкәч инде, бөтен гөнаһларыңнан арынасың, рәхәт булып китә... Кичә Казан урамында күргән ак әби әйткән күңел кояшың болыттан арынып яктыра, яңадан туган кебек буласың. Шулай итеп, миңа төрле низагларны җайлап, йомшартып, килештереп, гомер бизмәненең ике тәлинкәсен дә бер җиңеллектә яисә бер авырлыкта тоту насыйп ителгән. Чөнки туганда ук кальбемә Үлчәү йолдызлыгыннан шундый хасиятле нур иңдерелгән...

Болытлардан өстә, Раббыга якынайган киңлектә, аның барлыгын уема да кертмичә, үз-үземә акланаммы әллә... Башсызлыкмы, сансызлыкмы – актыктан ни буласын абайламыйча, кыдрачланып, кайчакта дуамал адымга бару – бу минем дөньяда барлыгымны исбатлаучы дәлилем. «Мин яшим! Мин бар!» дигән, ауганда да аумый торган текәлегем. Юашлыгымны тез чүктереп, кай мәлләрдә бер калкынып алу – эчке халәтемнең яктысы да, күләгәсе дә булып һәрчак мине котыртып тора. Холкым туфрагыннан шытып чыккан нәзберек үзирегем кыягын кырыкмасаң иде, кырыс язмыш урагы...

Нәкъ төш вакытында мин Казанның үзәгенә, кергәндә капкасы юмарт ачыла торган тимер читлегемә кайтып төштем. Монда әле кыш кинәнә алмый. Асфальт юллар, тротуарлар юеш. Шәһәр шавыннан куркып, кар ясканып яварга кыймый, күрәсең.

Кайчан китәсебезне белешергә дип, канцеляриягә сугылуым булды, эләктереп алып, чәчне кыркытырга җибәрделәр. Менә җәза сәгате миңа да сукты. Чәч алу урыны шушында гына, бушка, имеш. Бушкасын бушкадыр да бит... Чәч белән бергә унсигез яшьлекнең җилкуар җиле дә киселә...

Чәчне алдырганнан соң, бүрегем такыр башны танымыйча, ятсынып калды бугай, каты чәч камылы өстенә уңай гына кереп утырмады, үзеннән-үзе бушап, төшеп калырга җыенган кебек. Үз-үземә вәгазь укып барам: күнегергә кирәк, мәхлугым! Синең хәзер башың да, йөрәгең дә, акылың да үзеңнеке түгел. Кушканны карусыз үтәргә әзерлән. Синең өчен погонлы һәрбер карачкы – әмир. Аның акыл таләп ителмәгән һәр сүзе – әмер!

Әмма җан карыша. Килешергә теләми. Шәһәргә чыгарга дип капкага килгән

идем, дежур солдат, сынаулы караш ташлады да, бүрегемне күтәреп карап, такыр башка чәпәде. Вәкарьле кул ишарәсе белән генә кире борылырга икәнен белдерде. Аңлашылды. Чәч – хокук таҗы икән шул монда. Киемең алтын җептән тукылган булса да, башың такыр булгач, иреккә чыга алмыйсың. Йөрмә әллә кем булып, кереп чум әнә ишегалдында уйдык-уйдык булып чәчелгән төркемнәр арасына.

Тымызык көнгә, тымызык кәефкә үч итеп, күңелне Фәниянең ягымлы тавышы юатып ала: «Телисеңме, мин сиңа көн дә хат язып торырмын, өч ел буена меңнән артык хат була». Аның зур күзләре минем ышануыма шундый ышаныч белән карый... Юк, хәзергә мин бу кадерле мизгелне күңелемнән куам, бу шыксыз дөньяга төшереп керләндерәсем килми. Миңа бу тупаслыкта ялгызым гына талкынырга, өметсез бәргәләнергә, интегергә кирәк – гомернең якты аланнарына пакьләнеп кайту өчен...

Әнә, мәйдан уртасында унлап егет түгәрәкләнеп басканнар да буш консерв банкасы тибеп уйныйлар. Болар яныннан исем китмичә генә үтеп китмәкче идем дә, нигәдер, тукталып калдым. Тукталу гынамы, бирелеп китеп, хәтта онытылып күзәтә башладым. Калай банкага тибеп карарга кызыкканнар күзгә күренеп ишәя башлады. Китте – этеш-төртеш, сызгыру, кычкырыш, сүгенү – гүя ниндидер кыргый җәнлекне уртага алып шулай типкәли-типкәли азаплыйлар. Калҗаеп, яньчелеп беткән калай банка типкән саен тилерә бара; асфальт өстеннән тәгәрәп, әүмәкләнеп, сыдырылып очкан вакытта әллә нинди гасаби авазлар чыгара. Әле чиный, әле сыктый, әле инәлеп ялвара, әле кисәтеп яный шикелле. Калын стеналар арасында, амфитеатрдагы кебек, икегә-өчкә тапкырланып яңгыраган бу мәхшәрле авазлар, чайпалып, бөтен шәһәр өстенә таралыдыр шикелле.

Ә тибүчеләр, акылын аягына төшереп, отыры кыза гына бара. Түгәрәккә кергән һәркем, янәшәдәгесен этә-төртә, ямьшек калай кисәгенә тибеп калырга адарына. Минем кебек әлеге тамашага читтән карап, әсәренеп калганнар да шактый. Бу котырган авазлар көчәя-көчәя, чияләнеп, аң-зиһенгә бәрә, тешкә тия, җанны кыршый. Мәгънәсез уенны болай чарасыз карап тору да рухыңны кимсетәдер шикелле. Тизрәк туктатасы, бу мәхшәргә чик куясы килә... Күпмегә сузылгандыр, ахырда берәү табылды бит, тәвәккәл адымнар белән килеп, түгәрәкне аерып керде дә ажгырып тибелгән калай банканы футболистларча җитез-осталык белән өстенә басып туктатты, алагаем көч белән таптарга, рәхимсез изәргә кереште, ахырда, тәмам коймакка әйләндереп, җиргә сеңдереп куйды. Мондый кыланмышына сүгенеп, хәтәр ачуы чыккан өер аның үзен дә консерв банкасы кебек яньчеп, дыңкып ташлар иде, әмма бу алаңгыр гәүдәле егет иләмсез калын җилкәле, көче ташып торган гер йодрыклы иде шул. Саллы табанлы ботинкалары да кырык бишле размерга тартадыр, мөгаен. Мондый туң гәүдәгә нинди көч белән килеп бәрелсәң, физика закончалыгы буенча, маңгаең ярылып, шундый ук көч белән кире чәчрәп китәчәксең...

Шулай итеп, төркем таралды. Калай банканың зәһәр чинавы тынды, ә күңелне әллә нинди ямансу бушлык биләп алды. Бөтен барлыгым – уй-тойгыларым, упкынга убылгандай тынып калды. Моңа кадәр яшәлгән унсигез елым тәмле бер төш булып, чынбарлыгын раслый алмаслык ераклыкка күчте. Ә алда – тома билгесезлек. Мин, «яшәү» дигән гомер аргамагыннан ыргытылып калган бер йомычка халәтендә, менә шушы соры диварлы, шыксыз дөнья уртасында чарасыз басып торам. Тымызык көн. Ятим күңел. Уйсыз уйлар... Бая гына калай банканың тибелеп сөрән салуы үзенә бер юаныч булган лабаса, аның әче сызлануын юксынып күңел сулкылдый.

Муса Җәлилнең тоткынлыкта язган шигыреннән шундый юллар искә төшә:

Чәнечкеле тимер чыбык белән
Уратылган безнең йортыбыз.
Көне буе шунда казынабыз,
Әйтерсең лә тирес корты без.

Әмма минем күңелем базына яшерелгән тәкәббер горурлык хисе гел уяу тора; сыгылырга ирек бирми, түз, бар да вакытлыча, болар сизелми дә үтәр, ди. Кайчакларда, җиңелеп җиңәргә өйрән, ди. Әлбәттә, мин ул чакта әле яшьлектә кичергән авыр мизгелләрнең дә, олыгайгач, кадерле хатирәгә әйләнәчәген белмим. Күп нәрсәне белмәү бәхете – яшьлекнең җилгә аркаланган байрагы түгелмени!

*(Мин бу юлларны кырык сигез елдан соң, Урта диңгез буенда (Төрекләр кушканча: Ак диңгез) «Титаник» һотелендә язып утырам. Бу бик затлы һотельдә бер гадәт бар: кичке унда, мәйданчыктагы ачык сәхнәдә зур концерт башланганчыга кадәр, иртәнге уннан башлап төрле музыка уйнаталар. Фирүзә төсендәге суы җем-җем килеп торган бассейн кырыендагы ачык кафеда «Наполеон» коньягын тел өстенә сеңдереп, капучино йоткалап, көчле динамиклардан яңгыраган көйләрне тыңлап утыру үзе бер хозурлык. Менә шунда яңгыраган бер музыка сәерлеге белән җәлеп итте мине. Башта өнәп бетермәдем. Колакны сискәндерде, әмма ошатып кабул итә алмадым. Эзлекле көй итеп истә калдырырлык моңы да юк сыман. Авазлар какафониясе: ниләрдер ышкыла, чылтырый, сыдырыла, бәрелә-сугыла, тәгәри – әллә нинди хәрәкәт бара. Теләмичә генә тыңлый торгач, тора-бара ияләшә башладым бит. Хәтта бу музыканың сурәтен күз алдына китерәм. Имеш, бик борынгы дәвер икән бу. Иксез-чиксез дала буйлап тезелешеп кәрван бара. Дөяләрнең авызлык тимерләре чылтырый, камчылар сызгыра, тәгәрмәчләр шыгырдый, каядыр быргы кычкырталар, кубызда уйныйлар, йөрәкләр кага – кәрван яши, кәрван алга бара. Кинәт бер урында музыка кырт өзелә. Бер мизгелгә бар да тынып кала. Минем гөманлавымча, иң алда барган бөркәвечле арбаның алагаем зур тәгәрмәче чокырга төшеп, бөтен кәрванны бүәп туктатты. Тиз арада ярымшәрә коллар йөгереп килеп, тәгәрмәчтән күтәреп, арбаны тигез җиргә куялар. Кәрван дәррәү кузгала, тагын да көчәеп баягы тавышлар чылбыры зеңгелди, сызгыра, шыгырдый, чылтырый башлый.*

*Мин бу музыканы көнгә әллә ничә тыңлыйм. Тыңлаган саен әнә шул бер сулышка тукталган мизгелен түземсезләнеп көтәм. Менә ул – кинәт туктый да, дөнья бер мәлгә шомлы тын кала, аннары, кинәт, тагын җан керә, таныш авазлар үз куелыгында тантана итә башлый. Бу көйнең шул туктап калган һәм кабаттан башланган мәлендә йөрәк кысылып, әллә нинди моңсулык чәнчеп ала. Үзәкне сызып, күзгә яшь күтәрелә. Нигә шулай? Нидән болай? Кайда, кайчан ишеткән идем соң мин бу көйнең аерым, телем-телем авазларын? Әллә соң бу җирдә бакый заманда бер яшәп алганмынмы, япан дала буйлап кәрван куганмынмы?*

*Юк, асылы бик гади. Моны миңа музыка үзе төшендереп бирде. Шушы көй тәэсире аша мин кайчандыр хәрби комиссариат ишегалдында бер төркем егет-җиләннең түгәрәккә оешып, калай банка тибеп уйнаганнарын искә төшергәнмен. Бер үк охшаш авазлар кайтавазы. Бу минем үзем генә аңлаган ямансу халәт. Музыка туктап алганда, йөрәкнең убылып куюы*

*да аңлашыла... Теге чакта калай банка тибеп уйнау мәле... ул бит калын диварлар чолганышында, табигый яшәвеңнән аерылып, туктап калуыңны онытасы килеп, җан тарыгудан котыласы килү мизгеле булган...*

*Ә ул музыканы мин кайсы илдә, кем язганын да, исемен дә белмим. Еллар үткәч тә, тагын бер генә тыңларга иде дип, гел эзлим, сагынам, юксынам. Кайбер чакта берәр чит ил музыкасы эченнән таныш аһәң тибрәнеше сирпелеп киткән кебек була, колакны шомрайтам, әмма юк, бу – башка... теге сәер музыканы, сәерлеге белән истә калган, истә калуы белән күңелне сагышлы юата алган музыканы, кире кайтып, бүтән беркайчан да ишетмәм инде мин.)*

Иреккә омтылу үҗәтлегем куәтләнә генә бара. Ишектән кусалар – тәрәзәдән, тәрәзәдән кусалар, морҗадан чыгам, дигән шикелле булды бу. Мине берни дә туктата алмады. Казармада кунмаячакмын дигәнемә барыбер тугры калдым. Шуны белдем: капкадан чыкмыйча да чыгып була икән бит шәһәргә. Свердлов урамы ягында военкомат бинасы белән хәйран биек фабрика корпусы аерым стена белән тоташкан. Буе биш-алты метрдан артмас, биеклеге төгәл дүрт метр, моны инде карышлап үлчәгәннәр.

Ишегалды ягыннан әнә шул стенага менеп, урам якка сикерү гаҗәеп тәртипкә салынган. Эңгер төшкәч килеп чиратка басасың. Монда син берьялгызың берни дә кыра алмыйсың. Бер-береңне якыннан белү, танышлык та мөһим түгел. Кырык мирдән җыелган никрут туганлыгы бердәм гаделлеккә корылган. Этешү-төртешү дә, тупаслык та юк. Тәртип мондый: әйтик мин, чиратым җиткәч, аякларын аерыбрык, күкрәге белән стенага терәлеп баскан егет иңенә менеп басарга тиеш.Арттан этеп, миңа ярдәм итәләр. Стена сыртына миннән алдан күтәрелгән егет кулымнан тартып өскә менгерешә дә үзе урам якка сикерә. Мин аның урынын биләп, сузылган кулыннан тартып, нәүбәттәге егетне менгерешергә әзерләнәм. Әзерләнәм, дию дөрес булмас, һәр хәрәкәтең исәпле, җитезлек, өлгерлек кирәк. Киңәш бирүчеләрнең сүзе дә бик урынлы әйтелә. Каты сикереп, аягыңны имгәтмәс өчен, алдың белән борылып, стенаны «кочаклап», гәүдә авырлыгын аяк-кулларың белән тыйдырып төшәргә тиешсең. Синнән алда төшкән егет, стена төбендә кулын сузып, гәүдәңнең төшү тизлеген «сүндерергә» әзер тора. Җиргә басуга, син аның урынын аласың, ул инде ирекле, эре генә атлап, шәһәр куелыгына кереп күмелә. Менә шушы гадел тәртипкә буйсынган конвейер өзлексез эшләп тора. Ә чираттагы соңгы кеше ничек чыга, дияр дөнья күрмәгән берәрсе. Бик гади: соңгылар чыга алмый. Моңа алар алдан ук әзер; якташынамы, дустынамы эчкерсез ярдәм итәргә дип килә, яхшылык кылуыннан канәгать булып озатып кала. Гомумән, мондый катлаулы юл белән чыгарга адарынганнар бихисап була алмый. Үҗәтләр, теләклеләр генә.

(Дүрт-биш елдан соң, студент булып Казанда яшәгәндә, мин бу стенаны күрсәтергә дип дусларны алып килдем. «Китчәле, мондый биектән сикереп буламы?! – дип ышанмыйча торалар. Игътибарлап карасам... чынлап та биегәйгән бит бу! Стенаны тагын метр ярымга үстергәннәр, ялгавы да ачык сизелеп тора. Кайчандыр безнең дәвер шуып төшеп шомарткан эзләр дә беткән, буявы да икенче төстә... Нигә биегәйткәннәр? Мин моның сәбәбен соңыннан белдем: никрутларга каршы эшләп түгел, киресенчә, аларның иминлеген кайгыртып биегәйткәннәр икән. Бездән соң ике елдан солдатка алынган егет аңлатып бирде. Заман үзгәргән. Һәрвакыттагыча – кире якка. Шундый гадәт гамәлгә кергән: стенадан сикереп төшүеңне махсус көтеп торган

Казан малайлары ияк астына пычак терәп, кесәңдәге бөтен акчаңны күз ачып йомганчы чистартып алалар икән. Тора-бара стена янында ике яктан өер-өер килеп сугышу, чәкәләшүләр дә булып алган. Менә алмаслык итеп, менә ни өчен биегәйткәннәр икән низаг чыганагын.)

Шулай итеп, җиде көн, җиде төн кичердем Казан каласында. Соңгы икесендә шәһәргә чыгуның бүтән алымын сайладым. Бу юлның да үз Колумблары, үз белгечләре бар икән. Комиссариатның капкасы Курчак театры бинасына килеп терәлә. Узган гасырда ук төзелгән бу борынгы бинаның арткы дивары безнең ишегалды ягына карый. Өске катка менә торган таш баскычы бар. Менә шуннан күтәреләсең дә мәңгелеккә бикләнгән запас ишек яныннан үтәсең, аннары, артыңнан этеп, көч өстәүчеләр ярдәмендә, дивар почмагыннан тырмаша торгач, түбәгә чыгасың. Төп бина түбәсенең читенә килеп, икенче – түбәнрәгенә сикерәсең, аннары өченче түбәгә, аннары гына – җиргә.

Бу юл миңа ошады. Тик ике тапкыр гына чыгып калдым. Ниһаять, ирекккә сикерешнең соңы җитте. Командабыз тупланган. Безне алырга берничә офицер һәм сержантлар килгән. Каян килгәннәр – анысын белмибез. Взводларга да бүлеп куйдылар. Төнге сәгать унда Казан урамнары буйлап безне, сафка тезеп, тимер юл вокзалына алып киттеләр.

## Курсант

Поезд тәгәрмәчләре бер көйгә тыкылдап чакрымнарны уятып бара. Юнәлеш – Урал-Себер ягы икәнне чамалыйбыз. Кайсы төбәктә, нинди шәһәрдә тукталачакбыз – беркем белми. Командирлар да ләм-мим. Бу сер, каты төен булып, гел башка сугып бара.

Төн дә бетте, көн дә үтте. Карлы нарат урманнарын ерып поезд һаман алга үрмәли.

Барып җиткәнче тәки серне ача алмадык. Икенче төн кергәч, поезд Бахаревка дигән станцага килеп туктады. Әйберләрегезне үзегез белән алып төшәргә, дигән команда яңгырады. Дәррәү купты барсы – тынды юл ритмына көйләнгән гитара чыңы, аккордеон тавышы, җырлар, төрле телдә гамьле-гамьсез сөйләшүләр. Тиз генә җыенып, җылы, плацкарт вагоннарны калдырып, салкынга сикердек. Пермь шәһәренең чите икән бу. Бер якта урман шәйләнә. Карлы кырдан җәяүле сукмак ясап барабыз. Алда – аэродром утлары җемелди, бер җепкә тезелгән самолёт карамчыклары күренә.

Ниһаять, килеп җиттек шикелле. Алдыбызда – тимер койма, сыкылы агачлар, биек-биек биналар яктырып күренә. Бер кырыйда зур хәрефләр белән ШМАС дип язылган стелла тора. Нәрсәне аңлата, Ходай белсен. Сакчылар торган будкалы тимер капканы киереп ачып, безне эчкә кертеп җибәрәләр. Тагын сафны барлап, кары пөхтә итеп көрәлгән аллеялар буйлап кузгалабыз.

– Левое плечо вперёд! – дигән команда яңгырауга, капылт, алдагы рәт сулга борыла башлады.

– Отставить! – дип командир туктатты да, ачуланмыйча гына, елмая төшеп, аңлатып бирде. Сул җилкәне алга этәргәч, гәүдә уңга борыла икәнне без уйлаганмыни. Алга таба хәрби күнекмәләрне чын-чынлап өйрәнү дәресләрендә дә бу сәер командага мин ияләшә алмыйча интектем. «Левое плечо...» дигәндә – сулга, «Правое...» дигәндә, гәүдәң уңга борылырга тора инде. Тора-бара мин, команда яңгырауга, уң җилкәнеме, сулынмы – күңелемнән алга этеп карап, кайсы якка борылырга кирәген секунд эчендә ачыклый алырга өйрәндем.

Шулай борыла-сырыла йөри торгач, безне өч-дүрт катлы мәһабәт бер бинаның икенче катына кертеп тутырдылар.

Көтәбез. Мунча керәчәгебез инде сер түгел иде. Бер яктан киемнәреңне ташлап керәсең, юынгач, икенче яктан хәрби киемнәр киеп чыгасың, дигән халыкта таралган сүз чынлап та дөрес икән. Тик бер аерма булды: киемнәрен посылка итеп өенә салырга теләгәннәргә чама тартып тегелгән ак бәз капчыклар өләштеләр. Мин бик пөхтәләп төреп, пәлтә-костюм-чалбар-бүрегемне тыктым, ботинкалар гына сыймый калды. Шунда ук адресымны шәмәхә каләм белән язып, боларны махсус җыеп торучыга тапшырдым. *(Посылка килгәнлеге хакында атна-ун көннән өйдән хат алдым. «Пәлтә кесәңнән тиеннәренә кадәр бар акчаңны табып алдык. Онытып җибәргәнсеңдер инде, акчасыз нишләрсең, салыйкмы?» дигән хатка: «Кирәкми! Мин хәзер тулаем хөкүмәт карамагында», дип язып җибәрдем. Әлбәттә, мин кирәк-яракка дип беразын калдырган идем.)*

Шунысы кызык: киенеп чыккач, шаккатып бер-беребезгә карашабыз. Солдат киеме бу кадәр дә иләмсез булыр икән. Гимнастёрка итәгенең коточкыч киң икәнен әйтмим дә инде, галифе чалбарның кесә турларыннан тартсаң – шаккаткыч! Ачуың килмәгәе – як-якка берәр метрга җәелә. Бу галәмәтне ничекләр генә киеп йөрермен икән. Төптән уйласаң – йөгергәндә, утырганда, шуышканда, бөгелгәндә солдатка уңай булсын дип тегелгән инде болар. Әмма ыспайлыкны яраткан яшьлек бар бит әле. Күрәләтә карачкы булырга ничек ризалашсын ул.

Мунчага кергәнче берничә татар егете белән танышкан идем, чыккач, таный гына алмыйм бит үзләрен, хәрби кием кигәч, бөтен кешенең йөз-кыяфәте, рәвеше үзгәрде дә куйды.

Шулай итеп, билен каеш белән бугач, иплелек кысаларына керә башлаган егет-җиләнне бер батальон итеп туплядылар. Тезелеп киткән зур тәрәзәле, ачык сары диварлы өч катлы бинага өч рота урнашты. Икенче катта – мин хезмәт итәсе икенче рота. Эчтә – гадәттән тыш чисталык. Якты. Җылы. Озын коридор. Киң аркалардан керешле кубриклар – икәү. Беренче, икенче һәм өченче, дүртенче взводларга бүленгән рота тулысы белән сыя икән ике кубрикка.Тезелеп киткән зур тәрәзәләр каршында бер катлы, стена буйларында исә караватлар ике катлы. Паркет идәннәр ялтырап тора, таеп егылырлык. Коридор яклап, стена эченә кертеп куелган йозаклы, авыш ишекле шкафлар тора, болар корал саклана торган пирамидалар икән.

Баштагы көннәрдә бер секундка да тынгылык бирмәделәр, иркенләп хат язу һич мөмкин түгел. «Выходи строиться!» дигән команда секунд саен колакны ярып керә. Якыннарыма саран сүзле хатларда адресны гына хәбәр итә алдым.

Ротабыз командиры – майор Антонов. Казанда туып-үскән. Чибәр кеше. Елмайганда бит очлары чокырая. Кырыс күренергә тырыша. Әмма аңа кырыслык килешми. Кай ягы беләндер ул актёр Золотухинга охшаган.

Взводлар буйга карабрак сайланган. Беренче взводта метр да сиксәннәр дә бар. Мин – өченче взводта. Һәр взводта биш-алты татар. Дүртенче взводта күбесе – чувашлар. Взвод командирыбыз – Гаевский, хохол егете. Чибәр. Күкрәген киереп, гел көзге алдындагы кебек, үз-үзенә сокланып йөри. Холкы ярыйсы. Офыкта хатын-кыз күренсә, кукраеп, бу дөньяда фәкать мин генә бар, дигән кыяфәткә керә. Пермь кызлары аның бу һавалы кыюлыгын бәялиләр дә шикелле. Хлеборезкада эшләүче чибәр ханым янында ул ашханәгә кергән саен тоткарлана. Кечкенә тәрәзәсенә кош оясына башын тыккан шикелле кереп бетеп

сөйләшә, шуңа күрә безгә бирелгән ашау минутлары азга гына булса да сузыла. Әмма барыбер иркенләп ашауга күнеккән гадәтне үзгәртергә туры килде.

Без хезмәт итәргә тиешле часть гадәти генә булып чыкмады. Элек ул – Ленин комсомолы исемендәге ПВАТУ (Пермьское военно-авиационно-техническое училище) дип аталган. Никита Хрущёв хакимлеге чорында, армиядә кыскартулар башлангач, 1960 елда исеме һәм җисеме ШМАС (Школа младших авиаспециалистов) дип үзгәртелгән. Без менә шушында бер ел буена укырга тиешбез. Бер ел буена колак төбендә «Товарищ курсант» дигән сүз яңгырап торачак.

Башка төр гаскәрләрдә нинди тәртип булгандыр, анысын белмим, ә безнең авиациядә өч елга алынган солдат язмышы рәсми булмаган өч дәрәҗәгә бүленә икән: беренче елда син – «салага»; икенче елга чыккач – «молодой»; өченче елда инде – «старик», ягъни «дембель» булып, иң югары баскычка менәсең. Уставка карусыз буйсынудан тыш, солдат көнкүрешенә тамыр җибәргән шушы рәсми булмаган өч дәрәҗә казармада яшәү рәвешен, үзара мөнәсәбәтләрне билгели.

Без, бер үк вакытта армия хезмәтенә алынган бер батальон курсант – барыбыз да тигез хокукта идек шул. Шулай булгач, «салага» дигән мыскыллы кушаматны сизми-белми үтеп китеп, бер елдан соң инде, укуны тәмамлап, илнең төрле частьларына таратылып, яңа урынга «молодой» булып барып керәчәкбез икән.

***

Оешмаган, тарау холыклы яшь-җилкенчәкне җыйнак солдат итеп әвәләү җиңел бирелмидер шул. Җилкәне киереп, гәүдәне төз тоту, җәһәт кенә сафка басу, өч рәт булып тезелгәч, янәшәдәгеңне тоеп, бераякка атлап бара белү өчен никадәр күнегү кирәк. Көн саен, сәгать саен үткәрелгән строевая подготовка дигән дәресләрдә: «Шагоом – марш! Носок вытягивать! Чётче шаг! Выше! Выше ногу!» дигән командалар астында тиргә батып бетәбез. Честь биргәндә, кулны терсәктән бөгеп, кул очыңны каш биеклегенә китерүнең дә үз хикмәте, ыспайлык сере бар. Болар бар да тыштан караганда гына җиңел күренә, асылда исә йөзләрчә тапкыр кабатлап кына ирешелә торган күнекмәләр. Бу – Цезарьлар, Атилла, Чыңгыз ханнар дәвереннән бирле чарлана килеп, һәр ил армиясе үз милли бизәк-төсмерләренә баетып, үзенчә бер камиллеккә ирешкән хәрби сәнгать.

Моны өйрәнү миңа ошап та куйды шикелле. (Менә хәзер, илле елдан соң да мин строевой шаг дигән хикмәтне чыкылдатып күрсәтә алам.)

Безнең ротаның һәр дүрт взводында да илнең төрле тарафыннан җыелган алты-җиде татар егете бар иде. Чебоксар тирәсендә туып-үскән Юныс исемле егет аеруча истә калган. Рәвеше белән ул гел түгәрәкләрдән генә тора. Башы, чырае түм-түгәрәк. Калын иренле авызы, күзләре түгәрәк. Калын кашлары дугаланып тора. Гәүдәсе дә түгәрәккә охшаган: төшенке җилкәле, гимнастёрка итәген каешы астына җыеп китерә алмаганлыктан, кабарынкы артлы булып күренә. Үзе ул бик юаш, елмаеп кына йөри. Менә шул Юнысыбыз хәрбиләрчә атлап йөрергә өйрәнә алмыйча изаланды бит. Командир: «Курсант Исанбаев, выйти из строя, строевым шагом, ко мне!» диюгә, сафтан чыга да мәзәк кенә атлап бара башлый, менә хәзер, командирга метр ярым кала, тукталып, ул честь бирергә тиеш. Әмма Юныс адымын чамалап бетерә алмый, честь бирергә ничегрәк бөклим икән дип, кулы белән мавыгып, аягын онытып җибәрә дә түше белән командирга килеп бәрелә. Көлешәбез. Командир үзе дә: «Ну Исанбаев!» – дип, елмаюын тыярга тырышып, башын чайкый.

Иртәләрен савылып йоклап яткан чагында «Подъём!» дигән рәхимсез

команда яңгырагач, их, тагын бер генә минут йокларга, дигән өметсез-татлы уй йокы сүрүен умырып төшерә, караваттан ыргытылып, урындыктагы киемнәреңә ташланасың. Чолгавычны урап торсаң, җүләр буласың, итек кунычын ике куллап тартканда, ул аяк белән бергә үзеннән-үзе уралып кереп китә. Коридорга чыгып, сафка басканда, гимнастёрка сәдәфләрең генә эләктерелеп бетмәгән була. Йөрәк кага. Аң әле уянмаган. Сержант сәгатенә карап секундларны саный. Тагын шул Юныс гимнастёркасын кияргә онытып, баскан килеш йоклап тора инде. «Отставить! Отбой!» дигән команда яңгырый. Одеал эченә кереп чумабыз. Сержантның камчылы тавышына буйсынып, тагын торып, караваттан ыргытылабыз. Тагын ятабыз. Берәр белмәгән зат читтән карап торса, йокылык белән уяулык арасында чәбәләнеп, болар нинди уен уйныйлар икән, дип аптырар иде. Шулай берничә тапкыр кабатлана торгач – без җәһәтрәк кыймылдыйбызмы, секундлар акрыная төшәме – сержант Гаевский, өнәмичә генә канәгатьлек белдереп, ниһаять, безнең тәннән чыгып бетмәгән йокыны җилгәрүдән туктый. Соңыннан инде, бар да синең аркада, дип Юныска ябырылалар. Ә ул, гадәтенчә, түгәрәк елмаеп тик тора. Сүгеп кенә төзәтеп буламыни табигать баласын...

Казармада корт күче кебек оешып яши башлагач, мин русча сөйләшә белмәвемә төшенеп, сусыз балык кебек бөтенләй чарасыз калдым. Бөтен җирем сәламәт югыйсә, ә тел – гарип. Унсигез яшемә кадәр төенләнә килгән эчке горурлыгым мондый мескен хәлгә калуым белән һич тә килешергә теләми. Ничек җиңәргә бу чытырманлы рус телен? Күңел базында чыгу юлын таба алмыйча, тома караңгылыкта бәргәләнәм. Мәктәп дәреслегеннән кереп калган аерым-аерым сүзләрне әзме-күпме беләм дә шикелле, әмма кирәкле сүзне фикер җебенә тезеп, килешләргә төрләндереп җәһәт кенә әйтеп бирә алу – акыл белән аңлатып бирә алмый торган хикмәт икән ләбаса. Аннары... тере рус кешесе белән гадәти тормыш-көнкүреш хәлләре турында, күзгә-күз карап, беркайчан да сөйләшеп торганым булмаган ла минем.

«Застегнуть» яки «растегнуть» дигән сүзләрнең мәгънәсен аера алмыйча каушап калуым хәтердә; бу ике сүз шулкадәр охшаш булып тоела иде, кайсында нишләргә белмичә аптырап тора идем.

Менә бер төркем солдат русча гәпләшеп тора. Спорт турында барган әңгәмә аңлашыла да кебек, минем дә бу әңгәмәгә кушыласым килә; төкерегемне йотып, белгән рус сүзләрен эчемнән генә туплап, бер җепкә тезә башлыйм, белмәгәнен татарчадан алып, тәрҗемә итмәк булам; алхимик сыман кушып-алып, укмаштыра торгач, әйтәсе җөмләмне сипләп бетерәм дигәндә... спорт темасы үтеп китә, сүз сөреше, кызыктыргыч тәмләнеп, кызлар турындагы истәлекләргә күчә. Мин тагын «телемне канатып» җөмлә төзергә керешәм. Таралып яткан сүзләрне җыеп, уйлаганымны әйтеп бирергә тагын соңга калам. Шулай итеп, эчтән әллә ниләр әйтергә адарынып та, тыштан берни әйтә алмыйча, бүкән булып тик басып торам. Уең, фикерең булган килеш телсез кал да – ничек инде кимсенмисең ди. Ана сөте белән тәнеңә, җаныңа сихәтле сеңдерелгән Туган телеңнең монда кирәге бетте, кыерсытылып, ул, ятим калган җан иясе сыман, күңел почмагына кысрыкланды...

Күр инде әнә, итек кунычы тезенә җитеп тукталган, кыска аяклы, тупыйк гәүдәле, шул гәүдәгә ялгыш утыртылган шикелле олы башлы Двуреченскийның кыланмышын кара: рус милләтеннән булган өчен генә масаюлы йөри, кыяфәте адәм гыйбрәте югыйсә. Ике борын тишеге мәгарә авызы кебек киереп ачылган, ияге гер таккан шикелле авыраеп төшкән, сөйләшкәндә ике казык теше ирен

арасыннан калкып чыгып шом салып куя. Шушы бетәмәтнең үз-үзен тотышы сәерсендерә. Әнә ул, фарсы миниатюраларында сурәтләнгән кебек гаҗәеп чибәр, чем-кара чәчле Арча егете Җәүдәткә вәкарь белән, мыскыллы елмаеп карап торган була. Мондый да камил чибәрлек каршында яшәвеңнән оялырга кирәк, югыйсә... Җәүдәт исә, рус теле чытырманлыгына кереп уралган да, «тезен сыдырып», абына-сөртенә, чыгу юлын эзли. Уй-фикерен йөгертеп кенә әйтә алмыйча ык-мык азаплана. Бит очлары янып, маңгае тирләп чыккан. Фикереңне шома гына әйтә алмыйсың икән – рус каршында син томана саналасың. Әнә шулай уйлап торган Двуреченский тантана итә, чөнки ул – телне безгә караганда әйбәт белүе ягыннан бер башка өстен. Нишлисең бит, бу ике егетнең акыл-зиһен тустаганын үз милләте бизмәненә куеп үлчәсәң... кызыклы гына чишелеш килеп чыгар иде дә бит... Әйе, еллар йомгагыннан микъдарлап үрелгән туган тел хәзинәсен читкә тибәрергә мәҗбүр булып, яңгырашы, рухы белән бөтенләй ят тел ызанына чыгу – тетрәнүләр аша бирелә икән шул.

Ә Двуреченский кебекләр, нигә бөтен дөнья русча гына сөйләшми икән, дип аптырый, каяндыр килеп, татарча сөйләшеп тору тыйнаксызлыгына барган солдат аның өчен – кыргыйлык үрнәге. Рядовой курсант булса да, сиңа караганда ул үзен бер башка өстен саный. Чөнки ул – империя тоткан милләтнең улы.

Чувашлар русчаны ару гына сукалыйлар. Бу милләткә үҗәтлек, күндәмлек, карусыз буйсыну хас. Юк кына эшне дә алар шулкадәр җитди карап, бернинди хыял-фантазиягә бирелмичә, кушканга – хуш итеп башкарып чыгалар. Татар – киресенчә, елдам-мут. Көч куймыйчарак эшләү өчен әллә нинди хәйләләр үрә. Чувашка туп-туры барырга дигән әмер булса, юлында маңгае белән баганага килеп бәрелеп, күзеннән чәчрәп ут күренсә дә, ул уңнан яисә сулдан әйләнеп үтмәс, черәшеп, багананы аударганнан соң гына турыга узар...

Дүртенче взводта унбишләп чуваш егете бар. (Командирлары – сержант Хәеров – татарча «белми» торган татар.) Фамилияләре кызык: Пугачёв, Ульянов, Чапаев, Роговлар... Иван исемен бик яратып кушалар икән.

Баштанаяк «иван»га коенганнар бар: Иванов Иван Ивановичлар – өчәү. Шундый исем йөрт тә русча белми кара!..

Бервакыт Двуреченский чувашларның үзара үз телләрендә сөйләшүен чирканган кебек тыңлап торды да:

– Что это у вас бесконечное «ч-ч-ч»? Балякаете на своём, противно слушать! – диде. Минем янәшәдәрәк ишетеп торуымны искәреп: – Татарский куда бы ни шло... – дип куйган булды. Мин ул чакта түгәрәк йөзле, шактый таза иңсәле булып күренә идем. Фикерсезлегеен йодрыгына күчерә күрмәсен бу, дип Двуреченский сагая калды бугай. Керендереп әйтергә иде хәзер, тел юк шул, тел юклык сулышны буа, рухны үтмәсләндерә. Тел генәме, милли аң-зиһен дә бирелмәгән. Эчтән зәгыйфь тоемлау, үз-үзеңне бөтенләй салып таптатмау ихтыяры гына шәйләнә. Аннары армия тормышында милләтара низаг чыгу – иң хәтәр нәрсә. Мондый очракта хәтта үзен славян кавеменнән дип йөрткән руска да, украин-белоруска да ташлама ясалмый. Устав каршында барың да тигез хокукта. Армиянең бөтенлеген, бердәмлеген кайгырту өчен катгый таләпләр куелган. Без олы учакта бергә кайныйбыз. Ә инде милли төсмердәге вак кына чәкәләшүләр – шул учактан чәчрәп сүнәсе очкын бөртекләре генә... Шулай да, милләткә кагылышлы фикерләр күбрәк руслардан чыга, алар синең рус түгеллегеңне һәрдаим искәртеп торалар һәм бу искәртүдә күрәлмау түгел, күбрәк – экзотик аермалыкны ялкау акылның аңлыйсы да, танышы да килмәү мин-минлеге ята ахрысы.

***

Билең генә түгел, күңелең дә каеш белән кысып буылган. Ялгыз калып моңаерга һич ирек бирмиләр. Унтугыз елга сибелгән гомер сәхифәләре ышанып булмаслык ераклыкка чигенде дә куйды. Шаккатып уйлыйм: язмышның кисәк кенә тамырдан үзгәрүе в а к ы т дигәнне куркытамы әллә... минем бит туган яктан киткәнемә күп тә үтмәде югыйсә, ә арада – аргы яры томанга уралган упкын... Бер йомарлам хәтер генә яшьлек кырларында җәяүле буранга кушылып, сукбай булып йөри, ә миңа якын килергә ятсына бугай...

***

Күк йөзен парчалап, якты кар яуган көн иде.

Ниһаять, читлек эчендәге җан канаты куанычлы сулкылдап куйды.

Менә ул – карлы киңлекләр аша мине эзләп килгән беренче хат! Бер өем хат арасыннан сикереп чыкты да учыма кереп оялады. Конверт тышында унынчы класс укучысы Фәниянең самими хәрефләр тезеп язу рәвеше күзне иркәли, мин аны мең төрле язу көшеленнән дә танып алыр идем. Менә хәзер, аулаграк тәрәзә буена барам да... Кагылма миңа, сугылма миңа, болгавыр солдат кавеме, учымдагы бәллүр күбәләкне төшереп ваттыра күрмә!

Хатны ачмыйча, татлы көттерү газабын кичерүне озакка сузарга түземлегем җитми. Кара инде, бизәкләп эшләнгән махсус кәгазьгә язган бит. «Исәнме, бәгырем минем!» дип башлаган. Юк ла, арттырам. Бәгырем урынына исемемне куйган. Алай ук назлылана белми ул. Ялгызак исемем үзе генә суыграк тоелыр иде: «...ем минем», дип, исемгә ягымлы койрык өстәгән бит.Хат гади генә. Йолдыз уйдыклары эзләп күккә дә менмәгән, хыял дәрьясына китеп адашмаган да... «Бөгелмә аэропортына озата бармаганыма үкенәм.Үкенсәм, берәр нәрсә буласын көт тә тор. Кичә, мичкә ягарга утын алып кергәндә, бармагыма шырпы кадалган. Шешеп чыкты. Сулкылдап авырта. Йөрәк сулкылдавы бармакка күчте бугай...

...Кичер мине, ачуланма, икебез генә белгән серне әнигә чишәргә туры килде. Иртән, карда калган эзләребезне күргән дә, эти уянганчы дип, ишегалдын көрәп куйган. Аннары миннән сорау алырга тотынды: «Кем? Ничек? Нишләдең син?» Шуннан соң барысын да сөйләп бирергә туры килде. Шаккатып тора.Башсыз икән, ди синең турыда. Яратып, әлбәттә... Бу хакта беркемгә дә тишмә, әни, дип «ант» иттерергә теләгән идем дә... Әни бит ул, ничек инде әнигә ышанмыйсың ди, шулай бит!

...Фаварис дустыңны да иң соңыннан алдылар – бөтен яшьтәшләрең дә армиядә хәзер. Бу көннәрдә мин үзем бер штабка әвереләдем. Дусларың адресыңны сорап, әллә кайлардан миңа хат язалар...

...Иртәгә язарга да сүзләр калсын. Хуш, солдатым! Сагынып, Фәнияң.

6 декабрь,1965 ел.»

Менә щулай. Кулымда – өч ел буена барачак хатлар кәрванының беренче карлыгачы. Өч елның һәр көненә – бер хат! Моның гамәлгә ашасына ышануы да кыен. Алда бит әле үтеп чыккысыз гомер тавы. Чалып екмасмы язмыш...

Хат битендәге шундый мәктәби иплелектә тезелгән хәрефләр сәйләне артында мин генә белгән дөнья яңара: тавышы, күз карашы, чәч исе, кул җылысы, тыны-йөрәк тибеше һәм... артта калган эзләр... эзләр... эзләр... Бу хат миңа кадерледән дә кадерлерәк. Кисәтү дә, юату сагында торган эчкерсез – гади дога да бу минем өчен.

Тәрәзә каршында онытылып басып торам. Иренеп кенә кар ява. Яр астында әллә ничә тармаклы тимер юл челтәре. Себер ягына яшел вагоннарын сөйрәп поезд шуыша. Моңсу. Шулкадәр моңсу. Җан тарыга. Күзгә яшь килә.

Кинәт... Тып-тын күк йөзен алаңгыр карга каргылдавы умырып төшердемени – сержант Гаевскийның взводны тезелергә чакырган чорсыз тавышы яңгырады: «Выходи,строиться!»

Рәхмәт аңа. Солдатка уйланып тору – язык.

***

Телләргә «Ант» дигән хикмәтле сүз килеп керде. Бер селтәнүдә сөңгене кадап куйган кебек, кырыс-кыска, тирән мәгънәле, борынгы сүз. Бу сүзнең яңгырашы татарларга гына түгел, чувашларга да үз иде бугай. Сер йомгагы кебек бу сүзне без малай чактан ук ишетеп үстек бит. Халыкның зиһен сандыгында бу сүз аерым бер шомлы кадергә ия. «Ипи тотып ант итәм...», «Антымны бозсам, баскан урынымда җир ярылсын», «...Ике күзем чәчрәп чыксын!», «...Ризык чырае күрмим!» – тагын әллә ниләр...

Җиденче класста Туйкә мәктәбендә укыганда, сабакташ яшьтәшләр, авылга кайтышлый тукталып, ант эчкән идек. Кызыл галстукны таякка бәйләп, байрак итеп кададык. Шуның тирәли тезелештек тә дәфтәр битенә алдан язылган сүзләрне укый башладык:

> *«Мин – Ирек (Аксак Гәрәй малае), мин – Абрек (Җомай Вагыйз малае), мин – Әхсән (Бүре Сабит малае), мин – Фаварис (Керпе Җәңгир малае), мин – Зөфәр (Таз Зәки малае), мин – Халик (Чыпчык Хәлфи малае), мин – Марсыйл (Бакый Баян малае) – бердәм ант итәбез.*
>
> *Без – Балтач малайлары! Кая барсак та, Балтачтан икәнеңне онытмаска! Безнең ата-бабаларыбыз, җизнә-абыйларыбыз гайрәтле нәселдән. Йодрык сугышында тирә-юньне дер селкетеп, дан тотканнар. Шуларга тигезләник! Әгәр дә мәгәр чит авыл малае берәребезгә тырнак очы белән кагыла икән, бердәм булып, ул мокытның йонын язып ташларга! Белсеннәр безнең кем икәнне!»*

Шуннан соң, Мөкәтә тавына учак ягып, учларыбызны, пешәләндереп, ялкын өстендә тотып (каян күргәнбездер инде?) алдык, аннары, йодрыкларны чөеп, күк касыгына терәп кабатладык: Ант итәбез! Ант итәбез! Ант итәбез!

И җүләр чак. Без бит сугыш беткәч, илдә коточкыч ачлык котырган елны дөньяга килгән яшьтәшләр идек. Нинди могҗиза беләндер инде таза булып үстек. Өлкәннәр безне чиратлап көрәштереп җәфалыйлар, бер-беребезне җиңә алмыйча хәлдән таябыз, җиңдермәскә дигән үҗәтлектән кысылган иреннәргә кан савып бетә иде. Каян көч-дәрман килгән диген. Әз-мәз эләккән ризык та чын-табигый-бисмиллалы булгандыр шул. Ачы кукы, татар кукысы, тау юасы, кузгалак, балтырган, кымызлык, шома көпшә, кәҗә сакалы кебек сутлы үләннәрнең дә, капчыклап җыеп кайта торган киндер орлыгының да, учка сыймаслык зур башлы мәк орлыгының да, сарана кебек җир асты суганының да сихәте тигәндер, мөгаен...

Безнең бергәлек сигезенче классны тәмамлагач таркала башлады. Язмыш җиле һәркайсыбызны үз арбасына тартып алды. Сирәк кенә күрешкәндә, кайчандыр антлы ялкын өстендә тоткан учларыбыз гына кызышып алган кебек була иде.

Язмыш диген, бөтенебез дә ябырылып армиягә китеп бардык та, илнең әллә

кай тарафларына сибелешеп, Ватанга тугрылык хакында олы Ант бирергә җыенабыз менә. «Балтачтан икәнеңне, кече антыңны онытма!» дип, чит җирләргә таралышкан яшьтәшләргә Урал таулары аша кычкырасы килә.(Илле елдан соң, бу юлларны язып утырганда, һәрберсен күз алдымнан чигерәм дә... хәтер сыктый, яшьтиләр белән бергә җыелышып, мин онытканны – алар, алар онытканны – мин искә төшерешеп, хатирәләргә бирелергә иде хәзер... Юк шул инде... Нигә болай ашыктыгыз соң әле, дөнья мәшәкатьләрен читкә куеп, бер-беребезне соңлап булса да ярлыкау ызанына кайтып төшәргә иде дигән бәлигъ акыл кергәч кенә, ни үкенеч, җыела алмыйбыз шул. Нишлисең бит, безнең уртак хәтер агачының соңгы ботагы фәкать миндә генә калды... Шунысына шөкер: аларның берсе дә читтә гаип булмады, зиратның балачакта шом салып шаулаган мәһабәт, карт наратларына алмашка килгән яшь наратлар күләгәсенә кайтып, төп йортлы булдылар.)

*(Ант – антик дәверләрдән килгән хикмәти сүз. Меңнәрчә сүз хасиятенең яңгырашын, җан тибешен тыңлап, ис-төс-тәмен татып караган язучы буларак, мин бу сүзнең сәмави борынгылыгын җиде тирем аша да сизәм, тоям, икеләнмичә ышанам. Чагыштыру мисалында, хайванат дөньясыннан ташбака, фил кебек җәнлекләрне абайлап кара: күз карашлары, гәүдә төзелешләре, бирчәйгән тән-җисеме бу җан ияләренең туфани борынгылыкка ия икәнен раслап тора. Болар – миллион еллыклар белән исәпләнгән олпат вакыт гарасатыннан талкынып исән калган варислар... Шуның кебек, сүзләр дөньясында да эчке мәгънәсе җуелмый торган, төшүзәге алмаз катылыгына тиң мәңгелек сүзләр була. Төрки-татар галәменең гаскәри «Ант» сүзе дә, әнә шулай, кыйтгаларны кичеп килгән.*

*Борынгы бабаларыбыз: сак-скиф, камәр, сармат, һун, хәзәр, болгар, кыпчак, татарларның гаскәр ташкыны өч-дүрт мең еллар буена, катгый тәртипкә буйсынып, ант белән беркетелгән тугры көчкә ия булган. Һәм байрак астында ант бирү, ант кабул итү – Шәрыктән кергән ритуал тора-бара Ауропа илләренә дә таралган.*

*Руска бу – присяга бирү, присяга кабул итү рәвешендә, патша Пётр Беренче дәверендә гамәлгә керә. «Дать присягу, клятву, призывать гласно и торжественно Бога во свидетельство, съ установленномъ церковью, обрядами, целуя святой крестъ и Евангеліе, присягать царю на верность подданства...» диелә патшаның күрсәтмәсендә.*

*Иске сүзлекләрдән карасаң, присяга сүзенең мәгънәсе болайрак: «Сяг» – адым, «Сягать» – эләктерү, ирешү дигән мәгънәләрне аңлата. «Стяг», ягъни «байрак» дигән сүз дә шуннан килеп чыккан. Гади генә әйткәндә, присяга – байрак астында сыңар тезеңә таянып ант бирү булган...*

*Пётр Беренче чорында ант тексты болай башланган: «Я (имярек), обещаюсь всемогущим Богом верно служить его Величеству Петру Первому...»*

*Шунысы гыйбрәтле: әгәр яугир-солдат ислам яки лютеран, яисә яһүд дине тотучы булса, ант итү ритуалын үз телендә, үз рухание катнашында башкарган. Ант бирүче мөселман солдат уң кулын ачык Коръән өстенә куярга, тантаналы сүзен тәмамлаганда исә гарәпчәләп: «Иншаллаһ», дип түгел, ә татарча: «Аллаһ теләсә» диярgә тиеш була.*

*1917 елда гаскәриләр Вакытлы хөкүмәт башлыгы Керенскийга ант бирәләр. Бусында инде «Осеняю себя крестнымъ знамениемъ» дигән*

*сүзләр бүтән диндәгеләр өчен үзгәртелә. Мөселманнар өчен текст болай тәмамлана: «...Заключаю сію мою клятву словами преславнаго Корана и нижеподписуюсь».*

*1939 елгы ант текстын РККАның (Рабоче-Крестьянская Красная армия) Баш хәрби советы әгъзасы И.В.Сталин үзе раслап кул куйган.)*

Безнең заман башка. Кинәт бәрелеп-сугылган очракта гына, үзебез дә абайламыйча, «Алла» дип, күк Иясен искә төшереп, сызлаган урынны ышкып куябыз да бик тиз онытабыз... Өлкәннәр әйтмешли, алласыз да, мулласыз да заманда ант иткәндә әйтеләчәк сүзләрнең дә эчтәлеге бүтәнчә яңгыраштa.

Башта без бер ай эчендә «Яшь солдат курсы»н үтеп чыгарга тиешбез. Моңа хәрби күнекмәләр генә түгел, спорт төрләре дә керә. Үземә-үзем шаккатам. Бөтен нәрсәне теләп, күңел биреп эшлим. Алдагы тормышымда күбесенең бөтенләй кирәк булмасын белсәм дә... кеше алдында ким-хур булмыйм, дигән читенсенү-оялу-мин-минлекме – нидер миңа булдыра алмаганны да булдыра алырдай көч бирә.

Әйтик, мин, турникта бер мәртәбә дә тартыла алмыйча, Юныс кебек көпшәк капчык сыман асылынып торсам... көнем көн булмас иде, үз гәүдәңне күтәрә алмаган килеш, ничек инде кызларга солдат хаты язмак кирәк...

Кайсы милләттән икәнең мөһим түгел – присяга биргәндә яңгыраячак текст (1960 елның 23 августында СССР Югары Советы Президиумы Указы раслаган) барыбыз өчен дә уртак рус телендә язылган иде. Шушы бер ай эчендә без аны яттан өйрәнергә тиеш. Шушы бер ай эчендә ротабыздан ике курсант төшеп калды. Берсе – кыргыз егете – Тактагулов. Шәһәрдән. Русча әйбәт белә. Казармада күренеп кенә ала да тагын госпитальгә салалар үзен. Икенчесе – үзбәк егете – Абдуллаев. Кышлактан. Русча бөтенләй белми һәм белергә дә теләми. Ни әйтсәләр дә елмаеп, тик үзалдына сөйләнеп тора. Теле ачылганчы сабый бала бүтән дөньялар телендә нидер бытылдый бит әле – Абдуллаевның да шулайрак.

Сәламәтлек буенча яраксызга чыгарып, боларның икесен дә туган якларына – кояшлы Урта Азиягә кайтарып җибәрделәр.

Владимир Бацын дигән егет белән якынаеп киттек. Без бит вертикаль күршеләр. Бер төптән чыккан караватыбызның өске ярусында ул ята. Ульян өлкәсеннән. Барыш районы Смольково авылыннан. Клуб мөдире булып эшләгән. Бик ипле егет. Сары төсне дә уздырган ак керфекле, ак кашлы, ак чәчле бу егет мине бер дә игътибарыннан калдырмый. «Син татарга охшамагансың, мин сине русча теттереп сөйләшергә өйрәтәм», ди. Берәр ялгыш җибәрсәм, читкәрәк алып китә дә кай урында ялгыш җибәргәнемне, рус теленең нечкәлекләрен аңлатырга керешә. Сүзләрне дөрес әйтәсең син, ди, төрләнештә хаталар җибәрәсең икән, монысы тәҗрибә белән киләчәк, ди. Присяга текстын кычкырып укыганымны бик игътибар белән тыңлап, кайда басым, кайда пауза ясарга кирәклеген аңлатты. Болай булса, көчле тавышым белән руслардан да шәбрәк укыячакмын мин моны, дип күңелемә беркетеп куйдым.

Тантанага чаклы парад киемемне – китель белән галифе чалбарымны тарайттырып, рәткә китерәсе бар бит әле. Мин дә төштем «халык сукмагына». Таш баганалы тимер койманың куаклар баскан бер урыны астан казылып, такыраеп беткән. Кичке эңгер төштеме – агыла шуннан курсант кавеме. Топольләр астында – муртайган такта түбәле өй. Анда япон сугышыннан сыңар аягын өздереп кайткан ветеран яши. Кушаматы бөтен телләргә дә аңлаешлы,

истә кала торган: Банзай... Гаҗәп оста тегүче. Кулына күз иярә алмый. «Зингер» машинасында текелдәтеп кенә куя.

Гозерем билгеле бит инде, сорашып та тормыйча ул калын дәфтәрен ачты да, җирән мыек чылгые астыннан иренен кыймылдатып нидер санаганнан соң:

– Тугыз көннән килерсең! – диде. Минем өметсез кыяфәткә керүемне күреп: – Нишлим соң, бер минем җилкәдә тулы бер батальон күзгә карап утыра, – диде. Бу хезмәте өчен такса өч тәңкә икәнен беләидем (чарасыз калганда кыюланып китә торган гадәтем бар), кесәмнән бишлек чыгарып өстәлгә куйдым:

– Миңа тиз кирәк.

– Бөтенесенә дә тиз кирәк, – дип сөйләнә-сөйләнә, ул калын дәфтәренә ниндидер билге төртте дә, калын кашын сикертеп: – Иртәгә – шушы вакытка! – дип, бишлекне өстәл тартмасына шудырып төшерде.

Икенче кичтә, урыны-урыны белән эчтән купшакланган борынгы көзге каршында парадный киемнән басып торам. Банзай, оста тегүчеләргә хас булганча, әле аннан, әле моннан тарткалап, сыйпап, гәүдәмне боргалап карады да, иелеп, кирза итекнең киң кунычына «Их» дип, чирканган кебек суккалап алды. Җитез генә үрелеп, шкафыннан хром итекләр тартып чыгарды. Кирәк бит, нәкъ минем аякка исәпләнгән. Гармун кунычлы ялтырап торган хром итекләр, һава калдырмыйча, балтырга сыланып тора. На «ять» инде, гәүдә торышы, рәвеш икенче. Җитмәсә, Банзай үзе: «Вот это солдат!» – дип үсендереп тора. «Ах, ах, ах!» – дип, иелеп, итек күрүгеннән бармакларын йөгертеп ала. Саласы килми генә бит итекләрне! Бераз гына киелгән булса да, өр-яңа кебек әле. Күне лә күне. Кулга рәхәт. Исе тәмле. Күпме киноларда офицерлар кигән шундый затлы хром итекне күреп кызыга идем, хыяллана идем бит мин. Банзай елмаеп карап тора. Сизә, затлы әйбергә тиз бирешүемне чамалый, минем өлгереп җитүемне сабыр гына көтә, каһәр. Итекләр аякка ябышкан, ничекләр кубарып алыйм – салып калдырсам... гомергә үкенечкә калачак бит.

Сатулашу минем холкыма ят. Егерме биш сум дигәне белән шундук килештем. Мондагы тугыз айлык солдат акчасы икәнлеге башыма да килми, мин бит әле кайчан гына бүтән тирәнлектәге акча күлендә йөзгән малай... Шулай итеп... Юлий Цезарь бабаңчарак әйтмешли: «Күрдем, алдым, киттем».

***

Парад мундиры – куе яшел төстә, утыртма якалы, алтынсу төскә буялган биш сәдәфле. Билеңне бугач, дүртенче һәм бишенче сәдәфләр арасына йолдыз сугылган киң каеш аелы кереп утыра. Солдат телендә бу мундир, гадәттә, китель дип йөртелә. Банзай тарафыннан тарайтылып, гәүдәгә, билгә сыланып торган шул кителемне хәзер инде камиллекнең соң дәрәҗәсенә җиткерергә кирәк. Фабричный погоннар да, яка эченә тегәргә ак тасмалар да бирелгән. Әмма... солдатны эчтән һәрчак котыртып торган яшьлек фантазиясе моның белән һич тә килешә алмый. Бу шөгыльнең үз осталары, үз «Версачи»лары бар. Шулар тарата хәрби моданы.

Погон – хәрби киемнең көзгесе. Ниндие бирелгән, шуны тегеп куйсаң, мокыт буласың. Ул бит тупас, алагаем киң, калын булып, чабата олтырагы сыман бөгелгәләп, җилкә формасын алачак. Шуның өчен, иң әүвәл погонны бөтенләй сүтеп ташлап, тукымасын бастырып үтүклисең. Авиациядә еш кулланыла торган «плексиглас» дигән органик пыяла бар: җиңел эшкәртелә, киселә, шомартыла – тыңлаучан, гадәти пыяла кебек чәрексез түгел. Менә

шул юка гына плексигласны солдатлар куйган стандартка туры китереп кисәсең, үткен почмаклары тукыманы тарттырганда тишмәсен өчен, надфиль дигән үтә нәзберек игәү белән шомартып аласың. Аннары, бик төгәл үлчәп, башкаларныкын да кат-кат карап, тәмам ышанганнан соң гына погонның кирәкле урынына ике тишек тишеп калдырасың да... зәңгәр тукыманы тарттырып тегәсең. Теге тишекләрнең берсенә – сәдәф, икенчесенә авиатор билгесе беркетелә. Алтынсу төстә, җәелгән кош канатлары уртасына самолёт пропельлере куелган бу билге миңа бик тә ошый иде. Әле офицерлар гына тага торганы... пропельлер уртасында нәни генә йолдыз балкып торганын да куеп җибәрсәң... Ә нигә куймаска! Рәешкә кия торган киемең рәвешле булсын! Ә инде погонны җилкәгә туры-төгәл урнаштырып, җебе күренмәслек итеп ябыштырып тегә белү – үзе бер сәнгать. Моңа күпләр ирешә алмый. Тупас учында энә-җепне югалта торганнарга мондый нечкәлек бирешми. (Менә бит, хезмәт дәресе дип, башлангыч класста кулъяулык чиктереп изалаганнарының кайчан да бер файдасы тиде.)

Шулай итеп, казармабыз Парижның мода салонына әверелде. Кая карама – тегәләр, кисәләр, бозалар, бәхәсләшәләр.

Әнә, безнең взводның беренче отделение командиры Голованов погонына «лычка» тегеп утыра. *(«Лычка» дип погонга аркылы тегелә торган алтынсу төстәге тар тасманы атыйлар. Сержантныкы – өчәү, кече сержантныкы – икәү, ефрейторныкы берәү була.)* Голованов – Себер егете, Новосибирскидан. Борыны тумыштан чөенке бу егет үзен бик зур дәрәҗәгә ирештем дип уйлый. Отделение командиры буласың, дигәч, күз алдында ул бер буйга үсеп китте. Әнә бит, кителен киеп, лычкалы погоннарын сыйпый-сыйпый, әле уң ягына, әле сул ягына борылып, көзге каршында көязләнә. Канәгатьлектән бит очлары алланып чыккан.

Ефрейтор дәрәҗәсе – солдат тарафыннан көлкегә алына торган иң түбән дәрәҗә. «Собака – друг человека, сказал солдат, обнимая ефейтора», – дигән йөремсәк сүз дә юкка гына тумагандыр. Командир булырга, гадәттә, хохоллар ярата. Тавыш, «горлопан»лык шәп, гәүдә бар, башны эшләтү әллә ни кирәкми, оялчанлык аларга хас түгел. Әгәр инде хохол егете өч ел хезмәт итеп, ефрейтор булуга да ирешмәсә (бу – нонсенс), станицасына кайтып җиткәндә, ул, туктап, погонына бер лычка булса да тагып куя икән, дип көләләр иде алардан. «Хохол без лычки, справка без печати» дигән әйтем дә хәтердә калган.

Әнә минем икенче отделение командиры Колоколов Пётр Онуфриевич сабыр гына караштырып йөрде дә, погонын ничек бар, шулай текте дә куйды. Ул да Себер егете, тайга уртасындагы бер авылдын. Чырае, башын тоту рәвеше дөянекенә охшаган. Нииндидер күзгә күренмәс киштәгә ияген таяндырган да күзен кысып, көлсу керфекләре арасыннан дөньяга түгел, ә үз-үзенә карап тора. Беркайчан тавышын күтәрмәс, кызып китмәс. Муртайган салам түбәле ызба шикелле бик иске дә, бик борынгы да булып тоела ул. Текәлеп йөзенә карап торсаң, ул күзгә күренеп олыгая бара, олыгая, төгәл яшен дә аерып булмас шикелле, кайчакта онытылып елмаеп куйганда гына аның яшь кеше икәнлеген искә төшерәсең. Нииндидер ямансулык, беркем белән дә бүлешергә җыенмаган яшерен сер бар кебек бу егеттә...

Һәм бу сернең бер чите көтмәгәндә ачылып китте. Минем рус телемне энә күзеннән үткәзеп тыңлый белгән Володя Бацын белән гәпләшеп утырабыз шулай...

– Син мине татарга охшамагансың, дигән идең. Татар нинди кыяфәтле булырга тиеш соң синеңчә?

Бацын бер мәлгә аптырап калды, як-ягына каранып алды да, кызарып:

– Нинди дип... Кысык күзле, җәлпәк йөзле итеп ясыйлар бит рәсемгә. Татар шундый булырга тиеш, дигәнгә күнеккәнбез инде.

– Менә безнең ротада гына да егермедән артык татар бар. Шуларның берәрсе син әйткәнгә туры киләме?

– Революциягә кадәр татарларның күзе кысык булган. Революциядән соң...

– Кинәт ачылып киткәнме? Монголиядә дә революция булды. Нишләп соң монголлар кинәт европалылар кыяфәтенә кермәделәр?

Бацын үзе дә көлеп куйды. Мин һаман эзәрлеклим тегене:

– Менә син игътибар белән кара әле: ротада җитмешкә якын рус бар. Аларны тезеп карап, рус кешесе менә шушындый булырга тиеш, дигән эталонга кертә аласыңмы? Берегез – кап-кара, берегез – сары. Берегез – җирән, берегез – көлсу. Илдә ике йөзләп милләт кешесе яши, шуларның бөтенесенең дә чалымы бар бит руста, шулай бит!

– Сине үз башыма дип русчага өйрәтәм, ахрысы, – дип Бацын көлеп куйды.

– Шулай да... Бөтен ротага ике охшаш рус егете бар. Кыяфәткә димим. Үз-үзен тотышы ягыннан. Сүгенә белмиләр. Аларга тыныч холык, эчкерсезлек хас. Кирәк чакта үз-үзен онытып ярдәмгә килә беләләр.

– Кемнәр инде ул?

– Берсе – янәшәмдә утыра. Икенчесе – безнең отделение командиры Колоколов дигән егет. Погонын да үзгәртмичә, кителен дә, галифе чалбарын да тарайтмыйча киеп йөрүче бөтен ротага икәү генә бит сез. Уставны бозмыйсыз, янәсе... Сине әле күпмедер аңларга була. Ә Колоколовның эчке дөньясы тайга урманы белән уратып алынган.

Бацын миңа табарак елышып, иренenә бармагын аркылы куйды, ярымпышылдап:

– Петя, сын Онуфрия – старовер... Бу хакта беркемгә әйтәсең булма! – диде, күзендә шомлы очкын ялтырап куйгандай булды. Гомеремдә бер колагыма чагылмаган бу ят сүз минем аң-зиһен бусагасында бүәлеп калды. Володя нидер аңлата башлагач та, мин әле битараф халәттә, теләр-теләмәс кенә колак салган идем дә... Староверлар шул ук христианнар, әмма динне борынгы заманнарда кабул иткәнчә, ягъни искечә тотучылар икән. Яңа кануннарга буйсынырга теләмичә, үз пакьлегенә тугры калып, күпме җәбер-золым кичергәннәр. Туган җирләреннән сөрелгәннәр. Утка-суга кергәннәр, башларын бүкәнгә куйганнар. Чит илләргә чыгып китәргә мәҗбүр булганнар...

– Аларның тәрбия башка, – диде Володя. – Җинаять кылу, явызлыкка бару – аларда күрелмәгән хәл...

Ул сөйли дә сөйли, керфекләренә эленгән яшь пәрдәсен күз кабаклары чак тотып тора. Пышылдап ул миңа бәгырь авазын җиткерә иде. Мин тетрәнеп уйга калдым. Бәләкәй чагымда әбидән ятлап калган бер-ике дога белә идем, алар да инде онытылып бара. Мин аның кирәген дә тоймыйм. Кадими кара ябалдашлы дин агачы күзгә күренеп сула бара һәм ул, тамырынача төшеп, бөтенләй корып бетәргә тиеш дип уйлый идем. Бу дөнья мин гөманлаганча берьяклы гына түгел, русларда әнә нинди катламнар бар икән. Болар, безнең кебек, уңнан кычкырсалар – уңга, сулдан кычкырсалар – сулга ияреп китә торган беркатлы-аумакай түгел. Болар арасында күңелдәге үз ышанычын саклый белгәннәр дә бар икән...

Ни әйтә алам соң мин Володяга, сүз бит Петя Колоколовтан чыкты да менә нинди юнәлеш алды. Бәлки, Володя үзе дә берни әйтә алмасымны белгәнгә

миңа боларны сөйләп, бөтенләй чит кавем кешесенә ачылып алырга теләгәндер. Аптырагач мин, Володяның җаена төшәргә теләпме, әйтеп куям:

– Бөтен ротага чын рус сез икәү генә, димәк...

– Чын, димә, славян канлы, диген... – дип төзәтеп куйды Володя.

*Үз ышанычын саклый белгәннәр... дигәннән, Мәскәүдә Максим Горький исемендәге Әдәбият институтының Югары курсларында укыган чакта (1982-1984) группада Владимир Соколов дигән шагыйрь бар иде. Ерак Көнчыгыштан. Озын буйлы, калынча гәүдәле. Үзе бик тыйнак, юк-бар әңгәмәләргә, мәҗлесләргә катышып, вакытын юкка исраф итми. Биниһая озын поэмалар яза иде бугай. Стипендия алуга (150 сум), өенә тәм-томнар җыеп посылка сала, үзе ай буе такы-токыга калып яши иде. Бервакыт без группа белән Ленинградка, берничә көнлек сәяхәткә бардык. Шунда, шәһәр читендәге бер бик матур урында, Павел патшаның җәйге сарае бар икән. Ялтыр паркетлы идәненә зур тәрәзәләрдән якты төшкән заллардагы экспонатларны карап йөргәндә, мин кечкенә генә бер картинага тап булдым. Билгесез рәссам ясаган. «Обрезание Христа» дип атала. Милләте рус булуына шикләнмәгәннәр арасыннан мин Соколовка дәштем. Алгы тешләрен алдырып, әлегә куйдырырга өлгермәү сәбәпле, авызын каплабрак сөйләшергә мәҗбүр Соколов яныма килеп баскач, чүпрәк арасында яткан сабый сурәтенә күрсәтеп:*

*– Сез, руслар, нишләп аллагыздан үрнәк алмыйсыз, сөннәтләнгән ираттан көлгән буласыз җитмәсә? – дигән идем, Соколов, чирканган сыман, чыраен чытып, картина яныннан артка чигенә башлады:*

*– Хриштош не наш, Хриштош не наш!..*

*Соңыннан белдем: ул мәҗүсилек яклы, Перунга табына икән...*

***

Беренче тапкыр авызлыклы йөгән кигезү көне тайның исендә кала микән? Ә менә яшь солдатның анты, присяга бирү көне гомер бокрасында уемлы эз калдырадыр.

Кар көртләрен үтәли яктырткан кояшлы көн иде ул (1965 елның 19 декабре). Иртәнге физзарядка, иртәнге аш, иртәнге әзерлекләр – бар да ниндидер җилкенү дулкынында барды. Мәш киләбез. Күн итекләр күзгә кебек ялтыратылган. Кайберәүләр хәтта кирза итекнең мәңге тонык, ярмалы кунычын да ялтырату осталыгына ирешкәннәр.

Пирамидалар ачып куелган. Һәркем үз карабинын алып, маеннан чистарта. Ниһаять, соңгы команда яңгырый. Рота уку корпусларына юнәлә. Дүрт взводны дүрт класска бүләләр. Каушау. Дулкынлану. Таркаулык. Ярый әле командирларның кыска-кискен әмерләре аң-зиһенне кирәкле ноктага кадаклап тора.

Карабинны «К ноге!» куеп, бер сулышка, бер ритмдагы йөрәк тибешенә көйләнгән взвод каршына чыкканда инде син үзеңә-үзең хуҗа. Кызыл келәм өстеннән тантаналы атлап өстәл янына киләсең. Һәр хәрәкәтең төгәл, ипле, тәвәккәл булырга тиеш. Уң кулыңда кызыл катыргыга беркетелгән ант тексты. (Мин аны яттан беләм, дип әйтә алмыйсың, карап укырга тиешсең.) Сул кулың – күкрәк турына кыеклап асылган карабинга тотынган... Каршыда кыл кебек тартылган взводташлар сафын, командирларны күрәм дә, күрмим дә шикелле. Гүя минем шушы мизгелдә яңгыраячак һәр сүзем Мәскәү Кремленең үзенә барып җитәчәк. Дулкынлану соң ноктасына җитә...

– Я, гражданин Союза Советских Социалистических Республик...

Никадәр мәһабәт, колачлы сүзләр бәйләме! Сүзгә сүз ияреп, сине нииндидер олылык чоңгылына урап ала. Күңелне чиксез горурлык били. Мәктәп диварында эленеп торган биниһая зур СССР картасын күз алдыма китерәм.Ярларын өч океан хасиятеннән чыккан унике диңгез юган ил бит ул! Ничә меридианга бүленгән шул олылык уртасында минем дә туган җирем, республикам, туган халкым бар. Шуларны сакларга, якларга ышаныч баглатып, бүген мин ант итәм.

Димәк, мин олы вәгъдә бирерлек яшькә җиткәнмен. (Әлбәттә, мин кайчан да булса йөзләрчә милләтләрне сыйдырган ил исеме үзгәртелер дә, бер генә милләт атамасы торып калыр, һәм аны көненә мең мәртәбә колакка тукып торырлар, дип башыма китерми идем ул чакта.)

Шулай итеп, без армия дигән монстрга күзгә күренмәс чылбырлар белән бәйләнеп куйдык. Истә калырлык, тантаналы итеп. Оркестр астында, батальон белән парад үткәреп. Ашханәдә ризыклар да бәйрәмчә иде. Бусы инде солдат өчен иң мөһиме...

Кичен безне беренче мәртәбә шәһәргә алып чыктылар. Зур концерт карадык. «...Адресованная другу, ходит песенка по кругу, потому что круглая земля», дигән җыр яңгыраганда, күздән яшь килде. Мин шаккатып калдым. Моңарчы рус җырларына битараф идем. Җырчысы да нинди бит: яшь, хәрәкәтчән. Нинди чиста, матур тавыш. Мин бер-бер артлы гаҗәеп җырлар башкарган артистның Эдуард Хиль икәнен истә дә калдырмадым. Шул көндә русның заманча эстрада җырларына колагым ачылды. Сүзен-көен тыңлый, кабул итә, аңлый белә башладым. Алар миңа сагыну дәвасы булып, еракта калган татар җырларын алыштырдылар.

Бацын рус теленнән «дәресне» хат яздырудан башлап җибәрмәкче булды. Авылында Валя исемле бик чибәр кыз – писаная красавица бар икән.

Шуңа хат язарга утырдык. Ул әйтеп тора, мин язам, имеш. Володя шундый хискә бирелеп, дулкынланудан күзләрен кыса төшеп, матур сүзләрне тезә генә, әллә соң бу Валяга үзе күз атып йөргәнме, әйтә алмыйча калган фикерләрен минем аша җиткерергә телиме, белмәссең. Ни генә булса да ошамый миңа бу шогыль.

Барып җитте микән дип торганда, хат килеп тә җитте. Конверт тышына «Салиеву» дип язылган. «Г» хәрефен артык тырышып, бизәкләп сырлаган идем, Валя аны «С»ы дип аңлаган, күрәсең. Яңадан хат язмаска менә дигән сәбәп булды бу. Үпкәләгән рәвеш чыгардым. Икенче хатта Малиев, өченче хатта Шалиев булырмы дип, чын-чынлап үпкәләвемә Володяны ышандырдым шикелле.

Шуның белән хат язу дәресе тукталды.

## Карабин

Хыялда – автомат тотып карау, автоматтан ату иде дә бит... ә безгә карабин бирделәр. Һәркемнең үз номеры. «Тревога» вакытында кайсы пирамидада, кайсы ояда коралың – син аны буталмыйча, йокылы күз белән дә секунд эчендә таба белергә тиешсең. Карабинны беренче тапкыр иңгә аскач, штыгын да кайтарып куйгач, шыксыз озын булып тоелды. Ленин янына килгән «Мылтыклы кеше» картинасын хәтерләп, революция солдаты булдык, дип бер-беребезгә карап көлешәбез. Шушы кадими корал ярамаган тагын авиациягә дигәннәр, ахрысы.

Әмма ашыгыбрак хөкем чыгарганбыз икән. СКС (самозарядный карабин Симонова) карабины 1949 елда гына ясалып гамәлгә кергән. Автоматка

караганда төзрәк тә, ераккарак та ата. Бер минутка кырык пуля «төкерә» ала. Моны ГДР, Югославия, Мисыр, Албания, Намибия, Куба, Төньяк Корея, Лаос кебек илләр күпләп алдырталар икән. Тышкы рәвешен бераз үзгәртеп, оптик прицел куелганы – хәтта АКШ кебек илдә дә аучыларының яраткан коралы ди.

Боларны белгәч, карабинга карашыбыз үзгәрде. Күзне бәйләп тә минут эчендә сүтеп-җыярга өйрәнгән коралыбызга хөрмәт-ышаныч артты. Полигонга чыгып, атып та карагач, инде бөтенләй яратып өлгердем. Коралга ышаныч – солдатның ярты бәхете. Корал белән эш итүнең нечкәлекләренә өйрәнә торгач, бер нәрсәгә төшендем: ялгышып та, шаярып та мылтыкны кешегә каратып төбәргә, курогына басып уйнарга ярамый. Оясында патрон онытылып калган булырга мөмкин. Бу хакта армия тарихында булган йөремсәк хәлләрне командирлар гыйбрәт итеп сөйләп, гел искәртеп торалар.

Коралны сыйпап, чистартып, тәрбиядә генә тотарга кирәк. Шул чакта гына ул – синең тугры аркадашыңа әверелә, саксыз, дорфа кагылуны, җиңел акылллылыкны ул өнәми, кыерсыттыңмы – бер мизгелдә мәңге үкенечкә каласы шартлау яңгырарга мөмкин.

Тәрбия алымы – куркыту аша ныгытылса гына, гомерлеккә уелып кала. Мин менә шул курку-сагаю тойгысын карабинның затворына тотынган вакытта ничә тапкырлар кичердем. Әмма ул бик акыллы эшләнгән. Беркайчан да үзлегеннән атылмый.

Йомшак чүпрәк белән сөрткән чакта, мин аңа игътибар белән карыйм. Салкын корал дип, юкка гына атамаганнар. Металл өлешләре чынлап та салкын бит. Ә түтәсе җылы. Суга, дымга бирешми торган чикләвек агачыннан эшләнгән. Урта Азия, Шәрекъ илләренең күпме чикләвек агачлары автомат, ау мылтыгы, винтовка, карабин түтәләре ясау өчен кырылгандыр.

Мондый дәһшәтле коралга мәҗүси тартылу каян килә адәми затка? Кадими дәвердә, киек җәнлек артыннан куа килгәндә, үзе дә сизмичә, иелеп, очлы ташны кулына алуыннанмы? Скиф бабаларыбызның ук белән җәя уйлап табуларыннанмы? Каян килә?

Нишләп әле мин шушындый үтерү коралына ихтыярсыз сокланып утырам?.. Үзеңә беркетелгән коралны мактарга, көенә генә торырга кирәк. Югыйсә, үпкәләтүең бар. Үпкәләттеңме – үч алырга да күп сорамас.

Бу карабинга мин чиксез рәхмәтле. Синең аркада мин корал тотуның хәвефле җитдилеккә корылганына төшендем. Әгәр армия хезмәтенә үз вакытында алынмаган булсам, яшьлек ваемсызлыгы белән, саксыз кыланып, гомергә үкенечкә калырлык бер-бер фаҗига китереп чыгарган булыр идем. Аткан вакытта гына кызышсаң да, рәхмәт сиңа, салкын корал!

***

Без, сугыштан соң туган малайларда, көн тынычлыгын боза торган нинди дә булса шартлау китереп чыгарырга кызыгу шулкадәр көчле иде. Уеныбыз да күбрәк – сугыш уены. Акларга, кызылларга бүленәбез дә... Муенга агач автомат асып... Карны өеп, су сибеп катырып кальгалар ясап, төн куерганчы уйныйбыз. Кышның үз уены. Җәйнең үзенеке. Ни генә кыланмыйбыз. Җиз көпшәдән эченә шырпы күкерте тутырып ата торган «пугач» ясаулар дисеңме. Эченә дары тутырып, башы кысып чүкелгән гильзаны учак ягып, утка ташлаулар дисеңме!

Дустыбыз Зөфәр каян өйрәнеп алгандыр, өйдәге учак күмере өстендә ул ике табаны берьюлы кыздырып ала да, табаларның төбен-төпкә куеп, арасына кургаш чыбыкны тураклап сала. Өстәге табаны, көч куеп, уңлы-суллы

әйләндерә башлый. Кайнар таба арасында кургаш кисәкләре йомшап, түгәрәк ядрәләргә әверелә. Хәзер инде без коры дары гына шартлатмыйбыз, ә ядрә дә тутырылып, ачык башы чүкелгән гильзаны учакка ташлыйбыз. Бервакыт, бишенче класска Туйкә мәктәбенә укырга барышлый, Сталин межасы кырыенда туктап учак яктык. Күмере шәйләнә башлагач, эченә дары белән аралаш ядрә тутырылган гильзаны күмергә күмдек. Үзебез учактан читкәрәк китеп яттык та... көтәбез, көтәбез... Шартламый гына бит! Синең әфсенең, син уйла, дигән кебек Зөфәргә карап-карап куйгалыйбыз. Бераздан Зөфәрнең түземе бетте, торды да, таяк алып, учакка таба китте. Без дә калкына башлаган идек тә, ул таяк башы белән гильзаны учак уртасынарак этте дә кычкырып җибәрде:

– Ятыгыз!

Җиргә капланып өлгердек микән, колакны тондырып шартлау тавышы яңгырады. Баш түбәбездән сызгырып, ядрәләр очып узды, учак күмерләре сибелде... Барысы да атылып бетмәгәндер, дигән курку белән җиргә ныграк сеңеп ятабыз. Зөфәрнең таяк очы аркабызга тигәч кенә башны күтәреп карыйбыз. Ул исән! Елмаеп тора:

– Бәхетегез, сезнең якка очты ядрәләр, – дип көлә.

Алтынчы класста укыган елны Зөфәр, пугач белән генә канәгатьләнеп калмыйча, җиз көпшәне агач сапка беркетеп, төбеннән шырпы сызгач, шартлап, көпшәсеннән ут бөрки торган пистолет ясады. Бу хикмәтне малайларга күрсәтеп, мактанмыйча калып буламыни. Дәрес беткәч, бер төркем малайларны ияртеп, Туйкәнең Сугышлы тавына мендек. Зөфәр пистолетын көйләп, шырпы сызган арада, бездән түбәнрәк класста укыган борча малай килеп керде бит каршыга, ул арада шартлау белән бергә көпшәдән ут бөркелеп чыкты. Битен каплап, бөгелеп төшкән малай, еларга кирәклеген дә онытып, катып калды. Без дә куркудан өнсез калдык. Зөфәр, малайның кулларын ачтырып битенә карагач, агарып чыкты. Кирәк бит, шырпы күкерте бөтен битенә сибелеп, тирегә батып кергән, хәтта, ачык авызы аша кереп, тел очын да яралаган булып чыкты.

Кызгылт-көрән сипкелле булып ул шулай бер-ике атна йөрде. Бите төзәлә барган саен, сипкел бөртекләре коела барды. Нидән болай булганын ул беркемгә дә әйтмәде. Әти-әнисенә дә, укытучыларга да – ләм-мим. *(Еллар үткәч, ул танк училищесын тәмамлап, офицер булыр. Украинада хезмәт иткәндә, учение вакытында, урманны чыккан чакта, командир буларак, иң алдагы танк люгыннан күзәтеп барган мәлдә... агач ботагы аның башын кыеп кына алган...)*

Дустыбыз Фаварис берсеннән-берсе чибәр биш апасы куенында үскәнгәме нәфис-нәзберек иде. Аны гел бала каратып җәфалыйлар. Шулар белән ул курчаклы уйный. Чигү чигә. Башлангыч мәктәптән үк бию түгәрәгенә йөри башлады. Тальянда уйнарга өйрәнде. Бөтенләй кыз кешегә әйләнеп бетә күрмәсен бу дип, без аны апалары куеныннан каерып алып уенга алып чыгып китәргә җай гына эзлибез.

Зөфәр белән аңа ук, җәя ясап бирдек. Атарга да өйрәнеп алгач, Фаварис бу коралны бик ошатты. Әмма апалары юк итәр дип өенә алып кайтмады, минеке белән бергә безнең сарайга яшереп куя иде. Беркөнне безнең ишегалдында тимер-томыр белән машиналы уйнадык та, машина тавышы чыгарып гөрелдн торгач, башларыбыз түнә башлады. Өчебез дә, Мөкәтә тавына йомран ауларга барабыз дип, ук белән җәяләребезне алдык. Тегеләр җәя бавын тарттырыпмы матавыкланган арада, мин чирәмле ишегалдыннан капкага таба киттем. Келәгә тотынам гына дигәндә, кулымны корт чактымыни! Ул арада Фаварисның куркынган тавышы ишетелде. Карасам... Кул аркасын тишеп кергән ук уч төбенә бәреп чыккан. Фаварис арттан төзәми-нитми генә атып җибәргән

икән. Куркудан сүз дә әйтәлми тора. Мин үзем дә чарасыз. Әлеге укны үзем игәү белән бик тырышып очлайткан идем бит, дигән үкенүле уй гына узды күңелемнән. Зөфәр килеп җитеп укны суырып чыгарды. Укның тәнгә керүе түгел, чыгуы авырттыра икән. Әллә ни кан да күренмәде шикелле... Һәрвакыттагыча, күпбеләм Зөфәр:

– Ярый әле сөягенә тимәгән, – диде. Кимерчәк арасына эләккән. Фокусниклар кулның нәкъ менә шул турысыннан юан энәне үтәли чыгаралар бит, каны да күренми.

Фаварисның ул курач-юка гәүдәсен җилфердәтеп алды:

– Син күрше бакчадагы ботакта утырган чыпчыкка төзәгән идең бит, әйеме? Төзәп тә куйгансың, ә! Ворошиловча төз атучы... – дип мыскыллап көлде.

Мин дә кушылып көлгәч, Фавариска да җан керде. Ярага туфрак сиптек тә су буена төшеп киттек. Анда инде Мөкәтә тавын инештән аксыргаклы тугай гына аерып тора.

Унөч яшьләрендә микән, Зөфәр чып-чын ау мылтыгына ия булды. Тотып-тотып карыйбыз, иске булса да, мылтык мылтык инде: авыр, серле, соклангыч та, куркыныч та шикелле...

Олыларга ияреп, ул үрдәк атарга да йөргәләде. Хыялы – бүре ату иде. Бүрегә атап ясаган саллы ядрәне дә учына куеп күрсәтте.

Ә беркөнне бу ядрә белән көтелмәгән хәл булды. Зөфәрнең әтисе Зәки абзый балта эшенә бик чос түгел иде. Ихатасын да итәге ачылмаслык итеп кенә каккалап-суккалап торган була шунда. Бервакыт ул турылапас капкасын яңартты. Юан юкә бүрәнәсеннән салдырылган кайрыларны турайтып, өстенә әйбер бастырып киптергән булганнар, шуларны каяндыр юнәтеп кайткан да бу, турылапас капкасы ясарга керешкән. Ул капканы күргәч, без шаккатып калдык: тәбәнәк кенә аратага кадакланган кабыкларның биеклеге өч метрлар булыр, мәзәк булып, сураеп тора.

– Менә, әти безнең мирдә юк капка ясады, – дип Зөфәр көлә. – Кабыкларны кыскартып, өстән тигезләп кисик, дим, мине якын да китерми, ни беләсең син, ди. Әтәч биеккә менеп кычкырсын, бөтен авыл ишетерлек итеп, ди.

Менә шул сураеп торган кабык такталар Зөфәрне чак харап итми калды. Әтисе өйдә юк чакта Зөфәр мылтыгын алып чыккан да, биш-алты метр ераклыктан торып, шул капканың иң озын кабыгына төбәп атып җибәргән. Ядрә шартлап тиюгә, кабык артка бөгелеп киредән турайганда, шул ук көч белән ядрәне чирттереп җибәргән. Күкрәк турына ядрә килеп тиюгә, Зөфәр һушы китеп егылган. Бәхеткә, энисе Гаянттәйнең өйдә чагы булган.

Зөфәр Азнакай шифаханәсендә өч-дүрт көн ятып чыкты. Зәңгәр күзле, саргылт чәчле, аксыл тәнле Зөфәребез тагын да агарып калган иде.

– Калын кабыкны тишеп чыга ала микән, дип аткан идем... Ялгыш... Бүрегә дигән патронны алганмын, – диде ул гыжылдавык тавыш белән. Элек тә вакыт-вакыт тавышы карлыгып киткәли иде, хәзер инде бөтенләй тоныгаеп калган. Күкрәге марля белән катырылган. Шул турдан тәненә әллә нинди төсләргә кергән күгәргән эз җәелгән.

Шул вакыйгадан соң Зөфәр бүре ату хакында сүз чыгармады. Без ул чакта төрки-татар кавеменең бүзкорт, ягъни күк бүре – Ашинәдән яралган икәне хакындагы риваятьне белми идек әле. Ә бит халыкта бүрегә карата нindидер мәҗүси хөрмәт, куркуны җиңеп, эчтән олылау тойгысы сизелә иде кебек. «Авылга бүре төшкән, фәлән сарыкны буган», дигән сүзләр дә, ярымпышылдап, ниндидер күзгә күренмәгән рухны рәнҗетмим дигән шикелле, сагаеп кына, күршедән-күршегә хәбәр ителә иде. Курку – бәлки, безнең урманда бүредән

дә көчле җәнлек булмаганнан киләдер, табыну – бәлки, безгә борынгыдан, буыннан-буынга кан аша биреләдер...

Берәр шуклык кылсам, өлкәннәрнең мине: «Әй, бүре маңгай!» дип үртәп кычкырулары да, нишләптер, кимсетми, ачуны китерми иде, фәкать тере бүрене якыннан күрәсе, маңгаеннан сыйпап карыйсы килү теләген генә котырта иде.

Бүрегә дип арнаган ядрә Зөфәрнең үзенә тиде бит әнә, ихтимал, бу – өстән Күк иясенең, кисәтеп: «Кагылма урман патшасына. Тимә, яшәсен!» – дип бармак янавы булгандыр.

Азнакай мәктәбендә тугызынчы класста укыган чакта, мин Салихә әбинең таш сараеннан бер кап капсюль табып алдым (капсюль – патрон төбенә куела торган шартлаткыч пистон). Таш җөенә кем, кайчан кыстырган диген, капны ачсам, кул да тимәгән капсюльлар күзге кебек ялтырашып тезелгән. Капның бер почмагы гына дымланган ахрысы, яшел кунык капланганнары да күренә. Безнең телдә кәпсүл дип аталган бу хикмәтне Зөфәргә күрсәткәч, күзе кызды малайның. «Нәрсәгә алышабыз?» – бу безнең арада йөри торган таушалып беткән сорау. Ул елларда акча йөзен безгә бик күрсәтми, шуңа күрә без, хәзергечә әйтсәк, бартер белән шөгыльләнә идек. Бу кәпсүлләр өчен Зөфәр дустымнан ни каерырга дип торганда, ул:

– Менә бу ялтырап торган рәттән – берне, менә бу тутык йөгергән төшеннән – берне алып патроннарга куям, атып, сынап карыйбыз, – диде.

Бәрәңге бакчасы ягына чыктык. Зөфәр агач көрәкне сап ягы белән карга кадап куйды. Шәмәхә каләм белән көрәк йөзенә эреле-ваклы түгәрәкләр ясады. Ара ун адым. Иске тун кисәген карга җәеп, беренче булып үзе атып карарга булды.

Гөрс! Бар да тәртиптә. Кәпсүл үзен аклады. Чират – миңа. Җайлабрак ятыйм дип сузылганда күрәм – янәшәдәге сарайлар тезмәсе артыннан Зөфәрнең күршедә яшәүче җизнәсе күренде, арасыннан эт йөгереп чыгарлык камыт аякларын иплэп кенә атлатып болай таба килә.

Мин мылтыкны төбәп, курокка бастым. Тып-тын. Шылт иткән тавыш юк. Мылтык җансыз.

– Булмады бу! – дип, мылтыкны сыңар кулыма алып калка башлаган идем... Кинәт, гөрселдәү! Алагаем көч белән кулны каерып, иңгә китереп бәрде ки, үзем дә сизмичә мылтыкны төшереп җибәрдем. Күрәм, Идият абзыйның башына пыжлар коела, мылтык, каерылып, нәкъ ул килеп яткан якка атылган икән. Өчебез дә берни аңышмыйча, ни үле, ни тере хәлдә катып калдык. Идият абзый, ниһаять, исәнлеген белдереп, чебен кугандай, иңенә кунган пыж-кәгазь кисәкләрен кагып төшерде дә:

– Ата яздың бит, Баяныч, – диде. Кесәсеннән папирос кабы чыгарып, берне кабызды. Кулы сизелер-сизелмәс кенә калтырый иде. – Пуляң колак яфрагына тиеп үтте бугай, бүрегә дип кормаган идеңме? – дип, киная белән Зөфәргә ымлады. Идият абзый гадәттән тыш сабыр, тыныч холыклы шул. Берәү булса, йөгереп килеп сугып егар, мылтык түтәсе белән берне бирер иде.

– Яңа кәпсүлләр сыный идек, осечка килеп чыкты, бәясен төшерергә туры килә инде, – диде Зөфәр.

Бу вакыйгага ничә дистә еллар үткән инде, ату коралына тотынган саен, шул мизгел искә төшә дә... күңел сискәнеп куя. Секундның күпмедер өлешендә тоткарланып атылган патрон нинди фаҗига ясап куярга мөмкин иде бит. Чынлап та, булмый калдымы соң ул фаҗига, дип мин әлеге мизгелне кабат-кабат хәтеремнән әйләндереп, үз-үземне ышандырырга телим. «Ата яздың бит, Баяныч!» – киләчәктә аң бул, дигән кебек, тыныч кына кисәтә бу тавыш...

Ә инде унберенче классны тәмамлап, эшкә урнашкач, ике винтовка ике кулыма үзеннән-үзе килеп керде. Берсен авылга алып кайтып куйдым, икенчесен конторадагы кечкенә генә кабинетымда шкаф күләгәсенә, почмакка сөяп куйдым. Утлы корал тотуның җаваплылыгы, аны бикле сейфта сакларга кирәклеге хакында да бер кәлимә сүз әйтүче булмады. Мин дә кече калибрлы винтовканы малай чакта ясап мәш килгән «пугач»ларның дәвамы итеп кенә санадым.

Авылдашым Фәрит абый («Чёрный») район үзәгендә, ДОСААФта эшли иде. Ул миңа 100 кап патрон алырга язу бирде. «Целевые... дигәнен ал, андые кыйммәтрәк, әмма шәп бәрә», – диде. Миңа кыйммәтлесе кирәк тә. Профком хисабына 100 кап патрон алып кайтып, биксез шкаф шүрлегенә тезеп куйдым.

Кече калибрлы винтовканың шул ягы әйбәт: аткан чакта ау мылтыгы сыман чорсыз «тибенми», ә пулясы, барыбер, төзәгән җиргә чыкылдап барып тия.

Африка саванналарында яшәгән булсам, беренче атып аударганым – күпме күзләрне кызыктырган берәр кыргый җәнлек булыр иде. Ә бездә... Ишегалды дөньясында... агач ботакларына утырышып, гөнаһсыз гайбәт сөйләшеп чыркылдашкан чыпчыкларга күз төшә инде... Чирканчык алуым шул булды: бер-ике чыпчыкны чүкеп алдым. Җансыз таш булып, лып итеп җиргә төштеләр. бернинди ләззәт ала алмадым, үкенү генә калды. Нәзберек гәүдәле кошка нигә дип аттым соң әле, җан кыйдым бит, дигән үкенү, еллар үткән саен, кайта-кайта хәтерне бимазалап куя.

Тилгән атарга кызыгып, әллә ничә тапкыр талпынып карадым. Кесә тулы патрон, үземнән бер-ике-өч яшькә кечерәк малайлар уртасында, винтовка тотып, саргаскәр кебек барам. Киңәшкә янда Зөфәр генә юк. Аның бездән бер яшькә олы булганлыгы армиягә алынганда гына абайланды. Хәзер ул Германиядән хат язып ята. Миңа чират – быел көзгә генә. Аңынчы кыланып калырга кирәк.

Тилгән – мәһабәт кош, алагаем канатларын җәеп, күккә кадакланган шикелле, бер ноктада эленеп тора. Баскан килеш тә, чалкан ятып та атып карыйм, юк, «керфеген» дә селкетми. Малайлар миңа көч биреп, тилгәнгә йодрык болгый-болгый кычкырышалар. Мин, үчләшеп, һаман атам да атам. Прицел планкасын күчереп, төрле ераклыкка куеп карыйм – барыбер тигерә алмыйм. Тилгән миннән көлә, үчекли шикелле. Инде бу кадәр атуга тишкәләнеп, иләккә әйләнергә тиеш бит югыйсә. Әллә соң ядрәләр үтәли тишеп чыкканны сизми микән бу мәкерле кош?! Малайлардан оят...

Бераздан тилгән «Булмады синнән», дигән кебек, канатларын вәкарь белән генә селкетеп алды да, кинәт бер талпыныш ясап, урман ягына китеп югалды.

Шуннан соң мин, малайлар алдында булдыксызга калуымны оныттырыр өчен, яңа мавыгу уйлап табам. Ташка бер тиенлек бакыр куям. Егерме метрдан кем тигерә ала – менә бу ярыш ичмасам. Чиратка басалар. Бер-ике малайга аттырып карап, бер дә тигезә алмаячакларына ышангач, үзем тотынам. Бер тиенлек бик кечкенә нокта гына булып күренә. Атам. Бакыр тиен әллә кая чәчрәп оча. Җыйнаулашып эзлибез. Шулай бер таба, бер югалта торгач, малайларның ушлырагы тиенне гудрон сагыз белән ташка ябыштырып куя. Патрон көчле шул, пуля тиеп барыбер урыныннан кузгата.

Без авыл башындагы түбәҗирдә мәш киләбез. Аста, аяк очында өйләр, каралты-куралар. Каршыда иген кыры, арырак зират наратлары күренә. Ата торгач, тиен ябыштырылган таш теткәләнеп бетә.

И җүләр чак! Мин бит ядрәнең винтовка көпшәсеннән чыгуын гына тойганмын, төбәлгәнеңә тимичә, бәйсез очкан ядрә кая барып җитә, нәрсәгә барып керә – монысын уйламаганмын.

Шул көнне, без атып яткан вакытта, Миргазиян абзый (арка бөкресе тартып торганга, кыска буйлы, зур башлы булып күренә иде ул) асфальт ягыннан авылга төшеп килә икән. Үзалдына нииндидер көйгә сызгыра-сызгыра зиратка җитеп килгәндә... Кинәт... авызына сугылудан тетрәп, артка чүгеп китә яза. Учы белән авызын каплап, тирә-юненә карый. Беркем юк. Күк йөзендә тургай гына, ярсып, атына-атына сайравын белә. Учында сынган теш, ямьшек металл кисәгeн күргәч, ул, бөтенләй зиһенен җуеп, хафага кала. Кичен капка төбендәге утыргычка җыелган күрше-тирәләргә хәлне сөйләп бирә:

– Зират янында бит... Дога-мазар укыган юк күптән. Әллә, мәйтәм, шайтан үзе чыгып бәрде микән?.. – дип, ул кесәсеннән кульяулыкка төрелгән сынык теш һәм металл кисәген чыгара.

– Каяле, каяле, – дип, Әнвәр абзый кульяулыкны учына ала. Яшьлегендә каядыр йоклап китеп, кобурасыннан пистолетын урлаткан өчен милициядән куылса да, авыл халкы өчен ул барыбер дөреслекне эзләүче булып калды. – Ядрә бит бу! Мелкашканыкы. Тәк-тәк-тәк... Син зират турында идең, әйеме? Вакыт күпме иде, төш туры түгелме? Түбән очта, ком ала торган түбәҗирдә, нәкъ төш чорында үз күзләрем белән күреп киттем: Баян абзыйның улы, малай-шалайлар өере белән, мелкашкадан атып ята иде. Димәк... рикошет ясап, адашкан пуля синең ачык авызыңа килеп кергән дә, алгы тешеңне сындырып, тел өстенә төшкән, шулаймы?!

– Шулайдыр инде, син әйткәч, – ди Миргазиян абзый, сынык теш ачыклыгыннан «ш» авазын сызгыртып.

– Моны болай гына калдырырга ярамый!

– Көпә-көндез тешеңне сындырсыннар да...

– Ие шул, ие, – диешә утырдашлар.

– Туктагыз әле, мин үзем белермен нишләргә икәнен! – дип, үзсүзле Миргазиян абзый боларны кырт кисә.

Икенче көнне ул мине кичен клубка чыкканда эләктереп алды. Бөкресе белән койманы терәп утырган җиреннән тезбашларын чыртлатып калыкты, кечке сафлыкны үзгәртеп, авызыннан ачыбал исе аңкытып алды. Шакмаклы ияк белән тәмамланган калын кашлы чыраена усаллык төсмере чыгарды. Кыска буйлыларга хас гадәт буенча, башны артка ташлабрак, өстән аска карап сөйләшергә әзерләнде. Мин, әлбәттә, сүзнең ни турыда барасын сизенә идем, авылда бу хәбәр, капкадан капкага кереп тормыйча, таралып өлгергән иде: «...мылтыктан атып, Миргазиянның теш казнасын җимерткән икән... Ияген бөтенләй умыртып чыгарган, ди», тагын әллә ниләр. Шөкер, Миргазиян абзый тыштан караганда сау күренә. Менә ул кесәсеннән кульяулык чыгарып учында җәйде:

– Бусы – минем теш. Бусы – син аткан пуля. Моның өчен сине судка явит итәргә була, шулай бит! Тик... Миргазиян абыең самодур түгел, аңлый белә. Бу бит, апаем, тайпылган пуля, шулай бит. Сарык көтүеннән сарык качып китсә, көтүчене гаепләгән булалар. Ә бит сарык үзе гаепле ләбаса. Кичә кызып та алган идем, күргәч, бер тондырам инде моңа дип. Минем йодрык хакында ишеткәнең бардыр? Кыссам, трактор белән дә тарттырып ачтыра алмыйсың. Тимер дә тимер, минем йодрык та тимер! Ходай бер яктан бирмәсә, икенче яктан бирә ул... Атаң яхшы кеше синең, атаң әйбәт... Мин болай итәргә булдым, энекәш! Бөгелмәгә барып, үзебезнең авылдаш Сәгыйдулла абзыйдан яңа теш куйдыртам да кайтам. Алтыннан. Ә хакын син түлисең, булдымы?

– Ярар, Миргазиян абзый, – дидем мин, карлыгып чыккан юаш тавыш белән.

Миргазиян абзый саргаеп беткән, чатнаган тырнаклы бармаклары арасына кыстырып тәмәке кабызды, мул төтен бөркеп, ләззәтле өргәннән соң, күкрәк турын гыжылдатып көләргә тотынды:

– Нинди алтын теш ди ул, прастуй сүзле авызга! Шаяртам гына. Ә мужет син укып чыгып зур кеше, министр булырсың, ә?! Шуңа күрә бу пуляңны саклыйм әле сандык төбендә...

Икенче вакыт болай булды: бәрәңге бакчасына чыга торган бәләкәй капка башына шешә яткырып куйдык та... балдак кебек кенә авызына атып, шешәнең төбен кем коеп төшерә ала – китте ярыш. Атабыз, атабыз. Авызын бөреп кенә ачкан шешәгә тидерү җиңелдән түгел икән. Кызышып, мәш киләбез. Һәркемнең беренче буласы килә.

Бервакыт шау-кычкырып, олы капкадан, җилпенеп, Рудир килеп керде. Тыны-көне беткән, күзе акайган.

– Атып үтерәсез бит, юньсезләр, туктагыз!

Рудир (1941 елгы, аңа Франклин Делане Рузвельт хөрмәтенә шундый исем кушканнар. Таныклыгында Рузвельттыр инде ул, әмма халык йөгертеп кенә Рудир дип әйтә) әнисе Майсараттәйнең керләрен күтәрешеп, инеш буена төшкән булган. Кинәт өянкеләр кәүсәсенә шарт та шорт пулялар килеп тия башлаган.

– Әни, ят, бетерәләр! – дип кычкырган да Рудир, каян атканнарын чамалап, яр астыннан мүкәли-мүкәли тыкрыкка чыгып, монда таба йөгергән.

– Башыгыз бармы сезнең, ә! Аргы ярда көтү йөри, болында оя-оя казлар, тау ягында атлар... Себер китәсез бит! – дип ул кычкырынды-кычкырынды да киредән инеш буена йөгерде.

– Әнигә пуля тигән булса, бетерәм барыгызны да! – дигән янаулы тавышы гына капкага кысылып калды. Майсараттәйгә ул-бу булмаганын белер өчен аның артыннан малайларны йөгертәм.

Атуның тәме китте. Коткарыгыз, дигән шикелле аргы яктагы тау-үзәннәрне күкрәге белән каплаган тоташ өянкеләр гаскәренә карыйм...

Апрель башында Бөгелмә шәһәренә, трест беренчелегенә ату ярышына чакыру килде. Кыш буе әзерләнгән идек. Төзелеп кенә килгән автоколонна гаражлары корпусында кыш буе күнегүләр алып бардык. Командада биш кеше – төзү институтын бетергән инженерлар, мастерлар. Яшькә миннән зурлар.

Постройком председателе Ибат ага Әхмәтбаев «командаңны ресторанда сыйларсың», дип 75 сум акча бирдерде. Шулай итеп, миндә – винтовка, миндә – патроннар, миндә – акча.

Сынатмадык. Ничә районнан килгән командалар арасында трест буенча беренче урынны яуладык. Грамота алдык. Кәеф шәп. Ресторанга кергәч кенә күңел бөтенлеге бозылды. Ашау-эчүне мулдан алдырдылар. (Минем беренче мәртәбә ресторанга керүем.) Хәзер инде мине дә хәмер эчәргә кыстаячаклар – иң курыкканым шул иде.

Миңа болай да әйбәт бит югыйсә, нигә кирәк бу ачы су... Ахырда томат согына яртылаш аракы кушып, болай сизелми дә ул, дип кыстый торгач, ничек тә сынатмаска бит инде, эчә башладым, тамактан үтми генә бит, кире килә, күздән яшь чыгара-чыгара үз-үземне көчләп, тәки эчеп бетергән булдым шайтан суын.

Автобуска утырганда, винтовканың затворын алдырып, кесәгә тыктырдылар. Миңа ни әйтсәләр дә барыбер иде, рәхәт тә шикелле, нindидер кызышу, тән җиңеллеге, акылның тәннән ыргылып, әллә кая сикерәсе килүен тоям.

Азнакайга җитәргә сигез чакрым кала үземнең авыл – Балтач тукталышында төшеп калдым. Калганнар ары китте.

Барам кыр юлы буйлап. Кояш. Яз исе. Кардан арчыла барган җирләр – ала-кола. Тирә-якта ник бер җан иясе күренсен. Күңел мәтәлчек ата, әллә нишлисе килә. Винтовканы кулга алдым, патронны оясына кертеп, затворны урнаштырдым да, нинди карамчык күренә – юл буйлап әле уңга, әле сулга атып кайтам. Телеграф баганаларын «чүким». «Мин ярышта беренче урынны алдым бүген, белегез, күрегез!» Атам да атам.

Зират турына җиткәч, винтовканы иңгә астым. Хөснетдин бабайлар тыкрыгына төшеп борылуга – мәчет ишегалды. Анда иң беренче булып җир ачыла; үлән баш төртә башлый. Карасам, егермеләп адәм бура күтәреп яталар. Өмә икән бит монда. Болай күренү оят бит, эчкәнемне сизмәсеннәр өчен, мин бөтен тән күзәнәгемне, акылымны бер йодрыкка йомарладым. Яннарына килеп тукталдым гына, борынгы ырыс капкасыннан түшен киереп чыгып, «Иж» мотоциклын кабыза торган, гадәтенчә, бер-бер төртмә, мыскыллы сүз ычкындырмыйча түзә алмый торган «Алтынчы Шакир» – Миргазиян абый бу юлы да өрмичә калалмады:

– Нәрсә, ата белмәгән башың белән мылтык күтәреп йөргән буласың монда!

Ир-атларга көләргә генә булсын, Шакировны хуплап, авызларын көлү тарафына чалшайтып алдылар.

Кирәк бит, нәкъ шул мәлдә, кара ефәк җәймә булып, каргалар көтүе очып килгәнен күреп алдым да, корулы мылтыкны тиз генә иңнән алып, каргалар дуенына атып та җибәрдем. Йа Ходa! Өмә мәйданының нәкъ уртасына канатларын каера-каера шап итеп карга килеп төшмәсенме! Бөтенесе дә тып-тын калдылар. Шакиров, көнләшүдән агарып чыкты. Ул арада Шадра Салих абзый каударланып килеп, карганы канат очыннан күтәреп алды. Икенче канаты да кайтарылып төшкәч, карга дигән кош галәмәт зур, дәһшәтле күренә икән. Берәрсе кулдан тартып алмагае дигәндәй, Салих абзый кош гәүдәсен ике куллап күтәреп, үз ихатасына таба китте. Мин дә винтовканы иңгә асып, үзебезнең очка таба кузгалдым. Арттан ишетелеп калган ниндидер мактау ымлыкларына игътибар итәм димени, мин – болай да бәхетле. Гомердә бер була торган хәл. Япа-ялгызым калгач, бу мизгелнең һәр җепселен әкрен генә сүтә-сүтә, күңелдән кабат-кабат кичереп, ләззәтен суза-суза күпме тапкырлар искә төшереп хозурланырмын әле мин. Сирәк була торган хәл бит: шулкадәр тәвәккәллек белән винтовканы иңнән каерып алып, кошлар көтүенә каратып атып җибәр әле, төзәдеңме син аны, төзәмәдеңме – кемнең анда ни эше бар, кем асылына төшеп исбатлый ала?! Кимсетеп әйтелгән сүздән ярсыган яшь күңелнең үз-үзен раславы түгелме бу! Мылтык тотып караган кеше чамалый булыр... Ничә күз карап торганда... күкрәгенә ядрә алган кош мәйдан уртасына, саллы ирләрнең аяк очына, канатларын җәеп, шапылдап килеп төшсен әле! Мондый да мактанырлык мач килү очрагы – гомердә сирәк буладыр...

Һавалы бер горурлык белән кайтсам да, винтовкамны өйалдындагы почмакка сөяп кергәч, шымып калдым. Әти-әнигә кайда, нишләп йөргәнемне эчкерсез ачылып китеп сөйләү гадәтем юк. Әмма, бүгенге тәэсирләрне тыеп буламыни. Киерелгән җан канатларын күкрәк читлегенә сыйдырырлык түгел. Җитмәсә, хәмер тәэсире дә чыгып бетмәгән. Күңелдә әллә нинди рәшә тирбәлеше...

Бераздан җизнәй килеп керде. Ул да мәчет ишегалдында өмәчеләр арасында булган икән. (Мин анда кызулык белән кемнәр барын анык кына искәрмәдем дә.)

– Шәп килеп чыкты, – диде ул, бик юмартланып китеп, артык мактап ташламыйм тагын, дигән шикелле, сүзне икенчегә бормакчы иде, мин очынып, сикереп тордым:

– Әйдә, тагын берәр карганы атып төшерәбез!

Җизнәй дә калкынды. Бәрәңге бакчасына чыктык. Кара туфраклы җир парланып ята шикелле. Сарай-ихата кырыйларында ярмаланып, каралып яткан көпшәк кар өстеннән күрше Рәшидәттәйләрнең киртәсенә чаклы бардык. Мин, тезләнеп, винтовканы кордым. Тирә-якта яз шаукымы кергән кошларның дәртле чыркылдашуы ишетелә.

Әнә, бер сыгылып, бер чөелеп, тегермән яклап очып килгән карга көтүе күренде. Тезләнеп, винтовка көпшәсен киртәгә яткырып куйдым. Шундый тиз очалар икән, очыш тизлегенә ярашып, төзәргә тырышып винтовканы күтәрә барам, күтәрә барам, инде якынаеп, кошлар көтүе баш турысына килеп җитте, инде курокка кулны тигезгәндә... кинәт артка авып киттем дә, шартлау тавышы яңгырады, ул арада чылтырап нидер коелган тавыш ишетелде. Баксаң, уң як күршебез Нургали абзыйның сарай кыегындагы кечкенә тәрәзәне, пуля тиеп, коеп төшергән икән.

Шул елны, яз фасылы кыюланып, тулы хокук яулап, яшеллеккә төренеп барганда, тилгән ату уе белән җизнәйнең мотоциклында табигатькә чыгып киттек. Иңдә винтовка, кесәдә өч кап патрон. Капны ачып кара – нинди матурлык: патроннар тыгыз тезелешеп, алтын-көмеш сыман ялтырап, атылырга кыҗрап утыралар.

Үзән-тугайларны иңләдек, тауларга мендек – әмма бер тилгәнне дә күрергә насыйп булмады ул көнне.

– Тилгәннәрнең дә бала чыгару вакытыдыр, – диде җизнәй.

Аптырагач, урман буена тукталып, гадәттәгечә, ташка тиен акча куеп ата торгач, ике кап патронны исраф иткәнбез.

Шунда минем биектә, имән ботагындагы ояга күзем төште. Оя буш түгел, эчендә ниндидер кош утыра, башы, муены гына күренә. Ихтимал, ана коштыр, кайнар түше белән җылытып, күкәйләре өстендә утырадыр. Мин аңа озак карап тордым: ничек ул шулай, тын да алмаган шикелле оеп, гел бер рәвешле утыра ала икән?

Шуннан соң винтовканы алдым да, кошка ату гөнаһы уемда да юк, әлбәттә, болай, сынап карау өчен генә... Кошның баш янәшәсендәге кәүсәгә бер атам, ике атам, өч... Пулялар агачка шартлап барып тия, урман мылтык тавышын тагын да ярсытыбрак кабатлый, ә кош селкенми дә... Никадәр сабырлык, нәсел дәвамы – чыгачак балалары хакына курку белмәс нинди түземлек! Үлсә үләр, әмма үз җанын саклап очып китмәс, йомыркаларын суытырга әнкә кошның хакы юк. Бу кодрәт аңа табигать тарафыннан салынган. Мин моны күреп тетрәндем, кичер, кошкай-кошкынам, мин бит синең тугры-ныклыгыңны сынап карадым гына... Моннан соң мин, төз ату буенча теләсә кем белән ярыша алсам да, бүтән беркайчан да, бер кош-кортка да, бер киек-җәнлеккә дә утлы корал төбәмәм, җан кыймам, гомерен өзмәм, иншалла...

Ә теге чакта мин аткан карга гәүдәсен Салих абзый үзенең бәрәңге бакчасы башына озын колгага элеп куйган. Армия хезмәтеннән бер елдан соң Пермьнән ялга кайтканда да кара карачкы колга башында «исән» иде әле. Тагын бер елдан соң, Белоруссиядән кунакка кайттым, тора бит урынында – шул ук колга, шул ук карачкы, җилдә җиңел тибрәлүеннән үк сизелеп тора: тәмам кибеп беткән инде, шәүләгә генә калган минем яшьлек корбаны.

Солдат тормышы белән бөтенләйгә хушлашып, ике ел ярымнан соң кайтсам... Карачкы да юк, колга да юк урынында, Салих абзый үзе дә «теге» дөньяга күчкән иде инде...

***

*Кулга алып ата торган утлы коралларның нинди генә төре юк бу дөнья йөзендә. Кайберләрен миңа да тотып карарга, «тибенүен» тоярга туры килде үз гомеремдә. Бик үк ошап бетмәгәннәре – ТТ (Тульский. Токарева) һәм ПМ (пистолет Макарова) пистолетлары булды. Җиңел дисәң дә, авыр үзләре. Озаграк төзәп торсаң, сузылган кулың дерелди башлый. Пистолет атылу мизгелендә, кулга нык бәреп, өскә чөелә. Сыеграк кул аны тотып кала алмыйча, каушаудан, артында торган иптәшенә икенче пуляны атып җибәрергә дә мөмкин. Пистолетны мишень биеклегенә өстән аска төшергәндә төзәп өлгерергә кирәк. Киресенчә, астан өскә күтәргәндә – барып чыкмый. Чынбарлыкта пистолет (наган, маузерның дәвамчысы буларак) якын арадан, кеше силуэтына җәһәт кенә төзәп, җәһәт кенә атар өчен яратылган.*

*Пулясы – юантык, тупыйк башлы. Килеп тиюгә, кешенең бөтен тәнен тетрәтеп, тораташ калдыра. Автомат, карабин пулясы очлы башлы була, мондый пуля тигәндә, кеше заты кинәт параличланмый, йөгергән чагы булса, тагын бер-ике адым атлап өлгерә әле.*

*Пистолет – кесәгә сыймалы кызыктыргыч корал. Әмма мин аны ярата алмадым...*

*Автомат – башка...*

*Ижауда үзешчән оста Калашников тарафыннан эшләнеп, елдан-ел камилләштерелә барган (бүгенге көндә дә) совет автоматы, үрчи-үрчи, бөтен планетага таралган. Бик күп телләрдә аның уртак исеме – «Калаш». Чатнап ярылырлык туң салкында да, эреп агарлык эсседә дә, ком чүлендә дә, карлы-бозлы яңгырда да – нинди генә шартларга тарымасын, Калаш чыгымламый, хуҗасын кыен хәлгә куймый, карусыз атуын белә. Бу автомат – иң ышанычлы, тугры корал. Менә шуңа күрә дә ул мәртәбәле байларның да, саргаскәрләрнең дә коллекциясендә иң күренекле урында тора. Ил башлыкларыннан Сәддәм Хөсәеннең дә түтәсен алтын пластиналар белән каймалап бизәлгән автоматы булган... Кайбер илләрнең туграсында калаш сурәте ясалган, Мисырда аңа һәйкәл куелган икән – димәк, бу юкка түгел. Автомат сурәтен келәмгә чигәргә яраткан, гел сугыш сөреме сулап яшәргә күнеккән Әфганстанда ир бала Калаш кочаклап туа, Калаш кочаклап яши, Калаш кочаклап үлә... Һәм мондый илләр арта тора...*

*Хикмәт нәрсәдә?*

*Миллионлаган ир-егетләрнең ихтыярын алып, ничек болай дөнья йөзенә сөмсезләнеп таралган соң бу хикмәти корал? Күзне кызыктырырлык әллә нинди бизәкләре дә юк, рәвеше дә гади генә кебек югыйсә. Акылны җиңә торган нинди әфсене бар моның? Иблис тыны белән ярытылганмы әллә?*

*Үзең атып карагач кына, моңа төшенә язасың.*

*Университетны тәмамлаганда, хәрби кафедра тарафыннан лейтенант дәрәҗәсе бирер алдыннан, Казан читендәге полигонда Калаштан күп тапкырлар атып карарга туры килде миңа. Йөз-ике йөз метр ераклыкта хәрәкәт иткән мишеньнәргә яктырткыч пуля яудырган мизгелне һич тә онытасым юк. Искиткеч күренеш. Исерткеч манзара. Яктылык сызыгының бер очы автомат көпшәсеннән савылып чыга, икенче очы мишеньгә барып керә. Гүя син яшен камчысын селтәп торучы кодрәт иясе! Кан тибешенә тәңгәл итеп, әз генә кыймшат кулыңны – ут*

*сызыгы йә уңга, йә сулга тайпыла. Кылыч йөзе кебек үткен ут зәһәрлеге юлындагы бөтен нәрсәне – хәтта һаваны, уеңны рәхимсез кыеп төшерә. Моңа кадәр мин бу могҗизаны нишләп белмәдем икән?!*

*Берәмләп аткан чакта автомат кулга бәрә, ә инде тоташтан атуга күчсәң... Калаш йомшак кына дерелдәп, аккорд алып, бер көйгә җырлый башлый, бу көй рәхәт эретеп, бөтен тән күзәнәкләренә тарала. Эчтә җан тибрәнә, җан бии; бөтен барлыгың белән онытылып, оргазм алуга тиң хисси ләззәтне вөҗүдеңә сыйдыра алмыйча, шашып кычкырасы килә... Бу – акылга буйсынмый торган куркыныч илһамлы халәт!*

*Син – бу мизгелдә кичәгеңне, бүгенгеңне, киләчәгеңне онытып, шушы дуамал утлы корал сихеренә биреләсең; ул синнән өстен. Син аны буйсындырам дип, үзең аңа буйсынасың. Бу мизгелдә вакыт илаһына буйсынмыйча кыргый дәрт уяна; уяна гына түгел – тамырдан актарылып чыга; актарылып кына калмый, талымсыз котыртылып, эчтә тыеп торган аяусызлык сүрүләрен умырып төшерә. Каршыңдагы ясалма мишеньнәр мескен кала. Алар – җансыз. Алар – кызыксыз. Адарынган күңелең т е р е мишень сорый башлый...*

*Калаш җене кыргый теләгеңә тырнакларын батыра.*

*Яшь йөрәк сугыш театрында каһарман булырга тели...*

*Бер атып караган яшь-җилкенчәк Калаш тылсымыннан гипнозланып, тәкатьсез кала. Чөнки Калашның үзенә бертөрле тарту көче, хәтәр магиясе бар. Мең еллар буена камилләшә барган үтерү коралы – ук-җәя, сөңге, чукмар, утлы мылтыклар биреп бетерә алмаган мөмкинлекләрне XX гасырда Калаш автоматы, соң дәрәҗәгә җиткереп, үзенә туплаган. Аяусыз үлем уенына кергән яшь кешенең ул куенына керә, аркадашына, яклаучысына, таянычына әверелеп китә. Менә ни өчен Калаш автоматы тәненә береккән башкисәр егетләр бөтен планетаны бер итеп йөриләр, акылын җуеп утка керәләр; кеше җанын аулау, асу-кисү, кыру, юк итү аларның гадәти кәсебенә әйләнеп бара.*

*Юк, мин Калаш автоматына мәдхия җырламадым. Ходай сакласын. Мин бу коралның йогышлы асылын аңларга юаш кына талпынып карадым. Минем сурәтләү алымына шикләнеп, сагаеп караучылар булыр. Кем әйтмешли: «Бу мәсәлнең морале: үзең атып карале!»*

*Без дә яшьлектә Че Гевара кебекләр белән мавыгып, каядыр чит илләргә чыгып китеп, сугыш-революция гарасатына кушылып китәргә хыялландык. Әмма узган гасырның 60 нчы елларында дөньяның әле вөҗданлылык җөйләре сүтелеп бетмәгән иде. Бүгенге кебек, явызлыкның авызлыгы салдырылмаган, ялганның ялы киселмәгән иде. Бу заман башка... Шагыйрь әйтмешли, ахырзаман исе килә хәтта кызыл алмадан...*

*Күпме яшьләр теләсә нинди дингә табынып (янәсе), теләсә нинди идеяне яклап (янәсе), теләсә нинди илгә сугыш театрына гастрольгә чыгалар. Идеяләр – ялган исерткеч кенә. Аяусызлык асылында – гаҗәеп дәрәҗәдә мөкәммәл яратылган үтерү коралы – Калаш автоматының миллионнарны табындыра белү җене ята.*

*Дәвамы алдагы санда*



Гөлзадә
Әхтәмова

# БИРЕШМӘС КӨЧЛӘР ТАБАМ

## Әнкәм элемтәсе

Тел очыма килгән кайбер сүзне
Әйтә алмый торган чагымда,
Әнкәм ничек әйтер иде икән,
Диеп күзаллыйм мин чынында.

Туган телем аша элемтәләр
Салып китте әнкәм дөньядан.
Кайтавазлар булып колагымда
Тавышы чыңлый яңа-яңадан.

Ишетелә газиз әнкәм теле
Нәкъ үзенчә, безнең авылча.
Бәреп чыга чишмә суы кебек,
Чит сүзләрдән колак тыгылса.

Онытыла барган сүзләр гүя
Сикереп тора йокыдан уянып.
Шулчак –
Әнкәм сүзен, әнкәм әйтемнәрен
Кабатлыймын сөенеп-куанып.

Гөлзадә ӘХТӘМОВА – *шагыйрә; «Йөрәгемдә яшен», «Күңел ашкынуы» һ.б. китаплар авторы. С.Сөләйманова исемендәге әдәби премия лауреаты. Алабуга шәһәрендә яши.*

## Татар теле җырлабрак сөйләшелә

*Чит илдә булып кайткан бер ханым әйтүенчә, испан телләре белән чагыштырганда, татар теле җырлабрак сөйләшелә икән.*

Әкрен генә, бер-береңнең кадерен белеп,
Хәлләреңә кереп кенә эндәшелә.
Авыр чакта кайгыларны җиңеләйтеп,
Татар теле җырлабрак сөйләшелә.

Күп яуларны күргән башлар уйландыра,
Тыныч тормыш өчен җаннар килешелә.
Кан саркыган йөрәкләрне иркәләргә
Татар теле җырлабрак сөйләшелә.

Канлы еллар хәтерләре китми генә,
Моң-зарлардан юанычлар өләшелә.
Дәва булып күңелләрнең ярасына,
Татар теле җырлабрак сөйләшелә.

Гасырларның кайтавазы колакларда,
Үткәннәргә борыла-борыла эндәшелә.
Күкрәкләрдән чыккан моңга сарылып,
Татар теле җырлабрак сөйләшелә.

Күпме анда нәзакәтле назлы сүзләр
Сөю тулы күңелләрдә берләшелә.
Сөенечле җылы хистә тибрәндереп,
Татар теле җырлабрак сөйләшелә.

## Телим изгелек кенә

Яратмыймын кимсетсәләр,
Йомшаклыгымны сизеп,
Күңел кылларымны кемдер
Китмәкче булса өзеп –

Үрә басып каршы торам,
Тырмашам, үҗәтләнәм.
Ничек көч табам шул чакта? –
Үзем дә гаҗәпләнәм.

Ошатмыймын – төп башына
Утыртып калдырсалар,
Күңелем тартмаган җиргә
Кунакка чакырсалар.

Тәүбә иткән, онытылганны
Кабаттан актарсалар,
Җан дусларым гаеп эзләп,
Күңелемне кайтарсалар.

Шул чакта тынычлык сорап,
Ялварам бер Аллага,
Һәм аңа зур рәхмәт укыйм
Тудырганга дөньяга.

Тормышның бар гүзәллеген
Күз алдыма китерәм.
Караңгылык юкка чыга –
Тирә-ягым – бер дигән!

Кара болытлар тарала,
Җилфердәтеп итәген,
Онытам – йөрәкне тырмап,
Көндәшләрнең үртәвен.

Һәрбер җан иясенә мин
Телим изгелек кенә –
Мәрхәмәт, игелек, тәүфыйк
Бир, Аллам, дип һәркемгә!

## Җай

Бу дөньяга күпне биргән Ходай –
Зәмһәрир кыш белән эссе җәен,
Мәхәббәт һәм нәфрәт, кайгы-сагыш –
Һәм йөрәк аша үткәрергә җаен.

Ни күрсәң дә, бар да үтеп китә,
Гомер уза тора һәр таң саен.
Ни әйтсәң дә, яшәү – яшәү инде,
Елмаерга кирәк табып җаен.

Ачып җибәр кара пәрдәләрне,
Кояш керер күңел түрләреңә.
Юлларың уң булыр киләчәктә,
Яшә ышанып бер җай килеренә.

Бу дөньяда бар да хикмәт белән,
Бернәрсә дә түгел гади генә.
Бәхет үзе янда гына йөрер,
Очрамыйча калмас өметлегә.

## Фани дөнья

Алдандым, бик күп алдандым,
И, дөнья, фани дөнья!
Шуңадыр керсез күңелемне
Салдың мең төрле уйга.

Елмаеп каршы алсам да
Синең һәрбер таңыңны,
Киметтерде акрын-акрын
Ышанычын җанымның.

Иркәләрсең дигән чакта
Камчыладың син күбрәк.
Гаҗәпләнәм – бу көнгәчә
Ничек чыдады йөрәк?

Картлыгым ишек какса да,
Бирешмәс көчләр табам.
И, дөнья, мең ел яшәп тә,
Тик синнән туя алмам!

## Урау-урау юллар

Урау-урау юллар аянычлы –
Һич белмисең кайчан егыласын,
Язмышларның кайсы сынаулары
Сиңа каты итеп кагыласын.

Аймыл булып кемнәр яшәмәгән
Эзләгәндә бәхет юлларын,
Һич белмисең – күңелең әрнегәндә
Кем сузасын ярдәм кулларын.

Иркә-назлар һәм чәчәкле язлар!
Кабатлана сирәк, бик сирәк.
Тормыш мәгънәләрен аңлар өчен
Үз юлыңны табу бик кирәк.

Урау-урау юллар үткәч кенә,
Күңел күп нәрсәгә төшенә.
Бары үз башыннан узганнары
Җирдә сабак була кешегә.

***Редакциядән:***

*Каләмдәшебез бу айда үзенең юбилеен билгеләп үтә. Аңа исәнлек-саулык, иҗат уңышлары телибез.*

Данил
Салихов

# ЧУКРАК

РОМАН

Мифтах, сулы чиләген көч-хәл белән өстерәп тау астыннан күтәрелде дә, чиләгендәге суын чайпалдыра-чайпалдыра, ярты суын чалбар балагына түгә-түгә, идарә баскычын юып ятучы әнисе Гөлйөзем янына килеп басты. Беләге белән тирләгән маңгаен сөртеп алганнан соң: «Булдырдыммы?! Тау астындагы иң ерак чишмәдән үзеңә су алып кайтып бирдемме!» – дип, биленә таянды. Мактау сүзе өмет итеп, әнисенә карады.

Капкадан Батырҗан килеп керде. Капкага арты белән иелеп идарә баскычын юган Гөлйөземнең арт санын күреп тынсыз калды. Бераз гына капка баганасына сөялеп өнсез торганнан соң, түзмәде, сак кына килеп, Гөлйөземне кочаклап алды. Гөлйөзем куркып катып калды. Борылыргамы, әллә борылмаскамы... Ул көткән кешеме? Ходайдан үтенеп сораулары әллә тормышка аштымы? Әллә чыннан да ул көткән кеше исәнме? Капкадан атлап керде дә Гөлйөземне куенына алдымы?! Әллә сабыен аталы, бәхетле итмәк булдымы?.. Каршысында басып торган улына күзе төште. Мифтахның күзләрендә, карашында нәфрәт тоеп, кинәт артына борылды. Каршында берән-сәрән исән калган, саргаеп беткән тешләрен ыржайтып, нурсыз йөз елмая иде. Гөлйөзем кулындагы пычрак сулы мунчаласы белән Батырҗанның йөзенә китереп сукты.

– Нишлисең, җирбит! Хайван!

– Гафу ит, Гөлйөзем. Үз-үземне белештермичә, онытылып кителде. Зинһар, гафу ит. Яратуыма чыдый алмый ялгыштым.

– Ә син нәрсә катып калдың?!

Мифтах алып кайткан суны Батырҗанның өстенә каплады да чиләкне улына ыргытты.

– Мә! Су алып мен! – Батырҗанга борылып: – ә син, кайтып, анаң Сафура түтәйне кочакла! – дип кычкырды.

Батырҗан йөзенә килеп бәрелгән суга тончыгып, тын алалмыйча, көчкә-көчкә сулыш алып:

– Мыскыл итмә инде, Гөлйөзем, – диде.

---

*Ахыры. Башы узган санда.*

– Башка миңа кулыңны сузасы булма. Атамны үтердегез! Үземә пычрак аттыгыз! Аларны сөрдегез! Миннән тагын ни кирәк?! Тимәгез миңа! Зинһар, тимәгез! – дип ыңгырашты Гөлйөзем.

– Минем бер гаебем дә юк. Арслан, барысын да Арслан оештырды. Синең өчен генә яшим бит мин, Гөлйөзем.

– Кичә төнлә син идеңме ул безнең тәрәзә төбендә?

– Юк, Гөлйөзем, валлаһи, мин түгел идем.

– Алдашма!

– Анам белән ант итәм, мин түгел идем. Гөлйөзем, бул минеке?!

– Беркайчан да!

– Аны көтәсең?!

– Көтәм!

– Кайтмый ул. Анда киткәннәрнең берсенең дә кайтканы юк.

– Ул кайта!

– Теге дөньядан әлегә берәүнең дә кайтканы юк. Минеке бул! Минем дә бәхетле булырга хакым бардыр, – дип ялварды Батырҗан.

– Мин үз бәхетемне көтәм. – Ярымачык капкадан сөмсере коелган улының карашын тоеп, – мин баламның атасын көтәм. Мин улымның атасын көтәм, – диде Гөлйөзем.

– Кайтмый ул! Исән булса да кайтмый. Бу җир аны үзенеке итә алмый. Югалганына инде ничәмә-ничә еллар! Атасының бәхиллеген алалмаган кеше гомерендә дә рәхәт күрми! Гөлйөзем, малаеңны аякка бастырасы, егет итәсе бар. Синең дә тормышың күз алдында. Ал да гөл генә түгел, мин дә сиңа сүз әйтергә, сүз катарга оялып, картаеп барам. Әнкәй дә урын өстенә менде... – Батырҗан ничек тә Гөлйөземне күндерергә азаплана иде.

– Мин барыбер синеке булмаячакмын.

Ачык капкадан Арслан күренде.

– Нәрсә турында гәпләшәләр болар, пар күгәрченнәр?!

– Юк, менә идән юып бетергәнен көтә идем. Таптап керәсем килмәде.

– Ә син кереп торма! Пычак калганмыни сиңа ул кәнсәләрдә?! Әнә бар, хәзер үк җәйләүгә – «Марҗа чокыры»на чап! Теге дуңгыз Галимҗанның маллары таралган, ди. Үзен чыбыркы белән сыйлап кайт. Җелегенә төш. Бер генә сыерына берәр нәрсә булса да, икегезне дә Себергә сөрәм!

Болай да Арсланның вакытсыз кергәненә ачуы чыккан Батырҗан, бар ачуын Галимҗаннан алу теләге белән:

– Хәзер. Ну, селәгәйнең кирәген бирәм! – диде.

Һәм абына-сөртенә, кая басканын белештермичә, капкага ташланды.

Батырҗан теге чакта Сталин портретын әйләндереп куюы белән төзәтеп булмаслык ялгышлык ясавын, үзен-үзе Арслан җәтмәсенә мәңгелеккә илтеп тыкканын аңлаганга күрә, Арсланның һәр сүзен, һәр җөмләсен закон итеп кабул итә, аның күләгәсеннән дә куркып яши иде.

Арслан Мифтахны култык астыннан эләктереп алды да югарыга күтәрде.

– Егет урыны биредә түгел. Егет урыны – ат өстендә! Әйдә, мин сине атка атландырам, – дип урамга алып чыгып китте. – Бар! Тузан туздырып, малай-шалайларны көнләштереп, бер урам әйлән, – дип, атка атландырды да атының арт санына уч төбе белән сукты. – Әйдә, малкай! Бу селәгәйне урам әйләндер! Күзле бүкән кебек карап тормасын, – дип, борын астыннан мыгырданды.

Бу минутларда малайга анасы да, сулы чиләк тә кирәкми, аның җилкәләрендә канат иде.

Арслан ишегалдына керде. Капканы япты да шудырмасын тартты. Гөлйөзем янына килде. Бөтереп алып куенына тыкты, үбәргә үрелде.

– Сагындым үзеңне, асылым!

Гөлйөзем, җен ачуы белән, бар көченә аны этеп җибәрде.

– Яныма киләсе булма! Каберем якын булмасын!

– Нәрсә булды сиңа? Ник кәҗәләнәсең?

– Син, барысына да син гаепле!

– Аңламыйм.

– Син миннән теге вакытта уйнашчы ясадың!

– Көнләштем! Ни өчен әле мин сине аңа бирергә тиеш идем?! Ул – мулла баласы, мин батрак баласы булгангамы? Син минем өчен туган. Минем өчен яшәргә тиешсең дә! Син – минеке! Аңладыңмы, минеке!

– Син – минем атамны үтерүче!

– Ялгышма! Синең атаңның башына чабата киндерәсе җитте. Нуриәхмәт ярдәм итте. Мин гомерем буе, сабый чактан алып, алардан көнләштем. Алар абыйлы-энеле авыз тутырып икмәк ашаганда, мин алабута ашадым. Алар ефәкне кигәндә, мин киндер киеп үстем. Алар абыйлы-энеле синең арттан йөргәндә, мин, читән ярыгыннан карап, гарьлегемнән үксеп-үксеп елый идем. Ниһаять, минем көн килде. Үчен алдым. Әйткән сүземдә тордым!

Гөлйөземне беләгеннән эләктереп, йолкып алып күкрәгенә кысты. Гөлйөзем бар көченә чәбәләнде:

– Кагыласы булма! Кычкырам!

– Теләгең! Ачтан үләсең килсә, кычкыр! Тик уйла! Уйла... Мотавалларга тешем үткәнне, сине генә чәйнәп төкерермен.

– Нигә газаплыйсың син мине? Минем ни гаебем бар...

– Синең беренче гаебең шул: тирә-якта сиңа җиткән чибәр юк. Икенче гаебең, чабатачы Мостафа кызы гына булсаң да, аларны хуп күрдең. Бай тормышка килен булып төшмәкче идеңме?! Уйла! Син халык дошманыннан тапкан малай үстерәсең.

Кочаклап үпте. Гөлйөзем, көч-хәл белән аннан аерылып, кеше-фәлән карап тормагае, дип, капка артынарак китеп, сыдырылып менгән итәген төшерде, чәчләрен рәтләде, шуып төшкән яулыгын төзәтеп бәйләде.

– Җитәр инде. Кеше-фәлән килеп керсә.

– Күрсеннәр! Кемнән куркыйм? Берәүдән дә курыкмыйм. Алар миннән куркырга тиеш! Үзем – мулла, үзем – староста, үзем – рәис! Кич кунарга киләм, көт! – Арслан, гайрәтләнеп, арлы-бирле йөренде.

– Юк, кирәкми! Килмә! Малайдан уңайсыз.

– Беренче тапкыр түгел. Өйрәнеп килә. Син нәрсә, бүген гел кирегә сукалыйсың? Бу сүзләрне әллә сиңа теге надан бригадир аламасы өйрәтеп чыгып киттеме? Белеп тор һәм аң бул! Синең тормышыңның иң усал дошманы – ул! Ул Нуриәхмәтне тегендә озатты. Мин түгел, мин чиста! Ул пычак кадады. Мин түгел! Аң бул! Әгәр мин әйткәнне әйтсәң, нәрсә буласын яхшы беләсең! Син – халык дошманының хатыны! Ә хәзер бар, кайт! Абзар артыңа, кычыткан арасына он ташлап калдырдым, кара аны, күреп калмасыннар. Кичкә таба аш пешер! Мәе – миннән.

– Арслан, малай үсеп җитте бит, оят...

– Беләсең ич инде. Ул селәгәйгә ат биреп, атка атландырып урам әйләндерсәң, дөньясын оныта. Әйткәнне эшлә! Әйтергә онытып торам. «Кызыл байрак» колхозының мәктәп директоры югалган иде бит. Кичә төнлә шуның хатынын алып киткәннәр.

– Безнең нинди гаебебез бар соң?

– Районда сүз гел шул турыда. Халык дошманнарының хатыннарын, бала-чагаларын гына түгел, нәсел-ыруларына кадәр җыярга, дигән карар бар, – дип масайды Арслан, корсагын киереп.

– Дөньясы да чәнчелеп кенә китми! Авылдашлар булып авылдашлар да үземне әйләнеп узалар… – дип еламсырады Гөлйөзем.

– Мин әйләнеп узмыйм бит. Мин барында курыкма! Ялгызың бик кунарга тырышма! Мин янында булганда, сиңа чебен дә тия алмас.

– Хатының, балаларың алдында оят. Рәшидәңнең нинди гаебе бар?

– Рәшидәнең кабер кадәрле авызы, шул авызын тутырып ашарга икмәге, җылы өе, йомшак урын-җире, итәк тулы мин ясаган балалары бар. Тик ятсын! Рәхәтенә чыдый алмаса, түремә сине алып кайтып утыртырмын! Вәт шул. Бар, әйткәнне үтә! – Гөлйөземнең арт санына сугып алганнан соң, тиле кеше кебек көлә-көлә, капкага атлады.

***

Арслан үзе теләгән, кызыгып йөргән кешесенә – Гөлйөземгә өйләнә алмады. Районда, тирә-як авылларда иң данлыклы кешеләрнең берсе – райком секретаре белән бер табактан ашый торган күрше Наратбаш авылы Маркс колхозы рәисе – Мәмлиев гаиләсендәге балаларның иң өлкәне – кияве үлеп бер баласы белән тол калган кызы белән шаярып, корсак ясап, үзеннән җиде яшькә олы Рәшидәгә өйләнергә мәҗбүр булды.

Мәмлиевнең бер малае шәһәрдә – обком тирәсендә, икенчесе – райкомда, бүген, иртәгә Куйбышевка партия мәктәбенә укырга китәргә йөри, өченчесе авыл хуҗалыгы институтында агроном булырга әзерләнә иде.

Кызы Рәшидә генә, нәселдә булмаганча, кеше куркырлык ямьсез, кушаматы да «Каберавыз» иде. Аяк – кырык дүртенче размер. Өстәвенә кәкре. Куллар – көрәк. Тешләре чабатадай олы авызына сыялмыйча тырпаеп тора. Җитмәсә, озын гәүдәсен кечерәйтер өчен, бөкрәеп йөри. Шулай булса да, Арсланның артка чигәр юлы юк. Рәшидәнең тылы аны куркыта иде.

Иярә килгән бала, атасы Фәтхуллага охшап, бик акыллы, чамадан тыш сабыр, исеме дә – Өмет. Исемне аңа атасы алдагы гомерен, картайган көнен уйлап, таянычым, булышчым, нәсел дәвамчым булыр, дип куйдырган иде. Гомере генә кыска булды. Рәшидәгә өйләнеп өч ел да тормады, кичтән колхозның печәнлегендә билдән кар ярып, кар астыннан печән каерып кайтты да, иртәнгә Өмете белән Рәшидәсен калдырып, мәңгелеккә китеп барды.

Рәшидә Арсланнан тагын дүрт ир бала тапса да, шул биш баласы арасында иң өметлесе, иң акыллысы – иярә килгән баласы – Өмете булды.

Арсланның анасы Мәликә дә, үз каны, үз малаеның баласы булмаса да, башка оныкларына караганда Өметне яратарак төште. Башкалар белән өстәл артына утырырга да ярамаган сабыйны үзе белән кар көрәргә, мал асты чистартырга, печән кертергә ияртеп йөрде. Арслан күрмәсен дип, печән астына яшереп куйган стаканга кәҗәсен савып, кесәсеннән сынык икмәген чыгарып, сабыйны ашата иде. Кәҗәләре ташланган вакытта, бәрәнле сарык сөтеннән авыз иттерде, кетәклектән берәр йомырка арттырды.

Арсланның дөньяда иң яратмаган беренче кешесе Рәшидә булса, икенчесе Өмет иде.

***

Арслан идарә капкасыннан чыгып барганда, чак кына маңгайга маңгай Шәмсия әби белән бәрелешмәде.

– Син икәнсең әле, җен корткасы!

– Үзебез дип торабыз, – дип, үз-үзенә генә ишетелерлек итеп, борын астыннан мыгырданды да, Арслан киткән якка карап: – Сүрәбәт! Сасы тәкә! – дип, җиргә төкереп калды.

Гөлйөзем, үз-үзен кая куярга белмичә, сулы чиләктән мунчаласын алды. Мунчаладан итәккә аккан су тәнгә үтеп кергәч кенә уйларыннан арынып.

– Исәнме, Шәмсияттәй?! – диде.

– Әйтмә инде, аяз көнне яшен сукты.

– Нәрсә булды, Шәмсияттәй?

– Галимҗан хараплар булган. Үзе генә көтүгә чыккан ди. Исереп йоклап, маллары таралган. Алты сыеры бике басуына кереп күбенеп үлгән! Үзе «Марҗа чокыры»ндагы имәнгә асылынмакчы булган. Ярый әле, эскерт куючы хатыннар күреп, кисеп төшергәннәр.

– Исән калган диме соң?

– Исән, ди. Җир тырмап елый, ди.

***

Батырҗан Галимҗан янына килеп җиткәндә, ул, башын түбән иеп, чирәмдә утыра иде.

– Нәрсә булды, ахир?

– Башка сыймаслык хәлләр монда. Беттем мин, Батырҗан. Харап булдым.

– Нишләргә уйлыйсың?

– Белмим. Нишләргә дә белмим.

– Кач!

– Кая?!

– Дөнья киң.

– Юк шул. Дөнья бик тар икән шул ул.

– Кач, дивана!

– Язмыштан качып булмый. Мин качсам, әнкәйне нишләтерләр?

Ерактан чыбыркы шартлаган тавыш ишетелде.

– Әнә үзе – Арслан килә. Мин ирек биргәндә – кач!

– Юк, качмыйм.

– Алайса, миңа үпкәләмә!

Арслан килеп җитте дә күбенеп яткан сыерларга озак кына карап торганнан соң, сызгырып:

– Әйе! Ишкәнсең син монда ишәк чумарын! – дип, Галимҗанга чыбыркысы белән китереп сыдырды. – Мә, дуңгыз, ал кирәгеңне! – Тагын сыдырды. – Мә, сволочь!

– Үтерегез мине. Мин, мин гаепле. Тик өтермәгә генә озатмагыз. Үз авылымда, үз нигеземдә үләсем килә, – дип, Галимҗан еларга тотынды.

Арслан чыбыркы сабы белән Галимҗанның иңсәсенә китереп сукты.

– Син алты сыерга түгел, сасыган кәҗә тәкәсенә дә тормыйсың. Мине шушы сыерлар аркасында эштән кудырмакчы идеңме?

Галимҗан Арслан алдына тезләнде.

– Тизрәк үтерегез! Чит-ят җирдә җан тәслим кыласым килми. Үтерегез, үтер! Тик азапламагыз гына.

– Кара син аны, үлеп котылмакчы була, – дип, Арслан аңа тагын чыбыркы белән сыдырды. – Мә, Нуриәхмәт көчеге! – Тагын сыдырды. – Мә, Нуриәхмәт куштаны! – Җирдә яткан Галимҗанны типкәләп: – Батырҗан, нәрсә карап торасың! – дип акырды.

– Арслан, җитте, үтерәсең.

– Шул кирәк аңа. Дөмексен!

– Җитте, җитте, Арслан. Җитәрлеген алды. Аның закун алдында җавап тотасы бар. Самасуд ясаган өчен баштан сыйпамаслар, – диде Батырҗан.

Арслан чыбыркысын Галимҗан өстенә ыргытты.

– Батырҗан, бар! Минем атка атланып кайт та районга шылтырат! Милиция җибәрсеннәр.

– Була ул!

Арслан Галимҗан янына килде.

– Селәгәй! Хәзер Нуриәхмәт дустың янына озатабыз.

– Монда мин генә гаепле түгел. Минем атна-ун көн йоклаганым юк. Арслан, мин сиңа үземне алыштырырга көтүче сорап күпме ялындым.

– Алдашма! Ник алдыйсың. Мин сиңа алмашчы бирмәкче идем. – «Юк! Миңа акча кирәк! Мин йокыны савым вакытында, сыерларны утарга япкач та йоклыйм», – дидең. Минем бер гаебем дә юк. Син үтергән сыерлар өчен нишләп әле мин җавап тотыйм, ди.

Береаздан көтүлекне авыл халкы сырып алды.

– Мин гаепле түгел, шулай бит, авылдашлар? Шулай бит, Нурислам абзый, Мөхәррәм, Мофаззал туган?

– Шулай, шулай.

– Тынычлан, олан, тынычлан.

– Мине придсидәтеллектән алырга хаклары юк, шулай бит, авылдашлар?

– Шулай, шулай.

Артта астыртын гына мыек астыннан елмаеп торган Шәрифулла:

– Шулаен шулай да... «Ну»сы бар бит әле аның, егетләр, – диде.

– Нәрсә?! «Ну»сы бар?

– Бу күбенгән сыерлар өчен район хуҗалары алдында көтүче җавап тотмый. Придсидәтел җавап тота. Менә мин үзем, ундүртенче елда, герман сугышында...

– Шәрифулла, әллә сугышта көтү көткән идеңме?..

– Көтсәм нәрсә әйтерсең, Мофаззал? Армияне дә ашатырга ит кирәк, сөт кирәк.

– Күкәй, йомыркалар да кирәк. Син сыер белән кәҗәне бутама инде, Шәрифулла, – дип авыз ерды Арслан.

– Мин бутамам, Арслан. Менә хәзер син бутама инде. Синең җавап тотасың бар. Бәлки, ул сыерлар карданы җимереп чыгып, басуга үзләре кергәндер. Аларның карда җимергәнен бер-ике-өч кеше күреп тә калганнардыр.

– Күрми торсыннар әле.

– Нигә алай дисең? Сез бит Галимҗан белән – агылый да тагылый. Атай тапкан мал түгел, калхузныкы җәл түгел, дисез дә...

– Дими торыйк әле. Миннән дә котыласың киләме? Котылмый тор әле. Тиз генә төрмәгә озатыр идең бугай!

***

Галимҗанны ул көнне алып китмәделәр. Колхозның каравыл йортына бикләделәр.

Каравыл йорты дигәне – кечкенә генә, ярым җиргә чокып эшләнгән, мүкәләп

үк булмаса да шактый иелеп керә торган, салам түбәле, ел әйләнәсенә бер кочак утын күрмәүдән, салкыннан, бәстән акшарлары коелып, урыны белән бармак сыярлык тишекләр хасил булган кечкенә генә мичле, куш йодрык сыярлык тәрәзәле, кырыйда, бер як стенага терәп, ышкыланмаган тактадан эшләнгән булса да, язын-көзен бирегә җыелган ир-атларның каешланган бушлат, сырмаларыннан шомарып ялтыраган сәкеле, стеналарына, түшәм такталарына кадәр тәмәке, махорка исе сеңгән, сасы, тынчу һавалы, идәнсез бер йорт...

Галимҗан, мин беркая да качмыйм, минем качар урыным юк, дип ялынса да, авылның яңа гына мыек чыгып килә торган ике яшүсмер-җилбәзәген сакка куйдылар.

Арслан, эш кырган, дөнья җимергәндәй, кичкырын, караңгы төшкәч кенә өенә кайтып, ишегалдында атын тугарды да арбасына бәйләп, солы салды. Өенә керде. Ишек катындагы сәкегә утырып, көне буе аягыннан төшмәгән кирза итеген салырга дип, уң итегенең үкчәсен икенче аягындагы итеге очына гына терәгән иде, балалары кайсы каян йөгереп чыгып, аталарының итегенә ябыштылар.

– Китегез әле, эт себергән нәрсәләр! Болай да аякны аякка куярлык та хәлем юк, сез аякка асылынасыз, – дип, балаларын тибеп очырды.

Мич артында сулыш алырга да куркып торган хатыны:

– Шул сабыйларны күралмадың инде. Мине каһәрләсәң дә, анда бит синең дә өлешең бар. Мин генә тудырмаган лабаса аларны... – дип дәште.

Арслан, кабалана-кабалана, көч-хәл белән уң итеген салып, хатыны тавышы килгән якка – мич арасына ыргытты.

– Ат тугару, ат җигү – әнә тегендә күзле бүкән кебек басып торган мөртәтең, бирнә булып килгән малаеңныкы булса, итек салдыру, аякны юу – синең эш! Бәреп үтергәнче итекне тарт!

Рәшидә итекне салдырды. Өйгә әчкелтем ис таралды. Мәликә, килене кулыннан итекне алып, җиңе белән итек йөзен сөртә-сөртә, киптерергә куярга дип, мич арасына алып кереп китте. Арслан сәкенең түренә – өстәл кырыена күчеп утырды. Мәликә, мич арасыннан чыгып, мичтән чүлмәк чыгарды да улына аш салды. Күкрәгенә терәп, икмәк кисте. Агач кашык сузды.

– Ул баланы берәр ничек коткарып буладыр... Галимҗанны әйтүем. Үз теләге белән кылган гамәле түгел – язмыш!

– Синнән сораган кеше юк! Үз эшеңне бел!

– Дуслар идегез. Бергә үстегез.

– Ярар, булды! Телеңә салынма! Тынычлап ашыйм әле! – дип акырды Арслан, алагаем капкан икмәген көч-хәл белән чәйнәп. – Бар да акыллы! Мин генә дивана!

Мич башыннан аның авызына карап, ул капкан икмәкне чәйнәмичә дә йотардай булып, күзләрен мөлдерәтеп торган ач сабыйларына күтәрелеп тә карамыйча, бер түгәрәк икмәк белән ярты чүлмәк ашны ашап куйганнан соң, литр ярым кәҗә сөтен күтәреп чөмерде дә:

– Сиңа әйтәм! Рәшидә! Минем артка сырмамны ыргыт әле?! – диде.

Аркасына килеп бәрелгән сырмасын сизүгә, сәкегә ауды. Бераздан кечкенә йортның кечкенә тәрәзә пыяласы гырлау авазына кушылып зыңлый башлады.

Күпме йоклагандыр, «Галимҗан качкан!» дигән тавышка сискәнеп, күзләрен ачты. Тавыш кабатланырмы, юкмы дип, тын алырга да кыймый ятты. Кабат ишетелгән тавышка торып, шул якка борылды. Тәрәзәдән күренгән йөзләрне күреп, күгәренде, чырае качты. Аннан соң хатынына акырды:

– Сиңа әйтәм! Итекне китер!

Галимҗанны кемнәр генә эзләмәде дә, каян гына килеп эзләмәделәр. Һәр йортның чормасын, кура-каралтысын, базын, мунчасын тикшерделәр. Авыл янәшәсендәге урманның һәр метрын, һәр агач төбен җентекләп актардылар. Табалмадылар. Әйтерсең лә Галимҗанны җир йотты! Аның кайдалыгын бер Кәҗә Шәрифулласы гына белә, ул гына Галимҗан белән көн дә күрешеп, көн дә сөйләшеп, аралашып тора, имеш... Кичә, кичкырын, ул аны урмандагы «Дәүләт чокыры»нда күрсә, бүген... янәсе, фермада күргән.

Арслан, Кәҗәнең һәр сүзе ялганнан гына торганын белсә дә, аның бу сүзләрендә өлешчә хаклык булырга да мөмкин, дип, сыер савучыларның Галимҗан качканнан бирле сыерларының сөтләре кимү зарын ишетеп туйганга күрә, төнен, качып, ферманы сакларга булды. Ферманың түренә, сыерлар бәйләнмәгән өлешенә, улакка салам түшәп кереп ятты. Төнге икеләр тирәсендә, «булмады бу, килмәде бу» дип, кайтырга гына җыенган иде, капка шыгырдады. Арслан янәдән улакка сузылып ятты. Ярымкараңгы фермага бер адәм керде дә, як-ягына каранып, ферма эчен күзәтеп, тикшереп алганнан соң, бер сыерның кырыена килеп утырды. Бармак арасыннан саркып, сыгылып чыккан сөт агымы, буш чиләкнең төбенә бәрелеп, сыерларның күшәгән, мышнаган авазларына кушылып, үзенә генә хас көй чыгарды. Фермага сөт исе таралды. Арслан торып басты. Янәшәсендә тирескә кадап куелган сәнәкне алып, әкрен генә тегенең янына килде. Сәнәкне тегенең аркасына терәде.

– Үтәли тишкәнче торып бас!

Ярымкараңгыда шәүлә курка-курка гына торып басты һәм Арсланга борылды. Арслан куркуыннан артка чикте, катып калды. Озак кына телсез торганнан соң, тотлыгып:

– С... с... ин?! – диде.

Бу – Галимҗан түгел иде...

***

Галимҗан өч-дүрт көн дәвамында урманда үлән тамырлары ашап ашказанын алдарга тырышса да, ачлык үзенекен итте. Күзен йомса, йортында, мич авызында, анасының майланып, ысланып каралган чуен чүлмәгендә, чемер-чемер, сүлпән генә чыпырдап кайнап утырган ашы күз алдына килде.

Түзмәде, кара төн уртасында калын урманның уч төбе кадәрле кечкенә генә бер аланында пошиларга дип әзерләнгән печән чүмәләсеннән чыгып, авылга юл тотты. Авыл читендәге сыер абзарына килеп бәрелүгә, борынын кытыклаган сөт исе фикерен үзгәртте. Урамга керү үзе өчен бер хәтәр булса, бусагасын атлап керү – икеләтә, анасы өчен дә куркыныч янаганын аңлаган качкынның уендагы чуен чүлмәге, эреп, сыер имчәгенә әверелде.

Галимҗан сак кына абзар ишеген ачты. Абзарның ишек катында, сыер астына чүгәләп утырган Мәликә карчык, бармаклары арасыннан гына саркытып, чиләккә моң, үзенә генә хас муллык, хөрлек, ач кеше өчен хөррият көе итеп, сөт агыза иде.

Ике ачның карашы очрашты. Галимҗан абзар ишеген япмакчы, Мәликә урыныннан тормакчы булды. Катып калдылар. Йөзләрдә – агарыну, күзләрдә яшь иде.

***

Галимҗан качканнан соң ай ярым тирәләре үткәч, Арсланның тәрәзәсен шакыдылар.

– Кем бар анда?

Тыштан аңлаешсыз тавыш ишетелде:

– Сүзем бар. Чыккач күрерсең.

Анасының үзенә текәлгән сораулы карашына:

– Каян белим! Син дә минем белән бергә утырасың лабаса! Тавышыннан кем икәнен таныдыңмы соң?! – дип акырды.

– Чыга күрмә! Бу вакытта юньле кеше йөрми, – диде анасы.

– Синнән сорап торырмын! Йокла!

Арслан чыгып китүгә, Мәликә аяк очларына гына басып бусагага килде дә, ишекне аз гына ачып, колагын ишек ярыгына куймакчы булды. Тыштан Арслан бар көченә ишеккә типте, Мәликә аздан гына башын алып өлгерде.

– Җенле! Дивана! Тугач та мендәр каплыйсы нәрсә! – дип мыгырданды карчык, коты чыгып.

Тышта ике ир-атның ара-тирә аңлашылып, ара-тирә өзелеп киткән өзек-өзек бәхәсләшкән тавышлары ишетелде.

Мәликә күпме генә икенче кешенең кем икәнлеген белергә тырышса да, белә алмады.

Береаздан тавыш тынды. Малае да, ят тавыш та юкка чыкты.

Ана төне буе йоклый алмады. Тәрәзәдән тәрәзәгә йөреп, улын көтте. Арслан кермәде.

Шәрифулла Арсланга, төн уртасында Галимҗанның үз нигезенә кереп киткән, хәбәрен җиткерергә килгән иде.

Таңга Галимҗанның ихатасын районнан килгән милиционерлар чорнап, әйләндереп алган иде инде. Арсланның иртәнге таң тынычлыгын бозып акырган тавышына көтү куарга дип торган халык, берәм-берәм, Галимҗан нигезенә җыела башлады.

– Галимҗан, кулларыңны күтәр дә үз теләгең белән чык! Юкса!

Йортның чормасыннан Галимҗанның башы күренде:

– Нәрсә?! Юкса!.. Нәрсә эшләтерсең?! Мин дә синең кырын эшләреңне бик яхшы беләм, Арслан!

– Нәрсә беләсең, нәрсә беләсең?! Селәгәй!

– Төннәрен колхоз фермасында нинди эшләр майтарганыгызны халыкка сөйләсәм, синең эшләр минекеннән дә куркынычрак.

– Сөйлә! Әллә куркыр дисеңме?!

– Юк инде. Сине кызганмасам да, аларны кызганам. Мин синең кебек кансыз түгел. Миңа ул балаларның зыяны тигәне юк.

– Нинди балалар турында сөйлисең син, имгәк?!

– Шаярма! Диванага сабышма! Бик яхшы беләсең.

Районнан килгән милиция капитаны Шәмсиев пистолетын чыгарып һавага атты.

– Гаепләнүче! Хәзер үк үз теләгегез белән кулыгызны күтәреп бирегә чыкмасагыз, без сезгә турыдан-туры һөҗүм ясаячакбыз.

– Кемгә?! Миңамы?!

Галимҗан мылтыгын корып, аякларын иңсәсе киңлегендә аерып, чормадан өйалды түбәсенә чыгып басты. Уң кулындагы ике көпшәле ау мылтыгын күккә

төзәп атып җибәрде. Каты шартлаудан куркып, Исрафиллар карамасына кунган карга көтүе кара болыт булып авыл өстен каплады.

– Кемгә атасыз?!

Күкрәгенә акбур белән ясалган кеше сурәтенә күрсәтеп:

– Линингамы?! – Арты белән борылып, аркасына ясалган кеше сурәтенә күрсәтеп: – Сталингамы?! Сайлагыз! Һәм атыгыз! Көтәм! Ник атмыйсыз?! Җыелган халык сезнең хөкемегезне көтә! Кулыгыз калтырыса, алтатарыгызны Арсланга бирегез! Арслан, ат! Бу мәсьәләдә синең кулың калтырамый. Син бит – Сталин мәсьәләсендә азау теше чыгарган кеше! – дип кычкырды.

Районнан килгән милиционер Шәмсиев, алга ук чыгып:

– Яхшы. Димәк, үз теләгең белән бирелмисең. Тудырган анаңны кулга алам! – дип акырды.

– Кирәкми! Кирәкми, бирелә́м!

Галимҗан түбәдән төште. Ике милиционер, ике яктан килеп, аның кулларын каерып тоттылар.

– Сау булыгыз, авылдашлар! Минем карт анамны какмагыз! Мин сезгә зыян салган булсам да, аның сезгә тырнак очы кадәрле дә начарлыгы тигәне булмады. Озак яшәмәс. Адәм рәтле җирләгез. Йорт-каралтысы бер кәфенлек кенә булыр әле. Сау булыгыз! – дип кычкырды ул, абына-сөртенә артына борылып карап.

***

Батырҗан, көне буе үзенә урын табалмыйча, үз-үзен кая куярга белмичә, караңгы төшкәнен түземсезлек белән көтте. Арсланның Гөлйөземгә булган мөнәсәбәте, Галимҗанны җиңел генә төрмәгә озатуы аны тәмам чыгырыннан чыгарган иде. Ул Гөлйөзем белән аңлашырга дип, йә «юк», йә «бар!» дигән сорауга җавап эзләп, караңгы төшкәч, Гөлйөземнең тәрәзәсе янына килде. Сак кына тәрәзә шакыды.

– Кем бар анда?

– Мин идем әле бу, Гөлйөзем.

– Төн уртасында нишләп йөрисең?

– Ни бит… Теге… Йомышым бар  иде. Ишегеңне ач әле.

– Көндез, яктыргач килерсең.

– Бик ашыгыч йомыш иде. Ач инде!

– Ачмыйм. Улымны йокыдан уятасың.

– Ач инде, Гөлйөзем!

– Соң инде. Без йоклыйбыз.

– Ач инде, Гөлйөзем!

– Ачмыйм! Шакыма да, ачмыйм!

– Ач инде.

Шулчак ишектә ап-ак эчке киемнәрдән, ярсыган, ачулы Арслан күренде. Арслан, биленә таянган килеш:

– Ачам мин сиңа хәзер! Исән чакта бу ишегалдыннан үкчәләреңне күтәр! Юкса!.. – дип ысылдады.

– Син?! Арслан!

– Әйе, мин!

– Өркетәсең?

– Күп телеңә салынма. Сиңа гына тешем үтәр!

– Менә син нинди икәнсең!

– Нинди?

– Аңлашылды...

– Аңлашылса, кайт та анаңның сәләмә юрганы астына кереп ят!

– Ашыкма! – Итек балтырыннан пычак чыгарды. – Мин сиңа Нуриәхмәт белән Галимҗан гына булып калмам. Мин синеме, мин сине...

– Нишләрсең?! Бер генә адым атла. Иртәгә үзеңне нишләтергә кирәген белермен!

– Нуриәхмәттән котылдың, Галимҗанны үлгәнче кыйнап озаттың, хәзер минме?!

– Синең чират! Сталин, Сталин портретын онытма. Юкса…

– Ах, син шулаймы?

Ай яктысында пычагы ялтырады.

– Арслан, сак бул! Кулында пычагы бар!.. – дип, ачыргаланып кычкырып җибәрде Гөлйөзем.

Батырҗан кадамакчы булды, Арслан, койма аша сикереп, урамга чыгып чапты. Гөлйөзем Батырҗанның биленнән кочаклап тотып калды.

– Батырҗан, акылыңа кил. Ташла пычагыңны!

Батырҗан Гөлйөземне төртеп җибәрде. Гөлйөзем баскыч төбенә егылып китте.

– Ах, син, себерке! – Очып янына барды, чәченнән тотып сөйрәп торгызды. – Сиңа мин ярамадыммы?! Сиңа өйләнгән, күп балалы Арслан кирәк булдымы?! Сиңа иреңнең башына җиткән Арслан кирәк булдымы?! Мә, фахишә! Мә, себерке! – дип, Гөлйөземнең аркасына пычак кадады. Бераз аңсыз басып торганнан соң, һушына килеп, алпан-тилпән атлап чыгып китте.

***

Гөлйөземне Арслан аты белән тиз арада район хастаханәсенә озаттылар. Пычак умырткасына эләккәнлектән, хәле бик авыр булу сәбәпле, район хастаханәсендә озак тотмыйча, калага күчерделәр. Өч айдан соң, бүтән аягына басалмаячак, дип, авылына кайтардылар. Шул өч ай эчендә Мифтах, Мәсрүрә гаиләсендә, Ислах белән тарткалаша-тарткалаша ашап, күзгә күренерлек булып үскән, Ислах белән туганлашып беткән иде. Кайчакларда матур гына уйнаган җирләреннән бәргәләшеп тә алалар. Кайчан гына карасаң да, Мифтах – өстә, Ислах, үкерә-үкерә елап, аста ятар иде. Мәсрүрә аларны аерып, икесен ике тез башына утыртып тынычландыра, артларыннан чәбәкләп сөя, үгетли...

– Әй улым, улым, Ислахетдинем. Җиңәме? Җиңәдер шул. Ул бит башка орлыктан, ә син... Әниеңә орлык сайларга бирмәделәр шул. Комы коелган, шәлперәйгән картка көчләп бирделәр. Ә бу – алпавыт...

Мифтахны арт санынннан сөеп:

– Тутырган тавык, әй лә, әтәч... Суйган да каплаган, төшләремә кереп газаплаган, күзем йомсам, күз алдында басып торган нәкъ үзе инде, – ди.

Мәсрүрә Гөлйөземне ташламады. Нигәдер үз итте. Әллә Гөлйөзем Мотаваллар «килене» булганга, әллә үзе яшьтән Мотавал малайларына гыйшык тотып, бигрәк тә Галиәхмәткә мөкиббән булгангамы, Мифтахны күрүгә, Галиәхмәткә охшатса да, минем Мотавалым кайткан, дип, кечкенәдән алдына утыртып сөя торган булды.

– Мотавал өендә генә рәхәттә, оҗмахта яшәдем мин. Ул гына мине өрмәгән урындыкка да утыртмады. Мотавал өендә генә туйганчы икмәк ашадым мин. Үлгән булса, урыны – җәннәттә, авыр туфрагы җиңел булсын. Догамнан аны да, килендәшем Мөсәгыйдә абыстайны да калдырганым юк. Анысы да, көндәшем, дип тормады, үз баласыдай күрде, – дип сөйли иде.

***

Әгәр сугыш чыкмаган булса, төрмә Нуриәхмәтнең башына җиткән булыр иде. Аның гомерен, бәлки, сугыш саклап калдыргандыр да. Имгәнгән аягы аркасында сугышка – алгы сызыкка, штрафбатка җибәрә алмаганга, хөкем җәзасын җиңеләйтеп, аны төрмәдән оборона заводына эшче көчләр җитмәгәнгә күрә, эшкә озаттылар. Ул анда тимер кырды. Ачлыктан кешеләр үлгәндә, аның кулында паёк иде. Сугыштан соң, хөкем җәзасы беткәннән соң гына, авылына кайтып егылды.

Теге вакытта, Нуриәхмәт Себергә озатылганда, узып барган товар вагонының әз генә ябылып бетмәгән ишек ярыгыннан сәер карашны тоеп, өнсез калып, ачыргаланып:

– Әткәй! – дип кычкырган сүзләре, атасы утырган поездның аңа бәрелеп диярлек каршысыннан узып китүе, вакытлар үткән саен, аңа сәер булып тоелды.

Ул – Себергә! Ә атасы кай тарафка китте соң?! Бәлки, абыйсы Галиәхмәт теләгән, хөрмәле яккадыр?

Шул вакытта атасын утырткан поездга ияреп ник чапмаска?! Ул поездны куып тоталмаса да, сакчының ядрәсе аны куып тотар, атасы аны үз куллары белән җирли алмаса да, күңеле белән, бәхиллеген биреп, ясин чыгып җирләр иде бит!

Атасы Мотавал белән анасы Мөсәгыйдә авылдан сөрелгәч, кайда яшәгәннәр, үзләрен кем алып кайтып җирләгән, Галиәхмәтләре кая, кайда җирләнгән?..

Шул сорауларга җавап табалмыйча, дөреслекнең йөзенә карый алмыйча, кыйналып, тапталып, куылып, себерелеп, сөргеннәргә сөрелгән, үз канаты астына алып, яманат күтәртмим, уйнаштан бала тапты, дигән исемен чыгартмыйм, дип, күзенә генә карап торган Гөлйөземенең дә гомере буе Галиәхмәт чыгып киткән якка карап тилмергәнен, сулганын күреп Нуриәхмәт сөйләшмәс булды. Аның сөйләшер, сер сыяр кешесе юк иде. Шуңа ул үзе теләп телсез-чукракка әйләнде.

***

Урау юллар үтеп, илле өчнең караңгы, кар катыш яңгырлы көзендә авыл урамына култык таягында, аркасына капчык аскан, сыңар аяклы Галимҗан да кайтып керде. Ул төрмәдән штраф батальоны белән сугышка эләкте. Менә-менә сугыш бетә, дигәндә генә, Берлин янында яраланып, аягын өздерде. Аннары – унбер ай буе госпитальдә. Калганын башкаларга сөйләргә курка, яшерә иде. Сугышка эләккәннән соң, өч көн дә сугышмыйча әсир төшүен, аннан качып теләсә кайда кача-поса, айдан артык ачлы-туклы салам өеме төпләреннән тычкан тотып, шуның белән җан асрап, фронт сызыгын үтеп, үзебезнекеләр ягына эләгүен, сорау алулар, кыйналуларны, кабаттан штраф батальоны белән сугышка керүен авылда бер генә кешегә – Нуриәхмәткә, чукрак түгел икәнен белсә дә, «чукрак»ка сөйлим дип, курыкмыйча, шикләнмичә, бүтәнгә чыкмаячагына тәмам ышанып сөйли иде.

Шул ачы язмышы, әсирлеккә төшүе аркасында, гомере буе пенсия күрмәде. Тугызынчы май – Җиңү көннәрендә фронтовикларны бәйрәм мәҗлесләренә чакырганда, ул аларны, таягына таянган хәлдә, яшьле күзләрен мөлдерәтеп, бугазына утырган төерен йотарга да кыймыйча, койма ярыгыннан карап озатып кала иде.

Алар кайтканда, ул инде берәр кешенең ташландык абзарында йә булмаса колхозның каравыл йортында, тимерче алачыгында исереп аунап ятар, бәйрәмнән соң авылдашларының: «Син кичә нигәдер бәйрәмдә күренмәдең?» – дип, авырткан җирен чеметергә теләп биргән сорауларына, сөялләнгән бәгыреннән чыгарып:

– Сез бәйрәм итеп йөргәндә, мин Берлинны алып йөрдем, – дип шаярткан була иде.

Чыннан да, ул – авылның сугыш чоңгылында кайнаган, үлем белән якалашкан бердәнбер фронтовигы иде. Авылга кайтканчы, кечкенә генә бер шәһәрнең тимер юл вокзалында, яраларының сызлавына чыдый алмыйча бер ярты аракыга саткан күкрәк билгесен генә күрсәләр дә, авылдашлары аның хакында нәрсә уйларлар иде микән?!

Шулай, Галимҗан авылына илле өчнең карлы-яңгырлы караңгы көзендә, көн төнгә авышып килгәндә кайтып керде.

Нигезендә аны җир астыннан очлары гына тырпаеп чыгып торган идән асты бурасы, бураның берничә кара бүрәнәсе һәм салкын җил белән көрәшеп, сызгырып утырган корыган алабута, кычыткан таяклары гына каршы алды.

Галимҗанның күзе яшьләнде. Бугазына төер утырды. Күз алдына сабый чагы килеп басты. Әнә түбәндәрәк, ихатаның аскы өлешендә, уң яктарак – абзарлары. Әнисе Мөнәвәрә кәҗәләрен сауган да чыгып килә. Кулындагы сөтле савытын аңа суза. Әнә Батырҗан атасының малларына сүгенеп акырган тавышы ишетелеп китә. Алар – Галимҗаннардан өч кенә өй аша.

Ул бүрәнәгә утырды. Махорка төрде. Уйга батты. Нигә кайтты ул?.. Нәрсә өчен?.. Шушыларны күрергәме?.. Үзен күрсәтергәме?.. Үзен кызгандырыргамы?.. Үзенең барып чыкмаган тормышын сөйләргәме?..

Бәлки, кеше-фәлән күргәнче, китеп өлгерергәдер. Бу караңгы карлы-яңгырлы төндә сыңар аяк белән станциягә кадәр ничек сөйрәлергә...

Тәүге тапкыр елап аваз салган авылында баш очыңа салып ятарлык салам мендәрең дә, тупсасына башыңны төртеп йоклап чыгарлык чыбык очы туганың да булмый торып, нигә кайтырга, нигезеңдә шушы тырпаеп торган бүрәнәгә асылынырга бил каешың да булмый торып, нигә яшәргә иде?

Яшәү үлемнән көчлерәк. Батырҗанны күрү, аларда куну нияте белән, шулар нигезенә атлады. Әмма анда аны Батырҗаннарның ярым ишелергә торган, тәрәзәләренә аркылы такта сугылган йортлары гына каршы алды. Бәгырьләргә үтеп кергән рәхимсез салкын җил, озак басып торырга ирек бирмичә, аны Арслан ишек төбенә алып килде. Ишек шакыды. Ишек ачылып, өйалдына чыккан хуҗаның:

– Караңгы, шыксыз төндә нинди көтелмәгән кунак?! – дип мыгырдаган тавышы ишетелде.

Галимҗан үзенә таныш тавыш ишетеп, шатлыгыннан, кабыгыннан чыгардай булып:

– Мин, мин әле бу, Галимҗан! – дип кычкырды.

– Мин андый кешене белмим.

– Ничек белмисең, ничек?! Бу – мин, Галимҗан!

Арслан:

– Юк, юк! Мин бернинди дә Галимҗанны белмим. Капканы ябып чык! – диде дә кереп китте.

Галимҗанның: «Арслан, Арслан!» – дигән тавышы ишегалдында бүленеп калды.

Аның соңгы өмете дә чәлпәрәмә килде. Аңа хәзер, ничек кенә булса да ышык урын табып, таңга кадәр баш төртергә, төн уздырырга, таң белән станциягә китәргә кирәк иде.

Таңга җир өстен кар каплаган иде. Мәсрүрә, торып, кәҗә-сарыкларының тиресен чистартып чыгарды да, малларына печән биргәнче дип, көянтәсенә

чиләкләрен асып, турыдан гына – Арсланнар тыкрыгыннан чишмәгә юл тотты. Арсланнарның абзарына җитәр-җитмәс...

– Шушы сәнәк белән чәнчегәнче күземнән югал! Мин бернинди дә Галимҗанны белмим! Минем өчен Галимҗаннар, Батырҗаннар юк! Минем өчен алар үлде, бетте! Күземнән югал! Тапкан кая кереп йокларга! Җылыга, сарыклар янына кереп яткан! Бар, бар, үкчәләреңне күтәр! Кеше-фәлән, күрше-күлән күреп калса... Башны Себер җибәрерсең, – дигән тавыш ишетелде.

Мәсрүрә, үзен күрмәгәйләре дип, абзар артына ышыкланды. Абзардан, тыйтак-тыйтак атлап – Галимҗан, ә артыннан, сәнәк тотып, Арслан чыкты.

– Әйдә, әйдә, агай-эне! Синең белән алыш-биреш өзелгән! Юлыңда бул! Әнә Ходай Тәгалә үзеңә ак юл теләп, ак җәймә җәеп куйган. Кәбестә ашагандай, ак карны шыгырдатып, тыйтак-тыйтак атлавыңны бел!

Галимҗан бер сүз дә дәшмәде. Абзар түбәсеннән кар алып, бер-ике тапкыр битен уды да, караңгыдан чыгып ап-ак карда чагылган күзләрен яшерер өчен баш киемен батырыбрак киеп, урамга чыкты. Арслан капкасын япты. Галимҗан, озак кына барыр юлына карап торганнан соң, гәүдәсе белән борылмыйча, башын аз гына уң як иңсәсенә борып:

– Тегеләр исәнме? – дип сорады.

– Исән!

– Барысы дамы?

Арсланның тәне эсселе-суыклы булып, маңгаена тир бәреп чыкты. Тиз арада үзен кулга алып, мактанырга теләп:

– Бишесе дә!

Галимҗан сукмак буйлап тау астына төшеп китте. Арслан, ул киткән якка карап, үз-үзенә:

– Исән. Бишесе дә исән. Әнкәй генә – әбиләре генә үлде. Нинди егет!.. Нинди кеше иде!.. Типсә тимер өзәрдәй, барыбызны, бөтереп, бер тишеккә тыгардай егет иде. Гаепләмә, туган, гаепләмә. Алдыңны-артыңны карап яшәмәсәң, бу дөньяда аягыңны гына түгел, башыңны да югалтасың, – дип сөйләнде.

Мәсрүрә, Арсланның кереп киткәнен генә көтеп торды да, яшеренгән җиреннән чыгып, көянтә-чиләкләрен эләктереп, чишмәгә йөгерде. Чиләкләрен тутырып су алды да, бөгелә-сыгыла, арт санын уйнатып, турыдан гына кистереп, Галимҗан алдына килеп басты. Танымаганга салышып:

– Безнең авылда нинди таныш түгел кеше йөри? – дип сорады.

– Мин – күрше авылдан. Сезнең авыл аша тимер юл вокзалына юл тотам, – диде Галимҗан, тамагын кыргалап.

– Башта, миңа сугылып, чәй эчеп чыгар идең.

– Рәхмәт! Барыр юлым шактый. Аннары, буран да чыгарга тора.

Мәсрүрә, як-ягына каранып, кеше-фәлән юклыгына инангач:

– Юк инде, Галимҗан абзый. Мондый, сугыштан соң ирләрне чыра яндырып эзләп тә табып булмый торган авыр чорда, өстеңә ябынып ятарлыгы да калмаган кырыкмаса кырык ямаулы хәерче бушлатын да чыгарып ыргытырга җәлли торган кытлык заманда, синдәй кешене кулдан ычкындыраммы соң?! – диде.

– Син кем соң?

– Әллә танымыйсыңмы, Галимҗан абый? Бу – мин! Мотавал хәзрәтнең яшь бичәсе, авылыгызның яшь абыстае, Миркасыйм өчен карт хатын булсам, Арслан өчен сөяркә идем. Синең алыштыргысыз хатының булырмын, – диде.

– Минем белән нишләмәк буласың?

– Ябынып ятмак булам.

Галимҗан, сул аягы урынындагы агач түмәренә карап:

– Ябынырлыгым калгандыр дип уйлыйсыңмы? – дип күрсенде.

– Дөньясына үч итеп, Арсланнар көнләшерлек итеп яшәрбез. Мин сине өрмәгән урынга да утыртмам. Сиңа тәрбия кирәк. Хатын-кыз тәрбиясе.

– Минем әни карчык кай тарафкарак җирләнде икән?! Укый белмәсәм дә, күңелдә булганнарны бушатып, баш киемемне салып, күрсәткән кайгы-хәсрәтләрем өчен гафу үтенеп китәр идем.

– Алып барырмын. Чәйләп алырбыз да алып барырмын.

Мәсрүрә, кайтып керешкә, Галимҗанның каткан сырмасын салдырып, мич башына киптерергә җәйде. Аяк киемен салдырды. Агач түмәреннән ясалган протезына ябышты. Галимҗан, салмаска тырышып, җан-фәрман карышса да, хуҗабикә ничек итсә итте, хәйләләде, ачуланды – түмәрне салдырды. Протез асты чеп-чи ит, кап-кара кан иде. Мәсрүрә курыкмады, чирканмады, тубыктан өстә киселгән аякны кочаклап, Галимҗанның күзләренә мөлдерәтеп карап, яшь аралаш:

– Борчылма, борчылма, җаным! Без аны синең белән рәткә кертәбез. Мин синеме?.. Мин сине... – диде.

Галимҗан алдына табак китереп куйды. Мич артындагы казаннан су салып, үз терсәген тыгып, суның җылылыгын тикшерде. Исән аягын шул суга тыкты. Мәсрүрәнең кул бармаклары Галимҗанның аяк бармаклары арасына кереп адашты. Галимҗанның күзеннән яшь атылып чыкты. Гәүдәсен каз тәне каплады. Уң кулы белән, астымны юешләдем бугай, дип, чак кына ят җиренә үрелмәде. Күңеле тулды. Гомерендә беренче тапкыр үз тәнендә чит кеше – хатын-кыз кулының җылысын, назын тоеп, кайбер җире уянгандай булды. Үкереп, үксеп елыйсы килде. Елый алмады. Каткан бәгыре еларга ирек бирмәде. Күзендә – яшь, йөзе – көләч иде. Читтән карап торучыга ул тиле кешене хәтерләтте. Мәсрүрә кунагының аягын юганнан соң сәкесенә сузып яткырды, бил каешын ычкындырып, балагыннан тартып, чалбарын салдыра башлады. Кунак карышмады. Чалбар төбе тезгә җиткәч, чөйдән чүпрәк алып, кунагының оят җиренә каплады. Аяк юган суны мич арасындагы чиләккә түкте, табакны чайкап, өзелгән аяк астына куйды. Мич арасыннан кер сабыны алып чыгып, мич алдындагы комганнан су агызып, аякны сабынлап юды.

– Түз, түз, җаным! Син мондый авыртуларга күп түзгәнсеңдер инде. Хәзер мин синең ярана сырганак мае сөртәм. Ялап ала ул синең яраңны. Түз, түз, җаным! – дип сөйләнеп, мич арасыннан йомшак чүпрәк алып чыгып яхшылап корытканнан соң, ярага май сөртте.

– Батырҗанның хәбәре бармы? Исән микән? – дип сорады Галимҗан, каушаудан көч-хәл телен әйләндереп.

– Батырҗан абыйны алып киткәннән соң, хәбәре дә, кайтканы да булмады. Суга төшеп югалгандай юк булды. Сафурәттәй генә – анасы – акылдан шашардай булып, гомере буе тилмереп көтсә дә, улын башка күрә алмады. Мәрхүмәне: «Үзе ачка катып үлсә дә, чоланыннан капчык-капчык ярма, поты-поты белән он чыкты, киптерергә эленгән дару үләннәре генә дә уфалла арбасына төярлек иде», – дип сөйләделәр. Кергән бер кешегә: «Дөнья хәлен белеп булмый, Батырҗаным, сугышка кереп, ранен булып кайтса, менә бу үлән белән ярасын бәйләрмен. Үги ана яфрагы бу. Файдасы бик тия. Тын юлына салкын тидереп кайтса, менә кипкән мәтрүшкәм бар. Минем бурсык маем да бар әле. Күкрәген ышкырга. Менә монысы – гөлҗимеш. Әнкәй мәрхүмә, тын юлларына бик яхшы, дия торган иде. Кибеткә тары кайтканы юк. Батырҗаным көйләдә тарткан тары оныннан тәбикмәк ярата. Кайтып керсә, нишләрмен?

Мөнәвәрәнең тарысы бар микән? Шуннан алып торырмын микән? Биреп торыр микән?.. – дип сөйләргә ярата иде. Синең анаң Мөнәвәрәттәй белән, бер-берсеннән көнләшеп, үлән киптерделәр, ярма, он җыйганнар. Төенчеккә төрелгән йодрык кадәрле генә тары ярмасы гомерләренең соңгы көннәренә кадәр әле берсендә, әле икенчесендә йөрде. Үлемнәре хакында беләсеңдер инде... – диде Мәсрүрә, ризык хәстәрен күрә-күрә.

Галимҗанның бар көченә кысылган йодрыгында – учакта дөрләп янган нарат шыртлавы, йөзендә – кып-кызыл ялкын шәүләсе, тәнендә күмер кайнарлыгы иде. Кысылган йодрыктан, тартылган мускуллардан богауланган тамырларындагы кан, кая агарга белмичә, ярасыннан саркый иде.

Галимҗанның анасы Мөнәвәрә белән Батырҗанның анасы Сафураны кырдагы эскерт төбеннән яз көне, җирләр ачылгач кына табып, авыл зиратына җирләделәр. Сугыштан соң Кушкаен авылын гына түгел, тирә-якны тетрәндергән вакыйга иде бу. Сафура белән Мөнәвәрә, кәҗәләренә ашарга беткәч, яңа ел алдыннан, билләренә бау бәйләп, чүмәлә, эскерт төбе эзләп юлга чыкканнар. Алар артыннан ук буран кузгалган. Атна-ун көнгә сузылган гыйнвар бураны кырлардагы калкулыкларны, вак-төяк куакларны, чүмәлә, эскерт төпләрен тигезләгәннән соң, буран тынгач, авыл халкы, бу ике ятимәне күпме генә эзләсәләр дә, таба алмаганнар. Күпләр, ул еллардагы бүреләрнең күплеген истә тотып, бүреләр ашагандыр, дип, өметләрен өзсә, картаеп, аяк-куллар тузса да, тел тузмый, дигәндәй, яткан сәкесеннән – мич арасына – чиләккә, чиләктән – ятагына – сәкесенә көчкә аягын сөйрәп кыймылдаган Шәрифулла гына, үзләрен тимер юл станциясендә очратып, билет алып, поездга утыртып, малайларын эзләргә озатып калган, имеш. Тик каршы гына ала алмады. Үзе дә алардан соң озак тормыйча, шулар үлеме белән, кырык градуслы салкын төндә Мофаззалның капка төбендә катып үлде.

Мөнәвәрә белән Сафураны күрше авылның ат караучы Нигъмәт дигән кешесе, колхозның ат торагыннан йөз, йөз илле метр ераклыктагы бер салам эскертенең төбеннән берсенең әз генә чыгып торган аягын күреп, авыл халкына хәбәр итте. Авыл җитәкчеләре районнан милиция чакыртып саламны ачуга, мәетләрнең кабыргалары арасында күселәр утырганын күреп, күпләр аздан гына аңнарын югалтмадылар. Беррәттән кабер казып, икесен дә авыл зиратына җирләделәр. Авыл картлары, икесенең дә каберләрен бергә кертеп, каен такталарыннан чардуган корып куйдылар.

***

Гөлйөзем тормышында да тетрәндергеч хәл булды. Кояш югарыга күтәрелеп, өйлә вакыты җитеп килгәндә, бандероль күтәреп, авылның почтальон кызы Әнисә килеп керде.

– Гөлйөзем апа, сиңа бандероль бар, – диде ул, бияләен сала-сала.

Гөлйөзем, карават башына тотынып, шуыша-шуыша, гәүдәсен өскәрәк күтәрә төште.

– Нәрсә?! Нәрсә соң ул?

Әнисә, шәлен иңсәсенә шудырып:

– Бандероль! Кемдер почта аркылы сиңа әйбер җибәргән, – диде.

– Каян? Кем?!

– Белмим. Адресын да, исемен дә куймаган.

– Юк, юк! Берүк алып китә күр! Минем читтә беркемем дә юк. Аллам сакласын, – дип калтыранды Гөлйөзем.

– Мин алай эшли алмыйм. Мин бу бандерольне хуҗасына – сиңа тапшырырга тиешмен.

– Әй, Ходаем! Нәрсә икән инде монысы тагын?

– Нигә куркасың?! Кулыңны гына куй да, ачабыз да карыйбыз.

– Кызым Әнисә, кулларым калтырый. Пинсия алгандагы кебек, үзең генә куй инде.

– Ярар! Моны үзең генә ачасыңмы, булышыйммы?!

– Булыш, булыш. Рәтен дә белмим, ача да белмим, – диде Гөлйөзем, каушап.

Әнисә, ашыкмыйча гына, бандерольне өстәл өстендә сүтте. Бандероль эченнән ап-ак ирләр күлмәге килеп чыкты. Гөлйөзем сискәнеп китте. Дистә еллар ятагыннан кузгалмый, мендәр сөяп кенә утырта торган хаста Гөлйөзем, үзе дә сизмәстән, торып утырды. Күлмәккә үрелде. Күлмәкне уч төпләренә салып, озак кына карап торганнан соң:

– Аның күлмәге! – дип ыңгырашты.

Күлмәкне йөзенә, битенә китерде, иснәде.

– Аның исе! Галиәхмәтем исе!

Күлмәкнең түш кесәсеннән Гөлйөземнең үз кулы белән чиккән кулъяулык чыкты. Гөлйөзем кулъяулыкны алып, таратмакчы булды. Кулъяулыкның бер почмагы төйнәлгән иде. Калтыранган, ябык, хәлсез бармаклары белән чишә башлады. Шулчак Нуриәхмәт килеп керде.

***

Ислах әлифне таяктан аермаганга күрә, моннан барыбер рәт чыкмаячак, дип, мәктәптән куып чыгарылгач, башта хуҗалык көтүе көтте, аннары, исәя төшкәч, балигъ булып, яше тулгач, колхоз фермасына маллар карарга, сыерлар асты чистартырга керде. Ә Мифтахны мәктәпне тәмамлаганның икенче көнендә үк ферма мөдире итеп билгеләделәр. Ислах өчен бу аяз көнне яшен суккандай булды. Мифтахның сөйгәне – Хөллиясенә күз атып, ничек тә аны үзенеке итү теләге белән янып яшәгән Ислахның йокысы качты. Ничек тә Мифтахны яндыру, үч алу планы белән яши башлады.

Көннәрдән бер көнне, мал астына салам кирәк, дигән сылтау белән, Арслан фермага менде. Мифтах янына барып тормыйча, туп-туры, ат арбасыннан тирес бушаткан Ислах янына килде. Дәшми-нитми озак кына карап торганнан соң, Ислахта үз чалымнарын тоеп, үз канының тирес арасында газапланганын күреп:

– Нихәл, улым! Хуҗаң, Мифтах янына барып тормыйча, туп-туры синең яныңа килдем әле, – диде.

– Хуҗа?! Тапкансың хуҗа!

– Хуҗа инде, хуҗа! Сиңа мал асты карата, тирес, тизәк түктерә икән, димәк – хуҗа! Бергә, бер класстан башлаган идегез бугай... Бу – Кыяметдин белән Гыйльменисаның кызы Хөллия дә сезнең белән укыдымы соң әле? – Бу сүзләрне Арслан тиккә кулланмый, мәкерле планын тормышка ашырыр өчен җирлек әзерли иде. – Аларның нәселе шундый. Атасы Нуриәхмәт тә, бабасы Мотавал да хуҗа булырга, кеше эшләтергә яраттылар. Ә безнең нәсел буйсына торганнардан түгел. Мин үзем аларга буйсынмадым. Үзем аларны буйсындырдым! Атаң Галимҗан бер дә күренми, авырмыйдыр бит?

– Картая-картая акылың чыга башладымы?! Нишләп ул минем әти булсын!

– Картлык. Гафу ит. Картлык. Синең атаң...

– Азапланма! Минем атам Миркасыйм да түгел!

– Алай икән. Димәк... – Уң кулы белән сакалын сыпырып, – димәк, барысын да беләсең! – диде.

– Беләм!

– Белгәч! Нигә ник туганыңа үкенеп яшисең?! Суксаң – үтер, тотсаң – өз! Селәгәй булып яшәмә! Син аларга буйсынырга тиеш түгел! – диде Арслан, зәһәрләнеп.

Ислах, Арсланны бугазыннан эләктереп:

– Муеныңны борганчы, исән чагында югал күз алдымнан! Синең көнең бетте! – дип кычкырды.

– Ялгышасың. Минем көнем башлана гына әле.

– Имеш, мыскыл итә. Тирес түгәсеңме?! Син түктерәсең ул тизәкне миңа! Син, син аны фермага бригадир итеп куйдырдың!

– Чү, чү, улым. Акыллы бул. – Кулларын бугазыннан көчкә алып: – Килешмәгәнне. Тинтәк син! Өстәвенә, аңгыра! Ферманы яндырып була, тизәккә каткан сәнәкне яндырып булмый, – дип ысылдады.

***

Эңгер-меңгер төшеп килгәндә, Арслан Мифтахлар тәрәзәсенә чиртте.

Гөлйөзем, ятагыннан күтәрелә төшеп:

– Кем бар анда? – дип сорады.

Тыштан Арсланның:

– Энекәш, Мифтах, чык әле, – дигән тавышы ишетелде.

– Теге этең – карт бүрең килгән. Бүген тагын тынычлыгыбыз югала. Кылкындырганчы эчертеп, исертеп китә икән, – дип ыңгырашты ана.

– Телеңә салынма! Сез ике имгәкне караудан гайре файдагызны күргәнем юк әле. Ул миннән кеше ясады, – дип кычкырды Мифтах.

– Харап икән! Ике көн ферма мөдире булып эшләгәнсең икән. Моңарчы менә шушы мич арасында утырган гарип картның пенсиясе белән анасының кул эшеннән кергән акчага яшәгәнен оныткан.

Мифтах мыгырдана-мыгырдана чыгып китте дә бераздан, кереп, стакан белән кабымлык алып, тагын ишек катына юнәлде.

– Арслан абзыкай түгел ул, Галимҗан абый, – дип алдап, ишекне тышкы яктан япты.

Артыннан анасының:

– Алда! Галимҗанның намазга басуын, инде авызына бер тамчы да аракы алмаганын белми идек, – дигәне ишетелде.

Мифтах үз-үзен белештермәслек булып исерде.

– Арслан абзыкай, син бит – минем атамнан да якынрак кешем, – дип мыгырданды ул, телен көч-хәл белән әйләндереп.

– Ярар инде, Мифтах энем, ярар. Моны белүеңә рәхмәт, кәнишне.

– Әйдәле, синең исәнлегеңә күтәрик әле.

Мифтах стаканны Арсланга сузды.

– Җитте, энем, җитте. Яшь чак түгел. Яшь шактый, үзең беләсең, исерермен. Син тот, тот. Сезгә, яшьләргә, килешә ул. Мин аны яшь чагында бер утыруда бер литрны берүзем сындыра идем, – дип үртәде Арслан, егетне ныграк исертергә теләп.

– Исерсәң, өйгә керерсең дә аварсың. Син безнең өйдәге үз урыныңны беләсеңдер әле. Әллә оныттыңмы?! Күптәннән кергәнең юк шул. Ә мин онытмадым. Сабый чактагылар онытылмый ул, Арслан абзыкай, онытылмый. Әнкәйнең, Гөлйөземеңнең урыны һаман да шунда – түрдә аның.

– Исереп киттең.

– Юк, мин сиңа рәнҗемим. Син булмасаң, без әнкәй белән күптән үлгән, беткән идек. Син икмәк ташып ашатып үстердең мине.

– Нишлисең. Атаң тиешле кеше, Нуриәхмәтне әйтәм, юньле кеше булып чыкмады.

– Беләм. Бик яхшы беләм. Хәзер менә монысы, тере мәет булып, ничәмә-ничә еллар урында, хасталанып, минем җилкәмне кимереп ята. Катмый да! – дип елады Мифтах, селәгәйләрен агыза-агыза.

– Анаң турында алай сөйләмә. Анаңа алай ук каты кагылма. Озак гомере калмагандыр, – диде Арслан, яхшатланып.

– Башта мин катам әле. Ул кала. Хватит миннән! Иртәгә үк картлар йортына олактырам. Хөкүмәт карасын! – дип йодрык төйнәде Мифтах, йодрыгы белән башта борынын сөртеп.

– Түзәргә кирәк, энекәш. Түзәргә!

– Сиңа кадерле ул. Төннәрен сине җылытты шул ул. Мин – идәндә, сарык бәрәннәре белән, пумуй чиләген баш астына мендәр итеп салып йоклап үстем.

– Кызма әле, энекәш. Мә, мә, тотып куй әле.

Мифтах эчеп куйды да суган капты.

– Ә теге ата мәчесе аркасында гомерем буе эт типкесендә, халык дошманының малае булып кагылдым. Барыбер үстем.

– Үстең, энекәш, үстең, – диде Арслан, борын астыннан мыгырданып, – бар ялгышың да шунда.

– Синең арканда! – Мифтах, елый-елый, Арсланны кочаклады. – Бары тик синең аркада. Рәхмәт сиңа, Арслан абзыкай! Өшкерде мине тормыш, өшкерде! Үзем генә беләм.

Нуриәхмәт килеп керде. Утын өеменә килеп, кулына утын түмәрләре өя башлады. Арслан күз кырые белән генә аны күзәтеп, вакытсыз кергәненә үртәлеп, борын астыннан мыгырданып:

– Моның керүе кирәкми иде. Моның керүе начар. Бу бит, чукрак булса да үтәли күрә, – диде дә, Мифтах ишетерлек итеп, – моны әйтәм әле, атаң Нуриәхмәтне. Сыңар аягын өстерәп, ничәмә-ничә елдан соң Себер булып Себердән кайтты бит, ә? Һаман да булса яши, диген? – диде.

– Кайтты. Пычагым да Себердә булмаган ул. Бер завутта тимер кырып яткан. Рәте беткәч, шәһәрдә урын тапмагач, койрыгын бот арасына кыстырып, стададан куылган шакал кебек, аягын сөйрәп, барыр җире калмагач кайтты. Ну миннән яхшылык көтмәсен! Шымчы! Бәреп үтергәнче күземнән югал!

Нуриәхмәт, чайкала-чайкала, ашык-пошык кына берничә утын түмәре эләктерде дә кабалана-кабалана чыгып китте. Абзарның ачык ишегеннән Мифтахның бар көченә:

– Чукрак тәре! – дип акырганы өй эченә кадәр ишетелде.

Гөлйөзем, ятагыннан башын күтәреп, Мифтах Нуриәхмәтне кыйный, дип уйлап, җан авазы белән:

– Кагылма, кагылма аңа! Атаң бит ул синең! – дип кычкырды.

Абзардан Мифтахның мөгрәп җырлаганы ишетелде.

Бардым күлгә,
Салдым кармак,
Безгә балык эләкми шул...
Йөгереп китәрдәй булам да...

Гөлйөземнең, бусаганы атлап керергә азапланган Нуриәхмәтен күрүгә, кан качкан йөзе тагы да агарып:

– Син, барысына да син үзең гаепле! Син безне ташлап качтың да мәңгелек газапка салдың. Син үзең мине Арслан тозагына ташлап киттең! Мин нәрсә эшли ала идем? Ничәмә-ничә еллар халык дошманының хатыны булып газап чиктем. Ул баланың күргәннәрен син күрсәң, син дә... Мин, мин шул баланы үстерер өчен, бер уч икмәк өчен, үз-үземне корбан иттем. Ник дәшмисең?! Ник дәшмисең?! Ишетәсең син! Беләм бит, беләм, ишетәсең! – дип, ямьсез үксеп, мендәргә капланды. Бераздан башын күтәрде. – Бер уч икмәк... Ай ул бер уч икмәк! – дип көрсенде. – Ул елларда кемнәрнең генә башына җитмәде. Төрмәдәге бер учлыларны тезеп, шуларга сабыйларын ияртсәң, күз күреме генә ераклыкка җитмәсләр иде. Дөньясыннан туйдым, бауга менәр идем, итәгемнән шушы сабыем тартты. Әй сабый, сабый... Үсеп җитте дә хәзер мине вакытсыз кабергә өстери.

Гөлйөземнең Арслан тырнагыннан котылмакчы булып, мыскыл итүеннән туеп, исәеп килгән улының йөзенә карарга, багарга оялып, төнен колхозның амбарына барганы хәтеренә төште. Урам яктан амбарның бура астын бармаклары, тырнаклары белән казыды. Кечкенә тишектән арыш бөселде. Хатынның калтыранган куллары арышка үрелде. Шулчак иңсәсендә чит кеше кулы тоеп, катып калды. Сулышы бүленде. Эсселе-суыклы булып, курка-курка гына артына борылды. Ай яктысы Арсланның йөзен яктырта иде. Гөлйөзем төзәтә алмаслык ялгышлык эшләгәнен аңлап, өнсез калды... Бүгенге көндә дә шуларны уйлады, әмма бәгыре каткан иде, елый алмады.

***

Күңеле сизде Хөллиянең, төн буена керфек какмады. Уңга-сулга боргаланды. Мендәрен бер төшерде, бер күтәрде. Таң алдыннан гына йокыга изрәгәндә, капкаларын шакыдылар. Хөллия тиз генә торып, ятагы башыннан халатын алып киде дә, ишек катындагы фуфайкасын җилкәсенә элеп, капка ачарга дип чыгып китте. Өйалды ишеген ачуга, аны капка артыннан ишетелгән, күрше хатыны Мөгалимәнең, ачыргаланып:

– Нәрсә йоклап ятасыз?! Атаң белән анаң кая?! Торыгыз! Колхозның фермасы, савым сыерлары яна бит! – дигән сөремле тавышы каршы алды.

Хөллиянең өстенә кайнар су сипкәндәй булды. Катып калды. Әтиәнисенә хәбәр итәргә дип, ишек тоткасына үрелде. Кыяметдин абзый белән Гыйльмениса түтинең күрше авылга – бертуган апаларына киткәнен исенә төшереп, янәдән катып калды. Күз алдына ут капкан сыерлар, алар арасында ялкын эчендә йөгереп йөрүче Мифтахы килеп басты. Үз-үзен белештермичә, ярымъялангач килеш чыгып йөгерде. Тәненә, күкрәгенә килеп бәрелгән салкын һавадан айнып, капкага җитәрәк туктап калды. Кире борылып керде дә, үксеп, мендәргә капланды.

Пожар каланчасы каршысына җыелган халыктан читтәрәк баскан Арслан янәшәсендә торган каенэнесе – Куйбышев партия мәктәбен тәмамлап кайтып, яңа гына Кушкаен авылындагы «Коммуна» колхозында партоешма секретаре булып эшләгән Мәмлиевнең колагына:

– Җиңел котылдың. Ярый әле колхозның берничә сыеры белән абзары гына янды. Озаграк эшләсә, партиягә кереп, синең дә арт саныңа ут төртә иде. Синең урынга утыра икән, дигән сүзләр йөри башлаган иде, – диде дә, җилферди-җилферди, карт гәүдәсен чак-чак кына тотып, икенче якка чыгып басты.

Мәмлиев, әтәчләнеп, алга – уртага атылып чыкты. Чәй өстәле артында

җизнәсе Арсланның Мифтахлар нәселе хакындагы нотыгын исенә төшерә-төшерә, тиз-тиз тезеп китте:

– Җәмәгать! Тарих кабатлана. Кайчандыр шушы урыннан безнең авылның картлары Совет хөкүмәтенең дошманы Мотавалны сөргенгә сөргәннәр. Бүгенгесе көндә шушы Мотавалның оныгы Мифтах нәрсә эшли?! Колхоз фермасының януына сәбәпче була! – дип акырды.

Арслан, янәшәсендә басып торган Сөләй Сабирына колагын куеп:

– Колакка «Арслан» дигән сүз керде. Нәрсә ди ул? – дип сорады.

– Әле дә исәнме, катмадымыни, ди.

– Минеме?!

– Әйе. Колагым дөрес ишеткән булса, син диде бугай!

– Ай рәхмәт! Ашыкмыйм әле мин. Әле сезнең җеназагызны укып, соңгы юлга озатасым бар.

– Тфү! Тфү!!! Әстәгъфирулла, әстәгъфирулла! Аллам сакласын! Син җен картыннан, зират каргасыннан, барысын да көтәргә була, – дип, курка-курка, Сабир читкәрәк китте.

Арслан, тамак кырып:

– Кем... Исемең кем атлы әле? Ходайның ачы каһәре төшкере, хәтерем юк, – дип мыгырдады.

Халык арасыннан берничә кешенең, кабат-кабат:

– Соң, Арслан абзый, каенәнең ләбаса, каенешең! – дигән тавышларына, колагын тегеләр ягына куеп, диванага сабышып: – Кем?.. Каенлыктанмыни?..– дип сорады.

– Каенешең! Мәмлиев! Исемен генә белмибез.

– Ә, әйе. Мәмлиев энем... – Бу минутларда Арслан инде тәмам тилегә сабышкан иде.

– Минем синең авылыңда эшем юк! Каенлыктанмы син, Имәнлектәнме?.. Анысы – синең эш! Әмма шуны беләм. Ферманың януында Мифтахның бер катнашы да юк. Ферма тирәсендә кемнәр эшли, кемнәр күбрәк йөри, шуларны тыңлап караргадыр! – дип кычкырды.

Арадан берәү:

– Әйе шул. Әнә Ислах һәрвакыт маллар янында, фермада. Эчми, тартмый, күзе үткер, – диде.

Икенче берәү:

– Сүзгә кеше кесәсенә керми... – дип тә өстәде.

Ислах күзе белән халык арасыннан Арсланны эзләде. Касыгына килеп бәрелгән Арслан терсәгеннән сискәнеп, янәшәсендә басып торган ата тиешле кешенең күзенә карады. Арсланның мәкерле күзләре: «Мин имәнне аудардым. Сиңа чикләвекләрен генә җыясы калды, миңа үпкәләрлегең юк. Дәвам ит! Калганы – синеке», – дип елмая иде.

Ислах сабыр гына сүз алды.

– Авылдашлар! Мин авылда әлләкем түгел. Гади бер скотник! Миңа бүгенгесе көндә, бу минутларда сезнең барыгызга караганда да авыррак. Мифтах – минем сабакташым, классташым, партадашым! Нәрсә генә булмасын, ферма янган. Факт! Ә ферма өчен кем җаваплы?.. Минем гел бишкә генә укыган сабакташым, классташым, партадашым Мифтах. Мин Мифтахны бик яхшы беләм. Аның, кулына шырпы алып, фермага ут төртмәгәнен дә беләм. Әмма ләкин мин кайтып барганда, көчкә-көчкә генә атлап, шыр исерек килеш фермага кереп киткәнен күрсәм дә, күрдем, дип әйтә алмыйм.

***

Мифтах, төрмәдән чыгып, авылына кайткач, атна-ун көн баш күтәрми эчкәннән соң, башының чатнап авыртуына түзалмый уянып китте. Өйдәге бушаган шешәләрне тикшереп чыкканнан соң, анасы Гөлйөземне уятып, акча даулый башлады. Анасыннан акча алып булмаячагын аңлагач, сатарлык әйбер эзләп, өй эчен тентеде. Чормага менде. Бераздан, бармак калынлыгы тузан каткан, бабасы заманындагы самавырны күтәреп төште дә, эштер-өштер генә сөрткәләп, ишек төбенә җәелгән арыш капчыгына тыгып, җилкапкадан урамга чыкты. Кая барырга икән дип, алан-йолан каранып торганнан соң, җитез-җитез атлап, тыкрыкка кереп югалды. Бераздан ул Нургата карт оныгы, әлеге дә баягы сабакташы, спекулянтка әверелгән, «төнен сатар» Ислахның кызыл кирпичтән салынган ап-ак калай түбәле йорты баскычында, капчык авызыннан самавырының бер кырыен чыгарып, өстендәге сырмасының каешланган җиңе белән ышкып ялтыратып утыра иде.

Шыгырдап ачылган ишектән башта – кап-кара мәче, аның артыннан йорт хуҗасы килеп чыкты да иркенләп киерелде, иренеп кенә:

– Нинди йомыш, – диде, чәйнәлеп тә бетмәгән коймагының мыегына сыланган маен ялап.

Мифтах, кабалана-кабалана, капчыктан самавырны чыгарды.

– Менә! Менә күрәсең, настоящий реликвия! Тарих! Җиз самавыр. Хәтта менә медальләре дә бар. Күпмегә аласың? – дип, эчә-эчә эренләп, шешенеп беткән чепи күзләрен баскычның югары катында басып торган өй хуҗасына төбәде.

Керәсе мал тешне сындырып керә, дигәндәй, Ислах узган атнада гына каланың бер кибетендә мондый самавырларның бәяләрен күреп, ис-акылы китеп, шаккатып кайткан булса да, бер дә исе китмәгәндәй:

– Әнә тегендә – почмакка ыргыт. Бер яртылык алырсың, – диде.

– Син нәрсә, Ислах?! Бу бит – җиз самавыр! Бу бит, беләсеңме, ничәнче гасыр?!

– Белмим! Белергә дә теләмим. Самавыр, кирагаз заманы узды. Һәр кешедә – газ, электр. Эт пес иткәнче, чәйнектәге суың кайный да чыга. Тузаны юк, исе юк, күмер салып, көл түгәсе юк. Пычагымамыни бу самавыр миңа! Бу самавырдан акча ясар өчен, агай-эне... Башта әле аны, машинага егерме литр ягулык салып, калага алып барып, кача-поса йә булмаса милиция аркылы җиденче бабаңа кадәр тикшерелеп, антиквар җыючы абыеңа тапшырырга кирәк. Күпмегә ала. Әле аламы. Аннан егерме литр ягулык салып кайтасы... Беләсеңме хәзерге вакытта ягулыкның – бензинның күпме торганын?! Туда – егерме, сюда – егерме, менә сиңа – кырык! Мае, дегете, ашханәсе, трансмиссиясе, амортизациясе... Менә сиңа мә! Бу самавырыңнан бер чиреклек тә калмый.

– Алай итмә инде, күрше, сабакташ. Һич югы бер литрлык бир!

– Теләгең. Телисең икән калдырасың, теләмисең икән алып китәсең. Анысы – синең эш.

Ачуыннан еларга җитешкән Мифтах, апрель кояшының җылысына ләззәтләнеп, мырлый-мырлый аягына уралып бөтерелгән мәчене тибеп очырды.

– Кит әле! Ичмасам, син нервымда уйнама! Алай ярамый инде, Ислах. Баедым, дигәч тә...

– Нәрсәнең яраганын, нәрсәнең ярамаганын белгәч, нигә миңа килдең? Үзең генә илтеп тапшыр. Уч тутырып акча алырсың. Кайчандыр сөргенгә сөрелгән

бабаларыңны да исеңә төшерерләр. Сине өйрәтәсе юк. Син закуннарны яхшы беләсең. Милициядәгеләр – синең үзеңнекеләр. Спекуляция өчен ничәнче статья әле? – диде дә өенә кереп китте.

Кабат өй ишеге ачылды. Ишектән, мәче савыты кадәр кечкенә генә савытка салынган аш күтәреп, калтырана-калтырана, Хөллия, аның артыннан Ислах чыктылар. Ислах, нәрсә әйтергә дә белмичә басып торган хатынына астыртын елмаеп:

– Нәрсә өнсез калдың?! Әнә бит, миңа кияүгә чыкканчы артыңнан йөргән ухажорың төрмәдән кайткан! Хәер сорап килгән. Бабасыннан ядкарь булып калган соңгы самавырын сата. Аш бир үзенә. Бик бетерешкән. Ябагасын коялмый азаплана, – дип ыржайды.

Мифтах белән Хөллиянең күзләре очрашты. Мифтахның тәне эсселе-суыклы булып, тәненә каз тәне чыкты. Башын түбән иде. Исәнме, дияргә дә теле әйләнмәде.

– Нәрсә?! Күзләрегез белән... Биш ел сөешкәнегез җитмәгән, хәзер минем нигездә, минем бусагамда каш сикертәсезме?!

Ислах, Мифтах кулыннан самавырны тартып алып, югарыга – кояшка күтәрде:

– Ялтырыймы?! Ялтырый! Аһ, ничек матур ялтырый, – диде, самавырны кулында бөтереп. – Кара син моны, ничек ялтырый. Тырышкан! Минем бабай ничек тырышкан! Кара, минем бабай ничек ялтыраткан! – Кан сауган күзләре белән Мифтахка карап: – Ә син аша-аша, тартынма. Дөнья куласа, бер әйләнә, бер баса. Бер ялтырый, бер калтырый! – дип, самавырны, болгап, урамга ыргытты. Шаркылдап көлеп, кесәсеннән акча чыгарып, Мифтахка сузды.

– Хәзер ялтырамый. Юк. Хәзер ялтырамый. Мә, сабакташ! Мә, мә, яшьтәш! Мә, авылдаш! Ал, ал, сабакташ. Ал, күрше! Акча бу. Биш самавырлык акча. Алмыйсың?! Дөрес эшлисең. Бар, бар, сабакташ, бар, күрше, бар, авылдаш, юлыңда бул. Иртәгә шул самавырыңны ялтыратып алып килсәң, ун самавырлык акча бирәм! – дип кычкырды.

Хөллиянең кулындагы кайнар ашы өстенә акты. Тәненә үтеп кергән кайнар ашка айнып, аптыраган хәлдә, бер – алга, бер артка атламакчы булды. Күзләре, тирән уйга батып, карашы төпсез киңлеккә төбәлгән Мифтахка төште:

– Килешмәгән эшләр эшлисең. Күз алдында череп, юкка чыгып барасың. Бүтән капкамны ачып керәсе булма!.. – дип иңрәде.

Мифтахның күзе яшьләнде. Бугазына төер утырды. Хөллия артыннан ябылырга да өлгермәгән ишеккә борылып:

– Миңа гына түгел, нәселгә төшкән каһәр, каргыштыр бу! – дип, бугазындагы төерне йотмакчы булды. Авызыннан буталып, боламыкка әверелеп чыккан соңгы җөмләсен исән калган ярымчерек биш-алты теше белән чәйнәп, имгәтеп, һавага төкерде.

Күз төбенә бәреп чыккан яшен җиң очы белән сөртеп, карашын еракка-еракка төбәп, тирән уйга батты.

Реликвия... Гасыр... Ә ул беләмикән? Юк, ул белә микән Ислахның Миркасыйм атлы «атасының», Мифтахның бабасы Мотавал муллага ялланып, самавырчы малай булып, шушы җиз самавырны ничә тапкыр кайнатып, күмер салып, төннәрен сукыр лампа яктысында киез ката балтырыннан кисеп алынган киез белән ялтыратып утырганын?!

Юк шул... Мифтах та, Ислах та боларны имеш-мимешләрдән ишетеп белсәләр дә, күз алдына китерә алмыйлар иде.

***

Мифтах өенә кайтып керде. Гөлйөзем, гадәттәгечә, аның исереп, тузынып кайтачагын, өйнең астын-өскә китереп, икесен дә утлы табага бастырачагын белгәнгә күрә, өстәлгә башланмаган аракы утырттырган иде.

Мифтах шешәне алып әйләндергәләп торды да, башта – ятактагы хаста анасына, аннары мич арасында утырган ата тиешле кешегә – Нуриәхмәткә озак кына карап торганнан соң, шешәне алып, ишегалдына чыкты. Абзарга керде. Чөйдән бау алды. Бауга элмәк ясады. Элмәкле бауны абзарның өрлегенә бәйләде. Элмәк астына ит чаба торган бүкәнне китереп, шуның өстенә утырды да тирән уйга батты. Аның колагында, әле сәгать- сәгать ярым элек кенә, сөйгәне Хөллиянең: «Күз алдымда череп югаласың бит», – дигән сүзләре зыңлый иде. Шушы кыска гына – күз ачып йомган арада, күз алдыннан сабый чаксыз, үсмер чаксыз, сагынып искә төшерерлек шатлыкларсыз узган гомеренең кайгы-хәсрәтләре, тапталган, кыйналган, нахакка рәнҗетелгән, кояшсыз, болытлы көннәре тәгәрәп узды. Рәнҗетелүләргә түзә алмыйча, якыннарына кылган усал гамәлләре... Нахакка утырып, биш елын Түбән Тагилда калдырып кайткан яшь гомере, авыл капкасын атлап керүгә, беренче мәхәббәтенең, көянтәсенә буш чиләген асып, килен булып төшкән Ислах нигезеннән чыгып, аңа очравы...

Буш чиләк... Әйе. Авыл капкасыннан, Ислах нигезеннән каршы алган буш чиләк!

Мифтах шешәне әйләндергәләп торды да, утырган җиреннән, шешә борынына элмәк кидерде. Утырган урыннан торып, элмәк астындагы бүкәнгә уң аягын куйды.

– Йә – син, йә – мин! – дип, бүккәнне тибеп аударды. Асылынып калган аракылы шешә абзарның нәкъ уртасында, Мифтах гомеренең соңгы сәгатенә, соңгы минутына кадәр асылынып, эленеп торды. Аңа беркемнең дә кагылырга хакы юк иде... Мифтахны җирләп кайтканнан соң гына, авыл яшьләре ул бичара шешәне баудан азат итеп, баш киемен салдырып, өч ягына утырып «ясин чыктылар».

***

Бу көн – Мифтах тормышында икенче борылыш алган, аны иманга китергән, намазлыкка бастырган, картаеп, соңгы сәгатенә-минутына кадәр авызына хәмер алудан ваз кичтергән көн иде.

Мифтах авылда беркемнең дә сүзен колагына элмәсә дә, нинди генә исерек чакларында да Шәмсия карчыкны тыңлый иде.

Аның нигезендә, өендә тугангамы, әллә кендек әбисе булгангамы, бабасы Мостафа үлгәнче, әнисе белән шуның ышыгында сыенып урын тапкангамы, әнисе Гөлйөземнең Шәмсия әбигә булган изге карашын тоепмы, бабасы Мостафа йортыннан үз, нәселе нигезенә – Мотаваллар ишегалдына салынган «Кияү йортына» кайтып тәпи атлап киткәч тә, җан асрарга ризык эзләп, тимер кружкасын күтәреп, алпан-тилпән көчкә атлап, Шәмсия әбисенең кәҗә имчәген бүлешергә, сөт чөмерергә йөргән чагын искә төшерепме, әбекәйнең әрәмәлектә сабын чәчәге, зәңгәр кыңгыраулар астында пешкән бармак башы кадәрле җир җиләкләрен өзеп каптырган чагынмы, бәлки, уфалласына төялгән печәне өстенә утыртып кайткан сабый чакларын исенә төшерептерме, ул аны хөрмәт итә иде.

Күзен йомса, күз алдында – савыттан кайнар ашы итәгенә аккан, мөлдерәмә күзләрен тутырып караган Хөллиясе басып тора иде.

Мифтах шул көннән «әүлия»гә әйләнде. Җомга намазларын калдырмады. Өендә тәртип урнашты. Өйләнде. Хатыны – түбән урамның Чүрәкәй Гарифының уртанчы кызы Әкълимә иде. Хөллия белән бергә сабакка йөргән, бер парта артында сигез ел белем алган дуслар иде. Мифтах белән Әкълимә бергә кушылганнан соң, әйтерсең лә бу ике дус арасыннан кара мәче йөгереп узды. Әкълимә Хөллиянең яшьлек мәхәббәте – Мифтахка кияүгә чыккач та, алар арасындагы ярату хисләре сүрелмәгәнлеген сизеп, Хөллия белән сөйләшмәс булды. Ислах өчен дә бу кулай иде. Мифтах белән Ислах берсеннән берсе уздырып дөнья көтсәләр, хатыннары ярыша-ярыша бала тапты. Мифтах соңга калып өйләнгәнгә күрә, аның беренче баласы Нурбәк Ислахның өченче баласы Лилия белән бер елгы иде. Мифтахның дүрт кызы, бер малае, Ислахның дүрт малае, бер кызы туды.

Нурбәк белән Лилияне авылда Таһир – Зөһрә яки Ләйлә – Мәҗнүн дип йөрттеләр. Төскә-биткә дә, буй-сынга да матурлар, Лилия – коеп куйган анасы Хөллия, Нурбәк нәкъ атасы Мифтахка охшаган. Бер мәктәптә, бер сыйныфта бишлегә генә укыдылар. Ата-аналарының сүзенә колак салмыйча, җиденче сыйныфтан җитәкләшеп йөри башладылар. Хөллия белән Мифтахның яшьлеген белгән авылдашлары аларның мәхәббәтен Хөллия белән Мифтах мәхәббәтенең дәвамы дип атыйлар иде. Тик бергә булуларына гына ата-аналары, иң элек Әкълимә каршы булса, Ислах Мифтахны кодасы итеп түренә утыртуга мең тапкыр риза бәхил түгел: «Әгәр бусагамнан Мифтах атлап керсә, әнә баш очымда балта! Йә – ул, йә – мин!» – дия иде.

Лилия унны бетергәч, Казанның икътисад, Нурбәк Новосибирскиның аграр институтына укырга керделәр. Баштагы елларда Казан – Новосибирск юлын таптасалар да, соңга таба, өченче, дүртенче курсларга җиткәч, очрашулар сирәгәйде. Институтта Лилия артыннан чабучы егетләр күп булса, Нурбәкнең дә теләсә нинди кызга бер борылып елмаюы җитә иде. Ана буласы, бала сөясе, кияүгә чыгасы килү табигатьтән салынган кыз бала өчен Нурбәкнең аспирантурада укуын дәвам итәргә теләвен ишетү авыр булды, ике якның да ата-аналарының каршы булуларын да истә тотып, Лилия үзеннән өч курс алда укып бетергән, Казанның олы гына бер түрәсенең малаена кияүгә чыкты.

Тирә-якта булмаган, күрелмәгәнчә бай итеп, Казанда да туй ясадылар. Туйга ярты авылны чакырдылар. Кияүнең, кодаларының байлыгын, кемнәр белән туганлашканнарын күрсәтер өчен дип, Ислах, иң беренчеләрдән итеп, чакыру билетын Мифтахларга илттертте. Мифтах та, бераз гына үзеннән кушып, янәсе, малае Нурбәк институтны тәмамлап аспирантурага кергән, киләчәктә зур галим буласы икән, шул хөрмәттән институтның ректоры аларга чакыру җибәргән, иртәгесен поездга утырып Новосибирскига юл тотабыз, дип җавап кайтарды.

Мифтахның Новосибирск дигәне күрше авылдагы дусты Гарифулланың умарта бакчасы булып чыкты. Өч-дүрт көн дә үтмәде, битен биш-алты кортка чактырып, шешенеп, авыл халкы уянганчы дип, бакча артлатып кына авылына кайтып егылды.

Нурбәккә дә егет булып йөрергә күп язмаган иде. Ул институттан чыгып, тулай торагына кайтырга дип трамвайга утыруга, трамвайның урта ишеге ачылып, ишектән ике гүзәл эчкә үттеләр. Берсенең икенчесенә:

– Синең бүген ничә пар иде? – дигән җөмләсе, икенче кызның – озын кара юан толымлысының:

– Ике! – дип җавап кайтаруы барысын хәл итте.

Ерак Себердә, урыс шәһәрендә туган телен ишетү Нурбәк өчен әйтеп

аңлатмаслык могҗиза, бәхет иде. Ул тизрәк кызлар янына елышты. Кызлар төскә-биткә, чибәрлеккә дан булмасалар да, татарча сөйләшүләре белән Нурбәкне әсир иттеләр. Каш астыннан серле елмаеп, егетне үтәли тишкәне – Әнисә. Җиде яше тулар-тулмас әти-әнисе белән Әлмәт якларыннан Себергә нефть чыгарырга күчеп киткән гаиләдән. Атасы Шәйдулла – Новосибирск шәһәрендә «Газпром нефть» ачык акционерлык җәмгыятенең олы бер түрәсе, әнисе Зәлия – шәһәрнең үзәк хастаханәсендә баш табиб урынбасары, эчке авырулар табибы, терапевт.

Әнисә унберенче сыйныфны тәмамлагач та, шәһәрнең нефть-газ университетына укырга керде. Татар җанлы Шәйдулла, теләсә-теләмәсә дә, хатыны сүзеннән, үгетеннән туеп, кызын бәхетле итү теләге белән колагын урыс егете Сергейдан тешләтте. Егетнең әти-әниләре гаилә дуслары иде. Өстәвенә Сергейның атасы Василий Михайлович – Шәйдулланың төп хуҗасы да. Ике якта озакламый кода, кодагый булабыз, бары тик балаларның укуларын бетерүен генә көтәбез, тиздән туй ясыйбыз, дип хыялланалар, чөнки фатир, икесенең дә машинасы бар, тормыш башларга – ак көнгә дә, кара көнгә дә акча салынган иде.

Беренче очрашуда ук Нурбәк белән Әнисәнең күзләре бик тиз аңлаштылар. Кызның күз карашы – егет йөрәгенә, Нурбәкнеке Әнисә йөрәгенә ук булып кадалды. Ике йөрәк бергә сулкылдый, бергә тибә иде. Нурбәк, бар дөньясын онытып, үз тукталышын узып, кызларга ияреп, трамвайдан төште. Дөньяның кайсы якка барганын аңлаган Әнисәнең иптәш кызы тукталыштан сулга каермакчы иде, Әнисә аны туктатты. Читкә алып китеп, берничә минут сөйләшкәннән соң, кызлар, култыклашып, Нурбәк янына килделәр.

– Без кайтып җиттек, – диде Әнисә. – Исемегезне белсәк, китәр идек.

– Үрдәк! Әй лә, Нурбәк, – дип, кулын сузды егет. Аның һәрвакыт шулай шаярта торган гадәте бар иде.

Кызлар рәхәтләнеп көлгәннән соң, Әнисә дә кулын сузды.

– Син үрдәк булсаң, мин – әнисе, то есть, Әнисә!

Көлү дәвам итте. Егетнең Әнисә бакчасына кереп барганын сизгән Зинаида да йоклап тормады. Нурбәк алдында боргаланды, сыргаланды, кулын сузды.

– Татарстаннан! Зәй шәһәреннән.

Әнисә иптәш кызының дуэльга чакырганын аңлап-сизеп, көйдерә, яндыра торган сихри күзләре белән үтәли тишәрлек итеп, Нурбәккә карады. Күңел түрендә моңлы аһәң, сихри сүз, кирәкле тембр тудырып, егет күңеленә сары май булып ятарлык итеп:

– Пока, Нурбәк! – диде.

Нурбәк Әнисәнең аккош мамыгына манып сыйпаган, назлаган, изрәткән, оеткан сүзләреннән айнып, Зинаиданың кулын алды.

– Алай килешерме соң, Әнисә? Минем җанымда – давыл, гарасат! Хисләрем менә-менә ярыннан чыгарга тора. Ашыкма. Тынычлансын ул йөрәк. Берберебездән аерылсак, харап булабыз, – диде.

– Аның өчен нишләргә кушасың, егет?

– Бергә атларга, Әнисә, бергә! Ахыр көнгәчә бергә атларга!

– Кая?!

– Ярга! Без гомер итәсе ярга!

Егет кулын кызга сузды. Әнисәнең бармаклары Нурбәкнең учына кереп оялады.

Нурбәкнең беренче тапкыр Әнисә тупсасын атлап кергән көнне дә һич онытырлык түгел, хикәя итеп язарлык иде.

Әнисә фатирларының кыңгырау төймәсенә басуга, әнисе Зәлия ханым елмаеп ишекне ачты. Артта ят егет басып торганын күреп, йөзе үзгәрде, сөмсере коелды. Әнисә эшнең кай тарафка барганын бик тиз чамалап, тукталышта Зинаида белән корган сценарий буенча:

– Әни, таныш бул, Нурбәк! Зинаида, нәрсә карап торасың, таныштыр!.. – диде.

– Ә, әйе. Зәлия Фәтхуловна! Таныш булыгыз! Бу егет – минеке, минем... То есть, безнең якташыбыз, Татарстаннан, татар егете – Нурбәк! – дип елмайды Зинаида.

Хуҗабикәнең йөзе яктырды:

– Ишек катында басып тормагыз! Әйдәгез, түргә узыгыз! Кызым, аякларына кияргә тапочка бир, – диде һәм, елмаеп, Зинаиданың бит алмасыннан яратып тотып, – алайса, минеке, синеке, Татарстаннан, дигән буласың! Ах сине! – дип, эчкә кереп китте. Ерактан ишетелгән: «Кулларыгызны юыгыз да марш аш бүлмәсенә!» – дигән сүзләре фатирның зурлыгын, анда кемнәр яшәгәнен чамаларга мөмкинлек бирә иде.

Алар, кулларын юып, аш бүлмәсенә кергәндә, алъяпкычтан, олы яшьтәге ханым аш өстәле кырыенда кайнаша иде. Ул керүчеләргә борылды. Нурбәкне күреп, катып калды. Кулындагы итле савыты идәнгә төшеп чәлпәрәмә килде. Иреннәре кысылды. Кысылган иреннәр аша көчкә-көчкә генә ике сүздән торган җөмлә сытылып чыкты: «Син кайттың...» Тез буыннары калтырап, арык гәүдәсен күтәрә алмагандай идәнгә ауды. Зәлия күпме генә аңына китерергә тырышса да, «Ашыгыч ярдәм» машинасы килеп җиткәнче, хуҗабикә кулында җан бирде. Бу бичара карчык – аларның ашчысы, асраулары Зөлхиҗә иде.

Кем иде ул?.. Каян иде ул?.. Кемнәре бар? Кай тарафтан бу якларга, Себергә килеп чыккан? Бередә туган, дисәң, сөйләшүе чиста, нәкъ Казан арты сөйләме. Аның хакында үзеннән башка беркем дә берни дә белми иде.

Шәйдулла аны, Әлмәттән берегә күчеп килгәч, чеп-чи урыс шәһәрендә кечкенәсе Әнисәсе үз телен – ана телен онытмасын, дип, шәһәр картлар йортының элеккеге директоры, якын дусты Степанов Николай Иванович тәкъдиме белән, үзләренә асрау, өй хезмәтчесе итеп алып кайткан иде. Шул көннән башлап, Зөлхиҗә апа аларда яшәде. Акылы, сабыр, зирәк холкы белән үз кешеләренә, туганнарына әверелде. Аңарда нindидер үзенә генә хас зәвык, аристократларча затлылык бар иде. Алман һәм инглиз телләрен шома белүе, мандолина һәм рояльдә искитмәле уйнавы затлы гаиләдә тәрбияләнүен сиздерә иде. Кеше сүзенә кысылмады. Ярты ел саен, үз теләге белән, хастаханәгә барып, миннән шикләнмәсеннәр, сабый үстерәләр, дип, тикшерелеп кайта иде.

Каян килеп картлар йортына эләккән?! Чыгышы, нәсел-нәсәбе каян?! Зөлхиҗә апа үзе турында беркайчан да берни дә сөйләмәде.

«Син кайттың?..» Нәрсә әйтергә теләде ул?.. Нурбәкне кем белән бутады?.. Кемгә охшатты?! Туганынамы?.. Әллә баласынамы?.. Моны беркем дә аңлата алмый иде. Бу сорауга җавапны ул үзе белән мәңгелеккә алып киткәндер, дип уйладылар.

Шәйдулла, шәһәрнең картлар йорты, өлкә архивларын актартып, тикшертеп караса да, аның хакында бернинди дә мәгълүмат таба алмады. Еллар үткәч кенә Нурбәк, очраклы рәвештә, Зөлхиҗә карчыкның серенә азмы-күпме төшенә башлады.

Көннәрдән бер көнне Нурбәк, Әнисәсе белән телевизор карап утырганда, экранда Икенче Бөтендөнья сугышы вакытындагы балалар концлагерен

күрсәттеләр. Әнисәнең теленә җан керде. «Шулай берчак, – диде ул, – ул чакта миңа ничә яшь булгандыр, хәтерләмим, дүрт-биш яшь булды микән, Зөлхиҗә апа белән телевизор карап утырабыз – экранда нәкъ шушындый кадр: балаларны товар поездына төяп, Германиягә озаталар иде. Ачык вагон ишегеннән шыплап тутырылган балалар күренде. Иң алда сөяктән генә торган, коточкыч ябык бер кыз бала, ачлыктан йөзе зәңгәрләнеп, күз төпләре эчкә баткан нәни энесенме, әллә башка берәүнеме кочаклап басып тора иде. Зөлхиҗә апа, ачыргаланып: «Мөхәммәтҗан!» – дип, экранга капланды. Идәнгә ятып бөгәрләнә-бөгәрләнә, йодрыкларын тешли-тешли үксеп елады. Әйе, әйе, җиңү бәйрәмен каршы алган көннәр иде ул. Бишенче май – әтинең туган көне. Кичен безгә кунаклар – Василий Михайлович һәм Николай Ивановичлар хатыннары белән килгәннәр иде. Тынычлана төшкәч, Зөлхиҗә апа бу турыда беркемгә дә сөйләмәвемне үтенде».

***

Өй ишеге киерелеп ачылып, бүрегенең бер колакчыны төшкән, икенчесе өскә таба бөтереп күтәреп куелган, сул аягындагы киез итегенә галош кидерткән, таякка таянган Галимҗан килеп керде. Ишекнең төбенә кадәр киерелеп ачылуына, ишекне тотып калалмаганына үртәлеп, үз-үзен битәрләп:

– Эчергән кул! Ишек тотып калырлык та хәлеңнән килмәгәч, нигә яшәргә?! Мишәр әйтмешли, избагызга салкын кертеп тутырдым! – диде.

Көне буена кеше күрергә тилмергән Гөлйөзем:

– Өе җылыныр. Менә күңел суынмасын! Исәнлек-саулыкмы? – дип җаваплады.

– Соң... Күрмисеңмени? Әнә ич. Ишек тыңлатырлык та хәлем калмаган. Мәңгелек йортыңа китәргә вакытың җитте, төшеп ят, дисәләр, белмим, тибеп кенә төшермәсәләр, төшеп ятарлык хәлем булыр иде микән?.. Мин дөнья башланганда туган кеше бит инде. Арслан кайткан. Күрдегезме әле?

– Юк! Күрәсебез дә килеп тормый.

– Урамда, капкасы төбендә очрады. Сүзләрен көч-хәл белән аңлата. Әллә авызы чалшая башлаган. Селәгәе агып тора. «Киленгә түзеп була, малайга түзеп булмый. Малай талый. Малай начар, – ди. – Авылга кайттым. Аларда – шәһәрдә яшәп булмый. Өмет, Өметкәем вакытсыз китеп харап итте. Ул исән булса, мин мондый көнгә калмый идем», – дип, иярә килгән малаен исенә төшереп азаплана.

– Күрә әле ул. Кеше каргышы җирдә ятмый. Ул, бердәнбер исән калган төпчеге, ничек итеп аналары Рәшидәнең, әбиләре Мәликә түтинең газап чиккәннәрен оныткандыр дип уйлыйсыңмы?! Сабый чак мизгелләре онытылмый. Ул сабыйларның күргәннәре... Ярый әле, бәхетенә тегеләре үлде. Ул башкисәрләре исән булса, күрмәгәнен күрсәтәләр иде әле аның! Теге баласы кем атлы иде әле? – дип, яткан урынына җайлашты карчык.

– Кайсын әйтәсең, Гөлйөзем?

Баш астындагы мендәрен өскәрәк күтәреп:

– Иң өлкәнен, ияргә килгәнен беләм, Өмет! Тегесе... Иң беренчесе. Өметтән соңгысы. Уртак балалары? – диде.

– Тапкансың сорар кеше! Мин кайчакларда үз исемемне дә онытам, Гөлйөзем, – диде Галимҗан, сызлаган аягын уа-уа.

Арсланның иң беренче баласы Габдуллаҗан исемле иде. Мәктәпне әлле-мәлле генә көч-хәл белән бетерде дә, кешедән күрмәкче, бик тиз байыйм, дип,

читкә чыгып китте. Ярты ел чамасы югалып торганнан соң, өтек хәлдә авылына кайтып төште. Кайтып өч көн дә тормады, атасы белән пычакка-пычак килеп, канга батып сугышып, кичкырын, кояш батканда авылдан чыгып югалды. Атна-ун көн дә үтмәде, янәдән авылына кайтты. Бу юлы аның кулында затлы, кыйммәтле зур-зур бүләкләр тутырылган чемодан, кесәсе тулы акча, өстендә затлы кием иде.

Кайтып төшкән көнне үк авыл егетләрен сыйлап, кибеткә кергән һәрбер кешегә кибет шүрлегеннән нәрсә дә булса сатып алып бүләк иткәннән соң, үзенең энеләре белән өерелеп сугышып, кыйналып, клуб баскычына исереп ауды.

Арслан улының атна-ун көн эчендә баеп кайтуына шикләнә иде. Ул аны үз бусагасыннан атлатасы килмәсә дә, нишләсен, Өметнең сүзләренә каршы килалмады. Өмет: «Без агай-энеләре була торып, авыл халкыннан көлдереп, туганыбызны урамда, клуб баскычында аунатабызмыни?! Нәрсә генә дисәң дә, ул бит – безнеке, үзебезнең кан», – дигәч, ризалашты.

Габдуллаҗанның кинәт баеп кайтуы авыл халкында да шик уятты. Авылның үткен телле кешеләре, Арсланны күрүгә, көлеп: «Күчеп китәсез икән, дип ишеттем, кай тарафларга юл тотасыз, Себергәдер инде», – дигән сорауларына, Арслан: «Себердә миңа бетем калганмыни?! Ашыксаң, үзең бара тор», – дип җавап кайтара иде. «Себер» сүзен ишетүгә, ул эсселе-суыклы булып, куркып, калтыранып китә, күз алдына үзе төрмәләргә озаттырган Мотаваллар, Нуриәхмәт, Галиәхмәт, Галимҗан, Батырҗан, Мифтахлар килеп баса, Себерне ул башкача күз алдына китерә алмый, «Себер» сүзе аның өчен «төрмә» сүзе белән бер иде.

«Арсланның ышпанасы Себердә нефть вышкасы сатып алган, Арсланның башкисәре Себердә алтын приискасы сатып алган икән», – дигән мыскыллы сүзләрне ишетмәс өчен, ата кеше өеннән чыкмас булды. Авылның кыяк телле, әйткән бер сүзе белән кистереп, өздереп, өтеп ала торган кайберәүләре, мыскыллап: «Арслан Мотавал чакыруы буенча Себергә китә икән. Хәзрәт аңа үз шахтасында бер вакансия саклый, үзен самавырчы малай итеп алмакчы, шуның өчен Арсланның улын атасын алып килергә, кодаларга дип, күп акчалар тоттырып, киендереп кайтарып җибәргән, Габдуллаҗан атасы башына кайткан икән», – дип сөйләделәр.

Габдуллаҗанның гына бу гайбәтләргә бер дә исе китмичә: «Бер атна эчендә ничек бик тиз баеп кайттың?» – дигән сорауга: «Ярты ел шахтада эшләгән акчамны Әгерҗе саклык кассасыннан алып кайттым», – дип җавап кайтара торды.

***

Көтүче чишмәсеннән әллә ни ерак түгел иңкү урынны үткәч, бер чокыр бар. Авыл көтүен көтәргә ялланган күрше авыл марилары – Степан белән Николай, уйсу җирдә үлән күбрәк, куерак дип, малларын шунда куарга булдылар. Чокырга килеп җитәрәк, алдан киткән берничә сыерның чокыр төбенә төшеп, түгәрәк ясап, бер-берсенә карап, койрыкларын өскә күтәреп сөзәргә әзерләнгән кыяфәттә, шул җирне, чокыр төбен иснәүләрен күреп, гаҗәпкә калдылар. Карт мари Николай янәшәсендә телен асылындырып, арт аякларына утырып торган этенә «фас!» дип кычкыруга, кечкенә генә эт чәң-чәң килеп чокырга тәгәрәде. Сыерлар эттән өркеп читкә чәчелделәр. Эт алгы аяклары белән җирне чокыды да, авызына ниндидер чүпрәк кабып, артка тарта, чүпрәкне тартып

чыгармакчы булып тартыша башлады. Степан бу хәлне күреп, кызыксынып, чокырга төште. Төшүе булды, эт авызыннан чүпрәк өзелеп, маэмай артына тәгәрәде. Степан чүпрәкне тартып чыгармакчы булып иелде. Борынына сасы ис бәрелде. Чүпрәкне тартуы булды, җир астыннан адәм кулы килеп чыкты. Степан агарынып катты. Куркудан, ашыга-ашыга, өскә үрмәләде. Иптәшенә карап: «К-к-к... күрдеңме», – сүзенең «к» хәрефе генә авызыннан өзелеп чыкты.

Тегесе суларга да куркып, чокыр төбендә терсәгенең өске өлешеннән югарыга – җир өстенә чыккан кулның бер бармагы бөгелеп: «Кил монда! Минем янга!» – дигәндәй тоелып:

– Юк, юк! Не надо! – дип, борын астыннан мыгырданып алганнан соң, Степанга:

– Әйдә! Тизрәк башны алып качыйк моннан! – диде.

Степан каршы төште.

– Тизрәк авылга хәбәр итәргә кирәк, – диде ул.

– Кирәкмәс! Без үтергән диярләр. Бәласеннән башаяк! Күмик тә куйыйк.

Степан аның белән ризалашмады.

Урманнан бер күтәрәм чытыр урлап тотылып, биш ел гомерен төрмәдә утырып кайткан Николай, сорау алуларның нәрсә икәнен белгәнгә күрә, «Кирәкми! Ялгышасың! Башны харап итәсең!» – дип Степанга ялынса да, Степанның үз туксаны туксан иде. Ул читтә чирәм чемченеп йөргән атына таба йөгерде.

Бераздан ул авыл урамына очып диярлек килеп керде дә, авыл өстендә тузан өермәсе калдырып, кантор каршысына килеп туктады. Контор бакчасындагы сәрби куаклары белән янәшә, колхоз рәисенең ат бәйләү җайланмасына бәйләнгән, тарантаска җигелгән күк айгырын күреп: «Әһә, ул монда икән», – дип, җәһәт кенә атыннан сикереп төште дә, атын да бәйләп тормыйча, идарә урнашкан йортка кереп китте.

Озак та үтмәде, күзе-башы тонган Степан контордан атылып чыкты. Чыкты да, мондагы галәмәтләргә исе китмәгәндәй, солы тирәсендә иснәнеп, кияү егетеннән качып йөргән биясен эләктереп алып, менеп атланды. Атының арт санына тезгене белән каты итеп сыдырды. Җирән бия арт аякларына басты. Алга ыргылды. Бераздан пожар каланчасы урнашкан югары урамга кереп югалды.

Авылда чаң каккан тавыш яңгырады. Степан трактор чылбырларын бер-берсенә ялгый торган кырык-кырык биш сантиметр озынлыгындагы йомры тимер кисәге белән пожар каланчасы кырыендагы баганага эленгән сабан төрәненә ярсып-ярсып сукты.

Каланча урнашкан югары урамнан авыл үзе дә, тирә-ягы да уч төбендәге кебек күренеп ятканга күрә, авыл читендәге басуда чөгендер утап яткан авыл халкының карты да, яше дә, бала-чагасы да чаң тавышына авылга йөгергәннәрен, авылдагыларның кулларына чиләкләр, багор, көрәк ише ут сүндерергә яраклы әйберләр күтәреп, капкаларыннан чыгып, каушап, башта кай тарафка барырга белмичә аптырап калуларын да күрергә мөмкин иде.

***

Мәетне казып алып, ат арбасына салып, авылның су саклагычы янына кайтарып туктаттылар. Мәет ир затыннан иде. Буен, чәченең төсен әйтеп булса да, йөзен танырлык түгел, озак ятудан сөягеннән ите аерыла башлаганга күрә, бала-чагаларны, олы яшьтәге кешеләрне, хатын-кызларны, куркырлар,

дип, мәет тирәсенә китермәделәр. Районнан килгән милиционерлар авыл ир-атларын берәм-берәм мәет янынннан уздырдылар. Чират Габдуллаҗанга җитте. Ул мәет кырыена җитүгә, җирәнеп, җиргә төкерде. Бу – районнан килгән милиция капитаны Бәшәровка бер дә ошамады:

– Фамилиягез?! – дип сорады ул.

– Нигә? Габдуллаҗан! Отчествам да кирәкмиме?! Арслан атлы кеше улы булам!

– Бу кешене белми идегезме?! – дип өстәде капитан.

– Бу бит – кеше түгел, үләксә, мәет! Мин әлегә мәетләр белән таныш түгел, тегендә баргач танышырмын, – дип, Габдуллаҗан борынын тотып алга атлады.

Бәшәров янына милиция машинасы килеп туктады. Машина ишеге ачылып, кабинадан районның милиция начальнигы Хәбипов төште. Алар Бәшәров белән үзара бер-ике кәлимә сүз алыштылар да, Хәбипов:

– Иптәшләр! Соңгы атна-ун көндә, әйтик, берәр ай элек авылга читтән кайтучылар булдымы? – дип сорады.

Җыелган халыкның күзе Габдуллаҗанга төште. Габдуллаҗан, эшнең кай тарафка тәгәрәгәнен сизеп, ипләп кенә артка чигенде, халыктан аерылып, янәшәдәге урманга карады. Күзе белән тирә-якны барлап чыкканнан соң, үзеннән ерак түгел чирәм ашап йөргән җигүле атны күреп, шунда йөгерде. Йөгереп барган уңайга дилбегәне эләктереп алды. Ат арбасына сикереп менеп, йөгәне белән атны камчылады. Ат, кушаяклап, урман тарафына чапты.

Вакытсыз дөньядан киткән кеше – солдат, моряк хезмәтеннән соң, Владивостокта балык тотучылар артеленә ялланып, өч ел эшләп, туган авылына, ялгыз әнисе янына кайтып баручы, күрше район егете Әнвәр булып чыкты.

***

Әнвәр утырган поезд Әгерҗе тимер юл вокзалына кичкырын, кояш баер алдыннан килеп туктады. Ул, авыр чемоданнарын күтәреп, вокзал мәйданына, перронга төште. Армия хезмәтенә киткәндә – бер, җиде елдан соң икенче тапкыр аяк баскан бу вокзал аның өчен таныш түгел, һәр куагы, үскән агачы, йортлары чит, хәтта, татар телендә сөйләшсәләр дә, үз теле, ана теле күңеленә якын булса да, колагына сәер тоела иде.

Әгерҗе аның өчен чит. Әгерҗедә аның сүз катар, кереп сыеныр кешесе юк. Аның теләге – ничек тә авылына кайту. Тик ничек?

Вокзал мәйданчыгындагы эскәмиядә утырган, гомере буе берәр чемодан алтын йә булмаса акча табу хыялы белән яшәгән Габдуллаҗанның күзләре перрондагы авыр чемоданнарга төште. Тик ничек?.. Күзе вокзалның арткы ишегенә килеп туктаган атның арбасыннан исерек бер адәмнең, алпан-тилпән, ящикларны эчкә – вокзал буфетына ташыганын күреп, аның янына килде. Исерек белән бер-ике сүз алышканнан соң, ящик күтәреп, ул да эчкә кереп китте. Озак та тормады, чыгып, Әнвәр янына килде.

Әнвәр сүзгә саран булса да, сүзгә-сүз иярә, сүзгә-сүз тагыла дигәндәй, җиде елдан артык туган җиренә кайтмаган, туган җирен сагынган кешенең телен ачу, телен чишү Габдуллаҗан өчен авыр булмады.

Бераздан алар, исерекнең атына утырып, Әгерҗе читендәге урманга кереп баралар иде инде...

***

...Габдуллаҗанны атна буе тота алмадылар. Авылның актарылмаган сарае, мунча, каралтылары, өй түбәләре, кар базлары калмады. Хәтта коеларга кадәр тикшерделәр. Басулардагы эскерт, чүмәлә өемнәрен берәмтекләп карап чыктылар. Шәһәр гарнизоныннан солдатлар чакыртып, милиция хезмәткәрләре белән бер рәткә тезеп, урманның аркылысын буйга җентекләп актарсалар да, аның эзенә төшә алмадылар.

Иң авыры Рәшидәгә иде. Тугыз ай буе йөрәге янында йөртеп, ашатыр ризыгы булмаганлыктан, чираттагы баласына авырга узып та, ул баласын тапканчы, күкрәгендә сөте кипкәнче имезгән, азапланып, холыксыз иреннән качып, кычыткан, карлыган куаклары, лапас түбәләрендә кача-поса, ачлы-туклы шушы яшенә кадәр үстергән баласының кеше үтерүе ана өчен әйтеп аңлатмаслык авыр газап иде. Ире Арсланның атна буе сорау алучылар кулыннан кыйналып, сугылып, Мотавал өендә газап чиккәннән соң бауга менүе Рәшидәне тәмам аяктан екты.

Арслан сорау алучыларның эзәрлекләүләренә, кыйнауларына түзә алмады, алар чыккан арада, Мотавал өенең түр бүлмәсендәге түшәмгә тишеп эшләнгән, Нуриәхмәт белән Галиәхмәтнең сабый чактагы тал бишекләрен элгән элмәк турысына урындык китереп куйды да менеп басты. Бил каешын чалбарыннан суырып чыгарып, элмәккә бәйләде. Икенче башыннан муенына салды. Урындыкны тибеп аударды. Тик элмәк түшәм сайгагыннан суырылып чыгып, Арслан гөрселдәп идәнгә егылды. Ярсып, ачынып, идән тактасын тырный-тырный үксеп елады.

Шул ук көнне аны районга алып киттеләр.

***

Нуриәхмәт иртә таңнан торып урманга җыенды. Аның бу эшен Гөлйөзем сизеп:

– Син кая болай?! Иртә таңнан кая җыендың? Урмангамы?! Арслан баласын эзләргәме? Ике аягыңның берсен атлыйсы булма! Башкисәр ул! Синең башыңа җитәргә дә күп сорамас, – дип ялварды.

Нуриәхмәт дәшмәде. Аягына чолгау урады. Күн итеген киде. Кичә генә мичтән чыккан түгәрәк икмәкне күкрәгенә куеп кисте дә өстәлгә чүпрәк җәйде. Икмәкне төрде. Мич башыннан яньчелеп беткән, үзе белән бергә картайган, гражданнар сугышыннан кайткан солдат фляжкасы алып, ишек бусагасы кырыенда, җиләсрәк җирдә – идәндә, балчык кувшинда сакланган кәҗә сөтен шунда салды. Биленә бау бәйләде. Икмәк белән фляжканы куенына тыкты. Мич арасына кереп чыкты да Гөлйөземнең: «Әгәр минем сүзләремне тыңламасаң, бәхиллегемне бирәсем юк», – дип кычкырып калуына да игътибар итмичә, ишекне тышкы яктан япты.

Нуриәхмәт Габдуллаҗанның кайда качып ятканын чамалый иде. Капкасыннан чыгуга ук урманга борылды. Урман эчләп ага торган киң елганың сөзәк ярлары буйлап ярты көн чамасы баргач, карт бер имән төбенә утырды. Икмәк төрелгән киндер чүпрәген җиргә җәйде. Сөтле фляжканы чыгарды. Итек балтырыннан чүпрәккә төрелгән пычак чыгарып, икмәкне телемнәргә телеп, чүпрәккә куйды.

– Улым, Габдуллаҗан, чык!

Ничә еллардан соң авызыннан беренче тапкыр чыккан бу сүзләр аның үзенә дә сәер булып тоелды.

– Габдуллаҗан, улым, чык! Мин беләм, син биредә.

Яр читендә качкынның йөзе күренде.

– Кил! Тамагыңны ялгап ал! Менә икмәк, сөт!

Габдуллаҗан гаҗәпләнгән хәлдә өскә үрмәләде. Курка-курка гына, як-ягына карана-карана, Нуриәхмәт янына килде.

– Син!..

– Әйе, мин!

– Син сөйләшәсең?!

– Әйдә. Тамагыңа аша да, кайтабыз.

Габдуллаҗан чүпрәк өстендәге икмәк телемен алып авызына тутырды. Кабалана-кабалана, фляжканың капкачын ачып, сөтне авызына койды. Сөтле икмәкне авызыннан чәчә-чәчә:

– Нуриәхмәт абзыкай, мин кайтмыйм! Минем бернинди дә җинаять эшләгәнем юк! Мин үтермәдем аны. Аңлыйсыңмы, мин үтермәдем! Анам, атам белән ант итәм! Менә шушы икмәкнең чыраен күрмим! – дип пышылдады.

– Ярар, ярар. Мин ышанам сиңа. Милицияләргә дә шулай дип аңлатырсың.

– Алар мине аңламаячаклар. Мин аларны беләм. Алар кешегә ышана торганнар түгел. Нуриәхмәт абзый, Нуриәхмәт абзыкаем, син мине теге авылдан чыгып киткәннән соң ярты ел кайда йөргән, кайда яткан, дип уйлыйсың соң?! Шулар, шул кабахәтләр ябып яткырды мине. Ни өчен диген?.. Нәрсә өчен?! Үз теләгем белән түгел. Ачлыктан, ачлыктан бит. Бер хатынның кулындагы сумкасын тартып алдым. Шуның өчен ярты ел бит, ярты ел! Мин үтермәдем аны. Мин үтермәдем! – дип ярсып-ярсып елый, авызына дыңгычлый-дыңгычлый икмәк тутыра, сөт катыш икмәге, авызыннан бүселеп чыгып, ирен кырыеннан түшенә тәгәри иде.

– Атаңны үтерәләр! Анаң кайгыдан егылды. Кайтабыз! Кайтабыз, улым. Атаң-анаң хакы бар. Син кылган эш түгел икән, аңлатырсың, аңларлар.

Бу – Нуриәхмәтнең авызыннан чыккан иң соңгы сүзе, соңгы җөмләсе иде. «Аңлатырсың, аңларлар!..»

Нуриәхмәт белән Габдуллаҗанның урамга килеп кергәнен күреп, кайберәүләр күзгә-күз очрашырга, күзгә бәрелергә теләмичә, качып-посып, читән, койма ярыкларыннан карап калсалар, мәнсезрәкләре, кызык эзләп, берәм-берәм капкаларыннан чыгып, бала-чагалар белән аларга иярделәр.

Габдуллаҗанның авызында һаман бер сүз.

– Нуриәхмәт абзый, Нуриәхмәт абзыкай, мин үтермәдем, мин үтермәдем аны! Минем чыпчык та үтергәнем юк! – дип, ярсып-ярсып елый иде.

***

– Исемә төште, – диде Гөлйөзем, түшәм тактасына карап яткан хәлдә. – Тинтәкләр! Соң бит ул чокырны бүгенге көнгә кадәр «Габдуллаҗан чокыры» дип йөртәбез. Олы баласының исеме Габдуллаҗан иде. Кеше үтереп, үзен төрмәгә алып киткәннән соң шактый еллар узгач, бер тапкыр төнен кайтып киткән, Арслан бәхиллеген бирмәгән икән, дип сөйләделәр. Хәтерләсәгез, аналары Рәшидә балалары кайгысыннан акылдан шашкач, урам буйлап, яланаяк, иңсәсенә бик матур зәңгәрсу шәлен салып, кибет янына килә иде дә шәлен болгый-болгый йөзеп биеп китә, аннары туктый алмыйча, шашып, авызыннан күбекләр килеп, кибет каршына ава, диләр иде. Ул шәл – шул төнне улының анасына бүләк иткән шәле икән, дип сөйлиләр иде.

Икенче улы – Ибраһим атлы иде...

– Анысын хәтерлим. Укуын, мәктәбен бетергәч, ике ай чамасы минем белән фирмедә эшләде әле ул. Таналар карадык. Шуннан армия хезмәтенә китте. Алама егет түгел иде ул. Эшкә нык, кыяфәте белән суйган да каплаган – нәкъ анасы Рәшидә иде инде, – дип сүзгә кушылды Галимҗан.

– Ул гәүдә дисеңме – алып! Аяк – кырык дүртенче размер. Авыз Рәшидәнеке төсле, мулдан. Куллар – көрәк. Анасыныкы төсле озын гәүдәсен кечерәйтер өчен, бөкрәеп йөри иде. Армиядә авырлыкка түзалмый асылынган, дип сөйләделәр. Минем ышанасым килмәде. Авырлыктан курка торган бала түгел иде ул. Асканнардыр аны. Холкы белән атасына охшап, үҗәт иде шул. Үз туксаны туксан булды гел.

– Галимҗан, хәтерем ялгышмаса, өченчесе – Гарифҗан – калхуз идарәсендә баш хисапчы ярдәмчесе булып эшләде, ахрысы. Күрше авылның кибетен басып, ике ящик аракы алып чыгып, ирегеннән мәхрүм ителгәч, өч елга якын төрмәдә утырып чыкканнан соң, авылга кайтып ай ярым да тормады, уникенче басуда салам эттергәндә, «Беларусь»ы белән артка – Марҗа чокырына мәтәлеп төшеп үлде, – дип хатирәләрен дәвам итте Гөлйөзем.

– Нинди хисапчы булсын, ди инде ул, Гөлйөзем. Аларга тагын хисапчы! Арсланнар – нәселләре белән аңгыралар бит алар. Әрсезлек, нахаллык бар, белем – юк. Арсланы да бит аның, кулына тоттырган кәгазьнең кайсы башы, кайсы ахыры икәнен белмичә, биш-алты тапкыр әйләндерсә әйләндерде, әмма, укый-яза белмим, дип әйтмәде. Аңа тагын хисапчы ярдәмчесе! Арслан аңгырасы да хисапчы ярдәмчесе булса, башкаларга нишләргә?.. Анасының абыйлары – Мәмлиевләр читават итеп куйдырган иде. Ике ящик аракы өчен кибет басып азапланмады ул. Безгә әйтелгәне генә ике ящик. Кешегә чыкмасын инде. Калхузның акча саклый торган сейфын басып әләкте. Әлеге дә баягы, шул районгдагы агай-энеләре – Мәмлиевләр җайлады. Ул вакытта Мәмлиевләрнең төпчек кызлары райпо складында җитәкче иде. Өстенә бик зур сумма чыккан, диделәр. Имеш, кичтән күрше авылның кибетенә райподан товар кайтарып тутырганнар да, иртәнгә басканнар. Аннан алдагы төнне Арслан баласы Гарифҗан сейф баса. Төннәрне алмаштыралар. Ул балага нәрсә?.. Сейф басса да, кибет басса да – төрмә. Янәсе, Гарифҗан берничек тә сейфны басалмый. Сейф баскан көнне ул, кибет басуда гаепләнеп, район изоляторында булган. Чын җинаятьчене – кибет басучыны нигә табарга? Аны тотсалар, дөреслек ачыла. Милицияләргә дә җайлы. Кибет басучыны эзләп торасы юк. Җинаятьче бар – Гарифҗан. Дело ябык. Сейф хакында җинаять эшен туктату авыр түгел. Сейфтан алынган акча – Арсланнар кесәсендә. Колхозны әлегә тикшерергә җыенучы юк. Тикшерергә килсәләр, Мәмлиевләр, Арсланнар кесәсендәге акчаны сейфка салу авыр түгел. Аңынчы, тикшерүче килгәнче, берәр җае чыгар да әле. Шулай килеп чыкты да. Ярты елдан соң, аракыдан башын ала алмаган Вәрисне – Саескан Сәлисәсе белән Шадра Мәхмүтнең улын, калхуз сейфын баскансың, дип, исерек килеш фермада сыерлар астына җәяргә дип керткән салам өстендә аунап, исереп йоклап яткан җиреннән кулга алып, өч елга ирегеннән мәхрүм иттеләр. Сез нәрсә?! Сейф аның кулы иде дип уйлыйсызмы әллә? Пүчтәк! Ул бала эше түгел иде ул.

– Яшьли үлгән Фәтхулланың, картлык көнемдә үземне тәрбияләүче өметем булыр, дип өметләнеп исем куштырган Өмете, картайган көнендә Арсланның ныклы терәге, сыеныр почмагына, иң яраткан баласына, өрмәгән урынга да утыртмый торган, мунчада әйләндерә-әйләндерә чабып, баштанаяк юындырып тәрбияли торган ышанычлы кешесенә әйләнгән иде дә, гомере генә кыска булды. Ярты ел элек

кинәт кенә каты авырып үлеп китте. Арслан бердәнбер исән төпчеге – Мансурында калды. Мансурның төс-кыяфәте дә, холкы да атасыннан ерак китмәгән. Ике көннең берендә үзара ызгышып, Арслан, өенә кайта алмыйча, шәһәр паркында йә булмаса вокзалда, подъездда гомерен уздыра, өендә куна алмаган көннәре дә булгалый икән, – диде Гөлйөзем, сөйли-сөйли, тамагы карлыга башлап.

Нуриәхмәт авыр сулыш алды.

– Авыр сулама! Авыр сулама! Нәрсә әйтергә теләгәнеңне беләм. Син үзең дә гаепле, димәкче буласың. Мин аның хатынына да, балаларына да һичкайчан да начарлык теләмәдем. Мин аның үзенә – бары тик аңа – шушы көннең килүен теләп яшәдем. Аның ялгышын көтеп яшәдем. Һәм ул ялгышты. Яшьлегемдә, балам белән куркытып, миннән кол ясаса, картлыгында үзе баласының колына әверелде. Барысы да мин уйлаганча бара! – дип, Гөлйөзем, хәлсезләнеп, күзләрен йомды.

Галимҗан, урындык алып, мич алдында олтан салып маташкан Нуриәхмәт янына килеп утырды.

– Нуриәхмәтнең «ә»се дә, «җә»се дә юк инде аның. Бер ноктага баккан да, эшли дә эшли. Көн эшли, төн эшли, ничек туймый? Картайдык, яшьти, картайдык. Кабер якадан алды. Сезгә килгәнче, бишәр-алтышар тапкыр туктап ял итәм. Тын бетә. Күрсәтте дөнья! Барысын да күрсәтте. Алдын да, артын да ачып күрсәтте: төрмәсе дә калмады, сугышы, штрафной батальоны да. Күрде егет башлары! Ярый әле, без синең белән аяксыз, телсез булсак та – кайттык. Ә менә Батырҗан эзсез, хәбәрсез югалды. Җир йоттымыни үзен! Әнә Арслан мәләдис! Сәвит законы белән барыбызны да төп башына утыртып, төрлебезне төрле якка өтермәгә озатып, үзе сугышка да бармыйча, бездән калган хатыннар белән типтереп, калхуз икмәген ашап яшәде.

Гөлйөзем үзенә килеп кадалган кылчыклы җөмләгә җавап йөзеннән:

– Харап икән. Нәрсә?! Сүз берләштегезме?! Әнә хәзер, селәгәен агызып, үз авылында күршесенең капкасын, ишеген ачарга, тупсасын атлап керергә дә куркып, тилмереп йөри! – дип кычкырды.

Галимҗан, кирәкмәгәнрәк җөмлә әйтүен аңлап, сүзне икенчегә борырга теләп:

– Бу синең Мифтахың да, аракысын ташлагач, бик тиз киңәеп, баеп китте әле, – диде.

– Төпчеге – Нурбәге тугач иркенәйде. Мифтахым атасына охшаган, бабасы Мотавал ягына тарткан. Эш ярата. Суйган да каплаган – атасы, – Гөлйөземнең шатлыгы сизелеп тора иде.

– Төс, кыяфәт белән Нуриәхмәткә охшаган, дип әйтмәс идем.

– Нишләп Нуриәхмәткә охшамасын? Авыл халкы, Галиәхмәтнең миңе булмаса, Нуриәхмәттән аерып алала идеме соң?! Аларны аналары Мөсәгыйдә абыстай аералгандыр да, мин генә аера ала идем. Суйган да каплаган – атасы Галиәхмәт инде Мифтахым. Соңгы елда – Себердә, киленебез Әнисәбезнең атасы Сабир кодабыз, Нурбәгебезнең бабасы кул астында нефтяникларда эшләп кайтты бит.

Галимҗан, Галиәхмәт исемен ишетүгә, башта аптырап, аннары көлемсерәп, борын астыннан мыгырданып, әллә дөрес, әллә ялгыш ишеттем, дип, кабат сорарга батырчылык итмичә, хисләреннән арынып:

– Әйтсәм әйтим инде, Себергә ике-өч тапкыр барып, ничек итеп мәчет салырлык акча юнәтеп була торгандыр ул? Тегеннән, җил тегеннән исә. Авылга мәчет салдырырга йөри, диме?.. – дип сорады.

– Мифтах авылга мәчет салдыруын салдыра алмас, сүзләрем фәрештәләрнең «амин» дигән чагына туры килеп, улы Нурбәк салдырса гына! Аллаһы боерса, бабасы Галиәхмәтнең исемен дә куштырыр!

– Бабасы?!

– Әйе, бабасы Галиәхмәт исемен!

– Бирсен Ходай. Тик торганда гына чишмә буенда пар каен үсеп чыкмады... Нуриәхмәтнең дә безнең белән җомгага йөрмәве аңлашыла.

Гөлйөзем, ятагына җайлашыбрак:

– Чукрак бит ул, – диде.

– Чукрак түгел... Чукрак түгел ул...

Кулындагы таягын идәнгә төшерде.

– Әнә! Башы тавыш килгән якка борылды. Беләм. Сизәм. Чишмә буендагы пар каеннар – атасы Мотавал абзый белән Мөсәгыйдә абыстай каберенә утыртылган каеннар. Шунда кача-поса барып, җомга саен Коръән чыкканын да беләм.

– Булмаганны, тузга язмаганны сөйләп тә карыйсың инде, Галимҗан. Аларны бит сез үзегез Себергә озаттыгыз!

– Озаттык шул, озаттык... Сезгә килүемнең дә сәбәбе шул. Минем беләсем килә. Гөлйөзем, бәлки, минем сезнең бусагагызны соңгы тапкыр атлап керүемдер. Яшермә, әйт: Мотавал абзый белән Мөсәгыйдә абыстай шунда җирләнгәнме?! Берәүгә дә әйтмәм. Китәр вакытым җитте. Мин дә, барып, алар өстендә Коръән чыгар идем. Тешләде мине дөнья! Имгәтте! Җанымны, бәгъремне имгәтте. Тегендә барасым бар! Алар каршына барасым бар! Җавап тотасым бар!

***

Галимҗан пар каен төбенә намазлык җәя алмады. Гөлйөземнәр капкасын ябып чыкканның иртәгесендә, таң алдыннан, күзен йомды. Шул ук көнне аны җир куенына салдылар. Соңгы юлга озатучылар күп булмаса да, Арсланның Мансуры кайткан иде. Атаның моңа ачуы чыкты.

– Нәрсә?! Минем хәлемне белергә кайтканың юк, бу аксак үлгәч, ояңнан куптың?!

– Әби, әбекәй әманәтен, васыятен үтәргә кайттым, – диде төпчек. – Нигәдер ул безгә һәрвакыт Галимҗан абзыйга игътибарлы булырга куша иде. Вакыты җитеп, соңгы юлга – җир куенына салганда, кайда гына булсагыз да, нинди генә эшегез булса да, озатырга кайтыгыз! Хәер өләшегез! Дога укытканда, аның исемен атамый калдырмагыз! Миңлемөхәммәт бабай улы Галимҗан абзый рухына, диярсез, дип әйтә иде. «Ни өчен?! Нәрсә өчен аңа шундый хөрмәт?» – дигән сораудан һәрвакыт кача иде.

Ишегалдыннан кемнеңдер:

– Ләхет такталары юк бит, егетләр. Ләхет такталары әзерләнмәгән! – дигән оранына, Арслан, башын түбән игән хәлдә, хәлсез тавыш белән, улына:

– Чормада әзерләп куелган ләхет такталары бар. Алып төшеп бир, – диде дә, кеше булмаганрак җиргә, читкә китте. Күз алдында, бер якта ир-ат киеменнән сыер астында имчәк тартып утырган шәүлә – анасы Мәликәнең: «Нишлим?! Кая барыйм?! Оныкларым – балаларың ачтан шешенә бит!» – дигән ялварулы карашы булса, икенче якта Галимҗанның: «Барысы да исәнме?..» – дигән сораулы карашы иде.

Анасы Мәликә түти, үз ятагында да йоклый алмый теләсә кемнең идәнендә,

лапас түбәсендә, карлыган араларында сабыйлары белән төннәрен уздырды. Хатыны кыйналулардан, улларының авыр хәсрәтеннән тилереп, Богады урманында адашып үлде.

Арсланның сузылып ятып, үксеп-үксеп елыйсы килде. Елар да иде, авылдашларыннан оят. Авылдашлары карап тора. Кычкырып-кычкырып җырлар иде, моңын аңлаучы булмас. Далага чыгып, бүре булып улар иде, койрыгы бот арасында. Үз ыруын каһәрләгән адәм! Вожак була алмады...

Тамагына килеп тыгылган төерен йоталмыйча:

– Бетте! Барысы да бетте! – дип ыңгырашты.

***

Мифтахлар капка төбендә затлы машиналар җыелган иде. Нуриәхмәт корткасы Гөлйөзем бик авыр хәлдә, бүген-иртәгә үләргә мөмкин, Себердән кайтасы оныгын – Мифтахның төпчеге Нурбәкне генә көтеп ятмый микән, дигән хәбәр авылга таралды.

Чыннан да, Гөлйөзем Нурбәкне көтте. Мифтахның биш баласы арасында бердәнбер ир бала булып туган Нурбәк – аның аеруча яраткан оныгы – Галиәхмәтенә охшаган иде.

Гөлйөзем үз янында Нурбәкне генә калдырырга әйтте. Күз карашы белән оныгыннан үзен сөяп утыртуын сорады. Оныгы аны ястыкка сөягәч, ымлап, үзе янына утырырга кушты. Озак итеп оныгына карап торганнан соң:

– Галиәхмәтем минем! Каян, ерактан кайттыңмы, олан?! – диде.

– Себердән кайттым, дәү әни.

– Нindirәк җир инде ул – безнең гомер буе бәгырьләргә төшкән җир?

– Бик матур җирләр, дәү әни. Бигрәк тә язын.

– Шуңа кайтмагандыр инде.

– Шуның өстенә бик салкын.

– Туңып, катып үлде микән?.. – Мендәр астыннан кулъяулык чыгарып, хәлсез бармаклары белән кулъяулык почмагындагы төенне сүтте. Калтыранган бармаклар арасыннан, тәрәзәдән төшкән кояш нурларына манылып, күз явын алырдай, чәнти бармак очы кадәр зурлыктагы асылташ Нурбәк алдына тәгәрәде.
– Бәхетле бул, балам! Дүрт кыз туганыңның терәге бул, олан! Гыйбадәт кылган йортыңның гөмбәзе, шушы асылташ кебек, тирә-ягыңны яктыртып, балкытып, нур сибеп торсын. Минем шушы теләкләрем фәрештәләрнең «Амин» дигән чагына туры килсен. Бәхил бул, балам, – диде пышылдап Гөлйөзем.

***

Чишмә тавындагы кабергә кем яки нәрсә җирләнгәнен озак еллар беркем дә белә алмады. Ир белән хатын күп очракларда бер-берсеннән калып озак яшәми, диләр, хактыр. Дөреслекнең йөзен ачарга теләгәндәй, ярты ел чамасы үтүгә, Чишмә тавында икенче кабер дә барлыкка килде. Озак та үтмәде, каберләр өстендә каеннар үсеп чыкты. Еллар үткән саен, алар үсте, юанайды. Халык телендә чишмә тавы – «Хәзрәт тавы»на, чишмә – «Изгеләр чишмәсе»нә, Мотавалларны яратмаганнар телендә – «Хәсрәт тавы», «Хәсрәт чишмәсенә», «хәзрәт» белән «хәсрәт» сүзенең мәгънәсен дә аңларга, ишетергә теләмәгән Арслан кебекләр өчен «Колын тавы», «Колын чишмәсе»нә әверелде.

Бу өч яклы исемгә, Нуриәхмәт асылынып үлгәннән соң, оныклары чик куйды.

Кайсы кабердә карт әбисе Мөсәгыйдә йә булмаса Мотавал бабасы ятканын

төгәл генә белмәгәнгә күрә, өч каберне дә бер чардуган эченә кертеп, өчесенең дә исемнәрен яздырып уртак таш кую теләге белән, Нурбәк, Әнисәсен һәм дүрт яшьлек улы Инсафны машинасына утыртып, Чишмә тавына төште. Машинасыннан чыкмыйча, руль өстенә терсәкләрен куеп, кулы белән яңагын тоткан хәлдә, озак кына үзе утырткан каенга карап торды һәм, машинасыннан төшеп, карт каен кырыена килеп чүгәләде. Инсафын үз янына чакырып, тезенә утыртты.

– Улым, – диде ул. – Бу нинди агач?

– Биёза, – диде малай, борын астындагы юешеннән телен шудырып.

– Берёза түгел, улым. Ка-ен! Каен бу.

– Кайн, – дип кабатлады урыс акценты белән теләр-теләмәс кенә, атасы сүзен кабатларга өйрәтелгән, чит урынны үзенеке итәргә дә өлгермәгән сабый, күзләре белән тирә-якны күзәтеп.

– Бу урын, бу каеннар – синең һәм минем бабаларым җирләнгән изге урын. Менә бу карт каен астына безнең әбиебез – минем дәү әнием, синең өчен өчләтә дәү әни, өчәү ничек була әле ул? – дип улының бармакларын бөгә-бөгә санатып: – Өчәү! Мөсәгыйдә дәү әниебез җирләнмәде микән, дигән уем бар. Нуриәхмәт бабаң да якты дөньядан котылу юлын нәкъ менә шушы каен төбендә дип уйлаган. Ни өчен?! Нигә?! Димәк, ул анда кем ятканын белгән. Яшәгән чорының корбаны булып, дөньяда дөреслекне табалмый, кыйналып, тапталып, рәнҗетелеп, яклаучысыз калгач, арып-талып, үзенә сыеныр урын эзләп, бирегә – каен төбенә килгән. Каен ботагына үлем бишеге асып, үз гомерен шунда салган... Аның бу фатихасыз гөнаһ бишеген анасы Мөсәгыйдә тирбәтер, җаныма тынычлык, рәхәтлек алырмын, дип, мәңгегә күзен йомгандыр. Әнә теге каен – Мотавал бабаңныкы! Ә менә монысын мин утырттым. Мин үлгәч, минем каберемә ак каенны син утыртырсың! – диде.

Әнисә сабыен, атасы тезеннән алып, күккә чөйде.

– Ашыкма! Әле мине үстерәсең бар, әти, дип әйт, улым!

Нурбәк, бөтен дөньяга ишетелерлек итеп:

– Улым! Бу күк, бу җиһан – синең өчен! Бу кырлар, бу аланнар, бу чишмәләр – синең өчен! Бәхетле бул, балам! – дип кычкырды.

Аның тавышында киң даланы яңгыратып кешнәгән ат, елкы тавышы да, иксез-чиксез далаларда кылганнарны тараган дала җиле, урман шавы, чәчәкләр исе, җиләк тәме дә бар иде.

Нурбәк урыныннан торды. Улын җитәкләп, машинасына алып килде. Багажнигын ачып, көрәк, берничә чөй, олы чүкеч чыгарып, каеннар арасына куйды. Улының кулына биш литрлы буш савыт тоттырып:

– Әйдә, егет! Су алып менәбез, – дип, улын күтәреп, Әнисәсен җитәкләп чишмәгә төшеп китте.

Алар, төшеп, битләрен салкын чишмә суында юып ятканда, машина килеп туктаган тавыш ишетелде. Әнисә дә, Нурбәк тә тавыш килгән якка күтәрелеп карадылар. Үгез кадәрле кап-кара япон машинасының алгы ишеге ачылып, рульдән хатын-кыз төште. Арткы ишеген ачты. Ачык ишектән өч-дүрт яшьлек кыз бала чирәмгә басты.

Нурбәк сискәнеп, эсселе-суыклы булып китте. Бөтен тәне буйлап кайнарлык йөгерде. Чүгәләгән җиреннән бер торырга, бер тормаска белмичә, аптырап калды. Бит алмалары кызарып, маңгаена тир бәреп чыкты. Әнисә, эшнең нәрсәдә икәнен аңлап, Инсафын җитәкләде.

– Нурбәк, уяу бул! Йоклап торма! Кулыңнан ычкындыра күрмә!

Ничә еллардан соң беренче тапкыр күргән беренче мәхәббәте алдында югалып калган Нурбәк, Әнисәсенә нәрсә әйтергә белмичә:

– Син нәрсә инде, Әнисә, – дип авызын ачуга, Әнисәсе:

– Юк! Син уйлаган нәрсәне әйтмим!.. Савытыңны ычкындыра күрмә! Агып китә күрмәсен, улагыңа кара, дим. Әйдә, улым! Бабаңнар янына! Безгә монда рәт бетте! – диде.

Шундук Нурбәккә үтәли тишеп чыгарлык итеп карап:

– Әйдә, әйдә, улым! Атаңның сүзен онытмыйк! Син әле – кемгәдер каен утыртасы кеше. Нәсел дәвамчысы! – дияргә дә онытмады.

«Каян белгән? Белеп төшкәнме, белми төшкәнме?.. Ул аны танырга өлгердеме? Әллә танымадымы?.. Бәлки, таныр да кире борылып китәр. Күрә ич. Хатыны, баласы белән икәнен дә күрә...» Секунд эчендә шундый сораулар яшен тизлегендә Нурбәк башыннан узды.

Чишмәнең аргы ярыннан, җитәкләшеп, Инсафы белән Әнисәсе үргә – югарыга атласалар, икенче ягыннан Лилия, кызын җитәкләп, чишмәгә төшә иде.

Инсаф әллә кечкенә кызны күреп, әллә атасыннан аерыласы килмичә, анасы кулыннан ычкынып:

– Әти, әти! – дип, аска – атасы янына, тау астына чишмә тарафына йөгерде. Әнисә, улы төшеп киткән якка борылып та карамыйча, атлавын дәвам итте.

Инсаф белән кунак кызы чишмә басмасында борынга-борын төртелделәр. Бер-берсенең күзенә карап бөтерелгәннән соң, кыз чишмә йортына йөгереп керде. Аның артыннан – Инсаф. Бераздан чишмә йортының бусагасында Лилия басып тора иде.

Нурбәк белән Лилия озак кына бер-берсенә сүз катарга кыймыйча басып торганнан соң, Нурбәк кыз алдына чүгәләде.

– Чишмә йортына нинди күбәләк очып кергән, дип уйлаган идем, синең күбәләгең икән. Улым, ычкындырма мондый күбәләкне.

– Юк! Булмый! Ычкындыра. Мотавалныкылардан булмый, – диде Лилия, көлеп.

– Шулай дисеңме, Лилия?!

– Шулай дим, Нурбәк.

Бу сүзләрне әйткәндә, аларның йөрәк тибешләре бергә кушылып, сулыш алулары ешаеп, күз кабаклары, керфекләре бер-берсенекенә охшарга тырышып хәрәкәт итә, иреннәрендә генә аерма сизелә: Лилиянең чиядәй кызыл иреннәре беренче мәхәббәтенә – Нурбәккә булган эчкерсез тойгыларын сиздереп, энҗедәй ап-ак тешләре өстендә үзенә урын табалмый тыпырчына, калтырана иде.

– Әллә бу күбәләк тә анасына охшаганмы?

– Уздыра! Анасын да уздыра.

– Улым, алайса чыгарып җибәр! Күңел тәрәзәңә кунып, йөрәк кылларыңа басып сайрар да башкага барып кунар. Безгә баш бирә торганнардан түгел алар, – дип, улына караса, шаккатты, Инсаф белән күбәләктән җилләр искән, алар тау башында сап-сары тузганак – җонлыбаш чәчәкләре җыеп йөриләр иде.

Лилия белән Нурбәк чишмә басмасына чыгып бастылар.

– Матурлагансың син «Мотавал» чишмәсен. Бу тауга менә торган тимер баскычларны да, синең кул, диләр.

Чыннан да, чишмә өстенә күз явын алырлык җыйнак кына йортны, янәшәсендәге утыргычларны, тау битеннән югарыга үрмәләүче бизәкле тимер баскычны ул ясатты.

– Бердән, «Мотавал чишмәсе» түгел, «Хәзрәт чишмәсе», икенчедән, бу тау түгел, «Мотаваллар тавы»на менә торган тимер баскычларны әйтәсеңме? – дип өстәде Нурбәк.

Авыл халкының күпчелеге, хәзрәт белән абыстайны бер-берсеннән аермау, өстәвенә Нуриәхмәтнең дә шушында җирләнүен истә тотып, чишмәгә «Мотавал чишмәсе» дип язып куярга дигән тәкъдим белән чыксалар да, яшь кенә булуына карамастан, тирәннән фикер йөртә торган Нурбәк моңа каршы килде. Ничек итеп авыл халкының борын-борыннан – ата-бабасыннан килгән, мал асраган, җан асраган, яшәешен алып барган тереклек чыганагына – чишмәгә – басма итеп сыңар такта да салмаган Мотавал исемен куштырасың?! Нәселләрен яратмаучылар исән чагында «Мотавал» исеменнән качарга кирәклеген яхшы аңлаган онык чишмәгә «Хәзрәт чишмәсе» дип кушарга дигән тәкъдим белән чыкты.

– Минем кул түгел, бабамның атасы Мотавал куйдырды.

– Шулайдыр. Сине бик тиз баеп китте, диләр, – дип төрттерде Лилия.

– Бабайлар тегеннән – шахтадан – акча җибәреп торалар.

– Алтынны Себердә чыга, диләр. Әллә алтын приискалары да бармы?.. Һич уйламаганда, Казанга укырга барабыз, дип вәгъдәләшкән җирдән җәһәннәмгә – Новосибирскига китеп олактың! Район үзәгендә дә, авылда да кибетләр салдыргансың. Кибетләреңнең берсенә «Төнбоек» дип кушкансың. Берәр мәгънә салып куштыңмы?.. Хәзер мәчет төзергә җыенып ятасың дип ишеттем, аңа нинди исем куярга җыенасың?

– Безнең, Мотавалларның, кешечә түгел. Хыянәтчеләр исемен кушабыз. Мәчеткә дә иленә, туган җиренә, авылдашларына хыянәт итеп, сөргенгә сөрелгән бабам Галиәхмәт исемен кушмакчы булам.

– Хыянәтче, дисең инде... – Бу сүзләрне әйткәндә, аның карашы тау өстендә чәчәк җыеп йөргән кызы белән Инсафта иде. Лилиянең күзенә яшь тыгылды. – Исеме ничек?

Яшьлек хыялларына кереп чумган Нурбәк кинәт айнып китте.

– Нәрсә? Нәрсә дидең? Ишетми калдым.

– Улыңның исеме ничек, дим?

– Инсаф!

– Үзеңә охшаган.

– Ә синең кубәләгеңнең исеме?

– Алия!

– Матур исем. Үзең генә кайттыңмы?

– Ә мин кем белән кайтырга тиеш идем?

– Ирең белән.

– Ирең белән... Бу сүзне әйтү сиңа җиңелме?

– Юк! Юк, җиңел түгел.

Шулвакыт тау битеннән ике йомгак аска – чишмә буена тәгәрәде. Лилия кызының кулындагы сары чәчәкләрне күреп, алдына чүгәләде.

– Кирәкми, кызым! Ташла бу чәчәкләрне. Сагыш чәчкәләре алар. Кайчандыр миңа да шушы тау сыртыннан бу сары чәчәкләрне җыеп бүләк иткәннәр иде. Мин ул чәчәкләрне, шиңмәсеннәр, озын гомерле булсыннар дип, шушы чишмә суына утырттым...

*Беренче китап тәмам.*



Таңчулпан

# ГОМЕР ҮТӘ ШУЛАЙ ТОТАШТАН

## Дусларым

*Йөз сум акчаң булганчы,*
*Йөз дустың булсачы.*
Халык мәкале

Озак очтым, талды канатым,
Тау-ташларга бәреп канаттым.
Дуслар шул чак канат булдылар,
Хыялыма илтеп куйдылар.

Диңгез уртасында ялгызым,
Дулкыннарга елап ялындым.
Килде көймә туган җирләрдән –
Дуслар миңа җилкән җибәргән.

Сахра кебек иде күңелем,
Кайнар комга беттем күмелеп.
Тамды тамчы җанга дым булып –
Атап миңа килде ак болыт.

Көзге җилдә торам күшегеп,
Ямьсез сүздән рухым төшереп.
Дуслар янә терәк булдылар –
Минем җырны җырлап уздылар.

Йөзгә тулмаса да саннары,
Дусларымны тормыш сынады.
Булмасам да үзем әлләкем –
Дусларымны сайлый белгәнмен!

Таңчулпан (Чулпан ӘХМӘТОВА) – *шагыйрә; «Кыргый чәчәк», «Зилә белән Индираның урманга сәяхәте» исемле китаплар авторы. Казанда яши.*

## Чакырма...

– Кайт,  – дисең... –
Кайт, – дисең, – үткәнгә!
Авырдыр кайтуны көткәнгә…
Юк инде, юл инде өзелгән,
Кул изим гомерем көзеннән.
Үткәннәр үткәндә икән шул,
Үткәннәр үткәннәр икән шул!
Язларда ачылган бөреләр
Гөл булып саргаеп кипкәннәр икән шул.
Килми лә
Кайтасым үткәнгә!
Юк рәнҗү, юк нәни үпкәм дә.
Үткәннәр калганнар үткәндә,
Ямансу гомерләр үткәнгә.
Яшәлгән, яшьнәлгән, янылган,
Эзләнгән, нәрсәдер табылган…
Яшәмим үткәннәр белән мин,
Бүгенге көнемә табынам.
Чакырма, кадерлем, үткәнгә,
Сөюләр яңармас күңелдә…
Наз булып, сагышлы яз булып
Яшә син үткәнем түрендә.

## Кызыма

Син – минем илаһи халәтем,
Даным – син, һәм дә ки – шөһрәтем.
Көзгегә багам да –
Бар ямем
Кызыма күчкән, – дим, – шөкрана!
Син минем – нәп-нәни Чулпаным,
Тыюлар белмәгән шук чагым,
Уеннан туймаган курчагым,
Сөюдән кабынган учагым!
Син – минем иртәнге саф чыгым,
Син – минем чыркылдык чыпчыгым,
Акыллым, булганым, зирәгем,
Син – минем баш куяр тирәгем.
Аен – көн, елын ай үсәсең,
Тиземнән бигрәк тиз төшәсең…
Чү, балам, ул кадәр ашыкма,
Болай да  киртә юк вакытка.

## Төш

Шул ук төш –
Мин аның
Төш икәнен беләм:
Үтә газиз ямьле ишегалды,
Яшел бәрхет чирәм.

Көмешсыман тавык үлән чемчи,
Чеп-чеп чебиләре,
Ишетелә әбиемнең шунда
Медер-медер нидер сөйләнгәне.
Җилләр кочып китә, иркәләнәм,
Миңа шундый рәхәт!
Калыр идем бәрхет чирәмнәрдә,
Туялмаган ләззәт.
Әбиемнән шундый тәмле булып
Җиләк исе килә,
Сөялләнгән кулкайлары белән
Йомшак итеп сөя.

Уяндыра...
Уйлар уйландыра.
Гамьсез үткәнемә
Кайта алам икән, мин бәхетле –
Булсын төштә генә!

Төш икәнен беләм,
Шуңа елыйм.
Азга, төштә генә
Вакытларны чигеп кайтам әле,
Кайтам үткәнемә!

***

Күңелемдә күптән давыл тынган,
Ярларына кайткан ярсуым.
Тыныч кына гомер иткән мәлем,
Бер могҗиза итми кар суын...
Яшим дә күк, яшәмим дә сыман,
Язлар җәйгә, көзгә тоташа,
Елларның да иске-яңасы юк,
Гомер үтә шулай тоташтан.
Әмма бүген әллә нишләп киттем:
Бәгыремне өтеп өн килде:
Язда ярсып, җәйләрендә җилсеп
Яшәмәгәч гомер ник кирәк?!
Сискәндерде җанны.
Тамырларда
Кан агышын тойдым.
Мин исән!
«Яшьлек әле үтеп бетмәгән ич,
Канат итеп җилне кил!» – дисәм...
Ишетерме берәү?
Давыл тынган,
Ярларына кайткан ярсуы,
Әллә нигә иләс-миләс итә
Бу язларда көмеш кар суы...

## ЯВЫЗЛЫККА ҺӘЙКӘЛ КИРӘКМЕ?

**Рәсәй халкы аңында иң асыл патшалар булып аларның икесе саклана: Дүртенче Иван белән Беренче Пётр. Ягъни иң мәрхәмәтсез, иң явыз патшалар. Шуларның берсенә Орёл шәһәрендә һәйкәл дә куелды менә!**

**Аңарга, ягъни Иван атлысына, татар халкының рәнҗешләре күптин-күп. Ләкин, әйдәгез, рус тарихчылары язганга күз салыйк. Менә бу фикерләр Н.Костомаров (1817-1885) китабыннан[1] алынды: «Он до крайности труслив в то время, когда ему представлялась опасность, и без удержу смел и нагл, когда был уверен в своей безопасности». «Мучительные казни доставляли ему удовольствие». «Иван был человек в высшей степени бессердечный...» Хәтта малаен да тимер таягы белән бәреп үтерә бит әле!**

**Менә монысы Л.Гумилёв (1912-1992) китабыннан[2] алынды: «Опричнина была создана Иваном Грозным в припадке сумасшествия в 1595 г. И официально просуществовала 7 лет. Задачей опричников было «изводить государеву измену», причём определять «измену» должны были те же самые опричники. Таким образом, они могли убить любого человека, объявив его изменником... Особенно страшной расправе был подвергнут в 1570 г. Новгород, где было истреблено почти всё население. Даже младенцев опричники бросали в ледяную воду Волхова».**

**Пётр патша явызлык мәсьәләсендә Иван Грозныйдан калышмаган кебек. Янә Костомаров китабына күз салыйк. «До какой степени он был свиреп и кровожаден, показывает то, что он не побоялся унизить своё царское достоинство, взявший на себя обязанность палача во время дикой казни стрельцов...» «Казан утлары»ның 1992 елгы 1 нче санында Пётр патшаның «Яшерен васыятьнамә»се (тәрҗемәдә) басылды. Ул менә мондый сүзләр белән тәмамлана: «Җыелгән илләрне талап, кәсеп итеп, сез исә бөтен Европада хакимлек корырсыз. Тора-бара бүтән дәүләтләрнең һәммәсен үз мәмләкәтегезгә кушып, бөтен дөньяга ия булырсыз». «Сайланма әсәрләр»енең[3] IV томының төп өлешен шушы патшага багышлаган академик В.Ключевский (1841-1911) болай дигән: «Чтобы защитить отечество от врагов, Пётр опустил его больше всякого врага».**

**Халык асыл патша санаган тагын бер зат бар бит әле: Сталин. Үз «опричнинасы» аша тегеләрнекеннән бәлкем йөзләрчә кат көчлерәк репрессия дулкыны җибәреп СССРны имгәткән бу «гаделдән гадел даһи юлбашчы» 1939 елның 23 августында фашистлар Германиясе белән дуслык-хезмәттәшлек пакты төзи һәм шуның белән Беренче Бөтендөнья сугышындагы капитуляциясеннән соң нык көчсезләндерелгән Германиягә җан иңдерешә. Һәм тегесе, нык кына коралланып-көчәеп, ил арты ил яулый башлый. Сталин исә Кызыл Армиягә бик көчле удар да ясый әле. Хрущёв үзенең китабында[4] язуынча, хәрби округ командующийлары һәм дивизия командирлары тулысынча диярлек юк ителә. Болай ук түгел, моның әле яртысы гына булса да, йөзләп генерал лабаса бу!**

**Фән һәм мәгариф буенча президент советының 21 гыйнвардагы утырышында В.Путин Ленинны СССРны шартлатучы дип бәяләгән. Сталин турында исә Рәсәй җитәкчеләренең бер генә кырын сүз әйткәннәре дә юк әле...**

**Рәфикъ ЮНЫС**

---

1 Русская история в жизнеописаниях её главнейших деятелей. — Москва: ЭКСМО, 2004.

2 От Руси до России. — Москва: Хранитель, 2007.

3 Москва: Мысль, 1989.

4 Воспоминания. — Москва: Инф.изд.компания «Московские новости», 1999.

## Сурәт

Тәрәз читеннән үрелеп
Бер йолдыз карый –
Яшь сылу кыз ай нурында
Чәчләрен тарый.
Ефәктәй чәчләр үбәләр
Нәфис иңнәрен,
Чит күзләрдән каплый тәннең
«Яшерен җирләрен».
Ай нурында коена кыз,
Алтын тарагы,
Төн-пәрдә дә яшерәлми
Татлы газабын.
Мөлдерәмә хисләренең
Тулышкан мәле,
Уйларының гөнаһланган,
Сугышкан мәле.
Чәч тарый кыз, очкынлана
Толым очлары,
Таш йөрәкне эретерлек
Кайнар кочагы.
Күз тимәсен чәчләреңә,
Пәрдәләрне яп,
Таң ата бит озакламый,
Йокла, кызый, ят.
Төшләреңдә килер ярың,
Ап-ак ат менеп,
Бик татлы да, газаплы да
Яшәве сөеп.

## Ямь

Таң әтәче тавышымы,
Йолдызлар карашымы
Уятты да, озак кына
Эңгерне тыңлап яттым.
Кышкы иртә. Берән-сәрән
Йолдызлар сүнә бара,
Өйләрдә утлар кабына –
Йокыдан тора сала.
Иренеп өрә эте дә,
Ник өрсен – барсы таныш:
Хуҗасының атын җигеп
Эшкә китеп барышы.
Мөгрәп аваз салды сыер:
– Җитез бул, җиңги, тулдым...
Салкын һава баш әйләнгеч
Сөт исе белән тулды.
Күршедәге ак әбинең
Намазга оеган чагы,
Бу мизгелдә әтәчләр дә
Кычкырмый, туктап калды.
Бәс сарган агачлары да
Әйтәләр сыман зекер:
«Тыныч иртәләрең өчен,
Илаһым, мең-мең шөкер!»
Уянганымны сиздерми
Эңгерне тыңлап яттым.
Авылымның бу халәте
Җаныма шундый якын.
Ни ямь таба, беркайчан да
Авылы булмаганнар!
Кая барып сихәт ала
Авылда тумаганнар?
Әтәчләр таңны чакыра –
Дәртле соң тавышлары!
Ун тавыкка – бер әтәч бит,
Ходайның табышмагы...

***Редакциядән:***

*Каләмдәшебез бу айда үзенең юбилеен билгеләп үтә. Аңа исәнлек-саулык, иҗат уңышлары телибез.*



Гәүһәр
Хәсәнова

# ХИКӘЯЛӘР

### Ул

Ул биредә шактый озак басып тора иде инде. Вак кына яңгыр сибәли, һава да салкынча. Ләкин аның моңа исе китми. Тау битендәге өрәңге янында шулай басып торырга ярата ул. Өрәңге инде карт, яфраклары да коелып беткән, шуңа да ябалдашы аны яңгырдан ышыклый алмый. Әмма урыны әйбәт. Моннан тау астында агып ятучы елга, аръяктагы үзәнлекләр яхшы күренә. Кояшлы җәй көннәрендә җиләс җил бирегә ерактагы болыннардан төрле үлән һәм чәчәкләрнең исен алып килә иде. Тик хәзер ямансу көз, пыскак яңгыр, шыксыз кырлар өстен соры пәрәвез урап алган сыман. Кисәк-кисәк кенә әшәке җил исеп куя.

Ләкин ул күптән инде мондый вак-төяккә игътибар итми иде. Тормыш зилзиләләре каккан кешене мондый җил генә куркыта аламыни... Тәкъдир аны гомере буена сынады. Туганнан бирле.

Ул үзе дә көз ахырында туган кеше. Әнисе шулай дигән иде. Туган көнен төгәл белүче юк, туу турында таныклыгын соңрак, гаиләгә килгән бәла-казалар басылгач кына алганнар.

Аның әтисе тирә-юньдә могтәбәр хәлфә иде. Яшьлегендә патша армиясендә хезмәт иткән, атаклы мәдрәсәдә белем алганнан соң, күпмедер вакыт авылда муллалык вазифасын башкарган. Хуҗалык эшенә дә бик оста булган ул, шуңа да гаиләсе мохтаҗлык күрмәгән. Андыйларны элек атлы-тунлы дияләр иде. Үз хезмәте белән казганып яшәргә килгән сала кешесендә ни булырга тиеш, ул да шуларга ия иде. Абзарда сыерлар мөгри, ат кешни, алма бакчасындагы оялары тирәсендә умарта кортлары гөжли.

Гаиләләре зур иде – ул заманнарда гадәтләнгәнчә, балалар бер-бер артлы туа торды. Әниләре мулла кызы, шәригать кануннары нигезендә тәрбияләнгән,

---

Гәүһәр ХӘСӘНОВА – *тәрҗемәче, галимә; дистәдән артык китап тәрҗемә иткән каләм иясе. Г.Державин исемендәге Бөтенроссия, С.Сөләйманова исемендәге әдәби премияләр лауреаты, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. Казанда яши.*

белем алган. Аз сүзле, көчле холыклы: ул гүя туры сүзле, самими, кешегә ышанучан хәләлен тәгаен кысада тотар өчен яралган... Әйе, этиләрендә хәйлә дигән нәрсәнең эзе дә юк иде шул.

Алар икесе дә балаларында Китапка хөрмәт тәрбияләделәр. Кече яшьтән үк һәрберсенең кулында китап булыр иде.

Егерменче еллар ахырында авыл танып булмаслык үзгәрде. Дөрес, үзгәреш инде ун еллар элек башланган иде. Ә хәзер авылга күмәкләштерү дигән афәт килеп керде.

Ул менә шул вакытта – егерме тугызынчы елның көзендә дөньяда пәйда булды. Шатлыктан күңеле ташкан этисе аңа пәйгамбәребезнең исемен кушты. Тик туу турында таныклык алырга гына өлгермәде – малай туганның икенче көнендә үк авылның ярым исерек активистлары – гидайлар бәреп керде һәм аларның өен, ихатасын авыл ярлылары файдасына тартып алынуын белдерде. Болар аның мәдрәсәсендә әлифне таяк дип танырга өйрәнүчеләр иде. Көйләнгән хуҗалыкка гаиләсе ачтан үләргә җитешкән бер булдыксыз зимагур ия булды.

Мулланың гаиләсен, яңа туган улы белән бергә, өйләреннән куып чыгардылар һәм теге зимагурның кетәклек кадәр генә алачыгында яшәргә куштылар. Ләкин бер атнадан соң авылның рәтле кешеләре күтәрелеп чыкты, мулланы гаиләсе белән бергә кире үз өенә кайтарып куйдылар. Таланган малын да җыйнаштырып кайтардылар. Арбада төрле йорт кирәк-ярагы арасында биләүгә бәйләнгән төпчек тә бар иде.

Тик бу хәлләр алар күрәсе бәлаләрнең башы гына булган икән. Утызынчы еллар килде. Ул инде нәни чактан ук гаиләләре өстендә куерган кара болытларны шәйли башлаган иде. Әтисенең дус-ишләрен, фикердәшләрен алып китүләре турында хәбәрләр отыры ешайды, өйдә самими мөсәхәбәләр торган саен сирәгәя барды, һәм менә 1936 елның декабрь төнендә аның да әтисен алып киттеләр. Аңа – әтисенең төпчек улына – ул чакта җиде яшь иде, һәм ул әтисен бүтән беркайчан да күрмәде.

Баштарак ул аны көтте әле, авылга керәсе юлга күзен алмый еш карап тора иде. Еллар үткәч, язмышына күнекте, әтисенең беркайчан да кайтмасына ул инде эчтән ышанды. Ә Ил көнен дә, төнен дә бер кешенең исемен туглады, мәдхияләр укыды. Малай әтисенең фаҗигасен дә, үзенең аянычлы язмышын да шул кешенең исеме белән бәйли белде һәм аңа булган нәфрәтен тагын да эчкәрәк яшерде. Иң төп дошманга уянган шул ачы да, чарасыз да нәфрәт башта аның тынын кыса, суларга мөмкинлек бирми иде, әмма бераздан ул аның белән яшәргә өйрәнде. Яшәргә кирәк иде.

Ятимлек – бик авыр бәхетсезлек, ләкин «халык дошманының улы» дигән тамганы йөртү шул бәхетсезлектән дә аянычлырак. Әлеге кара мөһер аны гомере буена эзәрлекләде. Шәхес культын гаепләделәр, янәсе «җепшекләнде», аннары «торгынлык» дип аталган еллар килде, ләкин ул һаман үзенә ышанып бетмәүләрен сизде, үзенең аерым, үзгә булуын аңлап газапланды. Ә яшәргә кирәк иде – ул институт тәмамлады, диссертация яклады. Озак вакытлар архивларда, китапханәләрдә утырып, темасының төбенә төшеп, зур хезмәт бәрабәренә яклады. Тик гаҗәп хәл – аның уңышына көнләшкән, шөһрәтенә эче пошкан берәр кем даими рәвештә тормышында пәйда була иде. Төп дошманының шәүләсеннән ул гүяки арына алмый: әләк һәм яла, хыянәт,

битарафлык аның һәрвакыттагы юлдашлары, алар элеккечә... Бер генә аерма бар – хәзер алып китеп атып үтермиләр, тик киң сулыш белән яшәргә дә ирек бирмиләр.

Әмма ничек булса да яшәргә кирәк иде...

Озак еллар үткәч, «үзгәртеп кору» дигән нәрсә башлангач, ул әтисенең 1937 елның февраль башында атып үтерелгәнен белде. Шул турыда рәсми кәгазьне кулга алгач, ул сулкылдап елап җибәрде. Күз яше белән бергә күңелгә гомер дәвамында җыелган өмет, әрнү, кызгану хисләре дә сулкылдап-сулкылдап дөньяга чыкты, һәм гаҗәпләнүенә күрә ул күңелендә җиңеллек тойды. Аллага шөкер, әтисен озак җәзаламаганнар, җәлладлар аяк астында ул бер генә ай интеккән. Бу да бер юану. Аннары тагын бер нәрсә күңеленә тынычлык өстәде – әтисе үз гаебен дә танымаган, бүтәннәргә дә яла якмаган. Әтисе соңгы мизгеленә кадәр кеше булып калган икән!

Күңелендә зур фаҗига йөртсә дә, ул тормышта үз урынын таба алды. Матур гаилә корды, акыллы һәм чибәр хатыны белән ике бала үстерделәр.

Алар да инде тормышта үз урыннарын тапты. Әйе, шөкерана кыласы гына... Шулай да бер уй аңа беркайчан да тынгы бирмәде – утыз җиденче ел булмаса, аның язмышы нинди юлдан китәр иде икән?

Әтисе төшкә еш керә иде. Нәкъ шул килеш – җиде яшьтә истә калганча... Кайчакта ак чәчәккә күмелгән алмагач төбендә утыра ул, кайчакта аны да итәгенә ала, мыегы белән аның яңагын кытыклап сабагын сораша. Ә бер тапкыр, төшендә, әтисе борынгы бер җыр җырлады... аннары йөзен сөлге белән каплап елап җибәрде. Бакый дөньяда да нинди сагыш җанын борчыды икән? Әллә хушлаштымы ул кем беләндер...

Соңгы елларда әтисе төшкә еш керә башлады шул. Йөзе һәрвакыт якты, күзләре якын итеп карый. Ул үзе берни дә әйтми, ләкин аңардан бөркелгән ниндидер сәмави нур улына да көчә – ул күчкән бакый дөнья инде алай ук куркытмый, һәм бу дөньяның гаделсезлекләренә каршы көрәшәсе килү теләге дә кими бара...

Ул карт өрәңге янында шактый озак басып торды. Шул вакыт ул моннан ерак түгел шәһәр мәйданында кемнәрнеңдер әвеш-тәвеш килүен күреп алды. Ак япма капланган бер нәрсә янында кайнашалар. Кайсыларының кулында чәчәкләр. Әнә нәни оркестр да килде. Бөек көрәшләргә өндәгән музыка яңгырады. Кешеләрнең күбесе өлкән яшьтәгеләр иде. Әмма әле бик нык күренәләр. Нидер сөйлиләр, кулларын селкиләр. Менә, ниһаять, кайсыдыр ак тукыманы тартып төшерде.

Бу – ул иде. Гафу ителмәслек гамәлләр кылган Ерткыч, әлмисакка тикле каргалган Бәндә – аның төп дошманы. Шул ук әз генә кысылган күзләр, шадра йөз, дәү борын астында кабарып торган мыек...

Төп дошманын кул сузымында гына күреп, ул бөтен гәүдәсе белән тетрәнеп куйды. Бөтен асылын биләгән нәфрәткә лаек әлеге сурәт белән күзгә-күз калыр өченме күпме гомер сөрелгән, күпме вакыйгалар кичерелгән?.. Вакыт аерым кешеләрнең аһ-зарына да, фаҗигасенә дә искиткеч битараф. Яраларны вакыт төзәтә, диләр. Төзәтә. Тик ул яра эзләре әрнүдән дә, сызлаудан да туктамый.

Шәһәргә акрын гына эңгер төште. Тагын да салкынайтты. Кара-соры болытлар куерып күк гөмбәзенә тупланды, буазланып кабарды, һәм бераздан һавада эре кар бөртекләре бөтерелә башлады.

Мәйдан тиз арада бушап калды. Анда кайнашкан кешеләр шималь җиленнән качып өйләренә таралды.

Алар гына икәү урыннарыннан кузгалмады. Кар бөртекләре аларның бронза йөзләренә битараф кына төшүләрен белде. Аларның кеше хисләрендә, кичерешләрендә эшләре юк – җиргә төшәр вакытлары җиткән, бары шул гына. Иртәнгә инде кечкенә шәһәр кар көртләре астында калыр, ике бронза һәйкәл генә кар өстендә калкып торыр...

**Ркаил ЗӘЙДУЛЛА** *тәрҗемәсе*

## Кайту

– Килгәнеңә үкенмисеңме? – Ул игътибар белән күзләремә карады, мин дәшмәгәч, кабат сорады: – Син канәгатьме?..

Ләкин башымда, күңелемдә соңгы көннәрдә купкан өермәне мин берничек тә «канәгать» яки башка бер сүз эченә сыйдыра алмас идем.

– Миңа рәхәт. Мине монда язмыш үзе алып килде. Бу миңа күптән кирәк булган. Ләкин моны аңламыйча яшәгәнмен...

Ул талпынып алды, күрәсең, кулымнан тотмакчы булды, ләкин үзен тыйды. Яшел күзләре белән генә гүя сыйпап алды...

Алда, офыкны каплап, таулар өелеп тора. Иң артта – күз ышанмаслык биеклектә ап-ак кар каплаган, мәңге кеше аягы басмаган иң биек тау башлары күренә. Миңа – татар табигате кочагында үскән, урман-басуларга иярләнгән кешегә – бу манзара чынбарлык түгел, ә ниндидер реаль булмаган әкияти, параллель дөнья булып күренә.

Монда инде өченче көнемне яшим. Бу өч көндә кичергән хисләрем, күргән-аңлаганнарым берничә елга җитәрлек. Бирегә килүем язмыш тарафыннан хәл ителгән булган, ләкин өйдән шушы ерак сәер сәфәргә чыгып китүем, миңа калса, очраклы хәл.

Ничәмә-ничә еллар ял иткәнем булмады. Эштән җәй саен ял алып та шул санаулы көннәрне гел өйдә уздыргач, нинди ял инде ул?.. Акчасы да җитмәде, өй мәшәкатьләреннән дә арынып булмады, бүтән төрле сәбәпләр дә булды – шулай гомер уза торды.

Ләкин вакыты җиткән, күрәсең, – беркөн минем күңелемдә күптән яшәгән бер уй, дөресрәге – теләк калкып чыкты да бөтен хәятемне биләп алды. Шул теләгемнең ихтыярына буйсынып яши башлаган көннән тирә-юнемдәге кешеләр, дусларым миңа сәерсенеп карый башладылар, хәтта турыдан-туры «акылыңны җуйдыңмы әллә?» дип сораучылар да булды.

Ләкин йөрәгемдәге яра сызлый иде, нидер эшләргә кирәк иде, иң мөһиме – аңларга: теге фаҗига нидән килеп чыкты соң безнең тормышыбызда?.. Язмышның әшәкелегеме бу? Минем мәгънәсезлекме? Үземне гафу итәрлек сәбәп табып булырмы? Табасым киләме?..

...Кичерәк кенә аэропорт бинасыннан тышка чыктым. Еракта таулар сузылып ята, җиңел генә яңгыр сибәли. Җылы, якты көн. Каршымда тезелешеп таксилар тора, хуҗалары кызыксыну вә өмет белән миңа карый. Җирле халык инде күптән багажларын алып өйләренә кайтып киткән. Мин исә, тирә-якка

каранып, бар нәрсәгә исем китеп, авызымны ачып торам. Төс-кыяфәтемнән дә күренә ки, мин монда чит кеше, үзебезнең гадәт буенча юлга чалбар кигән идем, башым да яулык белән капланмаган...

Таксистларның акчаны күбрәк каерганын белсәм дә, сатулашып тормадым, чөнки монда да эшсезлек. Әйдә ярар, шундый горур халыкның ирләрен йөз сум акча өчен бөгәргә кирәкмәс.

Тору урынымны интернет аша алдан ук сайлап, хуҗасы белән телефоннан сөйләшеп куйган идем. Подъезд төбендә фатир хуҗасы көтеп тора иде инде. Буйга минем белән бер чамадарак бераз томса чырайлы урта яшьләрдәге ир.

...Уникенче каттан бөтен җиһан ачылып ята... дисәм, ялгыш булыр, – дөньяны чикләп, ерakта таулар тезелешеп тора. Йа Раббым, шушы гүзәллекне, бөеклекне күрмичә, моңарчы ничек яшәгәнмен?! Күздән яшьләр акты, мин рәхәтләнеп еладым. Юк, бу бушану түгел иде, шундый матур манзараны күрү бәхетеннән еладым.

...Ул кыш ахырында, һич көтмәгәндә кайтып керде. Өй ачкычын алып китмәгәнгә күрә, урамнан ук кычкырды. Беравык аңышмыйча тордым, аннан балконга атылып чыктым да аска карадым. Анда... Ул – битен сакал-мыек баскан, ябыккан, ләкин елмаеп басып тора. Исән-сау, куллары-аяклары урынында. Йа Хода, Синең рәхмәтең белән яшибез, ташлый күрмә, берүк!..

Аннан башка мин бөтенләй башка дөньяда яшәдем. Элеккеге тормыш ваклыклары: кирәкмәгән ыгы-зыгы, акча мәсьәләсе, кем кемгә нинди нахак сүз әйткән – болар барысы да коелып калды. Минем бөтен белгәнем – хәбәр каналлары, сәяси прогнозлар, сугыш кыры яңалыклары, махсус операцияләр, үтерелгәннәрнең саны...

Ә хәзер бетте, болар барысы да минем өчен бетте. Чөнки кайтты бит, исән бит!..

Беренче көн, беренче атна шатлыклары узды, гадәти тормыш янә бугаздан тотты. Элеккеге хәл ителмәс булып күренгән мәсьәләләр инде юк иде, ләкин... Нидер булды, нидер булган... Күзләре моңсу, кәефе төшенке, кулына бер эш ябышмый. Бирелгән ялын өйдән чыкмыйча, телевизор каршында футбол, хоккей карап уздыра. Элек тә әллә ни ачылып сөйләшмәгән кеше хәзер бөтенләй йомылды. Кайчан карама, авызында – тәмәке, йөзендә – хәсрәт... Ни булды соң анда, бәлки, сөйләрсең, дип, бер әйтеп тә карадым. Ул: белмәвең хәерлерәк, дип кырт кисте, мин бүтән сорамадым. Ах, ялгышканмын шул, сорыйсы, ялварып булса да, эчендә ни барын, йөрәген ни телгәләгәнен беләсе булган... Ах, җитмәде акыл, җитмәде күңел көче. Ярар, дидем эчемнән генә, шулай булсын, тормыш болай да җиңел түгел, монысын да күтәрә алмам, дидем...

Соңыннан, еллар узгач, инде эш беткәч, гел уйладым: бу хисчән, нечкә күңелле авыл баласы ниләр күргән дә ниләр кичергәндер?.. Кайчак ир кеше дә күргәннәрен күтәрә алмаслык була бит...

Үзе гел «таулар», диде, ялга да барып кайтты ак башлы таулар арасына. Шунда төшкән рәсемнәрен вакыт узгач та тыныч күңел белән карый алмадым – ул елмая, артында мәгъруур кыялар. Ләкин шул таулар безнең болай да җиңел булмаган тормышыбызны ябып, каплап куйдылар. Мин тауларны яратмый идем, миңа бир син җылы диңгезне! Ул «тау» дигән саен, сискәнеп китә идем. Шул салкын-шыксыз тауларның ни кызыгы бар инде?..

Көчле йөрәк тә көннәрдән бер көнне бирешә икән. Эчендәге хәсрәтләр, уйлар, ашкынып та тормышка ашыра алмаган хыяллар, вак-төяк күңелсезлекләр – барысы да аны эчтән кимерделәр һәм бу дөньядан алып киттеләр...

Син юк инде. Үзеңне тауларсыз, ләкин гомерең буена син яраткан инеше, су буйлары, урманы булган авылыңа кайтардык. Авылыңның иң биек җире – инешнең теге ягындагы тау бите. Без анда кайткан саен менә идек, балаларны да гел шунда өстерәдек. Өстән авыл шундый матур күренә, тирә-яклар да искиткеч гүзәл манзара булып ачылып ята...

Син юк инде, ә синең тауларга булган мәхәббәтең миңа күчкән булып чыкты. Шашу дәрәҗәсендә яратуга әйләнде. Ләкин бу тартылу – тауларның матурлыгы аркасында гына түгел. Вакыт узган саен, күбрәк төшенә бардым – ул таулар сине миннән тартып алганнар. Син минем яныма ярты күңелең белән кайткансың. Икенче яртысын тауларда калдыргансың. Хәер, аны син, бәлки, үзең дә тоймагансыңдыр. Миңа аңарчы да күңелеңне тулысынча ачмадың, мине анда кертмәдең... Моны аңладым, кабул иттем – ир кеше хатын-кызны күңел түренә кертмәскә тиеш, ул аны көчсез итә, киләчәктә башына җитәрлек бәла чыгарырга мөмкин...

Ләкин таулар мине үзенә тартты, саташтырды. Барасым килде, үз күзем белән күрәсем, аңлыйсым килде: ни булды соң безгә? Гаебем булдымы минем? Әллә күңел көчем җитмәдеме сине үземә кире кайтарырга?..

...Мине монда китергән максатларымны беркемгә дә әйтмәдем. Кирәк түгел иде. Монда да – һәркемнең үз фаҗигасе, үз тарихы. Танышкан, сөйләшкән кешеләрем барысы да – чын кешеләр: горур, матур, тормыш ваклыкларына бирешми торганнар. Узган тарихның аларга карата булган вәхшилекләре хакында бик ачылып сөйләмиләр. Бәлки, мин чит милләт кешесе булгангадыр, бәлки, артык сүз сөйләргә яратмаганнандыр. Фатир хуҗасы беренче көнне үк, минем таулар күрәсе килгәнемне белгәч, анда алып барырга сүз бирде. Әйберләремне урнаштырып, чәйләр куйгач, бүлмәдәге зур шкафны ачып карадым – хатын-кыз бит, беләсе килә – кемнәр яшәде икән бу матур өйдә? Хатын-кыз эзе бар микән? Шкаф эчендә ирләр киеме генә эленеп тора иде. Арасында хәрби кием дә бар. Күзгә тагын яшь килде – безнең өйдә дә андый киемнәр күп калды...

Кичкырын хуҗа кеше шалтыратып, берәр нәрсә кирәк түгелме, дип сорады. Мин, татарларга хас гадәт буенча, юк, борчылмагыз, дидем дә Казан күчтәнәчләре белән чәй эчәргә чакырдым.

Шәһәрдә инде бераз йөреп кайткан идем, исем китеп шуны мактадым, күргәннәремне сөйләдем, кешеләрнең матурлыгына сокландым: горур ирләр, чибәр хатыннар. Күзләрендә – тормыш дәрте чагылып тора, безнең кебек тонык, басынкы түгел. Узганнарыгыз – коточкыч, ләкин киләчәгегез өметле, дип сөйләндем...

Хуҗа күпсүзле түгел иде. Моңсу яшел күзләр, салмак хәрәкәтләр артында нindидер тышауланган көч... Нинди тарих бар артыңда? Нинди югалтулар?.. Узган сугышлар турында сорамадым – курыктым... Ярасына кагыласым килмәде. Шулай да сүз иярә сүз шуңа килеп чыкты. «Сугыш тагын булыр, ахры, – диде. – Булса, катнашмыйча булмас... Үтерерләр инде бу юлы...»

Бу хәсрәт катнаш елмаю, бу сагыш миңа таныш бит!.. Аңлыйм бит мин сине, бүтәннәргә караганда күбрәк аңлыйм...

Шәһәр артта калды, басулар башланды. Ноябрь ае булганлыктан, машина тәрәзәсеннән генә аңлашылып та бетми – бу басулар чәчелгәнме йә булмаса ташландыкмы? Көтү генә йөри торган җирләрме?.. Алда, еракта, таулар дәшеп тора, чакыра. Без шуларга таба җилдерәбез. Юл кырыенда ике-өч зират калды. Туктамадык, максатыбыз – караңгы төшкәнче тауларга барып җитү иде. Зиратлары бөтенләй икенче төрле – агач та юк, чардуганнары да күренми. Кайбер кабер өстендә – озын колга. Мәгънәсен сорадым – шәһит киткән кешеләргә куела икән. Йа Алла, шәһитләр бик күп булган...

Ноябрь көне кыска, таулар итәгенә килеп җиткәндә, кояш байый иде инде. Таулар караңгы урман белән капланган, түбәләрендә болытмы, томанмы чолганып эленеп калган. Бормалы юл буйлап эчкә кереп киттек. Вак яңгыр сибәли башлады, ераккарак киткән саен, тирә-юнь дәһшәтлерәк күренә. Ләкин бу минем күп еллар дәвамында күрәсем килгән чын таулар иде. Чит кеше өчен караңгы, куркыныч, ләкин шунда яшәгән халкы өчен – яраткан, матур, җылы туган Җир. Монда белмичә кереп исән калган кешеләр күп булмагандыр. Исән калганы йөрәгендә ниләр алып чыккандыр... Күк елады, мин дә еладым. Кайтарып булмаслык көннәр, хисләр, хыяллар күз яше булып акты. Янымда утырган ир миңа сәерсенеп карады, ләкин дәшмәде. Мин барыбер аңлата алмас идем. Үзем дә мәңге аңламам: бер бәхетсезне җиргә бирдем, икенче шундый ук бәхетсез янымда утыра... Безнең кылган гамәлләребезнең мәгънәсе нидә соң?..

...«Яратам» сүзен миңа әйтмәде. Аның телендә андый сүз юк икән. Хәер, мин ул сүзне үз телемдә дә еш ишетмәдем. Татарда матур сүзләр күп, ләкин сиңа барысы да язмаган икән... Миңа сүз кирәк тә түгел иде. Туң йөрәгем кузгалды, тибә башлады... Күптән көтеп алган назда коендым, һәрбер күзәнәгем гүя елмая иде: яшисе килә, яшисе килә!..

Мин тауларга сине эзләп килдем, бәгърем. Мин сине югалткан идем. Синең җаныңның бер өлеше шушында калган шикелле иде. Таптым микән аны? Әллә үземне таптыммы мин? Мине шушындый бožра ясарга язмыш этәрдеме? Яратуны җуйган йөрәккә юл күрсәттеме?.. Әллә мин үзем дә белмәгән әҗәтемне бирдемме бу җиргә?..

– Без тагын күрешербезме? – яшел күзләр миңа текәлеп, таләпчән карый иде.

Ах, мондый караш, мондый тавыш шундый таныш миңа, тансык...

– Күрешербез, җаным... Тауларсыз инде яши алмам... Җанымның бер өлеше монда мәңгегә калды...



*Лилия Рәфхәт кызы Фәттахова 1972 елның 22 октябрендә Яңа Чишмә районы Чаллы Башы авылында туган. Казан дәүләт педагогия институтының тарих-филология факультетын тәмамлаган. Бүгенге көндә Яңа Чишмә урта мәктәбендә тарих һәм җәмгыять белеме укыта. Югары категорияле укытучы.*

*Лилия Фәттахова лириканың күңел, пейзаж, фәлсәфи, иҗтимагый-сәяси төрләрендә иҗат итә, классик шигърият үрнәкләре янәшәсендә irекле, кыска (дүртьюллыклар, бишьюллыклар, алтыюллыклар) шигырь формалары, мәсәл жанры да үз урынында. Әсәрләренең нигезендә милләтебезнең данлы һәм шанлы дәверләренә заманча бәя, безнең чор кешесенең тормыш мәгънәсен эзләве, адәм баласының Табигать-Анадан аерылгысыз булуы кебек темалар ята, мәсәл жанрына хас сатира элементлары да чагылып ала.*

*Зур әдәбият даирәсендә Лилия Фәттаховага уңышлар телибез!*

**Редакция**

Лилия
Фәттахова

# ҖАНЫМДА ИЛАҺИ ТЫЛСЫМ

## Чәчтем – җыям

Чәчтем – җыям уйларымны,
Сүттем – җыям.
Көйсезен дә, көйлесен дә
Бергә куям.

Минем уйлар – минем язмыш –
Үрелеп бара.
Асыллары тыйнаграк,
Чүбе сара...

Башсыз җайдак чагым була –
Көчсез чагым.
Йомычкадай алып китә
Көчле агым.

Ишкәкләрне – уйларымны
Кулга алсам,
Офыкларны күреп алып
Ишәм тагын.

Мин – иясе уйларымның,
Мин – хуҗасы.
Ничек сызсам сызымымны –
Шул буласы.

## Болай гына уфтану

Бездә тукталмый икән лә –
Уза икән ул гомер.
Уза икән... Туза икән
Тән генә түгел – күңел...

Көмешләнгән чәчләр ни лә,
Маңгайдагы сырлар ни –
Күңел көзгесе тоныграк
Күрсәтәме әллә дим?..

Юл буенда өзелеп яткан
Чәчәкләрне сизми ул,
Яралы кошчыкны күрми,
Хыял иңләп йөзми ул...

Тупаслана, тутык баса,
Бурсый башлый ич күңел.
Без бит андый түгел идек,
Без һич тә андый түгел!

Бала чакның ал күзлеге
Кайчан салынды икән?
Күңел бакчасына кайчан
Кырау кагылды икән?..

## Томан аша ни күренә?

Томан аша ни күренә?
Кемгәдер
Якты көнне томалаган
Төн күренә.
Кемнеңдер
Йөрәгенә кармаланып
Шом үрелә.

Томан аша ни күренә?
Кемгәдер
Табигатьнең зәңгәр күзләрендә
Элпә белән яшеренгән
Моң күренә.
Кемнеңдер
Хыял аланында
Иртәнге чык тамчысына
Сер төренә.

Томан аша ни күренә?
Кемгә дә
Киләчәккә-күрәчәккә
Юл күренә.
Кемнәрнеңдер
Язмышының арбасына
Чор эленә.
Шул арбаның
Тәгәрмәче асларында
Кемнәрнеңдер
Уй-хыялы – чәлпәрәмә...

Томан аша ни күренә? –
Кемгә – ни...

***

Җаным – Җәннәт бакчасы ул,
Тәмуг та.
Илаһи тынычлык анда
...һәм ут та.

Уем белән уям өлге,
Калыплар.
Тын алырга авыр кайчак –
Калып тар.

Уем белән Күк капусын
Ачкан бар:
Сөю канаты иңнәрдә,
Тиңем – яр.

Җанымда  илаһи тылсым,
Моң барда,
Галәм кендегеннән кучәр
Сер анда.

## Уйлар күңелең төрлесен...

Кылдан нечкә күңел кылың
Бер тартыла, бер тына:
Кемдер тән ярасы сала,
Кемдер сүз йөге сона.

Илаһи көйне табалсаң,
Тартылган чакта кылың,
Сабыр канатлары сузган
Җандашка илтер юлың.

Кылдан нечкә күңел кылың
Уйнар көйнең төрлесен.
Тик озакка тынмасын ул
Отып көйнең керлесен...
Терелсен!

## Нигә сүзләр?!

Каләмемне алдым, куйдым бүген…
Куйдым… алдым…
Телем – ярлы.
Вакламасмы хисләрем, дип,
Уйга калдым.
Үҗәт акыл дилбегәне йомшартты да –
Сулу алдым –
Дөнья шулкадәрле гүзәл икән!
Хәйран калдым!
Сөю көен көйли җаным –
Нигә сүзләр?!
Күңел багым уртасында –
Синең эзләр.

## Керфегемә инде Төн эленгән

Керфегемә инде Төн эленгән...
Айдан төшкән
Өлгер Зөһрә-кыз
Бер әкият сөйли моңлы көйгә.
Ул әкият –
Сөю турындагы –
Синең турындагы татлы төш.
Бүген Көнем
Синсез төссез иде,
Төнем якты итте тулган Ай:
Йолдызларны
Бераз читкә этеп,
Күктән сукмак салып
Килгән ул
Һәм Төш элгән керфек очына.
...Бер тамчы яшь
тәгәрәде биттән.
Сөенечкәдер ул –
Очынам...




*Язучылар җыелышында.*
*Мәсьәлә җитди: ничек тавыш бирәбез? 1989 ел.*



*Киров өлкәсенең Түбән Шөн авылына якташлары*
*һәм аларның каләмдәш дуслары кайткан. 1998 ел.*



*Габдрахман Әпсәләмов Язучылар берлеге хезмәткәрләре белән. Узган гасырның 70 нче еллары.*



*Татарстанның халык артисты Айдар Хафиз. 2013 ел.*



*Рәсемдәгеләрнең өчесе төрле елларда Балык Бистәсе районы Солтан урта мәктәбен тәмамлаган кешеләр. Уңнан беренче – журналист-язучы Мидхәт Миншин, шагыйрә Фәүзия Солтан, актёр Равил Шәрәфиев. Сулдан беренче – шушы авыл кияве – галим, язучы Тәлгат Галиуллин. 2005 ел.*

# МӘҖНҮНГӘ ДӘ ҮЗ ДӘҮЛӘТЕ КИРӘК

## НУР ӘХМӘДИЕВКӘ 70 ЯШЬ

Күренекле шагыйрь һәм прозаик Нур Әхмәдиевнең татар әдәбиятында үз эзе, лаеклы урыны бар. Аның тәүге әсәрләре матбугатта җитмешенче еллар башында басыла. Шигърияттә дә, хикәя-повесть жанрларында да ул иркен иҗат итә. Нур Әхмәдиев – шигырьләрендә хис һәм фикер калыпларын бердәм камил үрә алган, ил, милләт, туган халкы язмышы өчен борчылучы шагыйрь ул; чәчмә әсәрләрендә исә, булсын балалар өчен язылганнары, булсын өлкәннәргә тәгаенләнгәннәре, яшәү ямен, тормыш мәгънәсен эзләүче гади җир кешесен, аның күңел халәтен ачып биргән прозаик. Бу мәкалә исә әдипнең шигърият гөләндәме булган аерым китабына багышлана.

Нур Әхмәдиевнең «Мәҗнүнлектә миңа тиңнәр юк» исемле китабында аның «Ыру башы – Ак бүре» шигыре иң беренче итеп урнаштырылган. Башында Ак бүре торган ыруы өчен шагыйрьләрчә горурлану да, шуңа тиң булмаган бүгенге яшәешебез өчен борчылу да чагыла анда.

*Никадәрле мактансак та,*
*Чынбарлыкта әле дә*
*Язмышыбыз капкындагы*
*Соры бүре хәлендә, –*

дип яза шагыйрь. Алай ук түгел лә инде, дип бәхәсләшәсе килә аның белән. Чөнки беләбез, без аста, кысылуда, ирексезлектә дип уйлаган саен сулышларыбыз иркенәйми, тын алулар җиңеләйми, шуңа күрә кайчак үз хәлебезне таныйсыбыз килми.

Шагыйрь ясап биргән сурәтебезне ни белән капларга соң? Мөмкинме бу? Ул да һәммәсен кара күзлек киеп язмый лабаса, димәк, бу очракта да чынбарлыктан ерак тормый. Зәгыйфь кенә бер юанычыбыз бар-барын: Татарстан белән чагыштырганда, бик күпкә зуррак хокуклы Союздаш республика булып яшәгән Үзбәкстаннар, Таҗикстаннар, «бөек Русь иле мәңгегә туплаган» Союздан төшеп калгач, ягъни тулы мөстәкыйльлек алгач, алга бармыйча, кирегә чигенделәр генә түгелме? Никадәр үзбәк һәм таҗик кардәшләр, авыр шартларга һәм иң кара эшләргә дә риза булып, Россиягә килде, килә! Үз илләрендәге рәхәт, иркен, «капкынсыз» тормыштан түгел инде бу. Мөстәкыйльлекнең «капкындагы» кадәреннән файдаланып та, алар үз кирәкләрен эләктерде анысы, инде кайберләренең балалары гына түгел, эш эшләргә өлгермәгән оныклары да Рәсәйнең иң бай кешеләре исемлегендә йөри. Суверенлык өчен көрәш максатлары шул гына булган мәллә? Үзбәк,

таҗик илләрендә дә бардыр «алтын саклап утыручы Кащей патшалар». Тик халык кына, бездәге һәм Россиянең теләсә-кайсы бүтән өлкәсендәге кебек, уртак малны бүлешкәндә, буш ваучер тотып калгандыр. Инде азрак иркенәя башлады дигән тормышыбыз кабат кысылуга юл алды. Үзләштерелгән, читкә ташылган, сабый оныклары исеме астына яшерелгән маллары дәүләт казнасына җитәрлек салым да бирмидер, күрәсең, шунлыктан ил кысык билне тагы да кысыбрак бәйләтү исәбенә җан сакларга азапланадыр.

*Такташ язган коммунизм кыры*
*Күренде дә бик тиз чигенде.*
*Кая коммунизм?!*
*Рухы сынган халык*
*Ачтан үлмәгәнгә сөенде, –*

дип яза Нур Әхмәдиев «Вәгъдә, иман, вөҗдан – бер чылбыр» шигырендә. Такташны вәгъдәсезлектә гаепләве түгел аның, Аллам сакласын, шагыйрьләрнең Такташлар чорында яшәгәне дә, туксанынчы еллар канатландырганы да – түрәләргә ышанып халыкны уятышкан да алданган корбан гына. Шагыйрь җиңел ышана, яхшыга өметләнә, рухи хөрлеккә, матурлыкка, камиллеккә тартыла, мәхәббәттә мәҗнүнләнә, кайвакыт аңа рәшә дә чынбарлык булып күренә. Хисле җаннар өчен гаеп саналмыйдыр болар. Кайберләренең көрәш мәйданнарына чыгып ачлык тотуы да шул ихласлыктан киләдер.

*Шома башлар ниләр уйламас та,*
*Сөяксез тел ниләр сөйләмәс.*
*Вәгъдәләрне күпме бирсәләр дә,*
*Читләр килеп безне көйләмәс, –*

ди Нур шул ук шигырендә.

Читләр килгәч, ни булганын китаплардан укып бераз беләбез инде анысы. Килгәннәр, талаганнар, чапканнар-кисkәннәр, дәүләтен җимергәннәр, кит... Юк, китмәгәннәр, Казанны үзләренеке иткәннәр дә җиңүче хуҗа буларак яшәп калганнар. Исән калган татарларны шәһәрдән читкә сөргәннәр, Казанда таш мәчет салырга да рөхсәт итмәгәннәр. Шагыйрь Нур Әхмәдиев, «Пискарёв зиратында» дигән шигырь язып, милләтнең берничә гасыр сызлаган ярасына тоз сибә. Тапкан янәшә куеп сурәтләрлек ике күренеш!

*Биредә кемнәр юк!*
*Баш ия*
*Бабайлар, аталар, оныклар.*
*Фашистлар үтергән кешегә*
*Немецлар куялар веноклар.*

*«Немецның чәчәкләр куюы – / Бу аның ярлыкау соравы»* – дип шигырен дәвам иттерә шагыйрь. Инде менә бүтән күренеш: «1552. Октябрь. Иделдә су түгел, кан ага». Монысына кем, кайчан, кемнән кичерү сорар? Хәер, җиңүченең җиңелүчедән гафу соравын тарих та белмидер. Шагыйрь дә аңа өметләнми: *«Булмастыр, / Мәскәүдән һаман да / Җилләр гел шом салып исәләр. / Баш кисү җитмәгән, күрәсең, / Татарның телен дә кисәләр».*

Кистергәч, кисәрләр шул, диясе килә аңа. Үзебез дә булышабыз. Ул чор вакыйгаларыннан татар үзе дә гыйбрәт һәм сабак алмады түгелме? Ханнар

белән халыкның мәнфәгатьләре уртак булмау, бердәмлек җитмәү җиңелдергән ләбаса безнең ерак бабайларны. Шушыңа охшаш сәбәпләр менә тагын күп елларга татарны мөстәкыйль дәүләтсез калдырды. Бу җиңелүебездә кемнең гафу соравын көтәсе?

*Хаталардан бәндә хали түгел,*
*Үкенечләр буса – нишләрсең?*
*Башка халыкларның,*
*белмим, ничек,*
*Татар акылы, диләр, төштән соң, –*

дип ачынып әйтә шагыйрь.

Исеменнән аңлашылганча, Нур Әхмәдиевнең бу китабы, нигездә, мәхәббәт шигырьләреннән тупланган. Мәҗнүн шагыйрь өчен мәхәббәт – бар дөнья, бөтен галәм, ай, кояш, йолдызлар, язылган һәм язылачы законнар, яланаяк йөрерлек киң сәхрәләр, йөзеп кичәрлек диңгезләр, ханнар, патшалар. «Син кояш та идең, аем да», – дип яза ул бер шигырендә. Нур Әхмәдиевнең мәхәббәт шигырьләре, «мәҗнүнләнеп» язылсалар да, һәрьяктан камилләр. Аның «Карлы чыршылар»ы көйгә салыну белән, җырчылар галәмендә уннарча тавышка яңгырый башлады. Бу китабына нилектәндер кертелмәгән ул, мөгаен, инде болай да әлеге җырны белмәгән татар юк, дип уйлаганнардыр. Аның каравы, үзеннән-үзе көйгә килеп, җырлап торган шигырьләре ошбу китапта йөзәрләп исәпләнәдер.

*Көзләр узар, кыш та, яз да килер,*
*Таң чыклары үбәр эзеңне.*
*Сагынуларым – сары яфракларда,*
*Йөрәккәем, түз син, түз инде, –*

дип яза ул «Түз инде» шигырендә. Әсәрләрендә еш кына җаннарны әле утка, әле суга салырлык әрнүле гыйшык хәлләрен язса да, мәҗнүнлегенә үкенми дә, аннан зарланмый да ул. Чөнки Мәҗнүн икәнсең, синең Ләйләң дә бар, дигән сүз. Гашыйк җанга шул да бәхет түгелмени? Ләйләсез генә бер Мәҗнүн дә, Галиябанусыз гына бер Хәлил дә, Мәйсәрәсез генә бер Булат та булмаган, була алмаган. Һәм киресенчә: Ләйлә булсын өчен, Мәҗнүннең булуы кирәк.

*Тагын кем бар сөю дөньясында*
*Яшен ташы булып атылган?*
*Син дөньяның соңгы Ләйләседер,*
*Мин соңгысы – Мәҗнүн затыннан, –*

ди шагыйрь. Чын гашыйклар һәммәсе дә үзләрен шулай бердәнберләр дип уйлыйлардыр, кичерик аларның гөнаһсыз алдануын.

Әмма Мәҗнүнлекнең дә, чиге үк дип әйтмим, бер үре, үзгәреш сызыгы, гашыйкларның күктән җиргә төшү, уйлану чоры буладыр. Төшкән җирең үз ата-бабаларыңныкымы, анда бүген кем хуҗа, кешеләр кайсы телдә сөйләшә, көй-моңнары нинди, балаңның беренче сүзе кайсы телдә булыр? Бу сораулар иң элек Мәҗнүн күңелендәме, Ләйләнекендәме туар? Хәтта шулары да мөһим хәзер: ананың балага йогынтысы атаныкыннан, һичшиксез, зуррак лабаса. Чөнки әнисе балага күкрәк сөтен имезә, бишек җырлары көйләп йоклата. Баланың теле әнә шул җырлардагы тел белән ачылачак. Бу чордагы ялгыш бик авыр төзәлә яисә баланың

гомере буена да төзәлмәскә мөмкин. Көенечебезгә, без моны соңлап аңлыйбыз. Әле Мәскәүнең бер телеканалыннан сөйләделәр: рәсми мәгълүматлар буенча гына да, илдә 600 мең (!) бала ялгыз әти тәрбиясендә яши, ди. Әниләре ташлап киткән, ана хокукыннан мәхрүм ителгән, тагын әллә ниләр... Хатын-кызлар, аналар азган җәмгыятьнең киләчәге нинди булыр? Ана назын, тулы гаилә җылысын белми үскән китек күңелле ул балалардан нинди әниләр һәм әтиләр чыгар?

«Баланың теле» дигән төшенчә күңелебезгә килгәч, ул яшәячәк, аның телен, динен, иреген саклаячак, күп хокукларын гарантиялиячәк дәүләт кирәклеге дә исебезгә төшә, әлбәттә. Бармы безнең шундый дәүләтебез? Бу сорауга җавап эзләп, без кабат Нур Әхмәдиевнең күзәтү башында телгә алынган яки шулар рухындагы шигырьләренә кайтырга тиеш булырбыз:

*Татар халкы төшеп калган түгел,*
*Башкалардан кимме сәләте...*
*Газиз телем чәчәк атсын өчен,*
*Әүвәл кирәк аның дәүләте.*

Бүген үз дәүләтебез булса, мәктәпләр, үзебезнең мәгариф кануннарына таянып, балаларга татарча белем бирсә, өметебез дә өзелмәс иде. Өзелеп бетте, дигәндә дә иң азактан шагыйрьләрдә, милләтне әйдәүчеләрдә сау калсын ул. Югалтуларыбыз болай да хәттин ашты: ирегебез, хөр дәүләтебез... Әдәп-әхлагыбыз белән телебез ярты-йортыга калды.

*Ничек тыныч йоклый алсын шагыйрь,*
*Милләтеңә уклар атылгач?*
*Ирек турындагы хыяллары*
*Челпәрәмә килеп ватылгач;*
*Алтыннардан өстен моңлы телем,*
*Бакыр бәясенә сатылгач, –*

ди Нур Әхмәдиев бөек Тукайдан эпиграф куеп язылган «Шомлы җилләр» шигырендә. Әйе, без туксанынчы елларның милли күтәрелешеннән артык күпне, булмастайны өмет иткәнбез, ансат җиңү көткәнбез. Кайбер шигырьләрдә гаҗизлек халәте сизелеп-сизелеп алу – шул өметләребезнең акланмавыннан гынадыр. Мәҗнүн булып Мәҗнүн җанында да күпчелек милләттәшләр гаме кайнаша икән, тәмам өметсезлеккә бирелергә, сыгылып төшәргә, шөкер, сәбәп юк, дигән сүз әле.

**Рәфыйк ШӘРӘФИЕВ**

# БАТЫРЛАРЧА ИҖАТ

## РАУЛЬ МИР-ХӘЙДӘРОВКА 75 ЯШЬ



Һәр вакыйганың да тарихи алшарты була.

1941 елның 16 ноябрендә фашист илбасарлары Мәскәүгә якыная. Волоколамск тирәсендә дошман һөҗүменең төп юнәлеше генерал-майор И.В.Панфилов дивизиясе плацдармына туры килә. Дүрт сәгатьлек бәрелештә 28 панфиловчы, фашистларның 18 танкын сафтан чыгарып, Мәскәүгә юлны кисә...

Ә икенче көнне – 1941 елның 17 ноябрендә, Рауль Мирсәет улы Мир-Хәйдәров дөньяга килә. Фронттан еракта, Казакъстанның Актүбә шәһәре янында туса да, сугыш афәте аның гаиләсен читләп үтми – кайгылары белән сыный, батырлыклары белән чыныктыра.

Ташкент политехника институтын тәмамлагач, ул шушы «икмәкле шәһәр»дә яшәп кала.

Узган гасырның 70нче еллар башында КПСС Үзәк Комитеты «Иҗат яшьләре белән эшләү турында» карар кабул итә. Советлар Союзы дигән иксез-чиксез илдә иҗат күтәренкелеге башлана. Рауль Мир-Хәйдәров та яшь язучыларның IV Бөтенсоюз съездында (1975) катнаша. Һәм шул ук елны аны СССР Язучылар союзына кабул итәләр.

Төзүчедән язучыга – бер адым, дигәндәй, инженер-төзүче булып егерме ел эшләгәч, ул кинәт кенә профессиональ иҗатка күчә. Беренче романы белән үк СССРда шау-шу күтәргән «Үзбәкстан вакыйгалары»н фаш итә. Сүз 1988 елда дөнья күргән «Пешие прогулки» («Җәяүле сәйран». – *«Казан утлары», 2010, №1-3*) китабы турында бара. Шул ук елны язучыга һөҗүм оештырыла, үлемнән котылса да, ул гомерлек II группа инвалид булып кала. Әлеге китап 24 тапкыр кабатлап бастырыла һәм әлеге әсәр өчен Рауль Мир-Хәйдәровка СССР Эчке эшләр министрлыгының әдәби премиясе бирелә.

Алга таба да гомеренә куркыныч янаганга күрә, Рауль Мир-Хәйдәров Ташкенттан герой-шәһәр Мәскәүгә күчеп килә. Һәм аның яңадан-яңа детектив әсәрләре басыла башлый. Бүгенге көндә ул – гомуми тиражы 10 миллионга җиткән кырыклап китап авторы.

Мәскәүдә яшәсә дә, аның иҗаты рухи мәркәзебез Казанга әйләнеп кайтты. Дистәдән артык романы журналыбызда һәм Татарстан китап нәшриятында ана телендә дөнья күрде.

Рауль Мир-Хәйдәров – Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. Сугышчан батырлыкка тиң иҗаты булган каләмдәш дустыбыз белән горурланабыз, әлбәттә!


**Камил КӘРИМОВ**

***Редакциядән:***

*Сайланма әсәрләре дөньякүләм укучыга таралса да, Казакъстанда, Үзбәкстанда, Мәскәүдә яшәсә дә, талантлы язучы Рауль Мирсәет улы Мир-Хәйдәров курку белмәс, кыю татар егете булып кала. Без аны олуг юбилее белән котлыйбыз һәм яңадан-яңа җиңүләр юлавын телибез.*

# КҮҢЕЛ ДӘРЬЯЛАРЫ КИҢ АНЫҢ

## РАВИЛ ШӘФИГУЛЛИНГА 75 ЯШЬ



Очрашкан саен туган ягым, ямьле Чирмешән буйларын искә төшерүче дустым, шагыйрь Равил Хасият улына да быелның 1 декабрендә 75 яшь тулды. Сугыш башланган кышта ул атаклы Парау авылында дүртенче бала булып туган. Ата назын, ата йөзен күрмичә үскән сугыш чоры балаларының берсе инде ул. Шул сәбәпле дә аның күңеле моңлы, зарлыдыр. «Мәктәптә уку елларында ук әниемнең моңлы итеп мөнәҗәт әйтүләрен тыңлап үстем. Соңрак ул мөнәҗәтләрнең күбесенең авылдашыбыз Габделҗаббар Кандалый шигырьләре икәнлеген белдем: *«Парау илендә төш күрдем, / Ки бер кош тотдым, ук атдым. / Парау илендә бер матур өчен / Йокымны югалтдым...»*

Шагыйрә Иделбикә дә Равилнең яшьли шигърият дөньясына тартылуын әнисе йогынтысыннан күрә. «Дини белемле әнисенең сөйләмендә Г.Кандалый, Г.Тукай, Һ.Такташ сүзләрен ишетеп, халкының рухи йогынтысын, катлаулы тормыш гамен аңына, йөрәгенә сеңдереп үскән», дип яза. Мәктәптә укыган елларында ук Равил кичәләр оештырышуда катнаша, сәхнәдән шигырь сөйләргә ярата. Шул сәләтен истә тотып, урта мәктәпне тәмамлагач та, аны 1959 елда авыл җитәкчеләре клуб мөдире итеп билгелиләр. Бер үк вакытта диярлек ул утыз чакрым ераклыктагы район үзәге Мәләкәс каласында (хәзерге Димитровград шәһәре) авыл хуҗалыгы техникумында укый, икътисадчы дипломына ия була, хәрби хезмәт юлы үтә. Ә күңеле аны Казанга тарта. Туган авылына бер кайткан вакытта университет профессоры Ибраһим Нуруллин да аңа Казанга барып укырга киңәш иткән була. Әмма язмыш аны икенче якка алып китә. Сугыштан соңгы авыр елларда Сахалинга барып төпләнгән өлкән апасы чакыруы буенча ул шунда китә. Биредә нефть һәм газ җитештерү оешмасында икътисадчы, аннары мең кешедән артыграк хезмәткәре булган оешманың кадрлар бүлеге мөдире һәм партком секретаре вазифаларын уңышлы башкара. «Сахалин toткынынннан 1994тә генә котыла алдым. Хәзер исән булган улым белән кызым шунда үстеләр. Күңел юанычым фәкать Казаннан килеп торган «Казан утлары», «Азат хатын» журналлары булды», дип искә ала Равил.

Димитровград шәһәренә кайтып урнашкач, ул өлкә үзәгендә яңарак чыга башлаган «Өмет» газетасының иң актив авторларының берсе була. Казан вакытлы матбугаты белән дә элемтә урнаштыра. Аның шигырь үрнәкләре 2006, 2008 елларда «Казан утлары» журналында чыкты. Кайбер шигырь һәм хикәяләре «Сөембикә» журналы, «Ватаным Татарстан», «Мәдәни җомга» газеталары битләрендә дөнья күрде, «Күңел дәрьялары» (2007), «Серле Парау» (2008), «Теге ярда» (2012), «Якты юлда» (2013) исемле китаплары чыкты. Бөтендөньяга таралып, Татарстаннан читтә яшәүче иҗатташларга багышлап Казанда нәшер ителгән «Кайда да йөрәктә» (2012) китабына да Равил якташымның шигырьләре кергән. Шуннан элегрәк ул Татарстан Язучылар берлегенә кабул ителгән иде.

*«Йөрәккә – дәрт, / Җанга – тыйнаклык, / Күңелләргә – тапсыз саф акыл»,* – дип, шагыйрьнең үз сүзе, үз теләге белән тәмамлыйм бу язмамны. Бүгенге көндә аның Ульян өлкәсендә яшәүче язучыларның җитәкчесе булуын да билгеләп үтү кирәктер.


**Лирон ХӘМИДУЛЛИН,**
*Г.Исхакый исемендәге әдәби премия лауреаты*

***Редакциядән:***

*Каләмдәшебез Равил Шәфигуллинны юбилее белән котлыйбыз! Аңа иҗат уңышлары телибез!*

# ЧЫН БЕЗНЕҢЧӘ – МИЛЛИ...

## РУШАН ШӘМСЕТДИНОВКА 70 ЯШЬ



Аның әсәрләрендә тарих үзе. Үткән белән бүгенге тылсымлы төсләр яктылыгында ерак гасырларны чагылдыра. Фаҗигаи язмышлы Ханбикә-Сөембикә, Кол Гали, Мөхәммәдьярларның карашларында уй, гамь... Тукайның «Су анасы» әкиятенә язылган иллюстрациядәге алтын тарак урлаучы малайның куркынган йөзен күреп, чәченнән сыйпап юатасы килә, Су анасы артыннан чапкан көчекләрнең һау-һаулап өргән тавышлары ишетелеп киткәндәй була... Миллилек – аның канында, калебендә, зыялы-затлы чыгышында.


Рушан Шәмсетдинов 1946 елның 25 ноябрендә Казан шәһәрендә туа. Яшь егетнең күңеленә милли рух Татар Бистәсенең үзенчәлекле, кабатланмас архитектура бизәкләре аша да, һичшиксез, сеңеп калгандыр. «Болар бит бер заман җимерелеп юкка чыгарга, югалырга мөмкиннәр, тарих безне гафу итмәс», дигән уй үсмер егетне Казан сәнгать училищесына укырга алып килгәндер. Әйтергә кирәк, инде студент вакытта ук эшләре белән ул төрле күргәзмәләрдә катнаша башлый. Үзенең уй-хыялларын егет укуын тәмамлаганда тормышка ашырырга керешә – диплом эше итеп «Сөембикәнең ире Сафагәрәй белән хушлашуы» исемле картина әзерләргә тели... Тик рәсми идеология егеткә хут бирми, нәтиҗәдә, җитәкчесе «Җәлилчеләр» картинасын язуны тәкъдим итә, ул училищедан рәссам-педагог белгечлеге алып чыга. Аннан инде мәктәптә укытулар, төрле газета-журналларда бизәүче-мөхәррир вазифалары, Казан сувенирлар фабрикасында эшләүләр... Аз, болар гына бик аз кебек тоела аның күңеленә. Сәнгать фәннәре докторы Фоат Вәлиевнең милли сәнгать, татар тарихы буенча биргән дәресләре егетнең күңелен һаман алгысытып, эзләнүләргә әтәреп тора. Һәм менә, Ходайның рәхмәте, остазы Рәшит Төхфәтуллин аңа Мәскәүгә укырга китәргә, аралашу, эшләү мөмкинлеген киңәйтергә киңәш итә. Мәскәүне алу беренче, хәтта икенче талпынуда да түгел, өченчесендә генә насыйп булып, 1981 елда Мәскәү полиграфия институтын тәмамлаган егет рәссам-график һөнәрен үзләштерә.

1968 елда ул Татарстан китап нәшриятында рәссам-бизәүче, 1993 елдан баш рәссам булып эшли. Россия һәм Татарстан Рәссамнар берлеге әгъзасы, Татарстанның халык рәссамы, атказанган сәнгать эшлеклесе, күп конкурслар лауреаты Рушан Шәмсетдинов тарафыннан бизәлеп, тарихи яктан баетылып, 500дән артык китап (Акмулла, Н.Исәнбәт, С.Хәким һ.б.ларның томлыклары, татар пьесалары антологиясе, «Идегәй» китабы һ.б., һ.б.) дөнья күргән икән – аның татар әдәбияты, сәнгатен танытуда өлеше бәһасез. 1991 елда «Мирас» журналы ачылгач, әлеге журналда эшләү, тарихчылар белән турыдан-туры аралашу да аның белемен баетып, уй-хыялларын тулыландырып җибәрә. Әйтергә кирәк, әлеге талант иясенең яңа ачылган басмада хезмәт куюы журналның укучылар арасында танылып китүендә зур табыш була.

Рәссам өчен иң мөһиме – шәхси күргәзмәңне оештырып, сәнгать белгечләренең бәһасен ишетү, хезмәтеңнен халык арасында танылa алуында. Аның күргәзмәләре һәрдаим оештырылып, хезмәтләре җөмһүриятебездә генә түгел, чит өлкәләрнең, хәтта чит илләрнең музейларында да саклана. Алар арасында бигрәк тә «Болгар ханнары», «Алтын Урда ханнары», «Казан ханнары» портретлар җыелмасы, «Татар халкының батыр бабалары» хезмәте, күренекле шәхесләр портретлары зур урын алып тора. Рушан Шәмсетдинов тарихка гына түгел, дөнья буенча да сәяхәт итәргә ярата. «Бер генә көн сәяхәт итсәң дә, бер ел өйдә утырганнан файдалырак», дип әйтергә ярата ул. Халкыбызның күренекле улын күркәм бәйрәме белән котлап, тарихи һәм дөньяви сәяхәт юллары озын булсын иде, дигән теләктә калабыз.

**Гөлзадә БӘЙРӘМОВА**

# ТУГАНКАЙ




Телчеләр, без – әдәбиятчылардан аермалы буларак, артык сөйләшми. Аларның фәне дә, фикер сөреше дә, тәгълим-тәрбиясе дә үзләре хак дип санаган бер улактан читкә чәчрәп чыкмый. Тел гыйлеменә караган фәннәрдә дә шулай бит: инде дистәләгән еллар дәвамында бер дә үзгәреш кичерми, бер агымга гына «гомер сөрә» торган кануннар алар. Әдәбиятта биниһая образлар, аларга бәйле рәвештә фикер вариацияләре, катлам-катлам сюжет линияләре... – тагын әллә ниләр үз дигәнчә яши, үзләренчә «тормыш көтә».

Булачак әдәбиятчыны тел галимәсенең аңлап бетермәве, елга-күлләрдә үзе ошаткан юнәлешләрдә колачлап йөзүен хупламавы, телчеләр ерганагы буйлап кына агарга мәҗбүр итәргә теләве миңа еллар үткәч кенә пәрдә артын ача...

## Ялгыз галимәнең гадел дөньясы

Ялгызлык... Нинди кырку сүз. Аның асылына ачыргаланып кычкыру да, сыктап елау, сагышлы әрнү газаплары да, шул ук вакытта башкалар каршында мәгърур баш имәүчәнлек тә салынган кебек миңа. Фән, иҗат, сәнгать әһелләре арасында ялгызлар күп, хәтта бик күп... Моның сәбәпләрен бармак белән генә санап бетерү мөмкинме? Юктыр... Туган халкына тугры хезмәттә булган әлеге катлам һәрдаим күз уңында, шуңа да аларның ялгызлыгы, гадиләр ялгызлыгыннан аермалы буларак, күз өстендәге каш кебек.

Татар ономастикасы, топонимиясе һәм гидронимиясе өлкәләрен өйрәнгән, йөзләгән педагоглар әзерләүдә армый-талмый көч куйган олуг галимәбез, филология фәннәре докторы (1992), профессор (1993), Татарстанның һәм Россиянең атказанган фән эшлеклесе (1995, 2003) Фирдәвес Гарипова ялгызлыгы да әнә шундыйлардан.

Фирдәвес Гариф кызы Гарипова 1941 елның 7 декабрендә ТАССРның Биектау районы Кодаш авылында гаиләдә сигезенче бала булып дөньяга килә. 1965 елда Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетын тәмамлаганнан соң, Биектау районы Ямаширмә урта мәктәбендә балаларга рус һәм немец телләре укыта ул. 1966-1970 елларда Республика фәнни китапханәсендә китапханәче булып эшләп ала. 1974 елдан – СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Тел, әдәбият һәм тарих институтында (хәзер – ТР Фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты). Биредә ул соңгы көннәренәчә – нәкъ 40 ел фәнгә хезмәт итә, институтның лексикология һәм диалектология бүлеге баш фәнни хезмәткәре була. 1976 елдан Казан дәүләт педагогия институтында студентларга хәзерге заман татар әдәби теле (лексикология), татар әдәби теле тарихы, татар теленең тарихи грамматикасы буенча белем бирә, югары уку йортлары өчен дәреслекләр, методик ярдәмлекләр яза. 1976 елда – «Казан арты гидронимиясе» (Казансу, Мишә, Ашыт, Шушма елгалары бассейннарындагы сулыклар керә) дигән темага кандидатлык диссертациясе, ә 1991 елда «Татарстан гидронимиясе» темасына докторлык диссертациясе яклый.

Фирдәвес Гарипова меңгә якын татар авылы, төбәге тарихын, сулыкларның географик атамаларын, аларның килеп чыгышын өйрәнеп, ике дистәдән артык монография һәм сүзлек язып бастыра. Ул Татарстандагы гидронимнарны тирәннән өйрәнгән, аларны сүзлек дәрәҗәсендә туплап эшләгән беренче галимә санала.

Фирдәвес Гарипованың фән каләме карасы тел белеменең гидрономия тармагы белән генә чикләнми – үзенең әһәмиятле табышларын башка юнәлеш мәҗмугаларына да мулдан яза. Шулай итеп, ике томлык «Татарстан гидронимнары сүзлеге» (1984, 1990), ике томлык «Татарстан микротопонимнары сүзлеге» (1992, 1993) дөньяга чыга, мәктәп һәм уку йортлары өчен төзелгән «Исемнәрдә – ил тарихы» (1994) кулланмасы басыла. Галимәнең «Борынгы Болгар шәһәрләре» (1990), «Авыллар һәм калалар тарихыннан» (ике томда; 2001, 2003), «Хәтеремнән чыкмый һич тә...» (2003), «Эчәр сулар йөртә безне» (2006) дигән һәм башка хезмәтләре җәмгыятебезнең төрле катлам вәкилләре тарафыннан яратып кабул ителде.

Әйе... Кыска гына бер гомер һәм күпме хезмәт! Шул дәрәҗәдә тыгыз һәм нәтиҗәле эшчәнлек. Моның сәбәбе – Дөбьяз төбәге халкына хас үҗәтлектәдер... һәм гомерен фәнгә багышлаган шәхси ялгызлыкта. Унике яшеннән әтисез калган төпчек кыз үзеннән өлкән җиде туганы, без – студентлары, сөйгән халкы белән тыгыз мөгамәләдә яшәсә дә, ул барыбер ялгыз иде. Моның шулай булуына мин аның соңгы елларында редакциябездә көн дә, көн дә көтелмәгәнчә пәйда булып, язмышыннан безгә нәмәгълүм эпизодлар бәян итүе аша төшендем. Фирдәвес апаның күзләре нигәдер миңа һәрвакыт сагыш, моң тулы касәне хәтерләтте, хәтта көлгәндә дә.

Шул вакытларда нигәдер аның яшь чакларын күрәсем килә иде. Фән юлына бер чорда аяк баскан фикердәше, галим Равил Әмирхан менә ничек сурәтли Фирдәвес апаны: «...ыспайлыгы, төз-җыйнак гәүдәсе, үз дәрәҗәсен үзе белүчән вәкарьлеге белән аеруча бер туташ игътибарны җәлеп итә. Күпләргә өлге булырдай затлы-камил причёска, җемелдәп торган мәгънәле күзләр, косметиканың ни икәнен дә белмәгән керфек-кашлар... Өстендә ул заманда модада булган, сорырак төстәге «строгий» лавсан костюм-юбка. Әлбәттә, чибәр. Хәтта артыгы белән. Чын авылча, шәһәр ясалмалылыгы бозмаган табигый матурлык. ...Гаҗәбе шул: һавалы түгел, үзен әллә кемгә куймый, тавышы азрак тоныграк, әмма төзек дикцияле, сүз каткан кешесе белән рәхәтләнеп сөйләшә» *(«Казан утлары», 2000, №9).*

Безне укытканда да (инде җитмеш ягына чыккан булуына карамастан) ул яшьлек елларындагы үз-үзенә булган таләпчәнлегенә хыянәт итмәгән икән.

## «Җиргә төкерсәгез, әнкәм йөзенә төшсен, дип төкерегез!»

Без Фирдәвес апа белән 2002 елдан соңгы көннәренә кадәр аралашып яшәдек. Университетта эшләү, төрле конференцияләрдә очрашулар, аннан соң журнал редакцияләрендә фикер алышып утырулар – гомумән, бер уртак сукмак булган инде...

Танышу болай булды. Икенче курста укыган чак. Муса Җәлил урамында урнашкан бинабызның икенче катындагы зур лекция залына килеп керде ул. Лексикология фәне иде. Керә-керешкә үзе белән таныштырды: «Мин, туганкайларым, Фирдәвес Гариф кызы Гарипова булам. Исегездә калдырыгыз, Гариповна түгел, Гарифовна! Бутыйсы булмагыз! Аннан соң исememне дә «вэ» аша язалар инде, дөресе «ү» аша булырга тиеш тә бит. Паспортисткалар татфак бетермәгән шул...» Үз исеменә дә шулкадәр таләпчән галимәдән беренче минутларда ук шүрләргә өлгердек. Лексикология, әдәби тел тарихы, тарихи грамматика кебек фәннәрдән лекция-семинар сәгатьләрендә «Фирдәвес Гариповна» дип ялгышучылар байтак булды. Ну, пешекләп тә карый иде үзләрен Фирдәвес апа. Бер әйткәннән төшенү галәмәте күбебезгә шул дәресләрдә килгәндер.

Аның дәресләрендә дуамал чебеннәр дә тәрәзә кашагаларында нәүмиз генә йокымсырап утыра, ул чыгып китмичә, урыннарыннан кузгалмый, күрше ишегалдындагы чиркәүдә башка көннәрдә ярсыган кыңгыраулар да тонык кына «чең» итә дә, Фирдәвес апа тәрәзәгә «усал» караш ташлагач, «ңе» авазын Болак суына бик ашыгыч чумырып тынып кала. Такта янына, җәлилчеләр сорау алырга кертелгән кебек, берәм-берәм, кулларны артка куеп чыгабыз – нинди дәфтәр күтәреп чыгу, чәнти бармак бите кадәр кәгазең булса да, «икеле»ң урыныңа үзеңнән алда барып утыра. Сөйли башлыйсың... Фирдәвес апа сине колагы белән күрә, ә күзләре – аудиториядә. Группадашларыңның берәрсе ярдәм йөзеннән андый-мондый «хык» итсә, җавап

рәвешендә укытучыбыз аңа мәгърур «икеле»се белән – «дык»! Вакыйгаларның бу дәрәҗәдә кискен үзгәрүе, йөзләргә чыккан сызлану катыш трагизм көләсене китерә.

Пырхылдык кытыгы кабырга аралары буйлап сикерә-атлый сәяхәткә чыккан гына иде, Фирдәвес апа каршыма очып килеп тә җитте, дәфтәремне куеныма кыстыртып, очыртып та чыгарды. «Мин монда сезне эти-әниләрегезнең алтын баганалары дип йөрим, ә сез хихылдап, миннән көлеп утырасыз!» – дигән сүзләре, ишек җиленә бәрелеп, «сквозняк» белән кире аудиториягә суырылып кереп китте. Бу ямьсез күренеш аркасында шактый оялып йөреп, галимәгә аннан көлмәвемне, ә мимикамның шундый булуын күпме дәлилләргә теләсәм дә, телче булачак әдәбиятчыны аңламады.

Икенче зур бәрелеш көтмәгәндә, яу янамаган тарафтан килеп бәрде. Фирдәвес апаны инде, өлкән курслар традициясе буенча, «Туганкай» дип атауны гамәлгә керткән идек. Иң үшән студент та аның Туганкай икәнен белә, тик галимә генә төшенми. Сүз ясалышы дәресендә, гөнаһ шомлыгы, «туганкайларым» сүзен төзелеш ягыннан тикшерү биреме эләкте бит. Укытучының зур итеп тактага язып куюы булды, безнең башлар өстеннән җиңелчә көлү дулкыннары йөгереп узды – сер бирмәдек. Әмма параллель группада сатканнар булып чыкты. Сүз ясалышы лексикологиягә җиткереп, фәннең әлеге ике тармагы арасында кызыклы гына сөйләшү булган.

Фирдәвес апа чираттагы лекциягә чебеш чәлдерергә томырылган тилгән тизлеге белән очып керде дә, бәйләнчек сары шөпшәдәй яскынып-яскынып, безне «тетәргә» тотынды:

– Әйтмим, бүтән беркайчан да әйтмим мин сезгә ул сүзне! Сезне яратып, эти-әниләрегезнең алтын баганалары булганга гына шулай атап йөртә идем бит, туганкайларым... Тьфү, тагын әйттем инде... Ялгыш ычкынды. Бүтән әйтмим, – дип «ярсыды». Вәгъдәсендә торды: әүвәл ул бу сүзне сөйләм түтәлендә сирәкләп чыкты, соңрак бөтенләй төбе-тамыры белән йолкып ташлады. Шулай да әлеге сүз берничә елдан яшь үсентеләр бирде: бездән соң килгәннәр дә аны Туганкай дип атыйлар иде.

Күңелгә авыр булып китте. Көләсе килми иде... Ни өчендер мин шул вакытта үземне уенчыгын югалткан сабыйдай хис иттем – кызык бетте, кушамат фаш ителде! Һәм әлеге шуклыкта ул безнең шаян группаны гаепләде, безгә «ачу» тотты. Моның шулай булуы имтиханда үзен аеруча да көчле сиздерде. Яшь йөрәк ярсуын тимер кыршаулар белән богаулап, сорауларга җавапларны ялтыратып ятларга кирәк иде.

Кышның ачы буранлы таңы атты. Каядыр китәсем бар дигән сылтау белән, Фирдәвес апа безне иртәнге җидегә үк чакырды. Мин 10нчы микрорайоннан килеп җиткәндә, аудиториядә егермеләп сабакташ шәмәхәле-яшелле күшегү катыш карашларын билет сорауларына кадаган булып чыкты. Имтихан иде бу...

– Әйдә, энем, билет ал! Син иң шугы бит! – дип тантана итте Фирдәвес апа. – Кешедән көлеп утыра белгәч, фәнне дә яхшы беләсең булыр... Бәлки, әзерләнеп тә тормассың?!

Инде барлык сораулар кат-кат ятланганга күрә, мин, карлы өс киемен дә салып өлгермәгән килеш, сөйли дә башладым. Бу кадәр үк әрсезлекне көтмәгән Фирдәвес апа мине ярты сәгатьтән артык «җәзалады», тик «бишле» куярга мәҗбүр булды. Әлеге адымымны көтмәгән куян йөрәкләр «уф» дип җиңел сулап куйды. Шул рәвешле, группа имтиханны җиңде – «өчле» билгесе булмады кебек. Имтихан белән бергә Фирдәвес апа да җиңелде. Безгә карашы үзгәрде. Ә бишенче курста дәүләт имтиханнарын тапшырганда, аның фәненә караган билетларны, гомумән, өйрәнеп торуның кирәге юк иде.

Инде өченче курста әдәби тел тарихы фәнен укый башлагач, Фирдәвес апа иң беренче эш итеп бездән туган авылларыбыз тарихын яздыртты. Кырык сигез битлек дәфтәрне тутырган язмамны укыгач, ул болай диде:

– Энем, син тагын мине аңламагансың инде! Бу кадәр кирәк түгел иде. Мин бит кыска, конкрет языгыз, дип аңлаттым, язучылар кебек чәчелә-чәчелә иҗат итегез, димәдем. Әйе, синнән телче чыкмас!

Үз-үземнән канәгать булып, инде дә Фирдәвес ападан мактау ишетмәсәмме, дип канатланып йөргән җиремнән – мәргән бәргән кош кебек – лап итеп җиргә түндем. Күпмедер ел узгач, Фирдәвес ападан, шул дәфтәр материалларын аралап, туган авылым Чупай (Әлмәт районы) турында фәнни мәгълүмат бастыруын сорасам да, икәү бергә утырып, бу эшне башкарып чыгарга кул җитмәде.

Фирдәвес апа бик кызыклы шәхес иде. Ул туган авылын үзенә генә хас бер мәҗүсилек белән яратты, Дөбьяз сөйләменә хәтта бер авазда да хыянәт итмичә, үз диалектында сөйләште. Бездән дә әти-әнине, табигатьне, туган якны яратуны таләп итте. «Җиргә төкерсәгез, әнкәм йөзенә төшсен, дип төкерегез!» – ди торган иде ул. Бүген дә кешелекнең әлеге ихтыяҗый гамәленә фәлсәфи якын килəм. «Адәм баласы оятны югалта башлады, авызлардан иман чыгып кача микән, халык теленә сүгенү керде бит...» – дип ачыргаланды. Аның йөрәге татар авылларының елдан-ел кими баруына сыза иде. Хәмернең нык тормышлы татар авылларын эчтән җимерүенә аеруча борчылды.

## Ул юк инде...

Фирдәвес Гарипова 2014 елның 4 ноябрендә Казанда вафат булды. Биектау районының Олы Битаман авылы зиратында 5 ноябрьдә җирләнде.

Җаны-тәне белән татар авылларын яраткан галимә соңгы көннәренә кадәр безнең журналда «Авылларыбыз тарихы» сәхифәсен алып барды. 2006 елның июль аеннан 2014 елның июленә кадәр төп-төгәл сигез ел дәвамында «Казан утлары»нда 148 авылның тарихын яктырткан ул.

Вафатына берничә ай кала, аеруча да еш килде ул безгә. Кайбер көнне хәтта икешәр тапкыр да килеп китә иде. Аның татар авылларына бәйле язмаларын тагын да күбрәк чыгарасы килде, ялкынланып, борчылып йөрде.

Редакциягә Фирдәвес апа мәкаләләренә бәйле хатлар да еш килә иде. Алар арасында рәхмәт белдергәннәре дә, авыллар елъязмачысын үз төбәкләренә чакырганнары да, галимә язганнарга өстәмә материал табып, шатлык уртаклашучылары да – төрлесе бар иде. Фирдәвес апаны соңгы хат тетрәтте. Ул Кукмара районыннан килде. Журналның 2013 елгы 7нче санында Кукмара районы Уразай авылы турында басылган мәкаләдә кайбер төгәлсезлекләр китүе язылган иде анда.

Фирдәвес апа бик борчылды, кичекмәстән ул төбәккә барачагын, әгәр дә ниндидер хата киткән булса, бик теләп төзәтәчәген сөйләде.

– Энем, фәнни хезмәтләрне язганда, мин гомерем буе борынгы грек-византия, кытай, гарәп-фарсы, әрмән чыганакларына таяндым, көнбатыш, рус галимнәренең хезмәтләрен өйрәндем, алардан төрки-татарга хас уртак тамырларны эзләдем. Авылларыбыз тарихын төп фәнни юнәлешем итеп махсус өйрәнмәдем, әмма сәфәр дәфтәрләрем гел тулы булды. Салаларыбыз тарихына бәйле материалларны берләштереп, йокы, ял исәбенә хезмәт куеп, дистәгә якын китап чыгардым, – диде ул, тынычлык саклап. – Максатым – авылның акчалы кешеләрен, милләтпәрвәрләрне туган төбәкләрен саклап калуга, аларның тарихын мәңгеләштерүгә чакыру бит. Татар авылының хәле мөшкел бүген. Көлтә-көлтә юкка чыгалар. 1965 елда биш меңнән артык татар авылы исәпләнгән, бүген бу сан өч меңгә дә тулмый.

Шуннан ул, дәррәү кубып, Кукмарага юл тотты. Озакламый (2014 елның июнь аенда) «Казан утлары»нда «Кукмара» дигән фәнни мәкаләсе дөнья күрде. Теге бәхәсле язма буенча да аның әйтәсе сүзе әйтелеп бетми калды...

– Энем, соңгы ике елда җиде бертуганым бер-бер артлы китеп бардылар. Берсенең күмү мәрәсимен онытып өлгерә алмыйм, икенчесен әҗәл йолкып ала. Соңгысы китте, чират миңадыр... – диде ул ахыргы очрашуыбызның берсендә. – Ә бит әле күпме татар авылы тарихы – күтәрелмәгән чирәм.

Әйе, Фирдәвес апаның йөрәген әрнеткән мәсьәлә барча татар кешесен дә борчырга тиеш. Туган тамырлары корыган, асылы җуелган халык киләчәк елларга ничек бара алыр?! Инде меңләгән татар авылы тарихын, язмышын үз бәгыре аша уздырган, матбугатта, радио-телевидениедә ялкынлы чыгышлары белән милләттәшләрен сискәндереп уятырга ашыккан тынгысыз галимәбез дә юк бит!

Гомәр Саттаров нигез салган, Фирдәвес Гарипова үстергән ономастика мәктәбен бүген Рифкать Шаһиев, Ренал Хаҗиев, Олег Хисамов, Гөлфия Һадиева кебек галимнәр дәвам итә. Димәк, өметләребез юк түгел.

**Рамил ХАННАНОВ**

# ТУКАЙ ЭЗЛӘРЕННӘН ЙӨРГӘН ГАЛИМ: МӨХӘММӘТ ГАЛИ

Габдулла Тукай, һәр ноктадан караганда – бәхетле шагыйрь. Милләткә иң кирәк бер вакытта дөньяга килгән, күзен ачучыларга ихтыяҗ зур заманда һәм нәфис сүзгә мәйдан киң бер вакытта яза башлаган, милләттәшләре арасында яшәгән, зыялылар арасында урын тапкан, дуслар булдырган, хәтта үзе тәнкыйть иткән байларның ярдәменә, игътибарына ирешкән. Боларны эшләп тә, әдәбиятта үзенә лаек бәяне алмаганнар юк түгел. Элек тә шулай булган, хәзер бигрәк тә нәкъ менә милләтпәрвәр язучылар катламы күләгәдә кала килә. Кызганыч ки, әлегәчә Ш.Бабич, С.Рәмиев, Һ.Такташ кебек корифейларның да иҗаты милләтебез файдасына, әдәбиятыбызга кылган изге гамәлләре тиеш дәрәҗәдә бәяләнгән дип әйтеп булмый. XX гасыр башында иҗат иткән һәм чынлыкта да талантлы булган берничә дистә язучының исемен бүгенге укучы түгел, әдәбият галимнәребезнең дә зур күпчелеге белми. Әлеге дә баягы узган чорлар белән ныклап шөгыльләнгән фән эшлеклесе генә булса инде.

Иң үкенечлесе: каләм ияләренә һәм иҗатларына гаделсез мөнәсәбәт көчәя генә барып, гадәти бер хәлгә әверелде. Бу көн язучыларының иҗаты, гомумән, тиешле бәясен ала алырмы икән? Шикләндерә. Әле талантлылары үз бәясен алып бетерер дип тә әйтеп булмый. Иҗатлары чын-чынлап ачылган, вакытлы матбугатта яктыртылган, китап тудыру мөмкинлекләренә ия соңгы буын алтмышынчы елгылар булды кебек… Аннан инде Күктән бәхет елмайганнарның гына укучы арасында исеме һәм иҗаты популярлаштырылды.

Бер яктан, каләм ияләре артканнан-арта бара, икенче яктан, түрдәге урынны гел әрсезләр дәгъвалый һәм анда утыруга ирешә дә. Әдәбият сан ягыннан бик зур үскән заманда, ни үкенеч, күпләрнең язганы бәяләнми кала, ярый әле Тукаебыз, халык проблемаларын тасвирлап, төрле катламнарның мәхәббәтен яулап, үзенә әдәбият сәхифәләребезнең иң түренә урын яулаган. Һәм, әйткәнемчә, аның шулай булуына бик күп кешеләр өлеш керткән. Бигрәк тә дуслары, иҗатын яратучылар, анда милли юламанлык сыйфатлары күрүчеләр Тукайны популярлаштыру эшен үз җилкәләренә салган. Әлеге игелекле шәхесләр үзләре дә – талант ияләре, беренче чиратта, каләм белән эш йөртүчеләр булган. Тукай иҗатын татар һәм башкорт арасында гына түгел, бөтен дөньяга, әлбәттә, беренче чиратта, төрки халыкларга таратучылар арасында узган гасыр күренеклесе, танылган язучы һәм журналист, югары уку йортларында белем биргән педагог, цензор, тәрҗемәче, Бөек Ватан сугышы елларында СССР Әдәби фондының Татарстан буенча вәкиле булып торган Мөхәммәт Гали дә бар.

Гали Мөхәммәт (Мөхәммәт Вәли улы Галиев, 1893-1952) – узган чорларның, классикларның, шул исәптән Тукай мирасын өйрәнүгә әһәмиятле бер эш дип караган галимнәрнең берсе. Ул озак еллар шагыйрьнең биографиясен яңа чыганакларга һәм үзенә электән таныш фактларга таянып тулыландыру юлында шактый зур эш башкара. Утыз биш яшендә шул юнәлештәге беренче хезмәте – «Г.Тукай белән күрешүем» басылгач ук, галим фәнгә бик күп мәгълүмат алып килә. Ул, «Болгар» кунакханәсендә яшәгәндә, Тукайны үз күзләре белән күргән кешеләрнең берсе була.

«Г.Тукай белән күрешүем» бүгенге укучыга яхшы таныш. Аны шагыйрьнең юбилеена хәзерлек барышында «Мирас» журналы да бастырып чыгарган иде. Г.Тукайның тышкы кыяфәте, кешеләр арасындагы үз-үзен тотышы турында төрле тасвирлар ишеткән, укыган бар, араларында барысыннан да детальлерәге, шагыйрь образын шактый тулы һәм, әйтергә кирәк, җанлы да, шат рухлы да, матур да, кимсенмәслек кыяфәтле дә итеп күз алдына торгызып бастырганы – Мөхәммәт Галинеке кебек.

М.Гали иң тәүдә «кыска буйлы, чандыр гәүдәле, бөдрәрәк җиткән чәчле яшь

Тукайны «Шәрык клубы»ның фойесында коляскадагы Фатих Әмирхан янына җыелган яшьләр белән көлеп сөйләшеп торганда очрата. «Аның өстендә ябык якалы кыска тужурка, аяк йөзенә үк төшеп торган озын тар чалбар, аягында тәбәнәк үкчәле, балтырыннан тотып кия торган шнурсыз резинлы ботинка иде».

Тукайга тирәлек мөнәсәбәте, аның тартып тору көче шулкадәр көчле булган һәм шуннан соң Мөхәммәт Гали гел аны якыннан күрү генә түгел, аралашу хыялы белән дә яшәгән дип уйлыйм, югыйсә ул Тукайдан киңәшләр алып йөрүче яшь шагыйрь, мәдрәсә шәкерттәше Габдулла Харистан Тукайның номерына үзе белән алып баруын үтенмәс иде. Яшьләрнең кунакханәдә очрашуының тәүге мизгелләре үк Тукайның ни дәрәҗәдә табигыйлеге, самимилеге, ачык күңеллелеге, ихласлыгы турында сөйли:

«Без барганда, «Болгар»ның өченче катында Тукай тора торган 41нче номерның ишеге ярык кына булып ачылып тора иде. Г.Харис, шакылдатмый-нитми ишекне зуррак ачып, башын тыкты да:

– Мөмкинме, Габдулла әфәнде? – диде.

– Ә, синмени әле бу, Харис? Әйдә, кер! – дигән тавыш ишетелде эчтән.

Ишекне яртылаш ачып, ул кереп китте, мин ишек төбендә калдым.

Бераз торгач, Харис:

– Минем бер иптәшем дә бар иде әле анда, – диде.

– Кая соң ул, ник әйтмисең аңа, керсен, – диде Тукай».

М.Гали язмасы Тукай бүлмәсенең теләсә кемгә, бигрәк тә милли яшьләргә һәрвакыт ачык икәнлеге, гомеренең иҗат белән шөгыльләнүчеләргә булышып узуы турында сөйли.

Әгәр бүгенге көнгә М.Гали кебекләр калдырган истәлекләр булмаса, без Тукай торган номерның эчке күренешен күз алдыбызга да китерә алмас идек. Дөрес, ул Г.Исхакый «Теләнче кыз»да тасвирлаган Мансурның һәм башка кайбер әдипләребез әсәрләрендә сурәтләнгән геройларның бүлмә күренешенә бик якындыр: «Бер кровать, бер-ике урындык сыярлык кечкенә генә бүлмә. Ашъяулык япкан өстәл, җыелмаган кровать һәм ишек янындагы чөйгә элгән кыска сөлге белән вак-төяк киемнәр һәм ике урындыктан башка бүлмәдә бер җиһаз да юк.

Без килгәндә, Тукай яткан булган икән. Мин кергәндә, ул, яңа урынынннан торып, өстенә ябынып яткан пальтосын чөйгә элеп маташа иде».

М.Гали язмасыннан гаиләле булмаган, балалар үстермәгән Тукайның ни дәрәҗәдә педагог икәнлеге дә ачык күренә. Ул яшь шагыйрьне дәресләр өзүдә, белемгә ялкаулылыкта гаепли, фикеренең кемгә дә үтемле икәнлеген белеп, кирәк дәрәҗәдә генә «тәрбия биреп» ала:

«– Юк, сине, малай, начар укый, диләр, ялкауланасың, – ди. – Алай ярамый бит ул. Русча да бер дә белмисең бугай син? Частный урок алып булса да, русча укырга кирәк. Болай синең каләмең өметле генә күренә. Укымасаң, рәт чыкмас бит, малай, – диде Тукай.

Харис башын иеп дәшми торгач, ул тагын өстәп:

– Пушкинның берәр шигырен булса да русча оригиналыннан укыганың бармы синең? – диде.

– Бар, – диде бик әкрен генә Харис.

– Ай-һай, бик әкрен әйтәсең, укыганың юктыр. Ичмаса, тәрҗемә аша булса да мәшһүр рус шагыйрьләренең әсәрләре белән танышырга кирәк, шунсыз рәтле шигырь язу буламыни ул, – диде Тукай».

Шулай тәнкыйдирәк сүз әйтсә дә, киткәндә, бераз кыенсынган Тукай болай ди:

«– Тагын килегез шулай. Мин әйткәнгә үпкәләмә син, Харис! Минем шундый турырак әйтә торган гадәт бар. Һәрвакыт килеп йөр! – дип калды».

Бу истәлекне, әгәр дәреслекләр язучы булсам, балаларга түбән сыйныфларда ук укытуны кайгыртыр идем. М.Гали – бик үзенчәлекле балалар әдибе, аның мирасханәсендә бүгенге дәреслекләргә дә кертерлек, җиңел укылышлы хикәяләр бар. Ә бит дәреслек авторлары һәрвакыт материал сайлауда зур кыенлык кичерүләре хакында сөйли.

Алга таба М.Гали шагыйрь биографиясен өйрәнү юлында эзләнүләрен туктатмый, әмма вакытлы матбугатта Тукай хакындагы язмаларын актив рәвештә бастыру эшенә

керешми. Ул аның турында саллы яктырткан хезмәтләр язу кирәклеген аңлый, аларны башкаруга хәзерлек этабы уза. Галимнең Тукай иҗатын яктыртудагы сүлпәнлеге бераздан Бөек Ватан сугышы башланып китү белән дә бәйле була. Шунысы мөһим: ул хәтта сугыш чорында да Тукай иҗаты хакында мәкаләләр язарга җай таба. Әйтик, аның «Тукай – җырчы һәм җыр-музыка сөюче» (1943) мәкаләсе Тукай лирикасының идея-эстетик, фәлсәфи нигезләре проблемасын ачуга юнәлтелгән. Балалар һәм укучы яшьләр өчен махсус язган «Шагыйрьнең тормышы» (1944) очеркы, исеменнән үк күренгәнчә, шагыйрьнең тормыш һәм иҗат биографиясен ача һәм балаларга аңлаешлы, якын телдә җиткерүне максат итә. М.Гали, аны язганда, Тукайның Кырлайдагы дусты, әле ул чакта исән булган Сафа Мөхәммәтшин, әнисе Мәмдүдә апаның ахирие Нәфисә Әхмәтшина истәлекләрен файдалана һәм язганнарын ышанычлы, җанлы, кызыклы итүгә ирешә. Әлеге хезмәт, заман шартларына бәйле рәвештә басылмый калып, инде башка исем белән – «Шагыйрь баскан эзләрдән» дип аталып, 1957 елда дөнья күрә.

Тукайчы сыйфатында танылып өлгергән М.Галине, шагыйрьнең күптомлыгын чыгарганда, редколлегиягә кертәләр. Әлбәттә, ул фәнни эзләнүләрендә замандашларының истәлекләренә генә таянмый, архив документларын да әйләнешкә кертә, китапханәләрдә эш вакытында табылган материалларны да фәнни эшкәртә.

М.Галинең шагыйрь юбилее уңаеннан язган һәм шул тирәдә бастырып чыгарган «Тукайның Уральскидагы тормышы» (1946) мәкаләсе Тукай гомеренең аерым этабы белән таныштыра. Бу хезмәт Тукай тормышына кагылышлы фәндә барган аерым мәсьәләләрне хәл итәргә булыша. Әйтик, анда шагыйрьнең Җаекка 1895 елның кыш башында килүе исбатлана. Бүгенге көн әдәбият фәне өчен, узганны өйрәнгәндә, нәрсә мөһим? Теркәлеп калган фактлар. Аларны хәзер табу, хаклыгын раслау шактый авыр. М.Галинең Тукайга кагылышлы хезмәтләре исә, бүгенге Тукай фәне уңышлары белән ярыша алмаса да, аның өчен ышанычлы чыганаклар булып торуы белән бинаһая кыйммәтле.

М.Гали мирасында Г.Камал һәм Тукай дуслыгы темасы аерым бер урын алып тора. Галим нәкъ менә Г.Камал иҗатының идея-тематик эчтәлеген һәм фәлсәфи-эстетик мәгънәләрен ачканда, Г.Тукайның аерым әсәрләренә чагыштырма планда бәя биреп уза, иҗатының сыйфатларын гомумиләштергән фикерләр әйтә. М.Галинең «Г.Камал» дип аталган китабында шушындый зур нәтиҗә бар: «Татарда юмор һәм сатира әдәбияты тудырып, аны массалаштыручы – Тукай белән Галиәсгар Камал».

Т.Гыйләҗев Тукай энциклопедиясенә хәзерләгән мәкаләсендә болай дип яза: «М.Галинең Тукайның тормыш юлын һәм иҗатының кайбер якларын өйрәнүгә багышланган мәкаләләре шагыйрь шәхесен һәм рухи мирасын мәгълүм идеологиягә буйсындырудан ерак тора. Аларның гыйльми-мәгънәви әһәмияте, иң беренче чиратта, Тукайны идеаллаштырмыйча, аны җир кешесе итеп җанлы образын тудыруда, шагыйрь биографиясен яңа мәгълүматлар, фактлар белән тулыландыруда билгеләнә».

Инде темадан читкә китеп тә, берничә сүз әйтәсе килә. Үзенчәлекле проза, бигрәк тә хикәяләр, драмалар авторы булган М.Галинең Каюм Насыйри хакында роман яза башлап тәмамларга өлгермәве билгеле. Хөрмәтле Президентыбыз Рөстәм Миңнеханов танылган шәхесләр сериясенә караган әсәрләр язуны матди тәэмин итү вәгъдәсе биргән иде, әлеге вәгъдә аның тарафыннан инде өлешчә үтәлде дә. Бу юлда язучылар тарафыннан да беренче адымнар ясалды. Кайберәүләрнең ел эчендә романнарны тәмамлый алмавы (югары сәнгать таләпләренә җавап биргән әсәрне, алдан хәзерлегең булмаганда, язу мөмкин дә түгел) әлеге эш барышына ниндидер киртәләр торгызды сыман. Килешү нигезен үзгәртеп, акчасын да соңрак бирү йә өлешчә биреп тору шарты белән, әлеге хәрәкәтне кабат җанландырасы иде. Әгәр бастырабыз, дип әйтсәләр, М.Гали яза башлаган романны, әйтик, мин үзем дә, язылган өлешендә аның авторлыгын билгеләп, тәмамлап чыгар идем. Һәм икенче мөһим фикерем: китаплар язылачак исемлеккә М.Гали кебек үзенчәлекле, гыйбрәтле биографиягә ия кешеләрне күбрәк кертергә, авторларга өйрәнү объектын сайлау мөмкинлеге калдырырга иде. Минемчә, М.Галинең дә милләт тарихында алтын җепләр белән теркәлергә хакы бар.

**Рифә РАХМАН**

# СИРИН БАТЫРШИННЫҢ ТУУЫНА 120 ЕЛ

*Иң элек шундый сорау туа: бу әсәр каян табылды? Ни өчен шушы көнгә кадәр ул билгесез булды? Ни өчен матбугатта аның турында бер генә мәгълүмат та чыкмады?*

*Җавап шундый: Сириннең бу автобиографик повесть-истәлегенең каралама кәгазьләре аның туган авылы Кәрәкәшледә, шагыйрьнең бертуган энесе Мәхәсиннең улы Батыршин Рифгатьтә сакланган. Бүгенге көндә Рифгать абый шагыйрь Сирин туып-үскән нигездә яши. Шагыйрьне дә беркадәр хәтерли: Сириннең сөргеннән кайтып, колхоз умарталыгында эшләп йөргән вакытларында Рифгать абыйга җиде яшьләр чамасы булган. Аның әйтүе буенча, әгәр Сириннән аның тормышы турында сорашсаң, ул гадәттә: «Һи-и, минем күргәннәрем бер китапка да сыеп бетмәс», – ди торган булган. Әйе, шагыйрь башыннан ниләр генә узмаган да, ниләр генә кичермәгән ул! Һәм үзе дә, язучы буларак, кул кушырып кына утырмаган, ә башыннан үткәннәрне киләчәк буыннарга да калдыру хәстәрен күргән, аларны кәгазьгә дә төшергән икән. Бу язмалар Сириннең туган нигезендә сакланган. Берничә ел элек Рифгать абый аларны: «Менә, Сирин абыйның язмалары», – дип, миңа китереп бирде. Бу – саргаеп-таушалып, кайберләре ерткаланып, баш-башлары теткәләнеп беткән кәгазьләр җыелмасы иде. Аларда Сирин үзенең туганнан алып 1940 елда сөргеннән кайтканга кадәр башыннан үткән хәл-вакыйгалар турында сөйли. Әдип буларак, аларны әдәби тел белән, сәнгатьчә сурәтләү чаралары кулланып бәян итә. Шуңа күрә истәлекләрне бер дә икеләнмичә автобиографик повесть дип атарга мөмкин.*

*Шагыйрьнең тормыш юлындагы этаплардан чыгып, алар түбәндәге бүлекләргә бүленгән:*

*1. Балачак хатирәләре.*
*2. Дөнья матур ул, аны «аклар» гына ямьсезли...*
*3. Казанда яшәгәндә.*
*4. Сөргендә.*
*5. «Син сөйләмә әле, мин сөйлим!»*

*Шунысына игътибар итик: беренче һәм икенче бүлекләрнең берничә тексты бар. «Балачак хатирәләре» бүлеге безнең көннәргә машинкада басылган ике текстта килеп җиткән. Сирин аны бер генә түгел, ә ике тапкыр кемгәдер әйтеп торып бастырган булса кирәк, чөнки ике текст ике төрле машинкада басылган: шрифтлары аерыла. Беренче текст (ул 18 биттән тора) аеруча иске, саргаеп-таушалып һәм баш-башлары ерткаланып беткән кәгазьләргә язылган. Аларда соңыннан Сириннең үз кулы белән төзәткән урыннар да бар. Монысын төп текст итеп алырга кирәк. Ә икенче текст тулы түгел, барлыгы дүрт бит. Аның да кәгазьләре иске, әмма алар чагыштырмача яхшы сакланган. Бусы беренче текстны кабатлап, Сирин төзәткәнчә итеп язылган.*

*«Дөнья матур ул, аны «аклар» гына ямьсезли» бүлегенең безнең көннәргә хәтта биш тексты – кулъязмада (Сириннең үз кулы) өч һәм машинкада басылган ике данә тексты килеп җиткән. Без аларны үзара чагыштырып, берсендә булмаганны икенчесеннән алып өстәп, тулы текстын барлыкка китердек. Ә калган 3нче, 4нче һәм 5нче бүлекләр Сириннең үз кулы белән язылган бер генә данә текстта килеп җиткәннәр. Шулай итеп, укучыларга Сириннең «Тормыш хатирәләре» дигән автобиографик повесте тулы, беренче ике бүлекнең берничә текстын үзара чагыштырып эшләнгән вариантта тәкъдим ителә.*

*Әлеге истәлекләрнең эчтәлегенә килгәндә, ул безгә үзенең документальлеге, 1910-1940 елларда аерым кеше (бу очракта шагыйрь Сирин) кичергән вакыйгаларны ничек булган – шулай, фантазиягә бирелмичә, бизәмичә тасвирлап бирүе белән*

*кыйммәтле. Укучы күрер, анда моңа кадәр матбугатта яктыртылмаган шактый күп материал бар: 1917 елгы инкыйлабка кадәрге Бәйрәкә мәдрәсәсендәге тормыш, 1914 елгы Беренче Бөтендөнья сугышы чорында Бөгелмәдәге халык хәрәкәте, Бәйрәкә төбәгендә гражданнар сугышы вакыйгалары, 1920-1930 елларда Казанда иҗат әһелләрен репрессияләү күренешләре һ.б. Бу повесть-истәлекнең тагын бер яңалыгы – анда Сталин лагерьларындагы әсирләр тормышы, аларның кеше ышанмаслык газап чигүләре сурәтләнә. Бу яктан караганда, Сирин истәлекләре Ибраһим Салаховның «Колыма хикәяләре» әсәре белән аваздаш һәм анда тасвирланган тоткыннар тормышы күренешләрен дәвам да иттерә шикелле.*

*Тагын шунысы да бар: Сириннең бу автобиографик повесте белән бер үк вакытта диярлек минем кулга шагыйрьнең бары шигырьләрдән генә торган архивы да килеп керде. Мин, әлбәттә, иң башлап аның шигъри мирасын өйрәнергә тотындым, ә аның прозасы бераз читтәрәк калып торды.*

*Шагыйрьнең шигъри архивы нишләп һәм кайчан нәкъ минем кулга килеп керде соң? Аның тарихы болай. Озак авырудан соң Сирин Батыршин 1969 елның 23 ноябрендә якты дөнья белән хушлаша. Шул ук көнне Баулыда аны күмү комиссиясе төзелә. Аның составына район хакимияте вәкиле Абдулла Вәлиев, ВЛКСМ райкомы вәкиле Сирин Нәбиуллин һәм язучы Рафаэль Төхфәтуллиннар керә. Шагыйрьне җирләгәч, алар 25 ноябрь көнне Сириннең архивын, акт төзеп, кабул итеп алалар. Архивны комиссиягә шагыйрьнең хатыны Фәһимә Батыршина тапшыра. Бу архив (ике папка каралама кәгазьләр) Әлмәт язучылар оешмасына китерелә һәм озак еллар буе шунда саклана. Гәрчә Сирин Татарстан АССР Югары Суды Президиумының 1957 елның 13 июнь карары белән реабилитацияләнгән булса да, аңа әле һаман «репрессияләнгән шагыйрь», «халык дошманы» кебек кара исемнәр ябышып торгангамы (аның хәтта исемен дә әйтергә курыкканнар!), әллә башка сәбәплеме – аның бу архивы белән кызыксынучы кеше булмаган: ул шул көе ята биргән. 1968-1972 елларда Әлмәт язучылар оешмасының җитәкчесе булып Равил Фәйзуллин эшләде. Шул чакта Равил Фәйзуллин миңа (без аның белән Казан дәүләт университетында бергә, бер төркемдә укыдык) Сирин архивының Әлмәт язучылар оешмасында икәнлеге һәм аның белән беркемнең дә кызыксынмавы турында әйтте. Мин үз чиратымда аңа шагыйрь Сириннең минем авылдашым гына түгел, ә әтиемнең туганнан-туган абыйсы икәнлеген дә белдердем һәм аңардан ул архивны үземә бирүен үтендем. Шулай итеп, беркадәр вакыттан соң Сирин архивы минем карамакка күчте. Мин аны өйрәнә башладым. Шундый игелекле эше өчен мин Равил Фәйзуллинга әлегә кадәр чиксез рәхмәтлемен.*

*Нәрсәләр бар соң аның әлеге архивында? Комиссия төзеп алынган архивта барлыгы 16 пункт күрсәтелә. Шунысы хак: комиссия әгъзалары шагыйрьдән калган кәгазь-дәфтәрләрне системага салып тормаганнар, кулга ничек эләкте – шулай терки барганнар. 16 пунктның 4сендә берәр битле шигырьләр, 3сендә өч мәкалә, 9ында шигырь дәфтәрләре, җыентыклар, төрле каралама кәгазьләр теркәлгән. Алар өч төрле имлада – гарәп, латин һәм кириллицада язылганнар. Мин аларны өйрәнә башладым. Дөресен әйтергә кирәк, шагыйрь әсәрләрен тәртипкә салу, аларның хронологик тәртиптә исемлеген төзү, архивта булмаган, әмма 1920-1930 елларда төрле газета-журналларда дөнья күргән шигырьләрен табу-барлау эше озакка сузылды. Сириннең шигъри мирасын өйрәнгәннән соң гына миңа аның прозасын да текстологик яктан эшкәртә башларга мөмкинлек туды. Шулай итеп, Сириннең әлеге автобиографик повесте укучыларга бары тик шагыйрьнең тууына 120 ел тулган көннәрдә генә тәкъдим ителә. Халкыбыз әйтмешли, «Соң булса да, уң булсын!»*

**Әнвәр ШӘРИПОВ,**
*филология фәннәре докторы*



Сирин Батыршин

# ТОРМЫШ ХАТИРӘЛӘРЕ

## АВТОБИОГРАФИК БӘЯН-ИСТӘЛЕК

### 1. Балачак хатирәләре

Мин элекке Ютазы районы Кәрәкәшле авылында 1896 елның (искечә) 17 ноябрендә туганмын.* Әтием – Кәрәкәшле Гыйльман карт улы Мөхәммәдхәниф, әнием – Кызыл Яр авылы Калпак Зиякай кызы Хөсникамал («Кәмаләтнең күркәме»). Әниемнең әнисе Шәмсенаһар («Көндезге кояш») булган. Әниемнең ата-анасы балаларына матур исем куйсалар да, «кыз балага уку харамдыр», дип, Хөсникамалны иҗек укырга йөрүдән мәхрүм иткәннәр.

Әнием укырга бик теләгән. Ул мич алдыннан күмер алып, яшеренеп кенә тактага берничә хәреф язган... Шулай итеп, үзенең тырышлыгы аркасында ул «Бакырган», «Мөхәммәдия», «Кыйссасел әнбия» кебек китапларны укыр дәрәҗәгә ирешкән. Хөсникамал күп балалы Зиякай гаиләсендә өлкән кыз булганга, аны 16 яшькә чыгу белән, Кызыл Ярдан 40 чакрым ераклыкта булган Кәрәкәшле авылына Мөхәммәдхәнифкә кияүгә бирәләр. Мөхәммәдхәниф сабыр холыклы, бик аз сүзле, эшчән кеше була. Ә Хөсникамал уйнарга, көләргә яраткан, матур җырлаган. Әле дә хәтеремдә, һәрвакыт җырлап, көйләп йөри иде. Аның күңелдән җырлый торган җырлары, шигырьләре бик күп иде. Әтинең салкын табигатьле, аз сүзле булуына әни көяләнеп: «Тиз генә җавап бирми бит ул, аның сүзен тартып алырга кирәк», – ди торган иде. Әнием туган авылын сагына, моңлана һәм кайгысын җырлар белән баса торган иде. Шунлыктан әти аңарга «укып күңел юатырга» дип, «Мөхәммәдия», «Кыйссасел әнбия» китапларын алып биргән булган.

Безнең гаиләдә балалар бик күп иде: Камил, Зәки, Җәмил, Мәрхәбә, Сирин, Гамил, Шамил, Мәхәсин. Гамил белән Зәки мин бәләкәй чакта ук, ә калганнары соңгы сугышларда үлеп беттеләр.

Минем төп исемем – Мөхәммәдсәйрин. «Электә тәфсир язучы Сәйрин хәзрәт булган, шуның исемен кушыйк әле» дип, ахун хәзрәтләре куйды», – дип әйтә иде әти.

Хәтеремдә шулай калган: күршедәге Шиһап исемле картның берсе Мәхүп, икенчесе Бибекәй исемле ике кызы бар иде. Шул Мәхүп дигәне керде дә, мине юрганга төреп, авылның икенче башына күтәреп алып китте. Өй эче ярлы, сәкедә самовар тора иде. Минем янга бер бәләкәй кыз утырттылар. «Чәй эчәсеңме?» – диләр. Чәйгә сөт булса да, шикәр юк икән. Хатыннар ул көннең авырлыгы турында сөйләштеләр, ә мин хуҗа хатынның сул кулындагы ике бармак арасындагы, тавык йомыркасы шикелле олы шарга карадым да утырдым.

* Туу датасы язмада өч төрле бирелә. (*Ред.*)

## Патшаларга нәфрәт

Мине хәзер беркем дә күтәреп йөртми. Үзем сәкегә менеп-төшеп йөри алам, кеше сөйләгән сүзләрне аңлыйм, үзем дә сөйләшә башладым. Әти сәкедә утыра иде; шунда югары очтагы Хәйрулла карчыгы Шәмси килеп керде. Аның малае Гарифулла Япон сугышына киткән икән. Хат укытырга дип килгән. Әни шул хатны кычкырып укыды, хат ахырында «Япон сугышы бәете» дә бар иде. Бәетне укыганда, хатын чыдый алмады, кычкырып елап җибәрде. Әни дә елый башлады. Аларның сүзләрен тыңлаган кешегә еламый калырга мөмкин түгел иде. Шунда Гарифулла хатыны: «Бу патшалар нигә сугышалар микән?» – диде. Әткәй аңа: «Җир өчен сугышалар, аларга җир җитми», – дип җавап бирде. Бу сүзләрне ишеткәч, минем дә ачуым килде. «Аларга җир кирәк булгач, үзләре сугышсыннар, нигә бүтәннәрне үтертәләр?» – дидем мин. Әти миңа: «Закон эше, закон аларныкы», – диде. Минем законнарны, патшаларны бетерәсем килде.

## Яу килгән

Җәйге урак өсте. Эшкә яраклы кешеләр бары да кырга китеп беткәннәр. Минем әти-әниләр дә, абыйлар да уракка киткәннәр иде. Мин Мәрхәбә апа белән өйдә йоклап кала торган идем. Өй йозак белән бикле була, ә без тәрәзәдән генә чыгып йөри идек.

Бервакыт малайлар урамнан: «Яу килә! Яу килә!» – дип кычкырдылар. Без барыбыз да капка астыннан ишегалдына кереп бикләндек. Капка ярыгыннан гына солдатларның үткәнен карап торабыз. Солдатлар бары да атка атланганнар, кара кием кигәннәр, аркаларына мылтык асканнар. Без аларны кат-кат санадык, ничә санасак та, егерме бишкә чыгардык. Алар безнең авыл аркылы узып, Бәйрәкәгә таба киттеләр. Алар киткәч, без тагын урамга чыгып уйный башладык. Тик уенның кызыгы беткән иде инде. Бәйрәкә белән Кәрәкәшле арасында көчле атыш тавышлары яңгырап торды. Кичен әтиләр урактан кайтып, ашарга утыргач, олылар сүзеннән шуны аңладым: Япон сугышында йөргән бертуган Вахитовлар: «Нигә сугышабыз? Кем җирен саклыйбыз? Безнең җир дә, урман да, су да юк», – дигәннәр. Аларның башлыклары: «Урман, җир, су үзегезнеке, саклагыз, үзегезгә кирәксә, файдаланыгыз», – дигәннәр. Вахитовларның кулында шулай дип язылган печатьле кәгазь дә булган икән. Менә шул кәгазь буенча бәйрәкәлеләр Жданов боярның урманын кисә башлаганнар. Бояр патшадан солдат сораган. Шул солдатлар Вахитовларны атканнар ди. Бөгелмәгә, Соколка күперенә барып кергәч тә, сул яктагы түбәсе пыяла белән ябылган кызыл кирпеч йортлар бары да шул Жданов боярныкы икән.

«Александр патша заманында солдат хезмәте 25 ел иде. Аннан соң 5 елга калдырылды. 5 елга калгач, беренче приёмга Кәрәкәшледән Сәхип белән мин бардым», – дип сөйләде әти.

## Укырга баруның беренче көне

Кышның кыска көннәре бәләкәй чана белән утын ташып үтә иде. Безнең салкында кияргә җылы киемнәребез юк. Аякта оек, чабата, башта мескен бүрек иде. Шунлыктан без бик тиз чирлибез. Авылда врач юк. Һәрбер чирне «кизү» дип кенә йөртәләр. Әле күптән түгел бер абыем, бер энем үлде. Өеңдә бер кеше үлсә, бик кыен була икән ул.

Мәрхәбә апа абыстайга укырга йөри башлаган. Беркөнне иртә белән мине

дә, букчалар кигезеп, бер тустаган он тоттырып, үзе белән бергә абыстайга алып барды. Без абыстайга барып кергәндә, кызлар шау-гөж килеп укып утыралар, абыстайга сабак тыңлаталар иде. Үзебезгә чират җиткәч, без дә абыстайга ике тустаган онны бирдек. Абыстай дога кылды. Кулы белән минем аркамнан сыйпап: «Укырга килдеңмени?» – диде. Мин нигә килгәнемне белмәгәнгә, нәрсә әйтергә белмәдем. Ул минем букчамдагы «Ясин» китабын алып, бисмилла әйтеп, «Әлхәмде» сүзен иҗекләргә тотынды. Мин бу сүзләрдән бернәрсә дә аңламадым.

Өйдә асмалы бишле лампа янып тора. Ишек янында лакан, аның янында бер бозау муенчак белән бәйләп куелган. Ишек өстендә кадакка элеп ике чыбык куелган. Әгәр кызлар сөйләшеп утыра башласалар, абыстай кулындагы чыбыгын гына күрсәтә, йә сәке тактасына бәреп куя. Кызлар бу хәлдән куркып, җилкенеп «фиасин фи, ләм-әлифлә» дип кычкырып куялар иде. Шулай бу абыстайның бик кыен иҗекне белүе мине бик гаҗәпләндерде. Өйгә кайткач, мин моннан соң укырга бармаячагымны, барсам да бернәрсә дә аңламавымны әтиләргә сөйләп бирдем. Әтиләр минем сүзләремә каршы килмәделәр.

Апам иҗек укырга йөрде, мин йөрмәдем.

***

Тагын кыш җитте. Ап-ак кар яуды. Мин чана шуып уйнарга бик ярата идем. Көн буена уйнап туя алмыйм. Безнең өйгә якын гына бер таш мәктәп бар иде. Мин бик күңеллеләнеп уйнап йөргәндә, Камил абый килеп, кулымнан тотты да: «Әйдә, укырга барабыз!» – дип, мине шул мәктәпкә таба алып китте. Минем бер дә барасым килми. Шулай да әкрен генә абый артыннан барырга мәҗбүр булдым.

Мәктәпнең ишеген ачкач та, бөркелеп, болыт кебек авыр исле пар чыкты. Мондый начар исне беркайда да иснәгәнем юк иде. Мәктәп эченә бер дә керәсем килмәсә дә, абый артыннан аякларымны көчләп, алга таба атладым. Ишектән кергәч тә, ике якта ике зур мич, һәм мич янында бер багана, шул баганаларга кадаклар кагып, чабаталар, хәшәпләр элеп куйганнар. Түрдәрәк эскәмияләр куеп, шул эскәмияләр астына балалар кереп утырган. Мин бу мәктәпне беренче күрүдә сарык бәрәннәре ябылган бер абзарга охшаттым.

Гали Гайсин дигән кеше бу мәктәпнең хәлфәсе икән. Ачык йөзле, ягымлы кеше. Камил абый аның белән минем турыда нәрсәдер сөйләште булырга кирәк, мин аларның сүзен тыңламадым. Минем күзем малайларга, малайларның күзе миңа караган иде. Чабатамны чишендем дә багана төбенә илтеп бәйләдем. Иң астагы чабата минеке була дип хәтергә салып куйдым. Шуннан соң мине Гали хәлфә тыйнаграк малайлар арасына илтеп утыртты. Язар өчен дип бер бит кәгазь, бәләкәй генә карандаш каләм бирде. Бу вакытта Камил абый ачылыкта (аяк киемнәре куя торган урын) басып тора иде әле, мине ташлап китмәсә ярар иде дип, аңардан күземне алмадым.

Бервакыт мин төрле исәпләрем белән Камил абыйның чыгып киткәнен сизми дә калганмын. Монда бар да чит кеше, миңа бик күңелсез булып калды. Башымда: «Мине малайлар кыйнамас микән? Тагын өйгә кайта алырмын микән?» – дигән уйлар кайный башлады. Минем бик рәхәтләнеп елыйсым килә, еласам, малайлар мыскыл итеп көләрләр кебек тоела. Ни теләсәм, шулай кыланып ирекле чана шуып йөргән чакларым искә төшә, күз яшьләрем тыгылалар да, инде чыгып агам дигәндә генә, мин аларны көчкә тыеп калам. Беркемгә белдерми, ишеттерми генә күңелемнән: «Нинди бәхетле, ирекле чакларым бар иде!» – дип, шуларны сагынам, әти-әниләрне сагынам.

Безнең каршыдагы стенага зур калай кадаклап куйганнар. Гали хәлфә кулына акбур һәм бер китап тотып, безнең каршыга килеп басты. Мин, теге абыстай сыман аңлашылмый торган нәрсә сөйләр микән, дип торганда, эш болай булып чыкмады. Хәлфә калайга аерым хәрефне язып күрсәтә дә, үзе шуның тавышын әйтә, бездән дә әйттерә, яздыра. Хәлфәнең кулы һәр хәрефне ничек язганын һәм теле белән ничек әйткәнен карап һәм тыңлап торам да ул язганча язып куям. Бу хәлфә безне ачуланмый да, кыйнамый да, кулында чыбыгы да күренми. Дәрес бик күңелле булды, вакытның ничек үткәнен сизми дә калдым. Шуннан соң мин дәрескә, вакыты җиткәч, үзем барам, үзем кайтам. Буш арада уйнарга да җитешәм, әти-әниләрнең кушкан эшләрен дә эшлим. Мин бу хәлфәне бик яраттым. Ул мине ике ай эчендә бик яхшы укырга, язарга өйрәтте.

## Акчалылар аш ашый, акчасызлар ач яши

Борынгы Бәйрәкә мәдрәсәсе бер катлы дүрт таш йорттан гыйбарәт. Һәр йортның ничек торуына карап, «Аркылы таш», «Иске таш», «Яңа таш» дип исем бирелгән. Шәкертләр шул йортларда ашыйлар да, укыйлар да, йоклыйлар да. Мәдрәсә эчендә аерым бүлмәләр юк, бүлмә урынына аерым тәрәзәләр бар[1]. Һәр тәрәзәгә 7-8 кеше урнаша, шулар арасыннан берсе башлык итеп куела.

Менә, зиратка караган беренче тәрәзә, монда кәрәкәшлеләр 8-9 кеше. Шулар арасында 1907 елда крестьян кузгалышы вакытында этисе үтерелгән Салих Вахитов та бар. Менә акбашлылар тәрәзәсе. Монда бары да – акбашлылар. Шулар белән бергә 1918 елда балалар өчен «Җырлы уеннар» китабын язган һәм «Качкыннар» драмасын язып, Г.Ибраһимовка тапшырган Сәхәү Миңлекәй дә бар. Ләкин бу әсәрнең басылып чыкканы күренмәде. 3нче тәрәзәдә Чупай авылы Мөҗәһит Г. тора. Палач булырга бик сәләтле кеше, шул эшне бик яратып үти. 4нче тәрәзәдә үзенең энеләре белән Мөсәгыйть Ганбәров тора. Революциягә кадәр «Сәгыйдә ханым» дигән роман язган кеше. Революциядән соң укытучы булып эшләде. 1921 елда сәнәкчеләр тарафыннан ерткычларча үтерелде. Башка тәрәзәләрдә дә төрле авыллардан килгән яшьләр тулып яталар. Бары да белем алырга, укырга дип килгәннәр. Ләкин монда ашау-туену ягы да, белем алуы да бик кыен нәрсә. Аш күмәк пешерелә, акчасы булган кеше ашый, булмаганнар – ашсыз, ач яши. Без Салих Вахитов белән бер тәрәзәдә торабыз, бергә укыйбыз, бергә йоклыйбыз. Салих мине кайчакларда үзенә, мунчага алып кайта. Алар бик фәкыйрь яшиләр. Өйләре кыйгаеп ава язган. Бу өйне күргәч, Салихның этисенең шушы өйне рәтләргә йөргәнлеге, шуңарга урман кисәргә барулары күз алдына килеп баса. Салихның әнисе тәбикмәк пешереп, чәй янына утыртып: «Гаепләмә инде, шәкерт, безнең сыерыбыз юк, шуңа майларга маем булмады», – дип, үзен гаепле санаган кебек әйтеп куйды.

## Шәкерт намазы

Иске мәдрәсәнең үзенең тәртибе бар: анда укыган һәрбер шәкерт шул тәртипне һәрвакыт хәтерендә сакларга тиеш. Әгәр ул шуны хәтереннән чыгарса, үзе дә сизми кала, бик тиз җәзага эләгә. Тәртип буенча, бер вакытта йокларга, бер вакытта ашарга, һәр намазны бергәләп укырга, зуррак класста укучылар икенде белән ахшам намазын мәчеткә барып укырга тиешләр. Аларның кайтуына яшьләр утларны яндырып, чәйне өстәлгә хәзерләп куярга тиеш. Ашханәдән чәй

[1] Бүлекнең икенче тексты шушында тәмам.

алып керү эшләре һәр тәрәзәдә чират белән эшләнә. Шулай бер вакытны ахшам чәен алып керү миңа туры килде. Мин, чәйнекне алып, ашханәгә чыктым. Анда су кайнамаган, малайлар җыйналып көтеп торалар иде. Мин дә бик озак көтеп тордым. Су кайнап чыккач та, бик ансат кына алып булмый әле. Көчлеләр сугышып алдан алалар, көчсезләр артка калалар иде. Мин, әдәп саклап, иң соңга калдым. Икенде, ахшам намазым да укымаган, берәрсе казыйга язып биргән булса, казый чакыртса, нишләрмен инде? «Чәй алып кердем» дип кенә котылып булырмы, юкмы – белеп булмый. Шулай уйлана-уйлана чәй алып кергәндә, хәлфәләр, зур шәкертләр бары да өстәл янында чәй эчеп утыралар иде. Мин чәйнек күтәреп ишектән керү белән, барысының да күзе миңа ташланды. Ашыгыч рәвештә чәйнекне үзебезнең урынга, өстәлгә илтеп куйдым да иптәшләргә: «Сез эчә торыгыз. Мин хәзер намаз укып кына киләм», – дидем дә, урталыкка, намаз укый торган урынга барып, чәй эчүче шәкертләргә артым белән торып, намаз укый башладым. Үзем намазлык өстендә, күңелем әллә кайларда: «Мине малайлар намаз укымады дип язып биргәннәрдер. Хәзер мине казый чакыртыр да: «Нигә бергәләп укымадың?» – дип әйтер. Мин аңа: «Чәйгә чыккан идем, тиз генә керә алмадым», – дип әйтермен. Шуның белән эш бетәр, дип уйланып, машина тизлегендә хәрәкәтләр ясап, намазны бик тиз генә укып бетердем дә, киемне шкафка элеп, инде чәй эчим дип иптәшләр янына барганда, казый: «Батыршин, монда кил әле!» – дип кычкырды. Мин борылып карадым да, бармый булмый инде дип уйлап, казый алдына барып, шәрә идәнгә тезләндем. «Нигә син намазны ялгыз укыдың?» – дип әйтер, дип уйлаган идем, ул миңа: «Син нәрсә эшләдең?» – ди. Мин аңа: «Намаз укыдым», – дидем. «Намазны шулай укыйлармыни? Нигә син намазны мыскыл итәсең?» – диде дә, бер кулы белән сандык өстендәге тал чыбыкка үрелеп: «Башкаларга да сабак булсын бу. Ят!» – дип кычкырды. Мин ихтыярсыз ятарга мәҗбүр булдым. Бу вакытта шәкертләрнең барсының да күзе миңа караган иде. Казый минем аркага бик каты итеп ике мәртәбә сукты да, бик зур эш башкарган кешедәй булып, өстәл янына чәй эчәргә утырды.

Минем өстемдә бер кат күлмәк, җиңсез юка камзулдан башка бернәрсә дә юк иде. Ике мәртәбә сугуга, аңгыраланып калдым, ахры, бернәрсә дә белми, аңламый тордым. Казый: «Тор!» – дип әйткәч кенә тордым да елап җибәрдем. Шуннан соң казый: «Бар, намазыңны яңадан укы!» – диде. Елый-елый торып киттем дә, идәнгә җиләнне җәеп, намаз укырга тотындым. Ашау вакытларында сөйләшеп, шаулап утырырга рөхсәт ителмәгәнгә, 70ләп кеше чәй эчкәндә, бер кеше дә юк шикелле, бер тавыш та ишетелми. Ара-тирә теш белән шикәр ваткан, чынаяк куйган тавышлар гына ишетелә. Мин үзем намазлык өстендә, күңелем һаман да әллә кайларда...

Мин хәзер намазны бик әкрен укыйм. Кайбер шәкертләр моны күзәтеп, бик көләселәре килеп торалар икән. Менә берсе түзә алмады, пырхылдап көлеп җибәрде. Аңа ияреп башкалар да көлде. «Болар минем бик әкрен укудан көләләр», дидем дә, намазны ашыктыра төшеп укып бетергәч, киемнәр шкафы артына кереп, кулым белән аркамдагы чыбык эзләрен тотып, бик озак еладым.

***

«Укыр өчен акча эшләргә кирәк, аннан соң шул акча белән укырга кирәк», – ди торган иде Җәмил абый. Ул шуның өчен акча эшләргә дип Казанга китте. Инде елдан артык вакыт узды, бер хаты да килми. Аның өчен әти, әни дә, мин дә бик кайгырабыз. Менә беркөн әткәйләргә хат килгән. Абый

үзенең исән булуын, «Гасыр» идарәсендә экспедитор булып эшләвен, Кабан күле буенда дүрт почмаклы ике катлы кечкенә бер өйдә Исләев һәм Оренбург Каргалысының Мәхмүт Рафиков дигән студент белән бер квартирда торуын, өс-башын да рәтләвен, ашау-эчүгә дә ач булмавын язган. Бу хатны алгач, әти-әниләр дә, мин дә бик сөендек. Шуның өстенә тагын кайгылы хәбәр булса да язый инде дип язган: «Халык шагыйре Тукай үлде бит. Бу барыбыз өчен дә бик зур кайгылы көн булды», – дигән. «Мин сезгә Тукай, Ф.Әмирхан, Г.Камал рәсемнәрен һәм Тукай турында язылган «Аң» журналын җибәрдем. Сирин укып аңлатыр», – дигән. «1914 ел кайтырмын дип йөрим. Кайтканда, Сирин, сиңа мандолина алып кайтам», – дигән.

Бу хат безнең өчен абыйның исәнлеген белдерү ягыннан зур шатлык, Тукайның үлеме ягыннан зур кайгы китерде. Тукай шигырьләрен, «Аң» журналын кат-кат укыдым. «Кайтканда мин сиңа мандолина алып кайтам» дигән сүзне генә аңлап булмады. Нәрсә икән ул мандолина? Бәйрәкәдәге хәлфәләрдән дә сорап карадым. Алар «Әхтәри»дән дә карап белә алмадылар, «Берәр ашый торган җимештер», – диләр. Шуннан соң мин Җәмил абыйга: «Син миңа мандолина алып кайтам», дип хат язгансың. Нәрсә ул мандолина? Бәйрәкәдәге хәлфәләрдән сорап караган идем, алар «Әхтәри»дән карап белә алмадылар. «Берәр ашый торган ят җимештер», диделәр. Син миңа аңлатыбрак яз әле: кия торган нәрсәме ул, ашый торган нәрсәме?» – дип яздым. Җәмил абый шул хатны иптәшләре алдында укыган икән, бар да кычкырып көлгәннәр. «Ашый торган да, кия торган да түгел, уйный торган нәрсә», – дип язган абый.

Шуннан соңгы бер хатында: «1914 елның язында мин кайтам. Кайтканда сине укытырга бер укытучы студент – Мәхмүт Рафиковны һәм кирәкле китапларны алып кайтам. Без сине бер язучы ясап булмасмы, дип уйлыйбыз», – дигән.

## Киләчәк – якын, үткән – ерак

Мин язгы сабан, тырма эшләрендә йөрим. Язның узып барганын сизми дә калганмын. Менә бервакыт Җәмил һәм Мәхмүт Рафиков абыйлар Бөгелмәгә кайтканнар да өч кешелек квартир алганнар. Аннан Кәрәкәшлегә кайттылар. Аларның кайтуы безнең өчен бик зур бәйрәм булды. Миңа кирәкле китапларны һәм теге без белмәгән мандолинаны алып кайтканнар. Алар кайткач, мин вакытны бушка уздырмыйм дип, тизрәк укырга тотындым. Мәхмүт Рафиков бик яхшы укыта. Их, мин әйтәм, шундый зур белемле кеше белән һәрвакыт бергә торсаң, бергә яшәсәң иде, дим. Ул сине һәрвакыт өйрәтә, һәрбер юк-барга ышанулардан көлә. Кайсы көнне бергәләп кырга эшкә барабыз. Алар белән эшләү дә күңелле, ялыктырмый. Шунлыктан минем алардан һич аерыласым килми иде. Кәрәкәшледә унбиш көн чамасы торгач, без тагын Бөгелмәгә барып, хәзерләп куйган бүлмәгә урнаштык. Авылдан китеп, анда барып торуның сәбәбе нәрсә булгандыр, мин анысын аңламадым. Мәхмүт Рафиков минем белән уку эшләрен бетергәч, миңа эш бирә дә, үзләре шәһәргә чыгып китәләр иде. Менә беркөнне аларга ияреп, безгә бер кеше килде. Мин ул вакытта бүлмәдә укып утыра идем. Алар өстәл янында бераз утыргач та: «Анда бүлмә эчендә кем бар?» – дип сорады ул кеше. Абый аңа: «Ул минем укырга килгән энем», – диде дә, үзе минем янга кереп: «Әнә, ул килгән кеше Камил Якуб була. Син чыгып аның белән күреш, ул бик әйбәт кеше», – диде. Мин бүлмәдән чыктым да Камил Якуб белән күрештем. Ул зур кеше, мин бәләкәй кеше булгач,

өс-башым да начар булудан оялып, ни әйтергә белми, кире бүлмәгә кереп укырга башладым. Камил Якуб Казаннан кайткан китапларның әле берсен, әле икенчесен карап утыра. Алар шунда бик озак сөйләшеп утырдылар, мин аларның сүзләрен тыңламадым. Алар Бөгелмәдә спектакль куярга «Ачлык кушты»ны хәзерләп йөргәннәр иде. Бөгелмә нотариусы рөхсәт бирмәгән, китапны русчага тәрҗемә итеп китерергә кушкан. Тәрҗемә итеп барганнар иде: «Укып торырга вакытым юк», – дип кире кайтарды. Шуннан соң Казаннан Уфага кайтышлый Фәттах Латыйпов, Бөгелмәдә тукталып, русча-татарча концерт бирде. 1914 елдагы бу концерт Бөгелмәдә, бәлки, беренче концерт булгандыр. Бу минем дә беренче концерт тыңлавым булды.

Җәмил абый да, Мәхмүт Рафиков та бик күңелле кешеләр, уйнап, көлеп сөйләшергә яраталар. Алар белән булганда, кайгырып торырга мөмкин түгел: көлке сүзләр әйтеп, алар синең кайгыңны бик тиз бетерәләр. Шунлыктан аларның сүзен һәрвакыт тыңлыйсы килеп кенә тора. Менә бервакыт Җәмил абый: «Бөгелмәдәге Шакир бай үзе ак кәгазьгә фамилиясен куярга белмәсә дә, безнең тирәдә аны белмәгән кеше юктыр. Бөгелмә бакчасы янындагы зур йорт, базар каршындагы өчәр катлы зур йортлар, квартал буена сузылган тимер баганалы магазиннар – барысы да аныкы. Шуның өстәвенә Бөгелмәдә хөкүмәт гаскәрен дә туйдыра. Менә шуның әтисе Хәкимов, үлем түшәгенә яткач, Уфада: «Дүрт малаем бар, берсе – Уфада, берсе – Оренбургта, болары бик байлар. Берсе – Казанда, анысы да бик бай дип әйтергә була. Менә берсе Бөгелмәдә, иң төпчегем, менә шунысы ярлырак. Шул ничек яшәр инде?» – дип кайгыра икән, ди.

Мәхмүт Рафиков та, мин дә көлеп җибәрдек. Менә ул, ди, нинди авыр хәлгә төшкән, аны кызганырга кирәк. Кеше хәлен кеше белми, үз башына төшмәсә, ди. Мондый хәл башыңа төшсә, яман булмас иде, дип, үзе дә көлеп җибәрде.

Шуннан соң, Мәхмүтне дә, Сиринне дә Оренбургка җибәрү өчен акча мәсьәләсенә күчеп: «Без менә шул Оренбургка барырга юллык акчага да аптырап утырабыз. Халык җырлап әйткән:

Бер еламый, бер җырламый
Эчкәйләрем бушамый.
Һәркемдә дә бар ул кайгы,
Кайгы кайгыга охшамый.

Хәкимов белән безнең кайгы бер дә охшашмый шул. Бу турыда Камил Якубта утырганда, И.Даишев: «Шакир байга мөрәҗәгать итеп карагыз әле. Кәефе килгәндә, аның фәкыйрь укучыларга ярдәм иткәләгәне бар иде, дигән иде. Без үзебез барып сөйләшүгә караганда, Сирин үзе барып сөйләшү яхшырак булыр, дип уйладык без», – диде.

Мин бу сүзләрдән бик уңайсызланып калдым. Мәхмүт Рафиков та, нәрсәгәдер уңайсызланып, урыныннан торып, бер читкәрәк китте.

Минем Шакир байга барырга күңелем тартмый. Барсам да файдасы булмас кебек тоела. Күңел тартмаса да, абыйларның сүзен тыңламый булмый инде. Мин шулай бик озак уйланып йөрдем дә, берсөнне, якшәмбе көн иде, ни булса да булыр, бармасам, абый ачуланыр дип уйлап, Шакир байга киттем. Шуннан башка көнне аны очратырга да мөмкин түгел икән.

Иртән сәгать сигезләрдә, бакча янындагы йорты капкасына килеп, капка ярыгыннан бик озак карап тордым. Капка тимер чылбыр белән бәйләнгән.

Тартсаң, әз генә ачыла. Шакир байның хезмәтчесе ишегалды себерә. Аның янында кызыл борынлы кыска юан кеше (Шакир бай үзе булырга кирәк) хезмәтчесен ачулана: «Миндә Андрей казнасы бар дип беләсеңме? Миңа да бит беркаян акча агып тормый», – ди. Бераз эчкән булырга кирәк, борын очлары бик кызарган. Бәхетсезгә – вакытсыз дигәндәй, мин үземнең бик уңайсыз вакытка туры килгәнемне аңладым. Үз-үземә: «Керергәме? Кермәскәме?» – дим. Кермәсәм, көн дә көн уза. Яңадан аны тагын бер атнасыз күреп булмаячак. Ни булса да булыр, Аллага тапшырам, дидем дә керергә булдым. Капка чылбыры астыннан гына кердем дә, кергәч, якын барырга куркып, капка янында гына басып тордым. Шакир бай хезмәтчесе белән һаман талаша иде. Бервакыт Шакир байның миңа күзе төште дә: «Сиңа нәрсә кирәк тагы?» – дип миңа кычкырды. Мин аның бу сүзеннән курыкмаска тырышып, аңа якынрак бардым да: «Шакир абый, мин Оренбургка мәдрәсәгә – «Хөсәения»гә укырга барырга хәзерләнгән идем. Барырга юлга акчам юк. Шунда бару өчен миңа юллык акча белән ярдәм итә алмассызмы?» – дидем. Шакир бай бу сүзләрне бик тиз аңлап алды: «Миндә Андрей казнасы бар дип беләсеңмени? Акчаң булмагач, нигә укырга йөрисең? Сине беркем дә көчләми торгандыр бит. Бар, чыгып кит моннан!» – дигәч, мин нәрсә әйтергә дә белми, «ни әйтсәм дә файдасы булмас», дип уйлап, әкрен-әкрен генә артым белән капкага таба чигендем.

Мондый күңелсез хәбәр алып кайту бик уңайсыз иде. Ныграк булырга тырышып, күз яшьләремне киптереп, кайтып ишектән кергәч тә, абыйның «Нәрсә булды?» дип соравы булды, минем күз яшьләрем тыгылып, сүземне сөйли алмас булдым. Буам ерылды. Минем мондый хәлдә кайтуым Җәмил абыйны да, Мәхмүт абыйны да бик күңелсезләндерде.

## 1914 елда Бөгелмәдә забастовка

1914 ел җилле, давыллы, икмәкнең уңышы начар ел булды. Шул сәбәпле халыкның күңеле төшенке. Менә авылларда кызу урак өсте; эшкә яраклы һәр кеше эштә. Шул хәлдә еллар тыныч булганда, һәркем үзенә эшләргә тырышыр иде. Әле көтмәгәндә «Германия Русиягә каршы сугыш башлаган» дигән хәбәр таралды. Бу куркыныч хәбәр халыкка яшен кебек тәэсир итте. Эш вакытында, беркем дә өйдә булмаганга, сугышка китәргә тиешле кешеләрне ат менеп кырлардан куып йөрделәр. Бөгелмә урамнары авылдан килгән солдатлар белән тулган. Кайберләренең балалары, хатыннары елый-елый әтиләре артыннан ияреп йөриләр. Безнең Камил, Кәрип абзыйлар да сугышка китәргә килгәннәр.

Беркөнне иртә белән Мәхмүт һәм Җәмил абыйлар чәй эчтеләр дә каядыр чыгып киттеләр. Мин аларның кая киткәнен белмәдем. Көндезге сәгать икеләр җиткәндә, рус хатыннары: «Бөгелмәдә забастовка булган икән. Военкомат начальнигын сүз сөйләгәндә таш белән бәреп төшергәннәр. Мылтыклы полицияләрне дә атларыннан бәреп төшергәннәр. Урамда бер полиция дә калмаган, бары да башларын бәйләп качканнар», – дип сөйлиләр.

Мин үз күзем белән күрү өчен урамга чыгып киттем. Урамда төркем-төркем кешеләр сөйләшеп торалар. Аларның сүзен тыңласаң, солдатлар: «Без сугышка бармыйбыз. Әгәр сезгә сугыш кирәк булса, үзегез барыгыз!» – дип әйткәннәр, дип сөйлиләр. Полиция ак йортка кереп бикләнгән, һәрберсенең башы ак марля белән бәйләнгән. Мин бу хәлләрне күрдем дә, «барысы да дөрес икән, абыйлар исән кайтсалар ярар иде», дип, абыйларны көтә башладым.

Күп тә үтмәде, абыйлар кайтып керде: «Полицияләр ата башлагач, Камил

Якуб каршыдагы бәрәңге арасына качты», – диләр дә көләләр. «Урамга җәяргә дип хәзерләп куйган таш бик яхшы булды», – дип, бии-бии «Марсельеза» җырлыйлар. «Марсельеза»ның нинди көй булуын Мәхмүт абый сөйләп аңлатты: «Бу көйне халык алдында җырларга ярамый», – диде. Мин бу көйне аңардан өйрәнеп калдым:

Ташлыйк, туганнар, иске тормышны,
Ул тормыштан безгә файда юк.
Булса, байлар илә тик түрәләр,
Аркабызда рәхәт күрәләр.
Нигә соң без болай тик ятабыз?
Нигә соң бер казык какмыйбыз?
Патшасын, Алласын һәм түрәсен
Шул казыкка бәйләп атмыйбыз?!

Мин бу җырны гомер буе җырлап йөрдем. «Бу җырны татарчага кем тәрҗемә иткән?» дигәч, «Анысы билгеле түгел», дип җавап бирделәр.

Безнең ишегалдында бер стражник тора иде. Ул, башын ак белән бәйләп, бүрәнәләр өстенә чыгып утырган. Абыйлар шуның янына чыкканнар да сөйләшеп утыралар. Мин моңарга бик борчылдым. Кич белән өйгә кергәч: «Сез нигә полиция белән сөйләшеп утырасыз? Ул сезне сизеп алыр да төрмәгә ябар», – дигәч, «Без үзебез аның белән ничек сөйләшергә беләбез. Син кайгырма», – диделәр. Мин шуның белән тынычландым.

## Озату

Бу вакытларда августның унбишләре җиткән иде инде. Мәхмүт Рафиковның да, минем дә Оренбургка китәр вакыт җитеп килә. Абыйлар, юл мәсьәләсен аз акча белән хәл итә алу өчен, поездга Бөгелмәдән утырмаска, бәлки Кәрәкәшледән 120 чакрым ат белән Абдуллинога барып, поездга Абдуллинодан утырырга план корганнар. Без шушы план буенча Кәрәкәшлегә кайттык. Аннан Кызыл Яр, Исергәп, Шалты, Чаганлы авыллары аркылы Абдуллинога барып, тимер юл вокзалы янына туктадык.

Мәхмүт абый станциягә керде дә, бик тиз чыгып: «Монда поезд хәзер Оренбургка китәргә тора икән. Билетлар сатылып беткән. Мин шунда Оренбургтан килгән бер кешене күреп сөйләштем. Ул әйтә: «Хәзергә «Мәдрәсәи Хөсәения»дә укулар юк. Ул хәзер, сугыш сәбәпле, солдатлар казармасына әйләнде. Кайчан бушатылуы билгеле түгел әле», – диде. «Шул сәбәпле сез хәзер кайтып торасыз инде. Яңадан мәдрәсә ачылса, мин сезгә хат белән хәбәр итәрмен», – диде дә, машинага соңга калмыйм дип, безнең белән күрешеп, станциягә кереп китте. Мин станция артында атны саклап, абыйның кайтканын көтеп калдым. Мәхмүт абыйдан бер дә аерыласым килми иде, аңардан аерылу бик кыен булды.

***

Без 1916 елны, бер казык та калмый, янып беткән идек. Түбәсе янган таш өйнең кысасын рәтләп, түбәсен ябып, биш-алты кеше шунда кышлап чыктык.

«Йорт салу нәрсә ул, мүклисе дә чутлыйсы», дип халык бушка гына әйтмәгән. Ул бик кыен эш булып чыкты. Камил абый бездән башка яши; Җәмил абый, 1914 елгы сугыштан яраланып кайтканнан соң, бер кулы эшкә ярамагач, Жмакинда ачылган кортчылык-бакчачылык курсларында укып, Бөгелмә янында ирләр монастырендагы совхоз умарталыгында кортчы булып

эшләде. Аннан соң Бөгелмә җир бүлегенә агроном-инструктор итеп куйдылар. Бер энем Фазыл Кызыл Армиягә алынды. Без хәзер өйдә әти, әни, Шамил, Мәхәсин һәм мин – биш кенә кеше калдык.

1917 елда гражданнар сугышы башлангач, авылда власть бик еш алмашынып торды. Менә чехлар килә, тагын кызыллар килә, тагын Колчак килә, тагын кызыллар килә. Сугыш вакытында авыл ике арада кала, ике яклап та авылны керендерәләр генә. Бары да авылны талап китәләр, ашарга сорыйлар. Бигрәк тә Колчак солдатлары, аклар – ару кием кигән кеше очраса, аның киемен салдырып алалар, бирмәсә, ату белән куркыталар; мичкә салган икмәгең булса, мичтәге икмәгеңне алып китәләр иде. Шунда безнең сыер абзарына снаряд төшеп, сыерны үтерде. Бу хәл безнең тормышны тагын да кыенлаштырды.

1920-1921 еллар ачлык еллар булды. Ачлык еллар моңа кадәр дә булган ул, ләкин безнең халыкның мондый кеше ашый торган ачлыкны күргәне юк иде әле. Бу ачлык шундый ачлык: язгы кар эреп беткәннән алып җәй буена җиргә бер тамчы яңгыр төшмәде. Чәчкән ашлыклар бары да, баш чыгара алмый саргаеп, көеп беткәннәр. Тауларда, су буйларында яшел үләнне күреп булмый. Җирнең өсте ягып кыздырган мич төбе кебек, яланаяк туфракка басып булмый. Кайбер егетләр, кызлар, чиләкләр алып, салкын су белән бер-берсен коендырып йөрсәләр дә, яңгыр яудыра алмыйлар. Күктә бер генә бөртек тә яңгыр болыты күренми; әгәр күренә икән, син аны куертып, зурайтып, күңелең белән матур яңгыр яудыра башлаганчы, ул болыт таралып юк була. Халык кычыткан, балтырган, бәрәңге сабаклары, чөгендер яфраклары, алабута кебек чүп-чар үләннәр ашый. Дөрес ашау булмау аркасында, ачлык чире – көзән җыеру – дигән бер чир чыкты. Моның белән кеше бер-ике сәгать чирли дә, кайнар табага салып куйган кебек, бик тиз куырылып үлә. Менә хәзер минем дә әни шушы чир белән чирләп ята. Врачлар юк, авыруга бертөрле дә ярдәм күрсәтеп булмый. Шуның өчен бу көннәр минем өчен иң авыр вакытлар булды.

Мин бүген кырга барып алабута чабып кайттым. Шуны киптереп сугып, алабута икмәге хәзерләмәкче булып маташам, башка кешеләр дә шул эштә. Менә тагын кич булды, өйдә керосин лампасы бик кайгылы гына янып утыра. Камил абый белән әти чирле әни янында ут тотып утыралар. Мин, арып эштән кайткан кеше, ишегалдына арбага чыгып, әнинең кайгысын кочаклап, йокларга яттым. Бик тиз йокыга киткәнмен. Төшемдә мин Бөгелмәдә курсларда укыйм икән. Мин авылга, өйгә кайтканмын. Безгә бергә укучы кызлар килгәннәр, укытучы Бастамов та килгән. Әни шул кунакларга чәй, аш хәзерләп йөри. Мин, кулыма мандолина тотканмын да, бер шатлыклы көй уйныйм. Мандолинаны туктатып, сүзгә күчеп: «Менә нинди зур шатлык! – дим. – Безнең әни чирли иде, менә шуңа без бик кайгыра идек. Менә хәзер безнең әни терелгән. Нинди зур шатлык!» – дип ятканда, Камил абый килеп: «Сирин! Сирин, тор! Әни үлә!» – диде.

Мин уянып киттем дә, «Аһ, бу шатлыклар бар да төш кенә икән!» дип, кайгыга баттым. Мин өйгә кергәндә, әнинең җан биргән чагы иде. Күзләремнән яшьләрем ага башлады...

## 2. Дөнья матур ул, аны «аклар» гына ямьсезли...

1919 елның февраль ахырлары иде. Без ул вакытта Кәрәкәшле авылыннан Фатих Махиянов, Сәетнур Фәхриев, Сәрвиназ Гыйсмәтуллина, Мәрхәбә Гәрәева, Гаишә Батыршина һәм мин Бөгелмә Тәрбия-тәгълим курсларында укый идек. Укучылар һәм шәһәр халкы арасында «Совет хөкүмәтенә каршы Себердән утыз-

кырык мең гаскәр белән Колчак дигән бер генерал килә икән» дигән хәбәр таралды. Бу вакытларда укучыларның язгы каникул вакытлары җиткән булганга, укучылар каникулга таралдылар. Шул сәбәпле без дә Кәрәкәшлегә кайтып китәргә тиеш булдык. Башка каникулларда без Кәрәкәшлегә кайтканда, авылдагы укытучылар белән бергә концерт, спектакль куярга хәзерләнеп кайта торган идек. Бу кайтуда эшләр алай булмады. «Колчак килә икән» дигән хәбәр укучыларга бик начар тәэсир итте. Ф.Махиянов: «Минем бер аягым зәгыйфь, әгәр аклар ягында калсам, минем качарга аягым да юк», – дип, бөтенләй кайтмаска уйлады. Кызларга килгәндә, алар инде таш яуса да, әти-әниләре янына кайтмый калмаячаклар. Ә менә миңа нишләргә? Мин бит Гыйльман Хәнифенең уртанчы малае. Мин дә, Махиянов та – Алланың рәхмәтеннән сөрелгән кешеләр. Әгәр мин авылга кайтып, аклар ягында калсам, авылның берәр куштаны: «Ул – коммун», дип акларга күрсәтеп бирсә, миңа ни булыр? Акларның табигате юлбарыс табигате белән бертөсле. Алар ачу килүгә карап эш итә. Акыл аларда баш түгел, гомумән, иске фикерле надан халыкка зур ышаныч белән карап булмый: аклар килсә, алар сине «Коммун!», кызыллар килсә, «Аклар яклы», дип күрсәтүдән һич тә тартынмаячаклар. Шулай булгач, миңа әллә авылга китми, шәһәрдә генә калыргамы? Шәһәр җирендә кемнең кем икәнен беркем дә белми, күрсәтүче дә булмый. Шулай димсең, шулаен ул шулай ла, миңа бит авылга кайтмый калырга ярамый. Бик яшерен сер булса да әйтим: минем авылда сөйгән кызым бар. Ул миңа кызыл кара белән: «Язгы каникулга кайтмый калма, бик көтәм», – дип хат язган. Мин ул кызны ничек сөйгәнемне, ничек сагынганлыгымны беркемгә дә әйтмим. Миңа кайбер иптәшләр бу турыда: «Син нигә ул кыз белән йөрисең? Ул бит шундый, мондый», – дип хурласалар да, ул хурлаулар миңа бертөрле дә тәэсир ясамый. Ул кечкенәрәк икән, артык кыю икән, җырларга-биергә, киенергә ярата икән, моның белән аны хурлап булмый. Кызлар шулай, бары да кыю булырга, ирләрдән куркып тормаска тиеш. Мин әле аның сез белмәгән тагын бик күп сыйфатлары өчен яратам. «Менә шуның өчен мин Колчактан курыкмый, авылга кайтам. Башкача булырга мөмкин түгел», – дип уйладым да, мин авылга кайтып киттем. Авылга кайткач, буш вакытларда укырмын дип, К.Маркcның «Коммунистик манифест» дигән китабын алган идем. Ул китапның башында К.Маркcның рәсеме бар икән. Өйгә кайткач, мин шул рәсемне кайчы белән кисеп алдым да, ашый-эчә торган өстәл каршына – стенага ябыштырып куйдым. Шуннан соң мин төрле исәп, төрле эшләр белән, ул рәсемне бөтенләй онытканмын.

Мин авылга кайтып алты-җиде көн торгач та, кызыллар Бәйрәкә ягыннан авылга чигә башладылар. Минем кызылларны бер дә чиктерәсем килми, аларга ярдәм итәсем килә – бертөрле дә ярдәм күрсәтеп булмый. Авыл халкының да күпчелеге минем кебек акларны бер дә яратмыйлар, кызылларны җиңдерәсе килә. Боярларны талауга катышкан авыл ярлылары аклар килүдән куркып торалар. Мәктәптә укучы балалар да: «Совет власте булмаса, безгә укулар булмас инде», – дип кайгыралар.

Мин үзебезнең өйгә кергән бер кызыл командирга:

– Сез нигә чигәсез? Бу чигүнең сәбәбе нәрсәдә? – дип сорадым. Ул минем сүземә көлемсерәп карап торды да: «Колчакның көче бик зур аның. Ул кырык мең гаскәр белән килә. Аның солдатлары сукыр чебен кебек, лыжа белән теләгән җиргә бара алалар. Ә безнең көчебез бик бәләкәй, барысы да атлы гына. Ат белән калын кар өстеннән теләгән җиргә барып булмый. Җәяүле гаскәр бездә бөтенләй юк диярлек. Безгә өстәмә зур көч бирелмәгәндә, безнең Колчакка каршы тора алырлык көчебез юк», – диде командир.

– Булмаса, сорарга кирәк. Совет хөкүмәте Колчак белән көрәшерлек кенә көч табар. Ничек тә Колчакны җиңәргә, алга җибәрмәскә кирәк, – дидем мин.

Кызыл командирның минем белән сөйләшеп торырга вакыты булмады. Аларга тизрәк Кәрәкәшледән чыгып, тимер юл буена чигәргә приказ булган иде. Алар бездән бик тиз генә чыгып киттеләр дә, Кәрәкәшледән дүрт километр ераклыкта, каршыда күренеп кенә тора торган тимер юл буена урнаштылар.

Аклар үзләренең батареяларын Кәрәкәшле артындагы Бәйрәкә тавы ди торган тау артына яшереп, шуннан атарга уйладылар. Бу план буенча, Кәрәкәшле сугыш эчендә калды.

Югарыдан офицерларга, офицерлардан солдатларга приказ бирелде: «Без алпавытларның, боярларның җирләрен, урманнарын үзләренә кайтарып бирәбез. Атыгыз кызылларга!»

Солдатлар пышылдап кына үзара сөйләшә башладылар.

Беренче солдат: «Болар безне үз файдалары өчен сугыштырып йөртәләр. Болар безнең җирләрне алып, боярларга бирәләр».

Икенче солдат: «Үзебез сугышып алып бирәбез. Без үзебезнең туганнарыбызга атабыз. Бу нинди ялгыш тормыш?»

Өченче солдат: «Атмый чараң юк. Син аларга кол кеше. Синең кулыңда ирек юк. Син үзеңә үзең хуҗа түгел. Әнә, кызыллар дөреслек өчен сугышалар. Алар дөрес юлда, без ялгыш юлда йөрибез».

Янә приказ: «Без элекке боярларның, алпавытларның җирләрен, урманнарын үзләренә кайтарып бирәбез. Атыгыз кызылларга!»

Солдатлар трубаларга снарядларны салып аталар. Бер снаряд авылның түбән башындагы бер фәкыйрьнең өй түбәсенә төшеп ярылды. Гаиләсендә биш кеше: ире Галимулла, хатыны Рәкыйга, кызлары Һаҗәр, Фатыйма һәм бер кунак кызы Шакирә булган. Гаиләдә бары да үлгәннәр. Шакирә дигән кунак кызының тешләре түшәм тактасына сыланып калган. Хуҗа хатыны Рәкыйга, авыр яраланып, ничектер үлми калган. Халыкка ясалган зарарның хисабын тиз генә белергә мөмкин түгел.

Кызыллар акларга җавап итеп: «Җирләрнең хуҗалары боярлар, алпавытлар түгел. Алар җирләрне ярлы халыктан сатып, талап алучылар гына. Җирләргә, урманнарга, табигый байлыкларга халык хуҗа», – дип, миномётларга уналты килолы миналар салып ата башладылар.

Аклар тагын: «Халык үзенең динен үзе тотсын. Аллага, муллага, үлгәч терелеп яшәүгә, үлгәч оҗмахка керүләргә ышанып яшәсен. Мәктәпләрдә иҗек, намаз, Коръән укылсын. Арба-чана укытулар бетсен. Без аны укымасак та беләбез», – дигән фикерләрне яклап, тагын команда бирелде. Солдатлар бер-берсенә карашалар да, нәрсәдер сөйләшеп, тагын ата башлыйлар.

Мин: «Безнең ат, сыерлар исәнме икән?» – дип абзарга чыккан идем. Ни күзем белән күрим: ат та, сыер да үлгән. Абзарның юан имән өрлеге, чыраланып, урталай өзелгән.

Кызыллар: «Динне, Алланы, мулланы наданлык тудырган. «Үлгәч терелеп, оҗмахка керәм», дип яшәү – үз-үзеңне алдау гына. Бу сүзгә акылы булган кеше ышанмый. Әгәр үлгәч, оҗмах була торган булса, ул оҗмахка байлар, муллалар үзләре керсеннәр. Без җир өстендәге, үзебез эшләгән оҗмахка керергә телибез», – дип ата башладылар. Һәр мина үтерү-җимерү эшен үти иде. Сугыш бик каты дәвам итте.

Минем энем Мәхәсин, урамнан атылган снаряд башы табып кереп, шуның җизен алырга маташа иде. Мин: «Кая, үзем алып бирим», – дидем дә, снаряд

башын аның кулыннан алып, кайчы очын бер тишеккә тыгып, каерырга тотындым. Атылган снаряд башы булганга, мин аңа кагылу куркыныч дип уйламадым. Кинәт снаряд башы бик каты шартлап, минем кулдан атылып китте. Мин бу шартлаудан бик каты контузия алып, морҗага ябышып, чак кына егылмый калдым. Әти ишегалдында нидер эшләп йөри. Әни, утын күтәреп, мунча ягыннан өйгә таба килә иде. Өйдәге шартлау тавышын ишеткәч, кочагындагы утынын ташлап, ашыгып өйгә керде дә, бик зур борчылу белән:

– Әй, балакайларым! Нәрсә булды? – диде. Мин, әнине борчымаска тырышып: «Бернәрсә дә булмады. Снаряд башы гына шартлады», – дидем.Әни бик борчылган тавыш белән: «Ник шундый кеше үтерә торган кораллар белән уйныйсыз?» – дип, бик каты тиргәде.

Минем башым исерек кеше кебек, томаланып тора. Бер колагым шаулый, начар ишетә. Мәхәсингә, миннән бераз читтәрәк булу сәбәпле, бернәрсә дә булмаган.

Мин бераз ятып ял иттем дә айныган кебек булдым. Түзмәдем, укытучыларның хәлен белим дип, Фәсхетдин абзыйларга барып кердем. Аларның да ишегалларына снаряд төшеп, подвалларын әйләндереп ташлаган. Бер өйләренә керсәм, тәрәзәсе ватылган, анда беркем дә юк. Икенче өйләренә керсәм, анда укытучы Сәрви Ишмакаева, Гайшә Батыршина, Риза Сәхәбетдинов, снарядтан куркып, морҗага ышыкланып утыралар иде. Мин барып кергәч, алар җанланып киткән кебек булдылар. Мин аларга үзебездә булган бәхетсезлекләрне – ат, сыерның үлүен, үземнең атылган снаряд башын сүтәргә маташып, чак кына үлми калуымны сөйләдем.

Укытучылар совет хөкүмәтенең акларга каршы зур көч куймавына бик аптырап сөйләшәләр. «Әгәр аклар монда озак тора торган булсалар, без нишләрбез?» – дип бик кайгыралар иде. Шул вакытта аклар Бәйрәкә тавы артыннан: «Без сезгә ачлык, коллык, бөлгенлек китерәбез!» дип аткан сыман, тагын да ата башладылар. Кызыллар аларга җавап итеп: «Без барлык кешене тигез, бәхетле, белемле итә торган, күптөрле милләтләрне бертуган ясый торган тормыш төзибез, һәм шуңа атабыз!» дигән сыман каршы аталар.

Аклар: «Безгә андый тормыш кирәк түгел. Без үзебез генә бәхетле булуны яратабыз. Һәркемне дә бәхетле итә торган тормыш булу – хыял ул. Үз корсагыңны гына зурайтырга, бер-береңне таларга, рәнҗетергә мөмкинлек бирегез!» дигән сыман, снарядларны яудыралар гына. Бер снаряд без утыра торган өйнең Гыймай өе белән ике арадагы читән өстенә төшеп ярылды. Читәнне күтәреп ыргытудан, тәрәзәләрне ватудан башка зур зыян булмады. Бик озак атышканнан соң, кичкә таба сугыш басылды.

Сугыш дүрт тәүлеккә сузылды. Урамнар, бәрәңге бакчалары, кырлар яз көннәрендәге кебек ала-тилә булып калды. Соңыннан кайда, кемнәр үлгән, кемнәргә нинди зыяннар булу турында төрле хәбәрләр йөри башлады. Бу вакытта башына куян бүреге кигән, аягына чабата бәйләгән, аркасына чабата киндерәсе белән мылтык аскан солдатлар урамнарга тула башлады.

***

Безнең әни мескен, үзенең карчык булуына карамастан, иртә белән иртүк торып, оек-чабатасын кия дә, әле теге эшкә, әле бу эшкә йөгерә башлый. Гаиләдә башка хатын-кыз заты булмаганга, аңа һәрбер эшне үзе башкарырга туры килә иде. Бу чаклы эшле халыкка җилкә белән су ташуны гына уйлап кара: нинди авыр хезмәт бу! Ләкин шуңа авылда игътибар иткән бер кеше дә юк.

Су китерү, кер юу – татарларда хатын-кызлар эше булып гадәткә кергән. Менә шуның аркасында безнең әниләргә гомер буе су ташып җәфа чигәргә

туры килә икән. Борынгыдан калган бу кыргый гадәтне бетерергә кирәген аңлый белгән кешене ул чакта авылларда табу бик читен иде.

Әле менә күптән түгел авылда кызыллар иде, ул аларны ашатты, туйдырды, тәрбияләде. Менә хәзер аклар килде. Бары да ашарга сорый. Ару киемең булса, салдырып алалар. Бирмәсәң: «Син кызыллар яклы. Син – коммун! Сезнең барыгызны да атарга гына кирәк...» – дип, ату белән куркыталар. Боларга каян икмәк табып җиткерергә кирәк?!

Генерал Колчак аңсыз малайларны мәҗбүриләп, мобилизовать итеп җыйган да: «Мә, сиңа мылтык, кызылларга каршы ат! Әгәр ашарга кирәк булса, сез бит авылларга, шәһәрләргә таба барасыз, кулыгызга мылтык бирелгән, авылларны, шәһәрләрне талап ашарсыз. Кием кирәк булса, «Без сезнең өчен йөрибез», дип, өсләреннән салдырып алырсыз», – дип, ул аларны үз эти-әниләренә, туганнарына каршы сугышка җибәрә. Надан малайлар шуны аңламый. Колчак кебек халык дошманнарына синең надан булуың кирәк тә инде.

Бүген мин өйгә кайтып кергәндә, ишегалдына кухнялар, солдатлар тулган, бер төркем солдатлар өйдә чәй эчеп утыралар. Әни һәрвакыт шулар янында: аларны ашата, алар белән һәр мәсьәләдә бер дә курыкмый сөйләшә ала. Мин ишек янына бардым да аларның сүзләрен тыңлап тордым: солдатлар иске тормышны, иске тәртипне, иске дини укуларны яклап сөйлиләр: «Хәзерге яңа укытучылар арба-чана укыталар. Моның безгә ник кирәге бар? Без моны укымасак та беләбез. Безгә дин, Коръән, намаз, иҗек укытсыннар», – дип, әни белән тарткалашалар. Мин боларның сүзләре белән кызыксындым да китә алмый бик озак тыңлап тордым. Әни карчык аларга:

– Хәзерге балалар яңача уку аркасында бик тиз укырга, язарга өйрәнәләр. Без менә элекке вакытта берничә еллар абыстайга укырга йөрсәк тә, укырга-язарга өйрәнә алмый калганбыз. Менә шул иске тәртип, иске уку аркасында сез дә надан калгансыз. Җитмәсә сез, шуның өстенә тагын мылтык тотып, шул иске тәртипне сакларга сугышып йөрисез. Бусы инде, үзең генә бәхетсез булу җитмәгән, балаларыгызны да бәхетсез итү өчен кирәктер, – диде.

Бер солдат:

– Ай-һай, бик усал карчык икәнсең син. Әллә малайларың коммунистмы? Дөньялык белән генә түгел бит, ахирәте дә бар аның. «Тегендә» баргач, ни җавап бирербез? – диде.

Әни карчык, бу сүзгә көлемсерәп:

– Анда баргач, борылып кайткан кеше юк әле. Кайтып сөйләгән кеше дә юк. Белмәгәнне кеше ышандырып сөйләргә ярамый, – диде.

Солдатлар:

– Вәт, әби дисәң дә әби! – дип көлештеләр.

Бер бик наданы:

– Син, әби, чистый коммунист булгансың икән. Сиңа бары тәре генә тагасы калган... – дигән иде, «әби» аны бик тиз әләктереп алды да:

– Коммунистлар тәре такмыйлар, алар – укыган, аңлаган кешеләр. Алар, сезнең кебек, генералларны, патшаларны, боярларны яклап, мылтык күтәреп, сугышка чыкмыйлар, – диде. Солдатлар бары да шаулашып көлделәр. «Дөрес! Дөрес!» диделәр. Әни карчык минем янга, ишеккә табан килде дә:

– Боларның берсе, әнә почмакта утырганы – укытучы, – диде.

Мин аңарга читтән генә күз төшердем дә, солдатлар ашап-эчеп кузгалгач, ул солдатны каршыдагы өйгә алып кердем: «Нихәл, исәнмесез!» дип, кул биреп аның белән күрештем:

– Сез укытучы буласызмыни? Миңа әни шулай дип әйткән иде, – дидем.

Ул:

– Әйе, укытучы. Бирски өязе, Л... волысы, ...авылы, – диде.

Мин:

– Бик яхшы! – дидем. – Сез ничек болай, үзегез укытучы булгач, аклар ягында сугышчы солдат булып йөрисез? Бу турыда синең уйлаганың бармы? Менә мин дә укытучы. Без, татар укытучылары, революцияне зур шатлык белән каршы алдык. Ул безнең барыбызны да, милләт аермасына карамастан, тигез хокуклы ясады. Синең кебек, минем кебек, хәер-садакага укытып йөргән татар, башкорт укытучыларын хәерчелектән коткарды. Минем сине дә, барыбызны да коллыктан, хәерчелектән коткарасым килә... – дигәч, ул миңа:

– Мин мобилизовать ителдем. Иптәшләрдән уңайсызланып кына йөрим. Уңайлы вакыт булу белән, кызыллар ягына чыгачакмын, – диде. Мин аңа рәхмәт укып, кулларын кыстым.

Бу вакытта кич булган иде. Бүген бу укытучы солдат бездә куначак булганга, без аның белән ындыр артына барып, тауларга менеп, сөйләшеп кайттык. Без кайтканда, аның иптәшләре йоклап яталар иде. Бу укытучы да идәнгә йокларга ятты. Мин, каршы өйгә чыгып ятсам да, тиз генә йоклый алмадым. Башыма төрле уйлар тулды: «Әгәр бу укытучы мине «ул – коммунист» дип күрсәтеп бирсә, мин нишләрмен? Мин нигә тик кенә тора алмыйм икән?» – дип, үземне-үзем тирги башладым. Моннан соң үземә саграк булырга куштым... «Юк, ул андый кеше түгел», – дип, тагын үземне юаттым. Шулай уйланып ята торгач, бик тәмле йокыга киткәнмен.

***

Кичтән сөйләшкән башкорт укытучысын миңа яңадан күрергә туры килмәде. Алар иртә белән чәй эчкәннәр дә үз юлларына киткәннәр. Алар урынына икенче төркем солдатлар кереп тулганнар. Тәрәзәдән карасаң, урам тулы солдатлар. Бары да икмәк эзләп йөриләр иде. Бер-бер артлы өйгә кереп-чыгып торалар. Кергәне берсе: «Карчык, икмәк бир!» – ди. Әни: «Каян алыйм? Икмәк юк», – дигәч, солдатлар: «Без сезнең өчен йөрибез»,– дип, сүгенеп чыгып китәләр. Әни аларга: «Сез безнең өчен йөрмисез. Сез байлар өчен йөрисез! Байларның җирен кайтару өчен йөрисез», – дип кычкырып кала.

Мин бу хәлне күргәч, икенче өйгә чыктым да, анда мичкә якмаган, салкын булганга өши башлагач, башыма кара бүрек (кубанка), өстемә кара пальто киеп, нишләргә белми торганда, ишектән бер солдат килеп керде.

– Атыгыз бармы? – ди. Мин әйтәм:

– Атыбыз юк.

– Бар бит. Ник алдыйсың?

– Булса, үзең сарайдан алып кит! – дидем.

– Син бик комиссарга охшаулы, әллә кызыллардан калган комиссармы? – ди ул.

– Һәрбер озын чәчле, кара бүрек, кара пальто кигән кеше комиссар булмый торгандыр ул, – дидем мин.

– Без сине яңадан килеп тикшерербез, – диде дә чыгып китте. Минем «Ат юк» дигән сүзгә ышанмый абзарларны карап йөрде. Анда, сарайда, кичәге сугышта үлгән сыер, үлгән ат ята иде. Шуларны күргәч, бик тиз чыгып китте.

Минем күңел тагын дулкынлана башлады. Теге солдат мине тикшерергә яңадан килер сыман тоела. К.Маркcның укырга дип алып кайткан «Ком-

мунистик манифест» дигән китабы бар иде. Күңел тыныч булмагач, ул китапны да укыйсы килми. Мондый вакытта китап укып буламы соң инде?! Теге «Без сине килеп тикшерербез!» дигән сүз күңелдән китми.

Менә тагын бер малай килеп керде, бусы үзебезнең авыл малае:

– Мине сиңа идарәдән Гәрәй абзый җибәрде. «Монда исеме чыкты. Үз җаен үзе карасын, дип әйт! – диде дә чыгып китте.

Мин нәрсә әйтергә дә белми аптырап калдым. Кая барыйм? Нишлим? Төрлечә уйлана башладым. Һичбер уңайлы урын таба алмыйм. «Әллә теге кечәге укытучы, идарәгә барып, сөйләп бирде микән?» Бәлки шулайдыр, бәлки түгелдер. «Тукта, мин әйтәм, әгәр урамда бәла-казага очрамасам, укытучылар янына барыйм әле. Алар ни хәлдә яталар икән?» дип, урамга чыгып киттем.

Урамда солдатлар йөри иде. Мин укытучылар торган Фәсхетдин картның капка турына барып җиткән генә идем, бер мылтыклы солдат:

– Әйдә, минем белән. Миңа подвозчик кирәк, – диде.

Мин аның бу сүзенә бер дә игътибар итмичә һәм тукталып та тормыйча, күңелемнән: «Сиңа подвозчик кирәк булуда минем ни эшем бар?» – дип уйлап: – Мин нишләп сиңа подвозчик булып йөрим? – дидем дә, бик җитез генә сул як капкадан кереп, кергәч тә сулга борылып бераз баргач, өйнең ишеген ачтым. Мин өйгә кергәндә, Фәсхетдин карт, аның карчыгы, иргә чыккан кызы Минсафа һәм квартирда торучы укытучы Риза Сәхәбетдинов сәкедә түгәрәкләнеп чәй эчеп утыралар иде. Мин кергәч тә аларга:

– Монда подвозчик эзләп бер солдат йөри. Әгәр мине эзләп монда керсә, «ул монда кермәде», дип әйтегез, мине тизрәк бер урынга качырыгыз! – дидем.

Укытучы Риза:

– Морҗа артындагы чытыр утын астына кер дә ят! – диде. Мин бик тиз генә утын астына кердем дә яттым. Бераздан теге солдат килеп керде:

– Монда бер кара пальтолы малай кердеме? – дип сорады. Укытучы Риза:

– Юк, кермәде, – ди. Солдат, һаман ышанмыйча:

– Нишләп кермәсен, керде бит, – ди.

Риза тагын аңа:

– Ул капкадан кергәндер дә, сул яктагы капкадан чыгып, су буена киткәндер, – диде.

Солдатның күзе һаман мине эзләде. Ләкин беркайда да кара бүрекле, кара пальтолы малай күренмәде. Тагын карана башлады, аның күңеле ышанмый иде. Тагын эзләде; ишектән чыгып, өйалдыннан эзләргә тотынды. Беркайда да кара пальтолы малай күренмәгәч, ишегалдына чыкты да, урам капка янына барып, тирә-якка каранып тора башлады.

Фәсхетдин карт, тәрәзәдән карап:

– Ул солдат ат, чана тапкандыр да шуңа подвозчик эзли торгандыр, – диде. Аның бу сүзе мине тизрәк чыгарып җибәрәсе килүне белдертә иде. Ул туп-туры әйтә алмагач, карчыгы минем янга килде дә, картның сүзен көчәйтеп:

– Бар, чыгып кит бездән! Алласыз, мәлгунь! Синең аркаңда безгә әллә нәрсә булыр! – дип, мине тирги башлады.

Мин морҗа артындагы чыбык-чабык утын астыннан чыктым да, теге солдат күренмиме дип, тәрәзәдән карадым. Ул һаман капка янында каранып тора иде.

Мин әбигә:

– Зинһар, әби, бераз гына сабыр ит инде. Теге солдат капка яныннан китсен. Ул киткәч тә, мин дә чыгып китәрмен. Син нәрсәдән куркасың? Сиңа бернәрсә дә булмас. Син коммун түгел бит, – дидем.

Карчык:

– Аллам сакласын! Алласыз! Мәлгунь! – дип һаман сукранды. Ул тагын: – Бар, бар, кит! Алласыз, мәлгунь! Коммунисны яшереп тоткансыз дип, үзебезгә әллә нәрсә булыр дип куркам, – дип, мине бик каты куа башлады.

Шунда аларда торучы укытучы Риза да, шул карчыкны юатып: «Борчылма, әби! Бернәрсә дә булмас», дип әйтеп куймый. Мин ничә мәртәбә әйтсәм дә, файдасы юк. Минем бу әбигә бер начарлык та эшләгәнем юк иде.

– Бу карчык нигә болай кылана? – дип укытучы Ризадан сорадым. Ул, минем янга килеп, колакка шыпырт кына:

– Минсафаның кияве Мәгъдүм, синең монда килеп-китеп йөрүеңнән, сине хатыны Минсафа янына килә дип көнли икән. «Мин этине итек калыбы белән бәреп үтергән идем. Әгәр монда килеп йөрсә, мин аны да бәреп үтерермен», дип әйтә икән. Шунлыктан син монда килеп йөрмә инде, алар шуңа ачуланалар, – диде.

– Ярый, килмәм, – дидем мин. Үзем тагын кая бару турында уйлана башладым.

Үземчә кыска гына бер план кордым. Теге әби яңадан килеп куа башлаганчы яки солдатны алып кереп тоттырып биргәнче, миңа моннан тизрәк китү кирәк иде. Мин теге солдатны тәрәзәдән карап тордым да, ул бер якка тайпылган арада өйдән чыгып, абзарга таба киттем. Аннан Ютазы суы чокырына төшеп, Шәмсетдин күпереннән чыгып, Җыланлы тауга бардым. Аннан Шәрип абзыйларның ындырында башак келәтенә килеп туктадым. Минем план шулай корылган иде.

Тирә-як тып-тын. Ап-ак кар өстендә аяк эзләре дә күренми. Келәтнең ишеген ачып эчкә керсәм, салам астыннан бер солдат килеп чыкты. Ул да курыкты, мин дә курыктым. Мин нәрсә әйтергә белми торганда, ул мине бик тиз танып алды булырга кирәк: «Син нишләп монда?» – диде. Хәзер мин дә аны тавышыннан танып алдым: бу солдат безнең күрше Шәрип абзый малае икән. Ул үзләренең ындыр келәтендә ята. Без аның белән мәктәптә бергә укыган идек. Мин дә аңа: «Син нишләп монда?» – дидем. Ул: «Мин акларда хезмәт иттем. Хәзер аклардан кызыллар ягына качып калмакчы булып монда, үзебезнең келәткә кергән идем. Хәзер акларның хәле ничек? Алга баралармы? Чигәләрме?» – дип сорады.

Мин аңа: «Аклар әле алга баралар, Бөгелмәгә таба китәләр. Күпме алга барырлар, кайчан кире чигә башларлар, анысын әйтеп булмый әле. Җәй җиткәч, барыбер чигәрләр», – дидем мин. Ул миңа: «Алай булгач, җәй җиткәнче шушы салам астында ятасы бар икән әле», – диде.

Мин аңа үземнең эшләрнең ничек булуы, нишләп бу башак келәтенә килүем турында сөйләдем. Ул минем хәлне аңлагач: «Алай булгач, син минем яннан кит. Әгәр эләксәк, икебезне дә тотып атачаклар», – диде.

Мин тагын уйга калдым: кая барырга, инде нишләргә?

Күңел бик җитез нәрсә: кешегә үлем куркынычы килгән чакларда, үзен үлемнән саклау өчен табигать аңа бик тиз уйлау сәләте биргән. Мин дә шул сәләттән файдаланып, бик тиз генә: «Хәзер моннан чыгып, үзебезнең бәрәңге бакчасына кайтырга. Ишегалдында солдатлар күренәме, юкмы – карарга. Әгәр күренмәсәләр, абзардан барып, сарай түбәсенә менеп ятарга. Шуннан башка чара юк», – дип, мин башак келәтеннән чыгып киттем. Абзарга кайтып, сарай түбәсенә менәргә барганда, минем бәхеткә каршы, әни мунча янына утынга килә икән. Күрде дә минем янга килде. Мин аңа хәлне кыскача гына сөйләп бирдем. Ул да теге җитез акыл белән уйлап алды да: «Хәзер солдатлар да, офицерлар да – барысы

да собраниегә киттеләр. Безнең урам як өйгә поплар, офицерлар керделәр. Хәзер берсе дә өйдә юк. Син хәзер шул өйнең базына кер дә ят!» – диде әни.

Ишегалдында кухнялардан башка бернәрсә дә күренмәде. Өйгә керсәм, анда телефоннар корганнар икән. Мин, күп караныплп тормый, базга төштем дә, умарталар янына барып утырдым. Менә бервакыт поплар, офицерлар, солдатлар шаулашып собраниедән кайта башладылар. Нииндидер зур мәсьәлә хәл кылган кебек, шау-гөж килеп сөйләшәләр. Өйгә кергәч, әнине чакырып алдылар да:

– Карчык, син безгә тизрәк аш пешер. Без аш ашамый китмибез, – диләр. Әни аларга: «Бернәрсәм дә юк. Нәрсә белән пешерим: оным да юк, итем дә юк», – ди.

– Булмаса, башкалардан алып кайт. Без ашамый китмибез. Каз ите алып кайт! Акчасын соңыннан бирербез, – диләр.

– Хәзер авылда бернәрсә дә сатмыйлар. «Әле киләчәктә кайсы патшаның акчасы йөрер бит, белмибез. Белмәгәч, ничек сатасың?!» диләр. Беркемнән дә таба алмыйм, – диде әни.

– Син кызылларны ашатырга табасың, безгә тапмыйсың. Сезнең барыгызны да атып үтерәсе генә бар. Бар, күршеләреңнән алып кайт! – диде берсе.

Шуннан әни тау буе Шәйхетдин картларга барып, бик ялынып, акчасын соңыннан бирербез дип әйттеләр, дип, бер каз алып кайтты. Кайткач: «Авыл халкы акчага бернәрсә дә сатмый. Хәзер акчасын китерәм дип, ялынып кына алып кайттым», – диде әни. Офицерлар: «Анда безнең эшебез юк. Безгә тизрәк ашыңны пешер!» – диделәр дә көлештеләр.

Әни анда йөгерә, монда йөгерә. Утын кирәк, су кирәк. Офицерлар аның берсе белән дә хисаплашмый. Шул ашны пешереп ашап, иркенләп чәй эчкәч кенә китәргә җыена башладылар. Бу вакыт көндезге сәгать уникеләр булган иде инде. Берөзлексез телефоннан сөйләшәләр.

Менә бервакыт, болар аш ашап, чәй эчеп туюга, офицерлар, поплар, чемоданнарын алып, өйдән чыгып китә башлагач, әни:

– Мин сезгә каз алып кайтып пешергән идем. Хуҗасына түләү өчен акчасын бирсәгез иде, – дигән иде, офицерлар аңа:

– Әле безнең яңа акча эшләнеп бетмәгән. Бераз көтеп торырга туры килер инде, – дип, әйберләрен алып, көлешә-көлешә чыгып киттеләр.

Мин, алар чыгып киткәч тә, ашыгып баздан чыкмадым әле. Аларның берсе керә, берсе чыга. Берәү ишектән килеп керсә, аның тавышын тыңлыйм, кем булуын белергә тырыша идем.

Поплар, офицерлар китеп байтак вакыт узгач, сөйләшә-сөйләшә бер кеше килеп керде. Алар әни белән сөйләшәләр иде. «Ул кайда ята?» – дип сорады. Бу тавыш хатын-кыз тавышы иде.

– Ул менә шушы базда ята, – диде әни. Мин сискәнеп киттем. «Кем булыр бу?» – дим. «Әллә мине тотып алырга эзләп йөриләрме?» дип, тәнемә кырмыскалар йөгерде. Тавышыннан бик тиз аңлап алдым: бу бит минем сөйгән кызым, укытучы Зәйнәп! Мин бит шушы кызны күрү өчен, Колчактан да курыкмыйча, Бөгелмәдән кайттым! Менә хәзер базда утырам.

Зәйнәп, өйнең идән сайгагын ачып: «Бу караңгы базда ятма! Әйдә, кояшлы көнгә чык!» – дип, мине баздан тартып чыгарды да, кысып-кысып кочаклап, мине үбеп алды. Күңелемнән: «Бу кояш каян чыкты?» – дидем. Мин аның белән танышып ничә еллар йөрсәм дә, аны кочакларга, үбәргә кыюлык итми идем. Үзе үпкәч, кочаклагач, миңа да юл ачылды: мин дә аны кысып-кысып кочаклап, үбеп алдым.

Ул килеп керү белән, өйгә кояш чыккан кебек булды. «Дөнья матур ул, аны аклар гына ямьсезли», – диде ул. Өстәл янында стенада Карл Марксның рәсеме тора иде. Зәйнәпнең күзе шул рәсемгә төште дә:

– Син нишләп монда бу рәсемне ябыштырып тотасың? Ул бит акларның дошманы. Шул рәсем өчен үзеңне ябып куйсалар, нишләрсең? – диде.

– Мин кайтканда, авылга аклар килмәгән иде. Аклар килгәч, мин аны алып куярга онытканмын. Офицерлар, поплар бу өстәлдә ашаган-эчкән вакытта, рәсем шунда торган. Алар аның кем булуын аңламаганнар, күрәсең, – дип, без көлештек.

***Искәрмә:** әлеге бүлекнең икенче бер вариантында түбәндәгеләр язылган.*

Кызыллар китеп, аклар кергәч, авыл бик ямьсезләнеп калды. Кызыллар барында авыл яңа чәчәк букеты кебек иде. Хәзер җансыз, урамнарда беркем дә күренми, беркемнең дә кулы эшкә бармый; хатын-кызлар, балалар да өйдән чыкмыйлар. Кызыллар барында балалар һәр көн иртән сумкаларын тотып, мәктәпкә баралар; укытучылар матур киенеп, күңеллеләнеп урамнан узып китәләр иде. Аларның урамнан узып китүе дә авылга зур ямь бирә иде. Аклар килгәч, алар берсе дә күренми. Чөнки авылда уку-укыту эшләре тукталган. Балалар: «Совет власте булмаса, безгә укулар булмас инде», – дип кайгыралар. Укытучылар: «Без хәзер хокуксыз кеше, әгәр кызыллар озак килми торса, без ничек яшәрбез?» – дип эчтән яналар. Хәзер авыл чирле, паралич суккан кеше кебек; аны дәваларга кирәк. Дәвасы шул: алар кызылларны көтәләр. Күк күкрәп, яшен яшеннәп яңгыр яуса, «безнекеләр киләләр...» дип, бер-берсенә карап көлешәләр иде.

Кәрәкәшле авылында берничә коммунист, комсомол һәм комсомолка бар. Аларның кайберләре aклардан куркып, кардәшләре булган күрше авылларга китеп, айлар буе шунда ята. Чөнки яшисе килә, шуннан башка мөмкин түгел. Күрше авылда аларны беркем дә белми.

Бөгелмәдән кайткан курсисткалар да урамга чыгып, гәүдәләрен күрсәтүдән куркып, авылдагы караңгы шартларга яраклашып, тын гына ята бирәләр – башкача мөмкин түгел иде.

Авыл кешеләре: «Аклар законы – патша законы», – дип, үзләренең патша вакытында сука, сабан артыннан йөреп, ач-ялангач яшәүләрен, ул вакытта үзләренең дә, балаларының да укый алмый калуларын, хатыннары, балалары белән бергә байларга дисәтинә урып йөрүләрен искә төшерәләр. Шуңа алар Колчакны яратмыйлар, кызылларны көтәләр.

Белмим ничектер, Кәрәкәшле авылының кайбер кешеләре аклар армиясенә эләккәннәр дә шунда хезмәт иткәннәр. Хәзер шулар кызыллар ягына чыгарга теләп, ындырларга, келәтләргә, салам асларына кереп, авылда аклардан качып калалар. Алар түземсезлек белән акларның чигенүен, кызылларның җиңүен көтәләр. Кызыллар килмәсә, аларның тормышы салам астында. Мондый качып калучы солдатларның саны байтак. Менә шуларның берсе безнең күршедә. Бәләкәй чакта минем белән бергә мәктәптә укыган Шәрип абзый малае Хаҗип ындырда салам астында яши; төннәрдә әнисе ашарга илтә. Хаҗип үзе халыкка күренеп йөри алмый.

Бервакыт минем үземә, аклардан качып, шул ындырдагы келәткә барып керергә туры килде. Ишекне ачып керсәм, келәт башак, салам белән туты-

рылган иде, салам астыннан бер солдат килеп чыкты. Ул да, мин дә курыктык; берсүзсез торабыз. Ул мине бик тиз танып алды...[2]

Мин чыгып киткәндә: «Дөнья матур ул, аны аклар гына ямьсезли», – дигән идем, «Дөньяның киңлегеннән ни файда бар, аягыңа кигән итегең тар булгач», – дип, ул көрешеп калды.

Аклар власте укытучыларны бер дә яратмый, ул аларны иске тормышның терәге булган динне, Алланы, муллаларны бетерүчеләр дип карый. Шул сәбәпле һәрвакыт аларны эзәрлекләп тора. Әгәр Колчак авылда озак яши торган булса, укытучыларның тормышы куркыныч астында. Аклар ягында аларга бертөрле дә ярдәм булмаячак. Укытучы Риза бу хәлне бик аңлый. Шунлыктан, дөнья хәлләрен аңлап кайтыйм әле, дип, Бөгелмәгә киткән иде, ул аннан бик күп хәбәрләр алып кайткан: «Аклар Мәләкәскә барып җиткәннәр дә шуннан ары алга бара алмыйлар икән. Кызылларга Самардан бик зур көч килгән. Самардан Куйбышев үзе килеп, «Хәзер акларны бер адым да алга җибәрмәскә!» – дип, речь сөйләгән ди. Шуннан соң аклар кая качарга белми, мылтыкларын ташлап качалар икән. Кызыллар безгә хәзер килеп җитәләр, көт тә тор!» – ди. «Әгәр алар хәзер Ыктан чыгып калмасалар, Ык ташый башласа, үзләре дә Ык белән бергә агып китәчәкләр», – ди, үзе кыт-кыт көлә. «Шул сәбәпле мин хәзергә беркая бармыйм, торган урынымда торам, ни күрсәм дә күрермен», – ди.

Бу хәбәрне мин салам астында ятучы күрше Хаҗип солдатка сөйләдем. Ул, нишләргә белми шатланып: «Аклар чигүен генә чиксеннәр. Без аларга авылдан бер ат та бирмәбез. Кемнәрдә ат бар, кемнәр аклардан качып калганнар – барыбыз да бердәм булып, бергә оешып, мылтыкларыбызны алып «Карлыганлы кул» чатына, урманга китәчәкбез. Әгәр аклар ат эзләп безнең янга барсалар, без аларны исән җибәрмәбез», – ди.

Шуннан соң биш-алты көн узды. Укытучы Ризаның сөйләгән хәбәре дөрес булып чыкты. Алтынчы көн дигәндә, аклар авылга кайтып керделәр, кая керергә белмиләр, бар да ат эзлиләр. Ләкин бу вакытта авылда бер ат та калмаган; аклардан качып калган солдатлар да, атлары булган кешеләр дә, атларны алып, «Карлыганлы кул» чатына качып киткәннәр иде инде.

Аклар авылда ат таба алмагач, ашарга да булмагач, авыл советына барып: «Атларыңны кая яшердең? Бир!» – дип, авыл советы башлыгы Күкәйче Гәрәйне (Сафиуллинны) кыйнап ташлаганнар. Аклар урамнан өч көн буена узып тордылар. Ләкин беркаян ат таба алмадылар.

Укытучылар яши торган Фәсхетдин карт үзенең атын урманга биреп җибәрмәгән икән; атын табып алганнар да, укытучы Ризаны подвозчик итеп, үзләре белән алып киткәннәр. Риза, Ык суы ташуына бүленеп, бер ай буена кайта алмый йөргән. Солдатлар аны җибәрми, һаман үзләре белән алып китәләр икән. Бер авылда, төнлә чанасын ташлап, атына атланып качкан. Шунда үзенең күргәннәрен сөйләп бетерә алмый. «Дөнья матур ул, аны шулай аклар гына ямьсезли», – ди[3].

## 3. Казанда яшәгәндә

1927 елда мин Казандагы Пединститутның тел-әдәбият бүлегенә укырга кердем. Анда татарның атаклы галимнәре Җамал Вәлиди, Галимҗан Шәрәф, Гали Рәхим, Галимҗан Нигъмәти, Габдрахман Сәгъди һәм башкалар укыта

[2] Шуннан соңгы текст беренче варианттагыча.

[3] Бүлекнең икенче варианты шушында тәмам.

иде. Авыл малаена уку эшләре авыр иде. Минем квартирым «II Солдатскида», ялгышмасам 9нчы номерда. Шакир Юсупов дигән бер студент белән тора идем, Арбузов степда. Мин, утырган тавык кебек, һәр кичне дәресләр өстендә утырам. Атнага бер мәртәбә әдәбият түгәрәге була, анда катнашам. Анда Такташ, Кутуй, Нур Баян, Демьян Фәтхи һәрвакыт була иде. Кичәгә студентлар да күп-күп килә иде. Язарга бер дә вакыт булмаса да, ара-тирә мин дә язгалап куя идем. Менә бервакыт «Тегүче кыз» шигырен яздым. Түгәрәктә һәм концертларда бик күп мәртәбәләр укыдым. Халык шигырьне бик яратып каршы алды.

Кайвакыт Галиев Гальгаф та безнең квартирга килеп утыра иде. Үзе дә хикәяләр яза, башкаларның язмасын тәнкыйть итәргә, халыкны көлдерергә бик ярата иде.

Башның бервакытта да буш торган чагы юк, йә берәр дәрес турында, йә берәр шигырь турында уйлыйсың.

Вакыт сәгать дүртләр иде. Менә берәү ишек какты: «Батыршин шушында торамы?»

– Әйе, шушында тора, – дидем мин.

Бу кеше кулына портфелен тоткан, битенә пудыр сөрткән, өстенә өр-яңа костюм кигән иде. Мин бу кешенең ненормаль хәленә аптырап калдым. Бу җүнле хәл түгел, дип шунда ук уйлап алдым. «Әйдә, утырыгыз!» – урын күрсәттем.

Ул өстәл янына урындыкка килеп утырды да портфелен ачып актара башлады:

– Синең исемең ничек?

– Сирин.

– Фамилияң ничек?

– Батыршин.

– Сез 21нче елда сату иткәнсез икән. Сездән ике мең сум налог тия. Сез менә шуны түләмәгәнсез.

Мин аңа: «Минем сату иткәнем юк. Минем үз гомеремдә сатканым да, алганым да юк. Гафу итегез!» – дидем.

– Бу ничек болай булган соң? Фамилия саташтыру булды микәнни? Ярый, алайса хуш! – диде дә, ул чыгып китте.

«Бу җүнлегә түгел» – дип, мин аптырап калдым.

Шуннан бер сәгатьме, ярты сәгатьме вакыт үткәндер, кичке ут алынган иде, ишектән дүрт кеше килеп керде. Шуларның берсе военный милиционер иде.

– Батыршин арестован, – диделәр дә мине милиция янына куйдылар. Хуҗа хатыны, күрше хатыннарыннан комиссия төзеп, өстәлдә булган китапларны, кәгазьләрне җыеп алып бәйләделәр. Әйберемне һәм үземне «Кара карга» дигән машинага утыртып алып киттеләр.

Караңгыда, бөркәүле машинада кая барганны да белеп булмый иде. Машинадан төшкәч, аңладым: мине Черек күл каршындагы НКВД төрмәсенә китереп япканнар икән.

Мин баш вата башладым. Ни гаебем бар соң? Минем бер начар эш тә эшләгәнем юк. Китапларым барысы да институт программы буенча укырга күрсәтелгән китаплар, язган шигырьләрем барысы да үземчә дөрес шигырьләр.

Берничә көннәрдән соң, гомуми камерада кайберәүләр:

– Мин Мәскәүдән килдем.

– Мин Ленинградтан килдем, – дип, үзләре белән таныштыралар.

– Ә син каян килдең? – дип миннән сорыйлар. Мин:

– Институттан килдем, студент, – дим.

– Кайсы милләт? Еврәйме? – диләр.

– Юк, – минәйтәм, – татар.

– Сине нигә яптылар?

– Белмим. Минем бер гаебем дә юк, – дим.

Мин бу вакытларда диалектик материализмнан зачёт хәзерли идем. Бу сорауларына Маркс, Ленин белән җавап бирә башладым. Шуннан соң мине ялгыз камерага керттеләр дә тагын берәүне минем янга керттеләр. Бу кеше дә: «Мин Ленинградтан килдем», – ди башлады. Кием-салымы начар, ашау-эчүе бик яхшы, байларча, ясалма кайгырулар ясый. Миңа милли мәсьәлә буенча төрле сораулар бирә. Мин аларның һәрберсенә Ленинча җавап бирәм.

Бу шымчы кешегә һәр көнне яхшы обед китерәләр. Ул ике-өч блюдадан ашый. Ләкин: «Батыршин иптәш, синең дә ашыйсың килә торгандыр. Менә бу майлы ботканы аша әле», – дими. Димәк, ул үзе өченгә аеры торган, үзе өчен генә тырыша торган кеше. Аның кайгысы да ясалма кайгы, мине ышандыру өчен генә. Ул минем белән өч-дүрт көннәр күп мәсьәләләр буенча сөйләшкәннән соң, «Мине допроска чакыралар», – дип чыгып, бер сәгать чамасы торганнан соң, тагын керде. «Мине кире Ленинградка җибәрәләр», – дип, әйберләрен алып, чыгып китте.

Шуннан соң мин дә күп тормадым: кулга алынуга утыз көн тула дигәндә, начальник мине чакырып алып: «Казаннан башка беркая барырга да рөхсәт ителми», – дип, шул кәгазьгә миннән кул куйдырды һәм теге китап-кәгазьләрне биреп, кайтырга кушты. «Без чакырсак, килерсең», – диде.

Бервакыт урамда гына очрап, Мансур Крымов белән танышырга туры килде. Шунда аның белән байтак сүзләр сөйләштек. Ул авылга барып кайткан икән. Ул мине авылдагы тормыш белән таныштырды. «Авылда балалар песи борчагы ашап көн күрәләр. Авыл тормышы начар, ачлык», – диде ул. Мин дә һәр ел авылга кайтып килә̣м, авылдагы халыкның алабута, кәлҗемә, өшегән чөгендер ашаганын белә идем. Бу нормаль хәл түгел, тормыш болай булырга тиеш түгел, дип карадым.

Мин бу вакытта Татиздатта эшли идем. Менә бервакыт телефон шалтырады: «Батыршин, бу синме? Яныңда кеше бармы? Минем сүзне кабатлама. Кичен сәгать алты да унбиш минутта минем янга кил».

Бер дә барасым килмәсә дә, аяк атлыйсым килмәсә дә, «Ярар», дидем мин. Шуларны искә төшерсәм, җаным тетрәп китә иде. Хәзер миндә эш кайгысы түгел, җан кайгысы килеп басты. «Нигә чакыра икән? Тагын исән кайта алырмын микән?» дигән уйлар кайный башлады. Шушы уй минем баштан бер генә минутка да чыгып тормады. Менә шундый шартларда ничек редакция эшен эшләргә кирәк?!. Язучы кешегә менә ничек ярдәм итәләр!..

Билгеләнгән вакытта капка янына барып җиткәч, тирә-якка карандым да эчкә кереп киттем. Бер дә исәнләшәсем килмәсә дә, исәнләштем. Ул миңа урындык бирде. Мин тик кенә утырдым. Ул кәгазьләрне актара торгач, бер кәгазь китереп чыгарды.

– Син Мансур Крымовны беләсеңме?

– Беләм, – дидем. Мин шунда ук уйлап алдым: болар минем Мансур Крымов белән йөргәнемне күзәткәннәр икән, дидем.

– Менә синең турыда Мансур: «Күмәкләшүгә каршы», дип яза, – диде.

– Дөрес түгел, ышанмыйм. Минем күмәкләшүгә каршы сүз сөйләгәнем

юк. Бу – ялган. Сез моны үзегез язгансыз. Кая, бир, үзем укыйм әле, – дидем.

Ул миңа язуны бирмәде. Димәк, ул миндә ялган юл белән Мансурга дошманлык кузгатырга тырышты. Мин Мансурга каршы бер сүз дә әйтмәгәч, «Бу барып чыкмады», дип, язуны яшереп куйды.

Аннан соң Ф.Хөсни турында сорый башлады:

– Фатих Хөсни үткән Язучылар җыелышында нәрсә сөйләде?

Мин:

– Белмим, – дим.

– Менә шуны язып бир!

– Белмәгәч, нәрсә языйм? Алдап яза алмыйм.

– Аның собраниедә сөйләгән сүзләрен яз! – ди. – Сез, контрлар, бер-берегезне яклашасыз. Әгәр язмасаң, син үзең дә контр. Син үзең дә шулар белән бергә булырсың, – диде.

Мин бер сүз дә әйтмәдем. Ул миңа пропускны бирде дә, мин чыгып киттем.

Өйгә кайтсам, квартир хуҗасы:

– Сиңа ике кеше килгән иде. Синең бүлмәңә кереп, китапларыңны, язуларыңны карадылар. Чемоданыңны актардылар, – ди. Алар мин үзем эштә чакта, минем квартирга барып, обыск ясап, шигырьләр эзләп йөриләр икән.

Татар бүлеге следователе Б.: «Фатих Хөснинең собраниедә сөйләгән речен язып алып кил», – дип миннән сорый иде. Менә мин бер көнне «Татарстан» гәзитендә Фатих Хөснинең шул рече турында бер мәкалә укыдым. Аны Ф.Мөсәгыйть язган иде. Ярый, мин әйтәм, булды. Менә бу газетны следователь Б.гә илтеп бирергә булдым.

Менә бервакыт телефон шалтырады. «Занятие беткәч, килеп җит!» – диделәр.

Занятие беткәч, бардым. Йөрәк ненормаль тибә. Б.гә: «Сез миннән Фатих Хөснинең собраниедә сөйләгән речен язып китер, дип сораган идегез. Менә мин Сезгә «Татарстан» гәзитен алып килдем. Анда Ф.Хөснинең шул рече турында Ф.Мөсәгыйть язган. Менә гәзитне укыгыз», – дип өстәлгә куйдым.

Б. гәзитәне алмады, кесәсеннән револьверын алып кулына тотты да:

– Бу формальность! Бу кирәкми безгә. Безгә синең имзаң белән үз язмаң кирәк, – диде. Револьверын кулына тотып, төзәп торгач, мин: «Бу мине куркытырга исәпли», – дип уйладым. «Бу – формальность» дигән сүзгә җавап итеп:

– Без шуны дөрес дип укыйбыз, – дидем.

Шуннан соң ул урыныннан торды да, телефонга барып:

– Миндә бер контрреволюционер утыра. Нишләтәбез аны? – диде. – Ябарга дисеңме?

Шуннан соң ул бүлмәдән чыгып китте. Мин бүлмәдә берүзем калдым.

Ярты сәгатьтән соң тагын керде. Минем белән сөйләшми башлады. Минем дә аның белән бер дә сөйләшәсем килми иде. «Ни булыр икән? Бүген исән кайта алырмын микән?» – дип, мин утырам да утырам.

Менә бервакыт следователь Б. мине бу бүлмәдән алып чыгып китте дә җыелыш залының сәхнәсенә кертеп утыртты. Мин: «Әллә бу мине атарга уйлый микән?» дип уйлап утырам. Нервларның гадәттән тыш авыр хәл кичерүе аркасында йөрәкнең эшләве бозылды, куллар язу яза алмас хәлгә килде. Үземне паралич сукмаса ярар иде, дип курка башладым.

Менә следователь Б. белән военный киемнән бер казак килеп керде. Бу теге телефонда сөйләшкән кеше иде. Миңа карап, куркыныч кыяфәт күрсәтеп:

– Шушымыни ул контр? Нигә япмыйсың аны? Яп та куй, ашарга бирмә. Менә шуннан соң тыңлар!

Бер татарча, бер русча: «Враг!.. Халык дошманы!..» дип чыгып китте.

Мин тагын бүлмәдә ялгыз калдым. «Болар үзләре халык дошманы!» дип, мин утырам да утырам. «Бүген болар мине җибәрмәскә булдылар, ахры», – дип уйлый башладым. Күңел төрлечә уйлый: кая барырга, нишләргә дә белеп булмый. «Әллә үземне һәлак итим микән?» диган уйларга да килеп куям.

Следователь Б. мине тагын үз бүлмәсенә алып чыкты һәм: «Монда килгәнеңне бер кешегә дә әйтмә!» – дип, пропуск биреп, кайтарып җибәрде. Кремль буена, аннан Казансу буйларына барып, уйланып йөрдем. Үз квартирыма кайтасым да килми башлады.

Бөтен эштән күңел кайтты. Язарга мөмкинлек юк. Яшәргә мөмкинлек, ашарга мөмкинлек юк. Үземне үзем үтерүгә генә мөмкинлек бар. Үлгәч тә: «Яшисе килмәгән кешегә үләргә мөмкин. Ул безнең кеше түгел, дип, дөньяда менә шулай яшисе килмәгән кешеләр дә бар бит», – дип куярлар. Дисәләр диярләр, мин һаман түзәм әле.

Бервакыт мине дә Язучылар союзы ябык лавкага беркеткән иде. Бер генә ай файдаланып калдым. Икенче айда сызып та ташлаганнар. Димәк, миңа ашамасам да ярый. «Яшәү мөмкинлеген кешегә кайда бирәләр соң? Минем дә ашыйсым, минем дә яшисем килә!» – дип, урамда кычкырасым килде...

## 4. Сөргендә

Бик күп еллар узды. Тәндә ит, кан калмады. Әгәр кулны пәке белән киссәң, кызыл кан чыкмый, саргылт су гына чыга; тәнеңдә кечкенә бер җәрәхәт ясалса, аны төзәтергә материал юктан, берничә еллар буена төзәлми.

Забойда эшләгәндә, тугыз йөз грамм икмәк алу өчен, ундүрт вагонетка таш-балчык төяргә кирәк. Аны бер кеше дә тутыра алмый; әгәр тутырса, норманы арттыралар гына, тачкада такта өстеннән җитмеш тачка илтергә кирәк. Әгәр син шул норманы үтәмәсәң (аны беркем дә үти алмый), «Норманы злостно үтәми» дип, 58нче статья булганнарны эштән кайтканда, лагерь капкасында туктап, карцерга ябып калдыралар. Көн буена бернәрсә капмый эшләгән кешегә йөз грамм икмәк, бер литр суга өч борчак, тоз салып пешерелгән шрафной суп бирәләр. Карцерда кеше тыныч йоклап ял итә алмасын өчен, кандаланы бик күп үрчетәләр; кандаланың күплегеннән бер урында утырып торырга мөмкин булмый. Бу шартларга кеше чыдый алмый, көн дә үлеп торалар. Кайберәүләр эштә, кайберәүләр юлда, кайберәүләр кич йокларга яткач, иртәнгә үлгән булалар.

Бервакыт тауда эшләгәндә, беркөнне тау шартлатылган иде. Икенче көнне һәр эшче үз забоенда эшләде. Һәр забойда ике кеше эшли иде. Таш, балчыкны ала-ала забой тау кыры киселеп төшә. Биек тауның урталарында зур моржа кадәр бер таш тәгәрәп төшми тукталып калгач, шул таш без эшләгән чакта, безнең забой өстенә, аннан вагонетка өстенә барып төште. Вагонетка һавага күтәрелде, рельс тимере дуга кебек бөгелгән иде, шул таш безнең өстән сикереп китте. Без исән калдык.

Беркөнне без ат белән эшли идек. Мин балчык арбасы (грабарка) тирәсендә эшләп маташа идем. Икенче арба өстендәге жулик малай, арбаның бер тактасын

кулына алган да, минем башка ике кулы белән бөтен көченә китереп сукты. Мин егылдым, һушсыз булдым. Ярты сәгатьтән соң тагын эшемә тотындым. Минем баш ярылган, кан аркадан аякка барып чыккан иде.

Бу жулик белән минем бер эшем дә юк иде. Жулик задание үтәде, дип белдем. Ул мине үтерергә дип суккан иде. Аңарга бу заданиене кем биргән? Казан биргәнме? Әллә колонна начальнигы биргәнме? Белмәдем. Мин «Казан – колонна начальнигына, колония начальнигы – жуликка бирде», дип уйладым. Бу эшләр 58ләрне үтерү өчен эшләнә. Казан өчен шул кирәк иде. Кемгә, ничек җәза бирү турында Казан язып җибәрә һәм хәбәрләшеп тора: әле ул үлгәнме, юкмы? Үләрлекме?

1936 елда мин ике мәртәбә үлгән идем. Бу ачлыктан булган иде. Мине дару белән түгел, азык белән, ашату белән дәваларга кирәк иде. Алар мине ачлык белән, дару белән дәваладылар. Анда врачлар да жуликларның үзләреннән куела. Чирлеләрне карап, дөрес дәвалау өчен түгел, чирлеләр «мин чирлим» дип эшкә бармый калмасын өчен куелалар. Эшкә бармый калса, «чирле түгел» дип тора. Шунлыктан андагы врачларга халыкның карашы бик начар. Миндә дә врачларга нәфрәт туган иде. Чирләсәм дә, мин аларга бармый идем. Белмим, аларның үзләрендә дә власть юк иде кебек тоела.

Ничә еллар буена врачлардан бер файда күрмәсәм дә, тагын бик начарлангач, врачка барып карадым. Чират бик зур иде. Көн бик суык, һич түзәргә мөмкин түгел иде. Бераз соңрак килермен дип уйладым да китеп бардым. Тагын барсам, чират беткән, врач китмәгән. Күрендем. Ул мине рәтләп карамады да, освобождённыйлар дәфтәренә язды да куйды. Врач – хатын-кыз, милләтен белмим. Икенче көнне тагын да бардым. Ул мине икенче көнне дә коткарды. Бу миңа бик зур шатлык булды. Эшләмәсәм дә, ике көн 600 грамм икмәк алам мин. Эшләсәм, норманы тутырып булмый; норма тулмагач, штрафной дип йөз грамм гына бирәләр, җитмәсә карцерга ябып, өч борчаклы баланда бирәләр.

Өченче көнне тагын да врачка барсам, оят булыр инде дип бармадым. Менә иртә белән сарайзмер (?) һәр баракны тикшереп йөриләр. Безнең баракка да килеп керделәр. Бу составта: бригадир, начальник, врач; белмим, тагын әллә кемнәр. Халык аларны: «Газраилләр керә», – дип каршы алды.

Начальниклар уртада тора, бригадир список укый башлады: исем-фамилияне «освобождён» дип әйтә. Списокта булмаган кешеләр барысы да карцерга ябылырга тиеш иде. Мин врачка бармагач, минем исем чыкмады. Бригадир: «Әйдә карцерга!» дигәч, шунда торган врач: «Юк, юк! Батыршин освобождён», – дип, списокка өстәп куйды. Шуның белән бригадирның сүзе бетте. Башкаларны карцерга, кандалага ашатырга алып киттеләр.

Тагын да кич булды. Мин тагын да врачка бардым. Ләкин минем яраткан врачым:

– Мин хәзер монда эшләмим инде. Мине икенче колоннага[4] җибәрәләр, – диде. Бу минем башыма таш белән суккан кебек булды. Яшәү өметләрем бер-бер өзелде. «Син кайдан, нинди кеше?» дип сорарга батырчылык итә алмадым. «Әллә бу врачны мине освободить иткән өчен гаепләп чыгардылар микән?» дигән уйлар килде.

Көннәрдән бер көнне, якшәмбе көн булырга кирәк, «Батыршин, сине конторада бер кеше чакыра», дип, чакырып керттеләр.

– Батыршин Сирин син буласыңмы? – ди.

– Мин булам, – дидем.

[4] Сирин язмаларында «колония» дип түгел, «колонна» дип язылган. *(Ред.)*

Өстәл янына утырдык. Өстәлгә бер ярты аракы куйды. 200 грамм ипи бар иде. Аракыны стаканга салып: «Эч, аша!» – диде, үзе дә салып эчте.

– Сез кем буласыз? – дидем.

– Мин артист Кәримов, – диде.

Кәримов фамилияле кешеләр күп булганга, мин аны белмәдем.

– Ничек, язасыңмы? – дип сорады.

– «Кайчан үләсең инде?» дип әйт. Мондый шартларда, үлем шартларында язу эше белән шөгыльләнү бик зур могҗиза булыр иде. Мин бит – үлем алды хәле, – дидем. – Шундый хәлдә кеше бер эш тә эшли алачак түгел.

Мин аңа бер-ике куплет җыр әйттем. Мин ул җырны үзем кайвакыт җырлап йөри идем. Ул бу җырны язып алды:

– Минем сеңлем Томскида радиода җырлый. Аңа биреп, мин аны җырлатам әле, – диде дә: – Безнең монда партия утырышы була. Мин шунда керәм әле, – дип кереп китте. Мин исәнләшеп чыгып киттем.

Кышның иң суык, ачы буран вакытлары. Көннәр, айлар, еллар кеше ышанмаслык газаплар белән үтә дә үтә. Ләкин моннан исән кайта алуга ышанып булмый. Мондагы тормыш кешелек, шәфкать-мәрхәмәтне белми. Монда бер-береңне ашый, үтерә торган урын.

Белмим, ничектер, мине бүген стационарга илтеп салдылар. Урыным җылы, азрак ашарга да бирәләр. Мин моңа ышана алмый башладым. Бу дөрес хәл түгел, төш түгел микән, дим. Яткач, исәпләп ятам: «Иртәгә алты йөз грамм икмәгем бар», – дим. «Эшкә барасым юк. Монда озаграк тотсалар, үлми калып булыр иде», – дим. Шатланып бетә алмыйм...

Иртә белән кычкырган тавышка уяндым. Бригадир кычкыра икән:

– Батыршин! Әйдә, капчыгыңны ал да этапка! – ди. Минем йөрәгем шау итеп китте.

– Нишләп мине этапка булсын? Мин бит стационарга салынган кеше, – дидем.

– Не разговаривать! Молчать! Быстрее! – ди.

Киенеп, үз бригадама барып, иртәнге баланда һәм алты йөз грамм икмәк алып, ишегалдына чыктым. Ишегалдында бер атаман, бандит, 58нче статья, «Злостно норманы үтәми торган», «Враг народа» – ул мин икән. Менә шул ике кешене 12дән 15нче колоннага озаталар икән.

Горносибирский тимер юл буенда 40лап колонна, бәлки аннан да күптер. Алар бары да штрафной санала. Монда иң начар кешеләрне җибәрәләр. Шулар эчендә 15нче колонна – штрафнойлар, штрафные. Дөресен әйткәндә, һәр колоннада үзенә башка закон. 15тә ларёкта икмәк сатыла, ләкин беркемдә дә акча калдырмый, тентеп кертәләр. Икенчесендә акча бар, икмәк таба алмыйсың.

Ике конвой килеп җитте. Безне кырык чакрым җиргә алып киттеләр.

***

15нче колоннага килгәнгә дә унбиш көн тулды. Организм һаман үләргә теләми, көрәшә. Килгәч тә көндез йолдыз күрә торган күзләремә «тавык күзе» булды. Эшкә барганда җитәкләп алып баралар, җитәкләп алып кайталар. Кайчакта «он килмәгән» дип, өч-дүрт көн өч-дүрт грамм штрафной, йөз грамм ипине дә бирмиләр. Бер генә суган бирәләр иде.

Беркөнне, төнлә кухняга бәрәңге, суган әрчергә бардым. Повар эшләгән кешегә берәр тәрилкә баланда бирергә вәгъдә иткән иде. Анда төн буе эшләп, ике суган, бер бәрәңге ашаган идем, – баш, йөрәкнең авыртуына үлә яздым. Ач кеше

ике суган ашаса, шуның белән үләргә мөмкин икән. Төнлә повар аш бирмәде, «Иртән бирәм», ди. Иртән, аш тараткач, бардым. Аш бирә торган тишектән барып сораган идем, аннан жуликлар кайнар су сиптеләр. Чак кына башымны алып калдым. Шуннан соң яңадан бармадым, эшләгәнем бушка китте.

Беркөнне алты малайга начальник алты грамм ипи бирә. Мин моны күрдем, авыр хәлемне аңлатып, начальниктан ипи сорадым. Ул миңа: «Бар кит! Син 58нче статья! Эшләп аша!» – дип, мине куып җибәрде. Минем хәзер яши алуга бер дә өмет калмады. Әйтерсең, эшләгәч – ашарга бирәләр инде!..

Беркөнне миңа повестка китереп бирделәр. Энем утыз биш сум акча җибәргән икән. «Үләргә тырышма инде», – дип хат язган. Ләкин бу повестканы монда саклап булмый инде. Мин аны ыштан бөрмәсенә кыстырып йокладым. Янымдагы бандит барыбер урлады. Киемнәремне төрле урыннан кискәләп, турап бетергән иде. Иртә белән начальникка кереп белдердем. «Минем повестка белән килүчегә акчаны бирмәгез», – дидем. «Бирмәбез», – дигән булдылар. Үземнең исемгә почтадан акчаны кайтарырга яздырдым.

Беркөнне трактта эшләгәндә, кичкә кайта алмаучылар, күзләре күрмәүчеләр күбәеп китте. Шунда бригадир, хатын-кыз бригадасыннан хатыннар алып килеп, ике хатынга бер кешене җитәкләп алып кайтырга беркетте. Мине дә ике хатын җитәкләп алып кайтты. Хатыннар безнең кебек начар түгел. Аларга яхшырак бирәләр иде. Мине җитәкләп кайткан хатыннар: «Безнең янга кер. Без сиңа үзебезнең калган ипиләрне бирербез», – дигәннәр иде. Бер мәртәбә кердем. Алар сүзләрендә тордылар. Икенче кат кергән идем: «Яңадан кермә. Безнең өстән жалоба булган», – диделәр. Хәзер хатыннар янына да кереп булмый башлады.

Инде бик начарландым. Бер өч көннән үләрмен, дип уйлый башладым. Бухгалтериягә кереп: «Минем почтада утыз биш сум акчам бар. Сез миңа авансом ун сум акча биреп торыгыз, акча алгач, мин сезгә түләрмен», – дидем. Бухгалтер: «Начальник белән сөйләшеп карармын, иртәгә керерсең», – диде. Икенче көнне кердем. Биш сум акча бирде. «Акча алгач, түләрмен», – дип, мин дә доверенность бирдем дә рәхмәт әйтеп чыгып киттем.

Ишегалдында ларёк бар. Иң элек бер кило икмәк, ике йөз грамм селёдка, йөз грамм конфет алдым. Барысына ике сум илле тиен акча түләдем. Тагын ике сум илле тиен акчам калды. Шунда якында өеп куелган бүрәнәләр тора иде. Бу зур байлыкны шунда утырып ашадым. Менә хәзер дөньяда миннән дә шат, бәхетле кеше юк инде! Җитмәсә, тагын иртәгә алып ашарга да акча бар. Ипи дигән нәрсә бик тәмле була икән ул! Капкан саен җан рәхәтләнеп китә, нервлар рәхмәт әйтеп, рәхәтләнеп торалар. Ашаган саен рәхәтләнә, миңа рәхмәт укый. Йөз грамм конфет та, ике йөз грамм балык та, бер кило икмәк тә бик тиз арада юк булды. Менә дөньяда шундый бәхетле кешеләр дә бар ул! Менә шундый хәлләрне башыннан кичермәгән кеше бәхетнең нәрсә икәнен белмәве дә мөмкин.

Икенче көнне тагын бер кило икмәк, ике йөз грамм балык, йөз грамм конфет алып ашап, шул бүрәнәдә утыра идем, бригадир: «Исемнәре чыккан кешеләр этапка!» – дип кычкырды. Монда минем исем дә бар иде. Мин, ахры, 15нче колоннада да бер ай янганмын икән. Хәзер шуларны иске урыннарына кайтаралар. Без тагын, капчыклар күтәреп, конвойлар белән 13нче колоннага киттек.

***

Бик күп еллар узды. Җәй булса, ашамаган үлән калмады, тамырлар ашап карадык, берсенең дә туклыгы юк. Энегә посылка сорап хат та язып карадым. Алар: «Җибәрдек», – дип хат язалар, «Үлмәскә тырыш», – диләр. Ләкин посылкалар килми. Әллә килгәч бирмиләр – белеп булмый. Бервакыт хатын салган иде; анда: «Колбаса, хәлвә, сары май салдым», – дип яза. Монда килгәч, капчыкны кисеп, хәлвә, колбаса, майны алганнар да, энә белән тегеп, сургучлы печать басып куйганнар. «Без рәсми алдык» дигән сүз.

Беркөнне, җәй көне эшкә баргач, откоска кәс тезә идек. Көндез обедка туктагач, бер кашык обедтан соң, конвой һәр кешегә бирәр бит тәмәке кәгазе өләшеп чыкты. Мин дә барып сораган идем, миңа бирмәде. «Син, – ди, – 58нче статья, халык дошманы». Бер кеше, конвой ашагач, калган ипине: «Миңа бир әле», – дип сораган иде, «Син – халык дошманы. Сиңа бирмим, эткә бирәм», – дип эткә ыргытты. «Эт синнән яхшырак», – диде.

Бервакыт миннән исем-фамилиямне сорадылар. Мин исем-фамилиямне белмәдем, туган илемне дә онытканмын, телдән калганмын, күрәсең. Мин йөрим икән, минем срогым тула икән.

***

Мин инде такта пилорамында да эшләдем, пчеловодлыкка да сынау бирдем, таш эшендә дә эшләдем. Кая барсам да, минем кара сакалым үз янымнан калмады. Кая барсам да, «58нче статья!» диләр дә, «Ярамый!» диләр...

Инде минем срок туларга күп калмаган иде. Менә беркөнне, төнге сәгать уникедә: «Шул числода, төнге сәгать уникедә синең срогың тула. Белеп тор!» – диделәр. Мин бик шатландым. Ләкин, әкияттәге сыман, тәндә ит кенә калмаган иде. Мин шуннан соң төнге йокыларны йоклый алмадым. Прораб миңа үзенең иске гимнастёркасын, иске күлмәген бирде. Бригадир бүреген, бер кило икмәк бирде. Казённый әйберләрнең барысын сдавать итеп бетердем.

Иртәнге сәгать сигез җиткәч, минем белән китүче бер рус та бар иде. Ул Кировка кайта иде. Капкага чыгарга баргач, каравыл будкасына кердек. Безгә пропуск бирделәр. Икебезгә бергә язылган иде. Мин: «Үземә аерым языгыз», – дип карасам да: «Бу бит Тимертауга кадәр генә. Анда сезгә документ бирәләр», – диделәр. Ярар, рус, пропускны алып, кесәсенә салды. Шунда икенче бер военный кеше бер хат бирде: «Бу хатны шунда, документ бирә торган кешегә бирерсез», – диде. Хатны сургучлап ябыштырган иде.

«Бу хатны укыма, ачма. Әгәр ачсаң, тагын ун ел алырсың», – диде. Мин күңелемнән: «Алай ун ел бирә торган булгач, кирәге юк, үзеңә булсын», – дидем. Шулай да кайчакта искә төшеп куя: «Мин укырга ярамый торган нәрсә – нәрсә микән ул?» – дим. «Берсенең дә кирәге юк, только тапшырып, котылырга гына кирәк», – дим.

Капкадан чыгып киттек. Шунда бер як читтәрәк өеп куелган бүрәнәләр бар иде. Рус әйтте: «Без хәзер иректә. Безне хәзер беркем тота алмый. Без шушы таудан тирә-якка карап, бер тәмәке тартыйк әле», – диде. Мин дә каршы килмәдем.

Иптәшем кәгазь табалмый бик озак маташты. Тәмәке тарттык та китеп бардык. Моннан безгә алтмыш чакрым җәяү, тимер юл буеннан барырга кирәк иде. Өч-дүрт чакрым баргач та, безгә тоннель чыгарга туры килде. Сакчы безне тоннельгә кертми, пропуск сорый. Теге рус кесәсеннән пропускны

тапмый. «Әллә тәмәке тарткан урында төшердем микән?» – дип, миңа: «Син әйберләр янында торып тор. Мин карап килим», – дип китте. Бер ярты сәгатьтән пропускны табып килде: тәмәке тарткан урында төшереп калдырган икән. Без зур тоннельне чыгып киттек.

Тимер юл буе халык белән тулган. Анда хатын-кызлар да, бар да бар. Безгә бер көн, бер төн барырга туры килде. Икенче колонналардан кайтучы кешеләр дә безгә кушылды. Без унлап кеше булдык. Күбесе хатыннар иде.

Тимертауга барып җиткәч, безгә паспорт, язулар бирделәр. Мин теге «ачсаң, ун ел алырсың» дигән хатны да тапшырдым. Мин хәзер почтадан кырык сум акча сорый башладым. Почта акчаны бирми. «Син казённый итек, одеал югалткансың, менә шуңа синең акчаң тотыла», – диләр.

Шунда колонна начальнигы күренде. Мин аңа: «Иптәш начальник, почта минем акчамны бирми. «Одеал, итек югалткансың, шуңа акчаң тотыла», – дип әйтә. Минем одеал да, итек тә югалтканым юк», – дигәч, «Ярар, үзем алып бирермен»,– дигән иде. Ул да качты. Ул үзе дә шул акчаны алып китәр өчен килде, ахры.

Юлга, ашап кайтырга биш сум, ярдәм комитетыннан бер сум бирделәр. Хатыннарга ярдәм комитетыннан илле сум, ашау өчен илле сум бирделәр. Минем статьям илле сигез булгач, мин бары биш сум алдым. Ул бары бер кирпеч икмәк алырга җитте. Миңа юлда хәер сорашып кайтырга туры килде.

### 5. «Син сөйләмә әле, мин сөйлим»

Лагерьдан кайткач, барып керер урыным булмаганга, мин Бөгелмәдәге энем Шамилгә төштем. Аның үз өе бар иде. Минем өс-баш бик начар, йөзләр дә кабердән кайткан кеше кебек – шул сәбәпле күз күргән, белгән кешеләр дә мине танымыйлар иде.

Советский урамы буенча «Аптека» почмагына килеп җиткәндә, миңа каршы Сәхәү Миңлекәй очрады да, каршыма килеп:

– Син сөйләмә! Мин сөйлим! Авызыңны да ачма, мин сөйлим, – ди.

Мин аның кулын тоткан килеш тик кенә торам. Мин нәрсәдер әйтергә теләдем.

– Син минем уемны бүлдермә, юкса минем уйлар бик тиз качып китәләр, – диде дә сөйләргә тотынды:

– Безгә иске мәдрәсәдә укыган чакта: «Нәҗес ике төрле була: берсе җиңел нәҗес, аны чиста су белән юсаң, шуның белән тазара, намаз укырга ярый», диләр иде. «Ә менә икенчесе – авыр нәҗес, анысы су белән юып кына тазармый, аны кисеп ташларга кирәк», дип өйрәтәләр иде. Менә син бит инде, шагыйрь кеше, авыр нәҗес. Сине ничек кисеп ташламадылар? Без сине, кисеп ташладылар инде, ул үлгән инде, дип тора идек. Син сөйләмә әле, мин сөйлим. Авызыңны да ачма, – ди. – Син ничек болай исән йөрисең? Син ничек үлмәдең? – ди. – Син сөйләмә әле, мин сөйлим, – ди.

Мин һаман сүзсез генә басып торам. Ул миңа бер сүз әйтергә дә бирми.

– Мин портфель күтәреп эштән кайтам. Иптәшем Сәкинә ишек янында мине туктата да: «Портфелеңдә язу-сызуларың юкмы? Әгәр булса, хәзер утка ягам. Шигырь, хикәя кебек әйберләреңне өйгә алып кайтма. Шул хикәя, шигырьләр белән үзеңне дә, мине дә, балаларны да харап итмәкче буласыңмыни? – ди. – Син сөйләмә әле, мин сөйлим. Син тик кенә тор! – ди. – Андый язу-сызуларың булса, өйгә аяк та атлама. Эшләгән җиреңдә калдырып кайт, – диде. Шуннан соң мин уйга калдым. Инде нишләргә? – дим...

## Икенче бер истәлек*

Мин электә – Ютазы, хәзердә Баулы районы Кәрәкәшле авылында 1896 елның 17 декабрендә туганмын. Әтием – Хәниф, аның әтисе – Гыйльман, бабасы Батырша булган. Александр патша заманында солдат хезмәте егерме биш ел булган. Минем әти солдатка барган елны ул биш елга калдырылган. Исемлеккә язганда, әтинең исем-фамилиясен сораганнар. Ул: «Исемем Хәниф, әтием Гыйльман, фамилиям юк», – дигән. Офицерлар аның бу сүзеннән көлгәннәр: «Әтиең – Гыйльман, әтиеңнең әтисе ничек?» – дигәч, әти Батырша дип җавап биргән. «Шулай булгач, синең фамилияң Батыршин була», – дигәннәр. Шуңа кадәр аның фамилиясе булмаган.

Солдат хезмәтен тутырып, Кәрәкәшлегә кайткач, Кызыл Яр авылының Калпак Зиякай кызына өйләнгән. Әнием Хөсникамал, аның әнисе Шәмсенаһар – «Көндезге кояш» дигән сүз була. Шулардан: Камил, Зәки, Җәмил, Мәрхәбә, Сирин, Гамил, Шамил, Фазыл, Мәхәсин – тугыз бала туган. Шулардан Зәки белән Гамил бик бәләкәй чакта чирләп үлгәннәр.

Мин тугач, миңа исем куярга кирәк булган. Ахун хәзрәт, миңа исем куйганда: «Борынгы заманда Ибне Сәйрин дигән бер язучы мулла булган. Ул Коръәнне тәрҗемә иткән. Бу баланың да исемен Мөхәммәдсәйрин кушыйк әле, язучы булмас микән?» – дип, Мөхәммәдсәйрин куйган. «Сәйрин» – гарәп сүзе, «сәяхәтче-юлчы» дигән сүз. Сирень – чәчәк, сирень татарча синиль агачы була.

Әти-әниләрем гомер буе авылда яшәп, игенчелек белән көн күргәннәр. Бала-чага бик күп булу сәбәпле, тормыш бик авыр булган. Кышын мал карау, язын-җәен сабан, урак эшләре бик авыр булганга, уку-язу белән шөгыльләнергә аларның вакытлары булмаган.

Мин беренче белемне Кәрәкәшледә, Бәйрәкә мәдрәсәсендә алганмын. (Кәрәкәшле дигән сүз «кара кошлы» дигән сүздән үзгәргән.) Кәрәкәшле, Әсәй, Азнакай авылларында укытучы булып эшләдем. Октябрь революциясеннән соң Бөгелмәдә укытучылар хәзерләү курслары ачыла. Мин дә шул курсларга укучы булып кердем. 1919 елларда Самарада «Яңа көч» газетасы чыга иде, аннан соң ул «Кызыл дөнья»га әйләнде. Бөгелмәдә соңга таба «Якты юл» гәҗите чыга башлады. Мин шул газеталарга шигырьләр яза башладым.

Бервакыт мин «Әнкәмә» дигән бер шигырь яздым да, «Баскач, бер данәсен Кәрәкәшлегә җибәрегез», дип, «Яңа көч» редакциясенә җибәрдем. Шигырьне газетага басып, Кәрәкәшлегә җибәргәннәр. Әнкәй бу шигырьне алып укыган. Бервакыт мин авылга кайткач, әни: «Әй, балакаем, газетта шигыреңне укыдым. Син мосаннифлар (китап язучылар) юлына кергәнсең икән. Иске китапта: «Мосаннифлар бик бәхетсез булалар алар», дип әйткән. Син дә бик бәхетсез булмасаң ярар иде», – диде. Мин аңа: «Ул бит патша заманында шулай булган. Хәзер бит патша заманы түгел, совет хөкүмәте, совет заманы. Без законны үзебезгә файдалы итеп ясыйбыз, үзебезне бәхетсез итә торган закон ясамыйбыз», – дидем. Әни бу сүзгә елмайды, каршы сүз әйтмәде.

Мин Бөгелмәдә укырга кергәч, комсомолга язылдым. Бу ел җәй бик җилле, давыллы булды. Бер тамчы яңгыр яумады. Көз көне ашарга бернәрсә дә булмау сәбәпле, халык ачтан үлә башлады. Ачлык чире – көзән җыеру чире чыкты. Моның белән кеше бер-ике сәгать чирли дә, кайнар табага салып куйган кебек, бик тиз куырылып үлә. Минем әни дә шул чир белән чирли башлады. Мин

* Бу истәлектә алдарак язылган вакыйгаларның беркадәр кабатлануы да очрый. Шулай да авторның язмасын үзгәртмичә бирүне дөресрәк дип саныйбыз. *(Ә.Ш.)*

алабута чабып, аны киптереп сугып, шуңардан азык әзерләп йөрим. Әмма алабуталар чабып, никадәр тырышсам да, әнине үлемнән коткарып булмады. Ачлык белән чирләп, кадерле анам үлде минем!.. Миңа дөньяның кызыгы калмады. Инде нишләргә?..

Үзем дә үпкә шеше һәм тиф белән чирләдем дә, кыш буе чирләгәннән соң, бераз аякка баскач, «Бәлки, Казанда үлми калырмын», дип, командировка белән Казанга киттем. Анда да ачлык; икмәкнең килосы бер миллион сум икән. Мине Кабан күле буендагы зур ак йортка урнаштырдылар. Бу йортка кыш буе ягылмаган икән. Мин шундагы ачлык, суыклардан «Салкын энәләр» шигырен яздым. Бервакыт шул зур йортта әдәби кичә булды. Анда бик күп, бик зур кешеләр бар иде. Мин шунда «Әнкәмә хат», «Салкын энәләр» шигырьләрен сөйләдем.

Еллар актылар...


Мин Бөгелмәгә кайтып, «Сабанчы» газетында бер ел (1926 ел) эшләгәннән соң, 1927 елда Казанга килеп, ВПИнең тел-әдәбият бүлегенә укырга кердем. Анда укыганда, «Тегүче кыз», «Кикрикүк!», «Кеше» һәм башкаларны яздым.

Укуны бетергәч, шәһәр мәктәбендә тел-әдәбият укытучысы булып эшләгәндә (1929 ел) «Булмый, булмый!», «Күп тарат!», «Яз, җәй, көз, кыш», «Җиләк бакчасы», «Бишек җыры» һәм башкаларны яздым.

Мин ялланып эшләүче кеше булганга, шигырь язарга минем бер дә вакытым калмый иде. Миңа язарга тынычлык бирмиләр иде, 1930 елда.

Ун еллык газапларны кичереп, 1940 елны Кәрәкәшлегә кайттым. Тагын илебезне дошманнардан саклау бурычын үтәргә армиягә киттем. Аннан өч мәртәбә контузия алып, сугыш инвалиды булып авылга кайттым. Хәзер пенсия алам. Кырык сигез сум.

*Икенче истәлек шунда тәмам.*


АКТ

25 ноябрь 1969 ел.

Без, түбәндә кул куючылар: шагырь Б.Сиринны күмү комиссиясе членнары – А.Вәлиев, С.Нәбиуллин һәм язучы Р.Төхвәтуллин бу актны шагырь Б.Сиринның архивын кабул итеп алу турында төзедек:

1. Шигырь: "Карт большевик һәм милиционер" /~~татар~~ гарәп хәрефе белән язылган/
2. Шигырьләр дәфтәре /52 бит/
3. Шигырь "Алтын күбәлек" /2 бит/
4. Шигырь "Кызлар җырлыйлар"
5. Шигырь "Таң йолдызы"
6. Кулъязма җыентык – "Октябрь нурлары" (333 бит)
7. М.Латифуллин мәкаләсе "Сирин һәм аның поэзиясе" /22 бит, 2 экз/
8. Кулъязма җыентык 149 бит
9. Сирин иҗаты турында мәкалә /93 бит/
10. Ике тәрҗемә /6 бит/
11. Шигырьләр. Бер төпләм /19 бит/
12. Шигырьләр дәфтәре /58 бит/
13. Кулъязма җыентык шигырьләр /41 бит/
14. Шигырьләр дәфтәре /42 бит/
15. Мәкалә: "Эшче Кортларның серкә урлап кайтулары турында /3 бит/
16. Төрле каралама кәгазьләр /15 бит/

Имзалар: 1. /А.Вәлиев/
2. /Нәбиуллин/
3. /Р.Төхфәтул/

Архивны тапшырдым /Ф.Батыршин/ Батыршина

*Сирин Батыршин архивын 1969 елның 25 ноябрендә кабул итеп алган күмү комиссиясе төзегән акт.*

***Редакциядән:*** *Сирин Батыршин 1946 елдан башлап Баулы районы үзәге Акбуа посёлогында яши. Татарстан АССР Югары Суды Президиумының 1957 елның 13 июнь карары нигезендә реабилитацияләнә. Тормышының соңгы еллары рәхимсез авыру белән көрәшеп уза, ул 1969 елның 23 ноябрендә вафат була. Баулыда һәм туган авылы Кәрәкәшледә Сирин Батыршин исемендәге урамнар бар.*

# «ХАЛЫККА ДӘРСЕ ГЫЙБРӘТТЕР ТЕАТР»

1906 елның 22 декабрендә Казанда беренче тапкыр татар телендә спектакль күрсәтелә. Бу көн татар театрының барлыкка килү датасы булып санала.

Казанда Татар укытучылар мәктәбен тәмамлаган күренекле шәхес, талантлы музыкант һәм җырчы Ильяс Кудашев-Ашказарский тарафыннан, алдынгы фикерле татар егетләрен туплап, бер төркем оештырыла. Бу – соңрак «Сәйяр» исемен алган беренче профессиональ татар театр труппасы буларак билгеле.

Озакламый труппага беренче татар артисткасы Сәхибҗамал Гыйззәтуллина-Волжская һәм «Сәйяр» труппасының булачак җитәкчесе – Габдулла Кариев кабул ителә. «Сәйяр» – 1908 елда труппага Габдулла Тукай кушкан исем («күчеп йөрүче йолдыз» мәгънәсендә). Татар театры, үзенең беренче исеменә гасыр буе тугрылыклы калып, ил гизә; ул Мәскәү, Санкт-Петербург, Баку, Уфа, Идел буе, Урал, Себер, Казакъстан, Урта Азия шәһәрләре һәм Балтыйк буе республикаларында, ерак чит илләрдә гастрольләрдә булып, үзенең милли-мәдәни вазифасын зур фидакярлек белән башкарып килә. 1918 ел ахырына кадәр «Сәйяр» исемен йөрткән татар театр труппасы артистлары, барлык авырлыкларны җиңеп, чор каршылыклары һәм фәкыйрьлек белән көрәшә-көрәшә, нибары ун-унике ел эчендә тормышчан, халыкчан, рухи тәрбия чыганагы булып җитешкән милли театр барлыкка китерәләр һәм аны чын сәнгать югарылыгына күтәрәләр.

1912 елда Сәхибҗамал Гыйззәтуллина-Волжская, «Сәйяр» төркеменнән китеп, Уфада «Нур» дип аталган икенче татар театры труппасы оештыра. Оренбург шәһәрендә 1915 елда Вәлиулла Мортазин-Иманский җитәкчелегендә татарча өченче театр – «Ширкәт» труппасы эшли башлый.

Шулай итеп, 1917 елгы Октябрь революциясенә кадәр татар театры ил күләмендә танылып өлгерә, һәм аның белән кызыксынучылар арта. 1917 елга Габдулла Кариев җитәкчелегендәге «Сәйяр» артистлары Россия буйлап даны таралган, театр белгечләре, тәнкыйтьчеләр күзлегеннән дә иҗади җитлеккән, тамашачыларның мәхәббәтен казанып, матди яктан да иркен сулыш алган труппа булып килеп керә. Бу вакытта театр өчен махсус бина булдыру чаралары да күрелә башлый. Октябрь революциясе театр тормышына яңа борылыш, яңа сынаулар алып килә. Кыска гына арада берничә исем алыштырып, театр үзгәрешләр чорында үзенең актив эшчәнлеген дәвам итә.

1922 елда, «Сәйяр» труппасы нигезендә һәм аңа төрле яклардан, төрле труппалардан артистлар, драматурглар, музыкантлар җыелу нәтиҗәсендә, Дәүләт театры төзелә. Ул «Кызыл Октябрь исемендәге Беренче Татар Дәүләт үрнәк драма театры» дип атала, аның җитәкчесе итеп Габдулла Кариевның шәкерте – артист, режиссёр, драматург Кәрим Тинчурин билгеләнә. 1923 елда Казанда театр техникумы ачыла һәм татар театрына артистлар әзерләүне башлап җибәрә. 1926 елда исә труппа техникум тәмамлаган беренче артистлар Галия Булатова, Галия Нигъмәтуллина, Галия Кайбицкая, Хәким Сәлимҗанов кебек яшь талантлар белән тулылана. 1926 елда театр «академия» исеменә лаек була, 1928 елда махсус җиһазландырылган, уңайлыклары булган бинага күчә, ә 1939 елда, Галиәсгар Камалның 60 еллык юбилее уңае белән, татар халкының төп театрына аның исеме бирелә.

Татар театры Бөек Ватан сугышы елларында да, сугыштан соңгы катлаулы чорда да иҗат эшчәнлеген туктатмый. Зур җиңүләр һәм табышлар аша бүгенге абруйлы көненә килеп җитә.

Бүгенге татар театры – Камаллар, Кариевлар, Тукайлар күрергә хыялланган чын тормыш мәктәбе ул һәм, татар театры дигәндә, әлбәттә, җөмһүриятебездә, илебездә эшләп килә торган күп кенә дәүләт, шулай ук район-авыл театрларын да зур горурлык белән исәпкә алу шарт. Алда тәкъдим ителгән язмаларда әйдәп баручы кайбер татар театрларының соңгы еллардагы эшчәнлеге белән танышырсыз.

**Редакция**

# ҖИЛКӘННӘРНЕ СЫНЫЙ ЧОР ҖИЛЛӘРЕ

**Галиәсгар Камал театрында – «Җилкәнсезләр» спектакле**

Кәрим Тинчурин иҗаты турында язылган фәнни хезмәтләр, мәкалә-истәлекләр бик күп, пьесаларына театрларыбыз кайтып-кайтып мөрәҗәгать итә. Галим-язучыларны да, режиссёр-актёрларны да әлеге фаҗигале язмышлы талантның уңышы нидә соң дигән сорау еш борчый. Заманында әдәби тәнкыйтьчеләр һәм вакытлы матбугатка язышучылар тарафыннан шактый кыйналган, чор афәте – репрессия корбаны булган Тинчуринның бүгенге көнгә иң популяр классик драматург сыйфатында килеп җитүенең серен мин әдипнең үз мәкаләсендә ачтым. Ул болай ди: «Миссионерлар яңа туып килгән драматургия сәнгатен игътибарсыз калдырмады. Аларның, татар драматургиясе идеологиясен үз кулларында калдыру өчен, мәсәлән, «Чистай комедиясе»н (соңгы тикшеренүләрдән бу пьесаның әби патша язган «О, время» дигән пьесасыннан тәрҗемә ителгәне аңлашылды) кулланма, күчергеч итеп дөньяга чыгарулары – хәзер ачык мәсьәлә. Әлеге әсәрнең, кәләпүш киертелеп, татар матбугатына чыгарылуы иттифакый бер эш булмаганлыгын түбәндәге мисал ачык күрсәтә.

1905 елгы революциядән соң туган реакция чорында берәр оригиналь татар пьесасын бастыру яки сәхнәгә куяр өчен рөхсәт сорап Петербургка барганда, цензор Смирнов, рөхсәт бирү түгел, әсәрнең язучысын арестовать итү белән янап, өркетеп кайтарып җибәрә, оригиналь татар пьесалары язмаска, бәлки Рыжковның яисә берәр мәгънәсез водевильне русчадан тәрҗемә итәргә мәслихәт күреп киңәш бирә иде. Бу хәл XIX йөздәге миссионерлар методының XX йөздә дә кулланылганын ачык күрсәтә. Шуның белән бергә, эксплуататорлар файдасын күзәткән татар пьесаларын бастырып таратырга, әлбәттә, рөхсәт ителә иде»[1].

Өзектән күренгәнчә, татар сәхнә әдәбиятының башында торган барлык драматурглар диярлек, цензура янавына буйсынып, «оригиналь татар пьесалары» язудан бигрәк, йә тәрҗемә белән, йә «эксплуататорлар файдасын күзәткән татар пьесаларын бастырып таратырга» мәҗбүр була. Озакламый илдә башланып китәчәк революцион күтәрелешләр, колхозлашу, яңа җәмгыять төзү барышы күп драматургларны, милләт язмышыннан бигрәк, җәмгыятьтә барган вакыйгаларның фотокүчермәсен сурәтләп калдыруга этәрә, репрессия еллары исә Тинчурин атаган сәбәпләрнең каһәрле дәвамы була.

Әлеге һәм башка каршылыкларны исәпкә алганда, милләтнең ачы язмышын күрсәтеп биргән сәхнә әсәрләре язу мөмкин булмастай хәл кебек күзаллана. Туган халкының җан авазын үзенең астарлы җөмләләре, этнография, фольклор элементлары, символлары арасына гади күз белән күреп булмас рәвештә яшерә алган, наданлыкка, хөсетлеккә, капкорсаклыкка сатира рәвешендә яңгыраган көлкеле ситуацияләр куелыгында «адаштырган» Кәрим Тинчурин моңа ирешә – аның төрле чорларда актуаль калачак фикерләренең сере дә шундадыр.

Быелгы театр сезонында Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры сәхнәсенә кире кайткан «Җилкәнсезләр» спектакле дә заманыбыз вазгыятенә аваздаш фикерләргә шактый бай. Узган гасырда татар театры сәхнәләрендә кат-кат уйналып, рус театрында да уңышлы гына барган «Җилкәнсезләр»не бу юлы Камалда Омск дәүләт академия драма театрының баш режиссёры, безгә 2004 елда премьерасы булган «Ханума» спектакле аша таныш Георгий Цхвирава куйды. Ул Кәрим Тинчурин «комедия» дип билгеләгән пьесаның жанрын «киләчәк турында искә төшерү» буларак үзгәртеп тәкъдим итте.

Чыннан да, әсәрнең жанры бәхәсле. Төрле чор галимнәре, театр белгечләренең фикерләре дә әлеге мәсьәләдә икегә аерыла. Мәсәлән, Совет чоры тәнкыйте Тинчуринны большевистик идеологияне алга сөрүче, кадимчелек һәм аның тарафдарларын кискен кире кагучы, алардан мыскыллы көлүче дип атый. Инде бүгенге заман күзлегеннән карасак, фикер шактый үзгә. Персонажларның күңел дөньясына, ягъни аерым күренешләрдәге эчке конфликт үзенчәлекләренә игътибар итсәк, драматургның

---

[1] Тинчурин К. Әсәрләр: Проза, әдәбият-сәнгать турында мәкаләләр: 3 томда. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1987. – 3 том. – Б.473-474.

шәхес мәнфәгатьләрен күз уңында тотып язганлыгына төшенербез. Совет чоры җәмәгатьчелеге көлкеле тискәре геройлар дип таныган Нуретдин (спектакльдә – Рамил Вәҗиев), Мисбах хаҗи (Искәндәр Хәйруллин), Батырхан (Эмиль Талипов) һәм Фәттахларның (Раил Шәмсуаров) асылында фаҗига ята, «...алар да, иң беренче, кеше, шәхес, җан иясе. Яңа тәртипләрнең урнашуы һәм ныгый баруы аларга фаҗига гына китерә. Менә ни өчен әсәрдә көлү генә өстенлек итми, монда сатира һәм фаҗига аралашып килә. ...Шуңа да ул, ...жанр төре буларак, «трагикомедия»[2].

Жанр мәсьәләсендәге икеяклы карашларны аңлаган хәлдә, режиссёр «комедия» ягына да, «трагикомедия» тарафына да авышмый – алтын урталыкны сайлый.



*Сулдан уңга: Мисбах хаҗи – Искәндәр Хәйруллин, Нуретдин – Рамил Вәҗиев, Сәхипгәрәй – Илдус Габдрахманов.*

Ә ник менә нәкъ «киләчәк турында искә төшерү» соң? Бу сорау шулай ук фәлсәфи уйлануларга китерә. Әдәбият галиме Әлфәт Закирҗанов язганча, «яңа хакимиятне кабул итә алмыйча, «тормыш төбендә» яшәүчеләрнең, шулай ук йорт-җирләрен, туган илләрен ташлап китүчеләрнең эш-гамәле артында күпләрнең ачы фаҗигасе ята. Әлеге адашып калган «җилкәнсезләрне» аңларга теләүче, ярдәм итүче юк. Үз иленең гражданнарын (бәреп төшерелгән сыйныф вәкиле булсалар да) шундый шартларга куйган, бик авыр хәлгә калдырган властьны ничек дип атарга? Пьесаның субъектив эчтәлегендә әнә шулар ачыла. Тексттагы зур булмаган репликалар да җитди уйлануларга этәрә. Мисал өчен, 1920 елларның икътисади сәясәте турында нэпман Зәйнетдин (Алмаз Сабирҗанов) болай ди: *«Сез бай чакта сезнең милләтегез булган. Ә без, каенатай, интернационал, ха-ха-ха!.. Бездә милләт тә, чёрт та юк»*[3].

Драматург Кәрим Тинчурин җиткергән әлеге фикерләр, тематик киңлек режиссёр Георгий Цхвирава тарафыннан урынлы тотып алынган. Бер гасыр элек (әсәрдә 1910-1924 еллардагы вакыйгалар сурәтләнә) ил язмышын үтәли тишеп узган Беренче Бөтендөнья сугышы, инкыйлаблар, Гражданнар сугышы, НЭП чоры бүген илләр арасында, гомумән, дөньякүләм барган яшерен сугышларга, икътисади тотрыксызлыкка, «милләт тә, чёрт та» икенче планга күчеп барган кешелек җәмгыятенең өстенлек алуына кайтаваз булып яңгырый. Менә шуңа да режиссёр идеясе, Кәрим Тинчуринның бер гасыр узгач кабатланачак вакыйгаларны алдан тоемлавын исәпкә алып, «киләчәк турында искә төшерү» рәвешендә формалаша.

1926 елда иҗат ителгән, әүвәл «Ишкәксезләр», аннан соң «Җилкәнсезләр» атамасын алган пьесаның исем символикасына игътибар итик. XX гасыр башы татар әдәбиятында, заман болганышлары аркасында, үз юлын таба алмаган, киң дәрьяда «ишкәксез, җилкәнсез калган», кыйбласын җуйган, кайсы тарафка авышса, алданмаячагын абайламаган образ-персонажлар бик күп. Чоры өчен хас типик геройлар алар. Бер гасыр узгач, нәрсә үзгәрде?! XIX гасыр, Совет чоры әдәбиятында «ялтыраган» идеаль яки кырт тискәре заман героен, XX йөз башында булмаган кебек үк, бүген дә табып булмый – җәмгыятьтә ишкәксезләр өстенлек итә.

Драматург һәм режиссёрның әлеге фикерен тормышка ашыруда спектакльдәге музыкаль бизәлеш тә (музыкаль бизәлеш авторы – Фуат Әбүбәкеров) зур роль уйный.

---

[2] Әхмәдуллин А.Г. Кәрим Тинчурин драматургиясендә жанрлар // Кәрим Тинчурин һәм татар сәнгате: Бөтенроссия фәнни-гамәли конференциясе материаллары. – Казан, 2007. – Б.15-16.

[3] Закирҗанов Ә.М. Кәрим Тинчурин поэтикасында символлар // Рухи таяныч: әдәби тәнкыйть мәкаләләре. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2011. – Б.218.

Сәхнә ачылганда ук яңгыраган, халкыбызның фаҗигале язмышының кайтавазы булган, илдәге хаотик хәлне гәүдәләндергән «Ком бураны» көе аерым күренешләрне бергәндә даими кабатланып килә, көчәйтелә. Гомумән, спектакльдә җырларның һәм музыканың диапазоны бик киң. Төрекчә, русча, инглизчә, немецча музыка-җырлар яңгырау, «Галиябану», «Җизнәкәй», «Ахырзаман» җырлары, «Кызыл Армия маршы» халыкның күңел халәтенең, җәмгыятьнең, илнең һәрьяктан чуар булуын, тотрыксызлыгын бар тулылыгында ачарга ярдәм итә.

Әлеге музыка-җырлар спектакльнең хронотобына бәйле рәвештә кулланыла. Георгий Цхвираваның шактый күләмле пьесадан җыйнак спектакль барлыкка китерүе кызыклы. Кәрим Тинчуринның сигез картинадан (бүленеш режиссёр тәкъдим иткәнчә еллап түгел) торган «Җилкәнсезләр»е ике пәрдә, алты күренештән (1910 ел, 1916 ел, 1917 ел, 1919 ел, 1922 ел, 1925 ел) гыйбарәт сәнгать әсәре булып оеша. Спектакльдә әлеге чор вазгыяте бар тулылыгында ачыла. Сәхнәдә еллап барган күренешләр экранда күрсәтелгән тарихи кинохроника белән башлана. Елларга бүленеш һәм кинохроник материал әсәрне фильмнарга хас эпизодик характерга китерә. Режиссёрның, шул рәвешле, «артык» мизансценалардан, реплика-монологлардан котылып, пьесаны җыйнак спектакль итеп оештыра алуының уңышы һәм сере шунда.

Күтәрелгән мәсьәләләрнең актуальлеге, форма яңалыгы, шулкадәр дә күп тарихи вакыйгаларны хроникальлек һәм эскизлылык «куркынычыннан» йолып кала алу, һәммәсенең үз ихтыяҗлары булган төрле катлам вәкилләре – ике дистәдән артык персонажның, шәхси йөзен җуймаган хәлдә, камил эшләнешен саклау ягыннан «Җилкәнсезләр» – уникаль әсәр.

Спектакль тәрәккыйпәрвәр, бай сәүдәгәр Нуретдин гаиләсе тирәсендәге вакыйгаларны сурәтләүдән башлана. Аның гимназияне тәмамлаган Дилбәр (Ләйсән Фәйзуллина) исемле чибәр кызы үзенең киләчәк язмышын инде тәгаенләп куйган: иркә кыз бары тик балда-майда гына йөзә торган бай бичә булырга тиеш. Үз максатына ирешү өчен, ул барына да риза – властька советлар килеп, Мисбах хаҗида хезмәтче вазифасын үтәгән Зәйнетдин баеп киткәч, аңа кияүгә чыга, Германиядә гомер кичерә. Соңрак сыйнфый дошманнарына әйләнгән әтисен, якыннарын туган йортыннан куып чыгарып, ире Зәйнетдин белән биредә склад ясаудан да тартынмый.

Кәрим Тинчурин күтәргән, ә Георгий Цхвирава тотып алган тагын бер уңышлы һәм бүгенге көн өчен актуаль «киләчәк турында искә төшерү» бар. Ул – җәмгыятьнең, тормышның киләчәк язмышы Зәйнетдин кебек уку-язу да танымаучы, шулай булса да әле илнең икътисады, сәясәте белән идарә итәргә омтылучы ялчылар, хәерчеләр кулына калуы. Ул – зыялы, ләкин болганчык елларда шулай ук үз киләчәген, язмышын фараз кыла алмаган Батырханның *«Их, менә шулай ятып йокыга китсәң иде дә йөз елдан уянсаң иде»* репликасы. Һәммәсе дә бүген актуаль бит! Ярлы-ябага, белемсез адәмнәр төзегән строй җимерелде, йөз ел элек «йокларга» мәҗбүр ителгән зыялыларның, байларның нәселе кабат ата-бабалары асылына кайтты. Алмаз Сабирҗанов белән Эмиль Талипов әлеге заман геройларын бар тулылыгында ачып бирде.

Әсәрдә Дилбәрнең бертуганы, бөкре, зәгыйфь Рөкыя (Айгөл Абашева) образы да аерым репликалар аша әһәмиятле вазифалар башкара. «Сүнгән йолдызлар»дагы Мәхдүм кебек үк, ул да «мин дә кеше бит, минем дә кешечә яшәргә, сөяргә хакым бар» фәлсәфәсен уздыра.

*Р ө к ы я. ...Дилбәргә өйләнергә уегыз бармы, дим?*

*Б а т ы р х а н. Булса соң?*

*Р ө к ы я. Ә миңа? Минем байлыгым Дилбәрнекеннән бер дә ким түгел бит.*

Атасы тарафыннан һәрдаим мыскылланган зәгыйфь Рөкыяның артык сүз боткасы куертучыларга да талканы коры. *(«Һаман сүз дә сүз, ә күмер юк!»)* Ул мәсьәләгә реаль якын килә һәм, ни өчендер, автор әсәрнең финал аккордын нәкъ менә җәмгыятьнең гарип вәкиленнән әйттерә. *(«Ишектә кешеләр бар... Керделәр!..»)* Шул рәвешле, гарип, кимчелекле саналган чынбарлык тормыш юкка чыгарыла.

Шулай ук «җилкәнсез» Давыт (Ришат Әхмәдуллин) белән Сөнгать (Илнур Закиров) тә үз язмышларына үзләре хуҗа түгел. Атасы бай сәүдәгәр Нуретдин белән барлык авырлыкларны кичкән Давыт спектакль ахырында, идән тактасын ачып, Батырхан (соңрак исемен Батырҗанга алыштырып, башка кешегә өйләнергә тырышса да) белән

берлектә, җир өсте тормышыннан гаип була. Сөнгать исә яңа җәмгыять вәкиле булып киткән хәлдә дә бәхетсез – элекке танышлары – байлар, милләтчеләрне фаш итеп йөрергә мәҗбүр. Үз язмышы да әлегә ачык кала.

Тагын бер персонаж – элекке Хәрби шура вәкиле, офицер, инде сәрхушкә әйләнгән Сәхипгәрәй (Илдус Габдрахманов) язмышы гыйбрәтле. *«...Соңгы көннәрнең соңгы сәгатьләрен аракыга батырабыз... Мин гомеремдә аракыны авызыма алган кеше түгел... Таза, сау, шат булып дөньяда торасым килде... а вон поди, большевик үтермәкче була... Нигә ул мине үтерә! Мин бит гимназист чагымда социалистлар кружокларында эшләдем. Прокламацияләр тараттым, комитетларга, съездларга сайландым. Мин бит монархист түгел!.. Мин укыдым, мин тырыштым, мин ватанга, патшага, халыкка хезмәт итәргә тиешме, түгелме?.. Кара халыкның миңа баш булуын каным күтәрә алмый».* Шул рәвешле, Илдус Габдрахманов үзе бер җырлы-биюле миниспектакльгә әйләндергән әлеге сәрхуш персонаж мизансценасы – спектакльнең идея-тематик яңгырашында аерылгысыз өлеш.

Лашман, үзбәк Голам әкә (Ирек Кашапов) образы да пьесада һәм спектакльдә очраклы түгел. Төркия белән булган киеренкелекләргә бәйле мәгълүм мәсьәләләр нәкъ менә ул катнашкан күренештә ачыла.

Мәхәллә имамы булган Хәзрәт (Фәннүр Мөхәммәтҗанов) образы, ни өчендер, артык комиклаштырылган, ясалмарак кебек тоела. Сәхнәдә five-яшь артистның мәхәллә имамы образын тудырырга теләү, инде 1920 елларда икенче планга күчеп барган диннең шундый хәлгә калуын гәүдәләндерергә омтылыш дип кабул итик моны.

Әлбәттә, спектакльнең үзәк баганасы – Нуретдин (Рамил Вәҗиев) белән Мисбах хаҗи (Искәндәр Хәйруллин). Алар – заманында дөнья терәге булган, инде тарих арбасыннан төшеп калырга мәҗбүр трагик шәхесләр. Кәрим Тинчурин әлеге геройларын пьеса башында ук көлкегә калдырып фаш итми, ә әсәр дәвамында сүз-репликалары, эш-гамәлләре аша җайлап кына сатирик тәнкыйть утына тота. «Җан хәрәкәте» аркылы ача ул аларны. Пьесаны әнә шул җанлы итә, курчак образларның асылын ача-ача, әлеге бурыч гыйбрәтләре белән тамашачы күңелендә кайтаваз таба. Тинчурин, шул рәвешле, вульгар социологизм дигән әшәке гадәтләре белән әсәрне коры лозунгка әйләндерә торган (димәк ки, көнлекче әсәр булудан коткарып калучы) афәтләрдән аралаучы иҗат үрнәген мәйданга куюга ирешә. Мин моны болганчык, буталчык заманда иҗат батырлыгы дип атар идем»[4].

Режиссёр да авторның шул үзенчәлеген спектакльдә өстен чыгарды. Мәгънәсез дәгъвалары, чәлпәрәмә килгән, гамәлгә ашмас хыяллары белән ахырда сатирик типларга әйләнгән Нуретдин һәм Мисбах хаҗиның драматик, гыйбрәтле бер диалогы автор идеясен бар тулылыгында яктырта.

*М и с б а х (сәләмә киемнән. Кулында сыңар киез ката, черек киез кисәге һәм иске читек балтырлары). Кем, Нуретдин, болар сиңа батмыймы? ...Без бай чагында бөтен дөнья тук иде. Дөньясы чәкмәрә килде. Үлеп тә булмый. Булмаса, боларны да алып кал, читек балтырларын, дим.*

*Н у р е т д и н. Боларга бит өр-яңа башлар кирәк...*

*М и с б а х. Әйе, яңа башлар кирәк шул, яңа башлар... Иһи-һи-һи!.. Заманында болар да кәҗүл булганнар бит...*

Бу инде чарасызлык. Давылга каршы йөгереп, аны туктатырга азаплану, ләкин замана гарасатында үзең һәлак булу, Рөкыянең соңгы репликасы – «Керделәр!» – тудырган чарасызлыкка аваздашлык. Шулай да спектакльнең ахыры күңелдә тирән оптимизм уятты. Нуретдин, Давыт белән Батырхан гамәлен кабатлап, идән астына чуммады, ул, гәрчә пьесада бу булмаса да, идән асты капкачы өстенә намазлык җәеп, гыйбадәт кылырга оеды. Болганчык еллар алып килгән чор фаҗигаләренең чишелеш юлын режиссёр иман юлында тапты.

**Рамил ХАННАНОВ,**
*филология фәннәре кандидаты*

[4] Бәширов Ф.К. Ул кабызган утлар мәңге янар // Кәрим Тинчурин. Драмалар, комедияләр, хикәяләр / төз.Ф.Бәширов. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2007. – Б.12.

# СИНЕҢ НИЧӘ НИГЕЗЕҢ БАР?

## Чаллы татар дәүләт драма театрында – «Яр» спектакле

Сигезенче Тинчурин фестиваленең финаль аккорды булып Булат Сәлахов пьесасы буенча куелган «Яр» спектакле (режиссёр – Фаил Ибраһимов) яңгырады. Әлеге спектакльне тамашачылар бик яратып кабул итте, ул беркемне дә битараф калдырмады, чөнки аның төп темасы һәркемгә аңлаешлы һәм якын иде. Драманың авторы – Булат Сәлахов – кешенең бу җирдәге миссиясе, тормыш мәгънәсе хакындагы уйланулары белән уртаклашты, һәр кешенең туган җире һәм үз ыругы алдындагы бурычы турында искәртте.

Спектакль хакында фикер алышуда Мәскәү академия сатира театрының әдәбият мөдире Нина Карпова, «Страстной бульвар» журналы мөхәррире Елена Глебова, Казан дәүләт мәдәният институты профессоры Ильтани Илялова катнашты. Театр сәнгатенең күренекле белгечләре спектакльне уңай кабул итүләре хакында хәбәр иттеләр, темаларның актуальлеген, актёрлар уенының үзенчәлекле булуын билгеләп үттеләр, ут һәм тавыш куелышына бәйле файдалы киңәшләрен бирделәр һәм кайбер образларның мәгънәләре ачылып, аңлашылып бетмәве хакында үкенечләрен белдерделәр.

«Яр» лирик новелласы үз исемен тулысынча аклый. Ул – бер архитекторның һәм, гомумән, туган ягы белән бәйләнешен, кан тартуын югалткан хәзерге заман кешесенең җан авазы. Әсәр атамасының мәгънәсе сюжетның төенләнү мизгелләрен үз эченә ала. «Яр» сүзе пьесада берничә мәгънәдә кулланыла: *чик* – яр, диңгез яры, текә яр; *яраткан кеше, сөйгән яр; яр салу* – кычкырып әйтү, белдерү мәгънәсендә. Әсәрне анализлаганда, пьеса атамасы янына еш кына өндәү билгесе куярга теләгән чакларыбыз булды.

Драманың нигезендә архетипик ситуация – юлдан язган, үз нигезен югалткан улның кире кайту вакыйгасы ята. Төп герой, чит илләрдә бәхет эзләп йөргәннән соң, күңел борчуларына дәва таба алмыйча, туган йортына кире кайта. Төп коллизия яңа түгел, ул әдәбиятта бик еш очрый торганнардан (А.Гыйләҗевнең «Өч аршын җир» (1962), «Әткәй җырлый да, елый да» (1980), В.Шукшинның «Односельчане» (1968), «Калина Красная» (1975), «Выбор» (1981), В.Распутинның «Живи и помни» (1974), Ю.Бондаревнең «Берег» (1975), В.Быковның «Карьер» (1985) һ.б.). Билгеле булганча, кире кайту вакыйгасының архаик мәгънәсе дөньяның пространстводагы моделенә юнәлә, ул модельдә үзәк белән периферияләр иерархиянең төрле баскычларына куелган. Кире кайту ул – ниндидер сәбәпләр яисә теләк аркасында югалган яки югалырга мәҗбүр булган сакраль үзәкнең кире кайтуы. Кире кайту мифологемасы үлеп терелгән Алла турындагы мифка барып тоташа; «югалу һәм кире кайту ниндидер космик драманың мизгелләре булып тора, аның чикләрен белдерә. Югалу һәм кире кайту нокталары арасында космик тормышның яшәве өчен җавап биргән КЕМНЕҢДЕР булмавы тора»[1].

[1] Евзлин М. Космогония и ритуал. – М.: Радикс, 1993. – С.123.

«Кире кайту вакыйгасының онтологик мәгънәсе – субъектның дөньяны барлыкка китерүдә катнашу-катнашмавын, сакраль субъектның КЕМ булуын билгеләү. Кире кайту процессы, вакыйга статусын алыр өчен, дөньяның элекке халәтенең кабатлануын гына белдерә алмый. Ул субъектның юкка чыгуы дөньяны ничек үзгәртүе һәм субъектның дөньяга нәрсә бирә алуы хакында хәбәр итәргә тиеш»[2], – дип саный Т.Л.Рыбальченко. «Кире кайту ситуациясенең башка генетик чыганагы, тикшерүче фикеренчә, – инициация йоласы: кире кайту белемнең өстәлүен һәм, башка, югары яки аномаль дөнья хакында белем алганнан соң, «үзәк»нең туган, үз пространствоның кыйммәте раслануын дәлилли»[3].

«Яр» драмасында Б.Сәлахов шәхси кыйммәтләрне традицион һәм рухи кыйммәтләр, ыруг кыйммәтләре белән тулыландыру, төгәлләштерү тиеш дип санаучы «туфракчы-язучылар» (рус әдәбият белемендә аларны «писатели-почвенники» дип йөртәләр) карашлары белән аваздаш. Татар драматургы әдәбиятта еш очраган «беленмичә калган кире кайту» сюжетын (В.Пропп)[4] яңа мифопоэтик мәгънә белән тулыландырырга тырыша. XIX гасыр рус прозасы традицияләренә ияреп, автор фабулага ике төрле интерпретация ясый: сурәтләнгән хәлне реаль вакыйга итеп тә, фантастик вакыйга итеп тә кабул итәргә мөмкин. Хикәяләүнең мифопоэтик катламы драматургка «җанландырылган универсум» образын тудырырга булыша. Геройларның исемнәре юк. Алар – әсәргә фәлсәфи төсмер өсти торган гомумиләштерелгән образлар.

Бер яктан, Б.Сәлахов юкка чыккан авыллар, ялгыз картлык фаҗигасе хакында уйлана кебек... Сюжет үстерелеше дәвамында исә «нигезен югалткан кеше» тарихы көнкүреш мәгънә ала, төрле сәбәпләр аркасында туган йорты белән бәйләнешен югалткан кешенең драмасы хакында сөйләүче замана бәяны төсмерләре белән баетыла.

Төп герой килеп кергән авыл дөньясында гармония булмаганлыгына басым ясала. Ул хаос сыйфатларын алган космос рәвешендә сурәтләнә; бу спектакльнең аеруча аскетик һәм шартлы сценографиясендә чагылыш таба. Элекке гармония хакында бизәкле капка калдыклары гына сөйли. Хәрәкәт үстерелешендә бизәкле капка образы иясез калган йортта яшәгән кешеләрнең нәсел агачы символына әйләнә. Бу образ спектакльнең төзелешендә хәлиткеч роль уйный. Авыл йорты образы баулар белән беркетелгән атлама ярдәмендә тулыландырыла; бау очындагы төеннәр туганлык җепләре, туганлык төеннәре *(чаг.: «узы родства»)* метафорасын визуальләштерә. Кызыл йолдызлар белән бизәлеп, сырлап ясалган капка кырыйлары, хронотопны төгәлләштереп, тамашачының игътибарын сугыштан соңгы буын тормышына юнәлтә. Капканың орнаменты татар йорты өчен традицион[5]: агачтан сырлап ясалган бизәкләрдә кояш чыгу, таң ату мотивы; геометрик орнамент (әйләнә, ромб, өчпочмак) өстенлек ала; капканың өске өлеше дулкынсыман формада. Капканың бер ягында төнге күк күренеше, стильләштерелеп, бизәк итеп ясалган. Шул рәвешле, спектакль сюжетының көнкүреш потенциалы визуальләштерелә. Капкадагы бизәк, бер яктан, бабаларыбызның иҗади потенциалын дәлилли, милли декоратив сәнгатьнең бай традицияләре хакында сөйли; икенче яктан, чит җирдә архитектор-урбанист, шәһәр цивилизациясен (бу цивилизация дә юкка чыгу куркынычы астында тора) тудыручы буларак танылган баш герой сәләтенең чыганагын ачып бирә.

---

[2] Рыбальченко Т.Л. Ситуация возвращения в сюжетах русской реалистической прозы 1950-1990-х гг. // Вестн. Том.гос.ун-та. Филология. – 2007. – №1. – С.58-82.

[3] Шунда ук.

[4] Пропп В. Морфология волшебной сказки. – М.: Лабиринт, 2001. – С.55.

[5] Мингазов И.Э. Приёмы декоративного оформления ворот в современном народном жилище (на материалах Кукморского района Республики Татарстан) // Вестник КазГУКИ. – 2013. – №3. – С.45-48.



*Ирьегет — Булат Сәлахов, Айзирәк — Ләйсән Нургалиева.*

А.Гыйләҗев[6] кебек үк, «Яр» драмасы авторы да ишекнең икеләтелгән символикасын актив үзләштерә; ягъни ишекне *тишек* (ярык) һәм *келә* рәвешендә сурәтли. Бу образ *чикне саклау* һәм *чикне җиңеп чыгу,* узу мәгънәсендә килә ала. Шул ук вакытта сценографиядә ишекнең *арка* – сакраль (изге) белән профан дөнья очрашу урыны мәгънәсе дә киң таралган. Спектакльне оештыручылар капка образын да милли-мәдәни коннотация белән баетырга телиләр.

Сюжет үстерелешендә капка *нәсел агачына* (шәҗәрәгә) әверелә. Бу – декорацияне һәлак булган абый-энеләрне символлаштырган йолдызлар белән баету сәбәпле килеп чыга. Шул ук вакытта аркылы борыска нисбәтле әлеге корылма үлчәүне хәтерләтә башлый. Үлчәүнең уң ягында – *тийәк* (диал., сарык түшкәсен эшкәртү өчен махсус җайланма), сул ягында *янгын рельсы* асылынып тора. Сценографиянең бу детальләре корбанчылык һәм язмыш мотивын көчәйтә *(чаг.: «якадан тәкъдир тотты»; «...тәкъдир килеп кысыла» (Нигезен югалткан кеше), «Тәкъдир дисең инде» (Бабай) һ.б.).* «Нигезен югалткан кеше» исә *тийәккә* плащын элеп куя. Шулай итеп, спектакльне оештыручылар, бер яктан, безне геройның үз-үзенә кул салуына һәм үз теләгенә ирешә алмавына әзерли, икенче яктан, геройның нәселенә, үз асылына кайтуын сурәтли. *Плащ* – шәһәр цивилизациясе, чит илдә гомер итү символы. Шулай итеп, метафора аңлатыла: плащын (битлеген) салган герой үз асылын, яшәү мәгънәсен таба. Геройның дөньяга карашында булган кризис тавыш (рельска сугу тавышы) ярдәмендә көчәйтелә (бу вакытта рельска сугу авылда янгын чыкканын хәбәр итә торган чаң сугуның бер инварианты булып тора).

Автор эчке психологизм алымын уңышлы куллана. Геройның эчке монологлары аның җанын, фикер сөрешен ачып бирә *(чаг.: «Сабый бала булып еласаң да» лирик монологы).*

Герой һәм Хозыр Ильяс (юлга чыккан кешеләрнең саклаучысы, юл хуҗасы)[7] арасындагы диалогларга көчле мәгънәви басым ясала. Фольклорчы галимнәр белдерүенчә, Хозыр Ильяс кулына таяк тоткан ак киемле карт рәвешендә була. Аны гади кешедән аеру өчен, кулларына карарга кирәк (аның баш бармакларының берсендә бер буын булмый). Ул, гадәттә, заманага туры килмәгән, көнкүрештә инде очрамый торган иске кием кия (мәсәлән, бизәкле киң чалбар, искечә тегелгән яшел күлмәк). Бу рухка яхшы мөгамәләдә булган, аны хөрмәт иткән кешеләргә Хозыр Ильяс бәхет һәм уңыш алып килә. Тупас холыклы, тәртипсез адәмнәрне

[6] Кара: Хабутдинова М.М. Хронотоп дверь и его функционирование в произведениях Аяза Гилязова // Язык и литература народов Поволжья: проблемы межкультурной коммуникации: Сборник трудов I Всероссийской интернет-конференции с международным участием. Казань, 1-3 октября 2012 г. – Казань: Изд-во Казанский университет, 2012. – С.132-138.

[7] Ислам: Энцикл. словарь. – М.: Наука, 1991. – С.94-95.

исә җәза да күтәргә мөмкин[8]. Спектакльдәге картның костюмында Хозыр Ильяс рухына юнәлтә торган ике деталь бар: яшел чалма һәм агач таяк. Картның сакалы – зирәклек билгесе. Герой өстендәге заманча костюм исә «тылсымлы ярдәмче» образының концепциясенә каршы килә. Яшел чалма кигән карт иң хәлиткеч вакытта – баш геройга дөрес карар кабул итәргә булышу, кирәкле адымга этәрү өчен пәйда була[9].

Әсәрдәге карчык образы да кызыклы. Автор «авылчылар» концепциясенә каршы килә: ул зирәк әбине түгел, ә акылдан язган карчыкны сурәтли. В.Шукшинның «Калина красная» әсәрендәге кебек үк, кире кайткан геройны үз әнисе танымый. Нәкъ менә аны тудырган, аңа тормыш биргән ана «юлдан язган ул»га бәя бирү критерие буларак кулланыла. Ана / ул сюжет сызыгы үстерелешендәге кульминацион мизансцена геройның үз ыруы каршындагы гаебен тагын да көчәйтә. Ләкин, Шукшин әсәреннән аермалы буларак, Б.Сәлахов тамашачыларга вакыйгаларның яхшы тәмамлана алуына өмет бирә: үкенү һәм үз гаебен тануы нәтиҗәсендә герой үз нигезенә кире кайта алачак. Аның әнисе белән сөйләшү күренешендә яулык белән китапларга көчле символик басым ясала. Бер яктан, алар – көнкүреш детальләре, икенче яктан, аерым репликалар контекстында, тамашачы аларның мифопоэтик потенциалын күрә. Улы әнисенә бүләк иткән яулык – геройның яшь вакытта ыруг, нәсел гореф-гадәтләренә тугры булуының дәлиле. Е.М.Бохонная күрсәтүенчә, *шәл / яулык* берәмлекләре халык авыз иҗаты текстларында, «чит дөньяга озатучы» мәгънәсеннән тыш, «дөньялар арасындагы чик» мәгънәсендә дә йөри[10]. Шул ук вакытта спектакль сценографиясендә (сценограф – Булат Ибраһимов) яулыкның берләштерү, саклау вазифасын үз эченә алган йола мәгънәсе дә кулланыла. Яулыклар белән бергә улы истәлеккә җибәргән китаплар да игътибарга лаек. Алар – герой яшь вакытта язган, аның күңел хисләреннән туган шигырь җыентыклары. Чит җирдә ул шигырь язмый инде. Шулай итеп, туган якның тагын бер мәгънәсе төгәлләшә: ул – күңел бакчасы.  Шул ук вакытта китап ахыргача укылып бетмәгән гомер китабы буларак та аңлашыла башлый. Ул – герой җанының символы. Китаптагы ком сибелгән хәрефләр хакындагы реплика исә Коръәндәге сөйләшә торган балчык турындагы мифка барып тоташа.

Шул ук вакытта карчык концепциясендә гаеп темасы үсеш ала. Чөнки балаларны тәрбияләүгә ана җаваплы. Бу яктан авторның *кычыткан* хакындагы мифы кызыклы:

*Ә б и. Кычыткан тәнгә сихәт бирә ул, балам. Ашы да тәмле була. И-и. Элгәре, мин бу йортта торганда, әллә нәрсәләр пешереп ашата идем балаларыма... Тик... артларын чәбәкләргә генә онытканмын.*

*Ә б и. ...Кычыткан тәме керми калган үзләренә...*

*Ә б и. ...Кычыткан пешереп ашасаң, хәтер кире кайта ди менә...*

*Ә б и. ...Кычыткан бит ул, олан, кеше яшәмәгән җирдә үсми. Кешесез яши алмый кычыткан. Аңа, үсәр өчен, кеше күз яше тамган җир кирәк. Кешенең күз яшьләре кычыткан зәһәре булып чыга аннары. Җирдә күз яшьләре беткәч, кычыткан да үсми башлый.*

---

[8] Корусенко М.А., Диянова А.М. Традиционное мировоззрение барабинских татар во второй трети XX – начале XXI вв.: представления о духах-хозяевах «Чужих» пространств // Вестник археологии, антропологии и этнографии. – 2012. – №1. – С.186-195.

[9] Чаг.: Хозыр образы А.Гыйләҗевнең «Урамнар артында яшел болын» романында сурәтләнә. Кара: Хәбетдинова М.М. Аяз Гыйләҗевнең 1973-1985 еллар иҗатына гомуми күзәтү // Гыйләҗев А.М. Сайланма әсәрләр. 6 т. – Т.4. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2015. – Б.604.

[10] Бохонная Е.М. Функции цветообозначения единиц с семантикой «одежда» в лирической песне (на материале сибирского фольклора) // URL: library.krasu.ru (дата обращения: 12.05.2000)


*Ирьегет — Булат Сәлахов, Әби — Гөлүсә Гайнетдинова.*

Автор мифының фольклор нигезләре турында без «Бер үлән бар чокырда, аны таный сукыр да» табышмагыннан һәм кычыткан чыпчыгы турындагы халык мифыннан беләбез: «Кычыткан чыпчыгы: «Үз өем, үз илем!» – дип сайрый икән. Моның өе кайда дип карап торсалар, кычыткан арасында кычыткан ефәгеннән үргән оясына кереп киткәнен күргәннәр».

Пьесада «Ишегалдын тутырып үскән кычытканнар – йортның бердәнбер сакчылары»; «Кычытканнар гына корып, искән җилдән хәбәр көтеп, сызгырып, җырлап утыралар» (автор), «Изге җаннар» (Әби), «Иң беренче кычыткан да түмәр астыннан чыкты», «Кычытканнар саклый бу нигезне» (Бабай), «Кычытканнар соңгы тапкыр чыктылар быел» (Түмер), диелә.

Шулай итеп, автор символикасында кычыткан дөньяның милли образына әверелә; ул туган якка булган мәхәббәтне символлаштыра, танып белү, саклау-яклау һәм җәза бирү идеяләрен күтәрә. Әкияти традиция кысаларында кычыткан (герой йортын калдырып торган вакытта) аның вазифаларын үти: кече угыл сыман, нигезне саклый.

Геройның малай, үз-үзе белән очрашуы сюжетта зур урын алып тора. Тамашачы геройны бала чагында «почык борын» дип йөртүләре хакында белеп ала. Авылда кушаматлар кешегә характеристика бирү өчен кулланылган. Бу кушамат исә геройга хас мин-минлек хакында сөйли һәм ниндидер дәрәҗәдә аның тормыш драмасының сәбәпләрен аңлата. Интертекстуальлек алымы ярдәмендә әлеге кушамат безне «Түләк һәм Сусылу» дастанына юллый; бу әсәрдә горур баш герой ярлы кием кигән хөкемдар атасын танымаган булып кылана. Бу исә кире кайту сюжетын яңа мәгънәләр белән баета. Балта һәм түмер сценасына зур басым ясала, ул кешедәге мин-минлекнең чагылышы гына түгел, хаос билгесе дә. Түмернең сакральлеге исә туган нигезнең, нәсел хәтеренең изгелеген символлаштыра.

Малай ярдәмендә герой әтисенең бабайлар зирәклеге белән сугарылган васыятен исенә төшерә (кендек каны хакындагы миф).

Малай геройга бүләк иткән сакраль предмет – кылыч ярдәмендә бабаларның сугыштагы батырлыгы турында сөйли.

Кәләшкә бәйле сюжет сызыгында яулык туй йоласының элементы булып аңлашыла. Ак төс кыз күлмәгенең аклыгына тәңгәл килә, бу исә туй темасының үстерелеше өчен җавап бирә. Ак төс – сафлык символы. Ак күлмәк кигән кыз ак күгәрчен белән чагыштырыла. Канатлар вазифасын исә канатларга охшаган җиңнәр башкара. Кыз йөгереп киткәндә, бу бигрәк тә ачык күренә.

Икенче яктан, ак яулык – мәхәббәттәге уңышсызлык символы да. Фольклорчылар билгеләвенчә, яулыкның нинди төстә булуы зур мәгънәгә ия. Ачык, якты төстәге яулык бәхетле мәхәббәтне символлаштырса, әлеге баш киеменең төсне югалтуы бәхетсез мәхәббәт символы булып тора.

Кыз образында безгә «Чура батыр» дастаныннан таныш булган ярәшелгән кыз / кәләш мотивы да бар: «әткәйләр дә сүз куешканнар ич» (кыз). Халык авыз

иҗаты әсәрләрендә герой һәрвакыт «үз» пространствосындагы кызга өйләнергә тиеш була. «Чит, ят дөнья» вәкилләренә өйләнү исә геройга бәхетсезлек китерә (чаг.: «Сусылу һәм Түләк»). «Яратмыйча гына өйләндең. Кызларың бар» (Кыз). Ярәшелгән кызга хыянәт итү дә шулай бәяләнә (чаг.: «Чура батыр»). Кызның «Еллар буе йөреп» лирик монологы гашыйклар вәгъдәсе кебек яңгырый. Кыз / хатын антитезасы чынга ашмаган бәхет темасын көчәйтә[11].

Әсәрдә сөйләм характеристикасы да мөһим роль уйный. Кыз геройга хөрмәт белән «Ирьегет» дип эндәшсә, хатыны аны «Исерекбаш» дип атый. Туй темасының финал аккорды булып спектакльдә *НИГЕЗ, ЙОРТ, ТҮМӘР*дән торган хор репликалары яңгырый.

*Н и г е з. Нинди ямьсез хатын.*

*Й о р т. Усал...*

*Т ү м ә р. Нигезен тапкан кешене кыерсытты.*

*Н и г е з. Мин аның нигезе түгел.*

Нигезнең репликасы туй йоласы контекстында аңлашыла башлый. Татар гаиләсендә туйдан соң кыз, исемен югалтып, йорт кешесенә – киленгә әверелгән. Шулай итеп, йорт туган йорты өчен җаваплы булган геройның хатынын һич тә кабул итә алмый.

Кыз концепциясе туй йоласы кануннарына җавап бирә дип әйтергә мөмкин. Спектакльне оештыручыларның кызның профессиясен сыер савучыга үзгәртүләре генә кызганыч. Б.Сәлахов әсәрендә Айзирәк – хат ташучы. Билгеле булганча, почта заманча әсәрләрдә үз / чит пространствоның чик вазифасын башкара (Убырлы карчык образының инварианты), ә хат ташучы исә ике дөньяны тоташтыручы булып төгәлләшә. Кызның ишарәсе һәм «күрше авылда сыер савам» репликасы беренче мәхәббәт аурасын һәм идеаль героиня романтик образын юкка чыгара (исемнең мәгънәсенә игътибар итегез: Айзирәк – «Зирәклегенә сокланырлык кыз»[12]).

Авыл кешесе (Илфат Әскәров) авылның бүгенге халәтен символлаштыра. Ул Шукшинның «Сәер кешеләр»ен хәтерләтә: «Ул – кайгыра һәм эш-гамәлләр кыла белә торган тере кеше; һәм, әгәр дә аның күңеле авыру, ә гамәлләре гомуми кабул ителгән фикер буенча мәгънәсез икән, сез аның ник шулай булганлыгын аңларга тырышыгыз, үзегездән мин аңа кызыгып карамыйм микән дип сорагыз» (Шукшин, «Чудик»).

Авыл сәрхушенең күңелендә әле гаделлек, шәфкатьлелек, ярдәмчеллек бар, ул бәхетсезлеккә очраган кешегә булышырга әзер.

Герой, үз-үзенә кул салып та, ниятенә ирешә алмагач, Хозыр Ильяс аңа Ибн Фадлан язмаларында очраган зирәк кеше турында миф сөйли. Һәм геройның үз-үзен үтерергә теләвен кан тартуы белән аңлата. Ибн Фадлан иң акыллы болгарларның үзләрен Аллага багышлаулары (корбан булулары) хакында яза. «Синдә шул бабаңнарның каны уянып-уянып ала булыр. Синең дә вакыт-вакыт изге буласың килә», – дип аңлата Карт. Ләкин авторның бу мифында хата бар: әлеге йоланың татарларда киң таралган әүлия культы белән бер уртаклыгы да юк. Үз-үзенә кул салучы беркайчан да изге була алмый. Бәлки, авторның бу мифы тамырлары белән борынгы риваятькә барып тоташадыр. Ул төркиләрнең бер йоласы турында сөйли. Хөкемдарга аеруча якын булган бәкләр аны, киез өстенә утыртып, тугыз тапкыр кояш йөреше буенча әйләнгәннәр. Шулай сәламләгәннән соң, хөкемдарны ат өстенә утыртканнар да муенына ефәк яулык бәйләп буарга

[11] Фольклор. Особенности функционирования частушечного символа // URL: http://slavyanskaya-kultura.ru/slavic/tradition/folklor-osobennosti-funkcionirovanija-chastushechnogo-simvola.html.

[12] Саттар-Муллиле Г. Татар исемнәре ни сөйли? – Казан: «Раннур» нәшр., 1998. – Б.337.

тотынганнар, үзләре аннан: «Син ничә ел идарә итә аласың?» – дип сораганнар, имеш. Шулай итеп, әлеге йоланың максаты илнең киләчәген ачыклау булган. Бу аспектта геройның әлеге гамәле тормыш мәгънәсен аңларга, киләчәктә үзен ни көтүен белергә теләве белән аңлатыла.

Әсәрнең финалы ачык. Герой үзен бер авылдашы таныгач («Карале, син безнең Җирьегет малае Ирьегет түгелме?») юкка чыга. Б.Сәлахов та А.Гыйләҗев концепциясенә тугры кала. Туган ягыңның «өч аршын җиренә» дә әле лаек булырга кирәк икән бит! Чит илләрдә сәяхәт итү драмада адашып йөрү белән тиңләштерелә. Тамашачы кечкенә кешенең, эше уңмый торган адәмнең, дәүләт системасы һәм шартлар корбанының тәүбәсен түгел, ә шактый зур уңышларга ирешкән шәхеснең истигъфарын ишетә. Шулай да бу уңыш та, бәхет тә чын түгел (ком мотивы), алар уйлап кына табылган; ә үтәлмәгән вәгъдәләр өчен кайчан да булса җавап бирергә кирәк булачак. Без спектакльдә ахыр чиккә җиткән өметсез герой белән очрашмыйбыз. Аны әле җәмгыять кабул итәргә дә мөмкин. Хәзер инде ул нигезнең кадерен белә... Без нигезен югалткан угыл белән ул үкенү стадиясенә җиткәндә аерылышабыз. Тамашачыларга катарсис һәм үз нигезеңне саклап калуга өмет уята, ярдан тәгәрәргә түгел, ә аңсызлык баткаклыгыннан чыгарга ярдәм итә торган «Яр» спектакленең әхлакый нәтиҗәсе менә шул. Авторның искәрмәсендә шундый шәрехләү бар: кеше кабер казый, озаграк казыган саен, ул биегрәк күтәрелә. Бу – авторның тормыш метафорасы. Кеше туганнан бирле үлемгә юл тота. Аның тормыш юлы – җиңүләр, табышлар һәм югалтулар чиратлашуы ул. Һәрбер кешенең нигезе, рухи фундаменты бар, һәм аны саклап калуга һәркем үз өлешен кертергә тиеш.

Б.Сәлаховның драмасы безне мифологик тышча артында хәзерге иҗтимагый тормыш чагылган борынгы грек трагедиясенә юллый. *Нигез, Йорт* һәм *Түмер*дән торган хор лирик новелланың драматизмын көчәйтү, борынгы бабаларыбыз һәм автор фикерен белдерү өчен кирәк. Әйтерсең лә хор туган йорт сакраль пространствосының космик энергиясен активлаштыра, туган йорт төшенчәсе изгеләр кабере, курганнар белән баетылган туган җир, Ватан мәгънәсенә кадәр киңәйтелә.

Актёрларның уены самимилеге, тәэсирлелеге белән җәлеп итә. Әни ролен башкарган Г.Гайнетдинова артык мелодраматизмсыз образны ачып бирә. Хозыр Ильяс (Р.Каюмов) ата һәм житәкче вазифалары арасындагы балансны саклый ала. Р.Каюмовтан үз көченә ышаныч, рухи көч бөркелеп тора, ул тамашачылар хәтерендә тере образ калдыра. Кыз (Л.Нургалиева) сәхнәдә беренче мәхәббәт аурасын тудыра; Ф.Сәхәбетдинов тамашачыларны малайларча шаянлыгы, дөньяга якты карашы белән куандыра; Хатын (Р.Таһирова) исә бик кыска эпизодта да әрсез холкын, усаллыгын, рухи ярлылыгын күрсәтә. Актёрлар коллективына, бизәлеш рәссамнарына (Булат Ибраһимов), режиссёрга (Фаил Ибраһимов) – композиторга (Нияз Тарһановка) искиткеч, ихлас, рухи яктан бай спектакль һәм кызыклы сценография өчен, ә авторга күңелгә ләззәт, уйланырга азык бирә торган әсәр өчен бик зур рәхмәт.

**Миләүшә ХӘБЕТДИНОВА,**
*филология фәннәре кандидаты*

# ТЕАТР – ҖӘМГЫЯТЬНЕҢ БАРОМЕТРЫ УЛ

## Кәрим Тинчурин театрында режиссёрлык мәсьәләләре

Татар театрына 110 ел. Әлеге датаны бөтен татар театрлары, шул исәптән Кәрим Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры да билгеләп үтә.

1993 елның 10 мартында театрның баш режиссёры итеп Рәшид Заһидуллин билгеләнә. Театрны үзгәртеп кору, күчмә халәтеннән тотрыклы, тулыканлы стационар театрга әверелдерү нәкъ менә аңа насыйп була.

Беренче дистә елда режиссёр эзләнүләр алып бара, төрле авторларның төрле чорга, жанрга караган әсәрләрен сәхнәләштерә. Р.Заһидуллин үзенең җитди иҗади эшчәнлеген Н.Фәттахның күпсюжетлы, күпкырлы «Итил суы ака торур» романыннан башлый. Әлеге спектакле белән беррәттән, Х.Вахитның «Кияүләр», Г.Зәйнашеваның кабатланмас Н.Шәйхетдинов һәм Л.Миңнуллина катнашындагы «Гайфи бабай, өйлән давай», Т.Гыйззәт һәм Җ.Фәйзинең «Башмагым», Мольерның гаҗәеп көлкеле «Галиҗәнап де Пурсоньяк» комедияләре озак еллар репертуардан төшми уйнала.

1990 еллар афишасында И.Грекованың «Тол хатыннар көймәсе» психологик драмасы, К.Тинчуринның күренекле «Сүнгән йолдызлар» мелодрамасы аерым урын ала.

«Тол хатыннар көймәсе» драмасында режиссёр сугыштан җаннары теткәләнгән хатыннарның йөрәк җылысын үҗәтләнеп сакларга тырышуларын тынчу мохит аша тасвирлый, сугыш фаҗигасен анык күрсәтә. Сугыш темасын дәвам итеп, Р.Заһидуллин Тинчурин театры сәхнәсендә беренче тапкыр күренекле драматург, антифашист Бертольд Брехтның катлаулы, сугышка каршы ярсулы «Кураж ана һәм аның балалары» әсәрен сәхнәләштерә. Брехт беркайчан да татар сәхнәсендә куелмады. Аның әсәрләрен милли тамашачы кабул итмәс дип уйладылар. Р.Заһидуллин исә тәвәккәлле. Һәм шунысы символик мәгънәгә ия: ул аны чечен сугышы чәчәк аткан чорда куйды.

Режиссёр документаль хәрби кинокадрлар, тәкъдир билгесе, сугыш символы буларак Үлем битлеге кебек төрле һәм көтелмәгән сәнгатьле чаралар кулланып, сәяси спектакль тудырды.

Театрда тәүге тапкыр Г.Тукайның «Сөй гомерне!», М.Мәһдиевнең «Без – кырык беренче ел балалары» һәм Р.Вәлиев әсәрләре буенча куелган «Язмышым юллары» кебек поэтик спектакльләр барлыкка килде.

1990 елларның икенче яртысы, 2000-2016 ел-



*«Сүнгән йолдызлар» (Кәрим Тинчурин) музыкаль трагедиясеннән Аулагөй күренеше. Режиссёры – Рәшид Заһидуллин.*

лар, югарыда телгә алынган куелышлардан тыш, К.Тинчуринның «Сакла, шартламасын!», «Хикмәтле доклад», Т.Миңнуллинның «Яшьлегем-юләрлегем», «Төш», «Саташу», М.Кәримнең «Айгөл иле» һ.б. спектакльләр белән дә истә калды.



*«Йосыф-Зөләйха» (Нурмөхәммәт Хисамов) риваятеннән бер күренеш. Йосыф – Илфак Хафизов, Зөләйха – Резедә Сәләхова. Режиссёры – Рәшид Заһидуллин.*

Соңгы елларда театрда яшь режиссёр – Р.Заһидуллинның шәкерте Резеда Гарипова эшли башлады. Ул инде К.Тинчуринның «Сүнгән йолдызлар», Э.М.Ремаркның «Без барыбыз да кешеләр», И.Юзеевның «Гашыйклар тавы», Р.Мингалимнең «Өченче бүлмәдә эт яши», Ш.Хөсәеновның «Чулпан» кебек берничә үзенчәлекле спектакль куярга өлгерде. Р.Гарипова, остазы кебек үк, актёрлар белән кыю эшли, метафоралардан оста файдалана һәм, һичшиксез, баш режиссёрның терәге булып тора.

Бүгенге көн театр тормышындагы иң мөһим куелышларның берсе – Т.Миңнуллинның «Төш» спектакле. Сәхнә әсәре тормышта үз урынын таба алмаган кеше фаҗигасен сурәтли. Төп рольләр – Елена белән Камилне гаҗәеп зур осталык белән Г.Нәүмәтова һәм Илфак Хафизов башкара. Шул ук елны «Төш» спектакленнән соң, Р.Заһидуллин Н.Хисамовның (Кол Гали буенча) «Йосыф-Зөләйха» әсәрен сәхнәләштерә. Үлемсез әсәр безнең уйларны моннан меңъ еллар элгәре булган чорларга, әүвәл «Ветхий завет»та, аннан исә Коръәннең 12нче сүрәсендә бәян ителгән Йосыф белән бәйле вакыйгаларга алып китә. Р.Заһидуллин әсәрдә үзен борчыган мәңгелек проблемалар белән очраша. Спектакльдә мәхәббәт, тугрылык һәм хыянәт темалары булса да, режиссёрны тормыш кыйнавына бирешмичә, кешенең катлаулы язмышын җиңә алуы мәсьәләсе, үз-үзенә, үз көченә ышануы кызыксындыра. Режиссёр бу теманы тормышның төбенә кадәр тәгәрәп тә кабат күтәрелә алган, алай гына да түгел, хаким дәрәҗәсенә ирешкән Йосыф язмышы аша ассызыклый.

Абыйларының үз энеләренә хыянәт итү күренеше дә, геройларның киләчәк тормышында урын алган башка вакыйгалар да сәнгати-сурәтле итеп чишелгән.

Персонажларның бөтен уй-фикерләре, эш-гамәлләре бер ноктада кисешә һәм алар барысы да әсәрнең төп каһарманы Йосыф, аның тормышы, холкы, кешеләргә, чынбарлыкка мөнәсәбәте белән бәйле. Илфак Хафизов, поэма авторының үзе кебек үк, Йосыфны эчке һәм тышкы яктан да матур, күркәм, изге күңелле, сабыр, пакь ниятле кеше итеп күрсәтә.

Тагын бер истәлекле вакыйга 2013 елның язында булды. Театр тамашачыларга күренекле инглиз драматургы Шекспирның «Гамлет» әсәрен тәкъдим итте. Р.Заһидуллин тулаем гаилә тарихы турында спектакль куя. Анда патша гаиләсе генә түгел, ә үз балалары өчен теләсә нинди адымга да барырга сәләтле Полоний гаиләсенә кагылышлы вакыйгалар да зур урын алган.

Фаҗигадә төп рольләрне Р.Заһидуллинның үз шәкертләре – А.Пискунов (Гамлет), Р.Сәләхова (Офелия), Илфак Хафизов (Лаэрт), З.Закиров (Горацио) башкара. Тамашачы тын да алмый Гамлеттагы үзгәрешләрне күзәтә. Аның



*«Өченче бүлмәдә эт яши» (Рөстәм Мингалим) комедиясеннән бер күренеш. Галия – Зөлфия Вәлиева, Райман – Ирек Хафизов. Режиссёры – Резедә Гарипова.*

күңелен җәрәхәтләгән этисе үлеменә бәйле авыр кайгы, әнисенең артык ашыгып кияүгә чыгуы белән килешмәве, хыянәт һәм вакҗанлылык белән очрашуы тора-бара дөньякүләм фаҗигагә әверелә. Бу Гамлет әле яшь. Шуңа да ярату, игелек хөкем сөргән тыныч шартларда үскән, хәзер исә явызлык, мәкер белән күзгә-күз очрашкан әлеге үсмер егет өчен йөрәк әрни. Тирә-ягындагыларның кем икәнлеген аңлаганның соңында ул якыннары – әнисе (Җ.Әсфәндьярова), король (Р.Шәмсетдинов), Полоний (З.Харисов), элеккеге дуслары (Х.Хөснетдинов, Б.Зиннәтуллин), Офелия (Р.Сәләхова) белән мөнәсәбәтләрен төрлечә кора. Р.Сәләхова үз героинясы язмышының драматизмын тулысы белән яктырта.

«Гамлет»тан соң театр көндәлек эшчәнлеген дәвам итә – К.Тинчуринның «Назлы кияү», Ф.Г.Лорканың «Өметсез хыяллар», С.Мрожекның «Шашкан бабай» («Король»), А.Гыйләҗевнең «Ефәк баулы былбыл кош» спектакльләрен сәхнәләштерә.

Р.Заһидуллин, поляк драматургиясе классигы С.Мрожекның Татарстанда билгеле булмаган «Король» абсурд пьесасын (татарча аны «Шашкан бабай» дип атадылар) куеп, чираттагы мәртәбә тамашачыны гаҗәпкә калдырды. Пьеса режиссёрны билгесезлеге, эчтәлеге, стилистикасы һәм формасы белән җәлеп итә. Әсәр кеше үтерү теләге турындагы коточкыч сюжетның заманга аваздашлыгы һәм спектакль аша шуның киресен – җирдә тыныч күк йөзе, игелек һәм мәхәббәт булдыру теләген күрсәтү мөмкинлеге булуы белән дә гыйбрәтле. Бабай белән Оныk «кирәк булган өчен» генә ниндидер бер Корольне үтерергә омтыла. Тик алар моны ни өчен эшләргә кирәклеген үзләре дә белми. Аларның җирдәге барлык Корольләрне дә юкка чыгару омтылышы абсурдка гына түгел, башбаштаклыкка китерә. Юлларына каршы төшкән бөтен кешене дә юкка чыгару ихтималы булуы метафора буларак яңгырый.

Спектакльдә нибары өч төп персонаж һәм тагын бер сүзсез Кыз образы бар. Актёрлар – З.Закиров (Окулист), А.Фәтхуллин (Бабай), С.Хәбибуллин (Оныk), К.Галиева (Кыз) образга хас характерларның көтелмәгән, сәер якларын ачып, ниндидер иблискә хас, явыз фантасмагория мохите тудыра. Мрожек пьесасы режиссёр тарафыннан актёрларга үз рольләрен гадәтләнгәнчә түгел, ә башкача эшләргә мөмкинлек бирә.

Хәзерге вакытта К.Тинчурин исемендәге театр – республикадагы төп театр коллективларының берсе. Ул – профессиональ режиссурасы, көчле актёрлар труппасы, халык ихтыяҗын канәгатьләндерә торган лаеклы репертуары булган тотрыклы, заманча театр.

**Ильтани ИЛЯЛОВА,**
*театр белгече*



Әхәт
Сафиуллин

# ШАЯН МОНОЛОГЛАР

### Аерма

Бәрәкалла! Палатабызга адәми зат шуышып кереп килә түгелме?! Кеше бит, җәмәгать, валлаһи, кеше! Әй, энем, кая шуышасың болай? Әйе, бишенче каттагы икенче палата шушы була. Сине дә шушында җибәрделәрме? Ярар, түргә уз, алайса! Нигә шулай шатланасың? Икенче көн шуышам, дисеңме?! Кичә ярты юлда «скурый» машинасының бензины бетте? Бара тор, куып җитәрбез, диделәр? Дөрес, энем, беркемнең дә «скурый»да җан тәслим кыласы килми шул. Куып җитә алмадылармы? Аннан соң тәгәрмәче җибәргән? Их, каһәр суккыры! Бер уңмаган юлга чыксаң, шулай була шул, энем: каршы килә дә тора!

Алай да бә-әк нык кеше икәнсең, тешеңне кысып булса да бульнис ишеге төбенә килеп егылгансың. Мулудис, энем! Хәзерге заманда үзең селкенмәсәң, башкалар кымшанып та карамас. Врачларга рәхмәт әйт, баскыч төбеннән өстерәп алып кергәннәр үзеңне. Әпиндисең шартлаган, диделәр? Тик нишләп сине монда арба белән алып менмәделәр соң? Ә-ә, дөрес, энем, лифте дигән нәрсәләре инде ел ярым эшләми, диләр. Ул чагында арба белән сине бишенче катка ничек алып менсеннәр?! Әкренләп үзең мен, алайса, диделәрме? Шулайдыр, энем, тагын нәрсә әйтсеннәр инде алар?..

Әгәр шулхәтле яшисең килә икән, уз энем, уз! Унбиш кеше сыйганны, уналтынчысы гына сыярбыз. Сугыш вакытында бер землянкәдә йөзгә якын кеше яткан чакларыбыз булды. Иту түздек!

Карале, энем, кулыңдагы төенчегеңдә мина-фәлән түгелдер? Дошман танкысы астына ташланырга җыенган солдат шикелле шуышасың... Пычак, энә, җепләр? Мулудис, аперацси ясарга кирәк нәрсәләрне алгансың. Хәзерге заманда бульнискә үз кирәк-ярагыңны кыстырып баруың хәерле. Тик ярар микән синең ул әйберләрең? Мин үзем, бүсереңне алу өчен корсагыңны ярырга пычак кирәк булыр, дигәч, авылга кайтып, пычакны чалгыдан ясатып килгәнием – ошатмадылар. Безгә медисинский пычак кирәк, диделәр. Менә шулай, энем, аларга ярап та булмый. Аннары тегәргә кәтүк җебе дә ярамый икән. Хайван эчәгесеннән ясаганы кирәк, диделәр. Нишлисең, авылга кайтып сарык суярга туры килде. Шуның эчәгесен телгәләп киптердек. Анысы ярады...

Алай да өметеңне өзмә, энем, аперацси ясый торган көннәрдә кирәкле струмитларны башка бульнистән дә алып торгалыйлар. Тик чират җиткәнче

Әхәт САФИУЛЛИН *(1936) – язучы, журналист, тәрҗемәче; «И гомер, гомер...», «Кешене өмет яшәтә», «Тормыш сукмаклары», «Җиденче буын», «Ике роман» һ.б. китаплар авторы. Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. Казанда яши.*

үлмәскә генә тырыш, аператсига тикле түзә алсаң, яшисең дә яшисең аннары! Тик аператсидан соң нинди дарулар кирәген белешеп куй: туган-тумачаларың эзли торсын. Шуларны тапмасалар, Алла сакласын, каравыл кычкырып ятарсың. Яраң да төзәлмәс, өеңә шул тишек корсагың белән кайтып китәрсең.

Туктале, энем, тукта, нишләвең бу?! Куй минем банканы урынына! Соң, эчәсе килә, дип, шуны эчәргә дигәнме?! И-и, җүләр, ниткән сыра булсын? Кил монда, мин сиңа сок бирәм. Эчеп җибәр әле рәхәтләнеп. Хәер, туктале, энем, сиңа эчәргә дә ярамыйдыр әле. Врачлар килгәч, иртәгә алардан сорарсың. Бүгенме? Бүген кайтып киткәннәрдер инде.

Хәер, белмәссең, берәрсенең килеп чыгуы да бар. Кайчакта кергәли алар.

Нигә чыраеңны сыттың, энем, бик авыртамы? Кычкырмас өчен, син авызыңа яулык йомарлап кап! Безнең баштан үткән нәрсә инде ул. Вакыт җитмичә үлеп булмый – түзәргә кирәк. Әлбәттә, Ходай өмет дигән нәрсәдән дә аермасын! Элегрәк түзүе ансатрак ие: бик авырта башласа, укол кадыйлар иде дә, хәтта йоклап китә иең... Ә хәзерге заманда кайдан алсыннар ул даруларны?

Моннан ундүртенче караваттагы ирне күрәсеңме? Әйе, китап укып ята. Менә өмет нишләтә кешене! Үлгән дип, мурыгка чыгарып аткан булганнар мескенне. Ә ул, өч көн, өч төн шунда яткач, ыңгырашып куйган. Ышанмаганнар, әлбәттә. Ныграк ышану өчен шунда тагын ике көн яткырганнар. Ул кычкыра ук башлаган! Алып менделәр аннары. Ә хәзер әнә, үзең күрәсең... Укымаган нәрсәсе юк! Көнен дә укый, төнен дә. Төнен хәтта утсыз укый! Мурыгта караңгыга ияләшкән. Бәхете дә бар икән үзенең. Мурыгның суыткычы ватылган чакка туры килгән! Әгәр шул эшләгән булса, катып үлгән булырые...

Ике көн, бер төн шуыша-шуыша хәлең дә беткәндер. Ә-ә-нә моннан уналтынчы караватсинеке булыр. Ят та ял ит, көч җый, сабыр әйлә! Сөенергә дә онытма: бездә дәвалау бушлай бит, энем! Әгәр син шартлаган әпиндисең белән Әмрикә бульнисенә керсәң, беләсеңме, күпме акча түләгән булырыең? Ә бездә – Ходай кушып, исән калсаң, – бер тиен дә түләмисең! Сизәсеңме аерманы?

Бар, энем, бар, авызыңа яулыгыңны йомарлап кап та ял ит!..

## Каян белә дигән!

Хатын-кызның бер дә белмәгән нәрсәсе юк! Мин үзем ничәнче размерлы туфли киюемне дә белмим, хатынымнан сорыйм. Баш киеме алырга кирәк булганда да: «Онытa күрмә, илле җиденче размерлыны киясең син!» – дип, кат-кат тукып чыгара. Җитмәсә: «Кара аны, бүрек урынына Гулливер ботинкасы алып кайтма тагын!» – дип кала. Монысы былтыргы хәлгә ишарә инде...

Былтыр аягыма алырга чыкканда, ул әйткән размерны онытып, ялгыш күлмәк размерын әйткәнмен. Сатучының күзе маңгаена менде:

– Үзегезгәме соң ул?!

Минем дә ирлегемне күрсәтәсем килде: «Миңа булмый, кемгә булсын?!» – дидем. Шулай дигәч, ул да сүз куертып тормады, иң зуры шушы, дип, кулыма бер тартма төртте. Кайткач ачып карасак, кырык сигезенче размерлы ботинка! «Син аны киеп карамадыңмыни?» – диде хатын. Менә ничек: әйберне киеп карап алырга кирәклеген дә белә бит алар!

Шушы арада хатыннан тагын бер яңалык ишеттем. Шулай беркөнне ул мине базарга бәрәңгегә дип җибәрде. Карыйм – юк яхшы бәрәңге! Бер-ике җирдә чикләвектәй бәрәңге генә саталар. Кая андыйны аласың инде?! Хатының шул бармак башы хәтлеләрне әрчеп утырсынмы? Дәлше киттем. Күрәм, берәү

чөгендер сатып утыра. Чөгендерләре баш хәтле! Менә, мин әйтәм, боларны әрчүе үзе бер рәхәттер. Алып кайттым шуларны бәрәңге урынына. Менә шунда әйтте ул миңа теге яңалыкны. Бер чөгендергә, бер миңа карап:

– И-и, җаныем, быел сиңа алтмыш тула түгелме соң инде! – диде.

– Син нәрсә, – мин әйтәм, – ниткән алтмыш ди әле?!

Бәхәс чыкты. Шунда ул миңа кайчан өйләнешкәнебезне, кызларыбыз Гөлзадә белән Светлананың кайчан тууларын, кайчан кияүгә чыгуларын, оныкларыбыз Руслан, Эльдар һәм Даниска ничә яшь булуларын тезеп китте! «Кайдан белә икән ул боларны?!» – дип терәлдем дә каттым! Ахырда паспортымны алып килеп күрсәтте. Аның кайда ятканын да белә икән! Карасам, әгәр паспортка дөрес язган булсалар, миңа, чыннан да, төп-төгәл алтмыш тула икән шул! Ә мин һаман үземне кырыкта дип йөрим...

Кыскасы, хатынга ышанырга туры килде. Алай да бу турыда шауламаска куштым. Чөнки безнең халык кеше ышанмаслык сүзне дөрес булса да сөйләмәү ягында. Җир җимертеп йөргәндә, нинди алтмыш ди әле?!

## Аркистыр, имеш!

Халык ялкауланды, хәйләкәргә әйләнде. Кая ул хәзергеләрдә элеккеге тырышлык! Әле менә беркөн, Казанга кунакка килгәч, малаем аркистыр кансиртына алып барды. Кызык нәрсә икән ул аркистыр дигәннәре: андагы кеше! Безнең авыл клубы хәтле сәхнә тулып утырдылар! Ике мәртәбә санарга тырышып та очына чыга алмадым. Барысының да кулында ниндидер уен коралы, ә күтәрергә авыр дигәннәрен идәнгә куйдылар. Андагы иструминтлар исемен артислар үзләре дә белеп бетермидер...

Утырыштылар. Шуннан соң кулына кечтеки генә таяк тоткан берәү каршыларына чыгып басты. Прафиссыр, диделәр. Әнә шул прафиссыр дигәннәре таягын селтәп җибәрүе булды, дөбер-шатыр килеп уйнап та җибәрүләре булды, купты тавыш, купты тавыш! Стеналар селкенә! Куркуымнан түшәмгә карап куйдым. Шушы тавышка менә шушы люстыра килеп төшсә, мин әйтәм, бездән юеш урын гына кала, сөякләрне дә җыеп алалмаслар. Хәвеф-хәтәрләрдән саклый күр, Ходаем!.. Бераздан тынычландым: килеп төшәрлек итеп эләләрме соң? Аркистырда уйнаучыларны күзәтәм. Булдыралар, тырыша-тырыша уйныйлар, ә теге, аларның каршысына баскан прафиссырның кызуы җиткән – таягы белән генә түгел, инде кулы белән дә селтәнә башлады. Кайчак йодрыгын да күрсәткәләп алган шикелле. Барыгыз да уйнагыз, диюедер, мөгаен.

Туктале! Карыйм, барысы да уйнамый бит! Кайберсе кулындагы иструминтына онытылганда бер генә кагылып ала. Ә үзләре, уйнаган атлы кыланып, әллә кызыклы журналмы, әллә китапмы укыштыргалап утыра. Менә сиңа аркистыр, мин әйтәм! Кешедән акча җыеп, җүләр сатып утыралар! Ачуым килмәгәе, андагы иллеләп кешенең яртысы шәләй-вәләй генә уйный бит! Халык алдына чыккансың икән, бөтен күңелеңне биреп, намус белән уйнарга кирәк!

Эш урыннары чиста, бөтен җир ялт-йолт итеп тора. Шунда да хәйләгә керешәләр. Их, мин әйтәм, шундый яхшы эшләренең кадерен белмиләр. Кызларына резин итек кидереп, бер генә көн безнең фермада сыерлар саудырасы, ә ир затларына абзар чистарттырасые боларның! Йә көзге пычракта бер генә мәртәбә безнең авыл урамыннан уздырасы! Шуннан соң белерләрие эшләренең кадерен! Нибуч, алларына күзәтүче прафиссыр бастырып куймыйча да уйнарларые.

Нигә шулхәтле кеше чыгарырга? Заманында, Ленин бабабыз кушканча, аз

булсын, яхшы булсын, дип яши идек. Монда да тырыш, үз эшен чын күңелдән яратканнарын гына сайлап аласы югыйсә. Юк, күп кеше җыелгач, яхшы була, дип уйлыйлар бугай. Алай түгел шул. Хәзер, гомумән, коллектив хезмәттән баш тарта башладык бит инде. Чөнки хезмәт убшый булганда, ялкаулар үрчи. Безнең колхозда моны күптән аңладылар. Шуңа күрә кооператив дигән нәрсә оештырып куйдылар. Элек барыбыз да колхозныкын урладык, хәзер уртак эш өчен, элек урлаганнарны кооперативка вакытлыча биреп торабыз. Кем атын, кем арбасын, кем сукасын, кем көрәген... Бөтенләй аяктан егылмас өчен. Шунсыз кая китәсең... Булган техника тузды, тузмаганын сатып эчтеләр...

Аркистрда да шулай кирәк. Әйтик, син эскрипкәдә уйныйсыңмы? Бик яхшы. Чык та уйна, күрсәт үзеңне! Кешегә салынмыйча гына. Ә син кәкре-бөкре торбада уйныйсыңмы? Бик хуп, чык, уйна! Өр күркәдәй кабарынганчы! Күрсәт кемлегеңне! Һәрберсе әнә шулай ялгызы гына чыгып уйнаса, барысы да ниндидер җаваплылык сизәрие. Ә болай...

Аннары ул чиертеп уйный торган иструминтларның яртысы да бик җиткән, барыбер ишетелми бит убшый уйнаганда.

Аркистырга кушылып җырлауларын әйт тагын. Җүнле кеше аркистырга түгел, гармунга кушылып җырлый! Моңы да бар, җыры да ишетелә. Ә монда – бака туе! Тавыш кына җитмәгән, өстәвенә барабан кагалар! Әйтерсең, без папуаслар... Карале, әнә теге кара мыеклы егеткә селтәнеп китереп суга, сискәнеп-сискәнеп китәсең. Самавыр капкачы белән поднос кагып утыручыны күр тагын! Тора-тора да китереп ора. Ялгыш орып җибәрәме, куллары белән тотып, шундук тавышын да бетерә. Сукkансың икән, нигә бетерәсең аны? Бәлки, шул тавышны яратучылар да бардыр...

Аркистыр, имеш! Ә үзләренең хадавай иструминтлары юк! Әйе, гармунны әйтәм. Гармунсыз аркистыр буламы инде?! Их, егетләр, егетләр... Китереп утыртасые менә шунда безнең Борһан малае Гыйльманны! Күрсәтерие сезгә аркистырның ничек булырга тиешлеген! Берүзе кыл чиертеп утыручы егерме кешегезне алыштыра ул! Бераз салып та бирсәң – бөтен аркистырыгызны. Прафиссырыгыз белән бергә. Аны алдында таяк селкеп куркытып торасы юк. Үзе белеп уйный. Кеше сүзен, гомумән, яратмый... Хупҗамал малаеның туенда Чүкеч Хәнәфиен тәрәзәдән ничек тотып атты! Муенына ике кат рамны киеп чыкты, мескен! Аягы белән кабыргасы сынып, игә килә алмыйча, ике ел урын өстендә ятты. Хәзер туйга чакырырга килсәләр, куркуыннан өстәл астына кача торган булып калды. «Яшьлегемә кире кайтыр идем»не уйнама, имеш...

Аркистырлы кансиртны карап утырганда, менә шуларны уйладым. Бу аркистыр мәсьәләсендә эшлисе дә эшлисе әле! Бәлки, тиешле кешеләр аны гармун белән алыштырырга кирәк дигән дөрес фикергә килерләр. Гармун үзе бер аркистыр бит ул! Әле минем сәхнәгә чыккан бер генә гармунчының да кеше өстенә салынганын күргәнем юк. Үзе уйный! Хәрәмсез!

Аннары финаныс дигән ягы да бар бит әле. Бер гармунчыны тоту кыйммәтме, әллә йөзгә якын аркистырчынымы? Шулай шул менә...

## Хәбибулла хастасы

Әле генә подъезд төбендәге эскәмиядә үз ишләре белән сөйләшеп утырган Хәбибулла абзыйга әллә нәрсә булды: күршесе Рәхимҗанның яңа машина сатып алу хәбәрен ишетүгә, кулы белән йөрәген тотып, өенә кереп китте. Шуннан бирле, инде бишенче көне, урын өстендә ята. Тамагына да капмый,

дару да эчми, сөйләшми дә. Күзе – түшәмдә. Хәлен белеп чыгыйм, мин әйтәм, су кранын да төзәтте, ишегебезгә йозак та куйган иде...

– Авырып киттекмени, Хәбибулла абзый? – дим.

Дәшми. Хәтта күзен түшәмнән дә алмады.

– Әйе, бәла аяк астында гына йөри... – дидем аннары, сүз юктан сүз булсын дигәндәй. – Кеше мәңге яшәрлек булып дөнья куа-куа да... Әнә син «олигарх» дип йөргән Валентинны... Кичә атып үтергәннәр...

Хәбибулла абзый, башын борып, миңа карап алды.

– Тән сакчылары да коткара алмаган! Шушы көннәрдә генә кәттиженә дә кызыл әтәч җибәргәннәр дип ишеттем.

Хаста җанланып китте.

– Яхшы иткәннәр! – диде ул, башын күтәреп. – Ходай барысын да күрә! Хәрәм акчага салалар...

– Дөрес, аның тагын өч йорты булган икән...

Хәбибулла абзыйның әле генә елмаю йөгергән йөзен янә болыт басты. Шунда артыгын әйтеп ташлавымны төшенеп алдым.

– Берсен тыюлыкта салган булган да, хәзер сүттермәкче булалар ди...

– Шул кирәк андыйларга! – диде хаста, тагын җанлана төшеп. – Булдыра алсалар, айда да кәттиж салдырып куярлары бар!

– Ә бишенче каттагы Хикмәтулла абыйларның... Беләсең син аны... Бездельниклар, һаман подъезд төбе саклап утырасыз, дип бәйләнә иде... Шуларның фатирын басканнар...

– Димәк, подъезд төбен түгел, өен дә саклый алмаган! – Хәбибулла абзый урынына ук торып утырды. – Кешегә акыл өйрәтеп йөрсәң, шулай була ул! Нәрсәләрен алганнар?

– Өч миллионлык әйберләрен чистартканнар.

– Күпме яңалык! – диде йөзенә елмаю җәелгән Хәбибулла абзый, аягына тапочкасын кия-кия. – Ә мин урын өстендә ятам! Юк, энем, болай яту эш түгел бу! Әйдә, урамга чыгыйк әле...

## Күрче бу маймылларны!

Рәсәй депутатларын әйтәм, Дума кәнәфиенә чумып өлгермиләр, дөнья гизәргә тотыналар. Чит илләрнең парламентлары, хөкүмәт төзелешләре, законнары белән танышалар, янәсе! Баралар, йөриләр, карыйлар да, кайтып үзара якалаша, чәч йолкыша башлыйлар... Хәзер телевизордагы Дума утырышы – халык арасында иң популяр, иң көлке тапшыру! Караганда, көлә-көлә эчләр катып бетә! «Вокруг смеха»ны нигә бетерделәр, дип йөри идем, бетермәгәннәр, аны шул утырышлар белән генә алыштырганнар икән. Дөрес эшләгәннәр: бер үк эчтәлекле ике тапшыруның нигә кирәге бар?

«Хайваннар дөньясында» дигән тапшыруны да бетерергә була.... Дума депутатларын тәҗрибә алыр өчен Африка джунглиларына җибәрәсең дә... Анда «алтын йонлы» маймыллар яши икән. Менә кемнәрдән өйрәнергә кирәк безнең депутатларга! Дөрес, бу маймылларның Югары Совет, Дәүләт Советы, Дума, парламент дигән нәрсәләре юк. Президентлары да, хәтта премьер-министрлары да юк. Чөнки аларда акча да юк! Хосусыйлаштыру чеклары да юк! Анда бары тик тәртип дигән нәрсә генә бар!

Президентлары да, хөкүмәтләре дә булмагач, алар белән кем идарә итә? Иң олы, иң абруйлы ак сыртлы маймыл аларның лидеры. Бер гаиләдәге йөзләп

маймыл тормышын әнә шул башлык алып бара. Берүзе! Бер «пом»сыз, бер «зам»сыз! МВДсыз, Генпрокуратурасыз, судсыз! Бездә аны губернатор яисә президент дип йөртерләр иде. Аларда аны бөтен джунгли хөрмәт итә.

Әйе, аларда суд та юк, чурт та, милиция дә юк, КГБ да юк! Алар тәртип бозуның, безнең депутатлар кебек үзара сугышуның ни икәнен дә белмиләр.

Кеше маймылдан чыккан, дип исбат итәләр. Нигә без «алтын йонлы» маймыллардан түгел икән?!

## Рәшәткә

Сигезенче катка күтәрелеп, лифт ишегеннән чыксам!.. Йа Алла! Тәннәрем чымырдап китте. Уңга карасам да, сулга баксам да – тимер рәшәткә. Һәрберсе – юан-юан арматурадан! Алары артында янәдән кат-кат тимер челтәрләр. Һәрберсендә ат башы кадәр йозак! Төрмәме соң бу, әллә зоопаркмы? Зоопарк дисәң, киек-арысланнары юк, төрмә дисәң, богаулы ристаннары күренми. Коточкыч шомлы тынлык!

Ялгыш килеп эләктем, ахрысы, дип шыпан-шыпан артка чигенә башлаган идем, шунда кинәт, күңелне сискәндереп, шалтыр-шолтыр иткән тавыш ишетелде, яман чыелдап, ике катлы рәшәткә артындагы авыр тимер ишекләрнең берсе ачылып китте дә, аннан болай ярыйсы гына кыяфәтле кеше килеп чыкты. Ул, ишеген бикләде дә, кесәсеннән бер бәйләм ачкыч алып, башта беренче, аннары икенче рәшәткәне ачты. Үзе чыгу белән аларын да ашыга-кабалана бикләп куйды.

– Сезгә кем кирәк? – дип сорады ул, миңа шикләнеп карап торганнан соң.

– Мин ни... Кырык алтынчы фатирга, Маһинур апаларга дип килгән идем дә... Әллә ялгыштым, әллә өйдә юклар...

– Шакыгыз, чыгарлар, – диде ул, тынычлана төшеп.

Рәшәткәне дөбердәтә башладым. Ишетәм, шалтыр-шолтыр килеп ишек ачылды да, аннан Маһинур апабыз үзе килеп чыкты.

– Исәнме, Маһинур апа! Сезгә танксыз кереп тә булмый икән хәзер!

– Кем соң әле бу?! Ә-ә, синмени, Сәлимҗан энем? – диде Маһинур апа, тагын бер эчке рәшәткәле ишекне ача-ача.

– Хәлегезне белешеп чыгыйм дигән идем...

– Рәхмәт инде, энем, рәхмәт, – дип сөйләнә-сөйләнә, ул мин басып торган рәшәткә янына якынлашты. – Карале, чыннан да, синме соң бу?! Исәнме, энем, исән-сау гына йөрисеңме?

Ул, күрешергә дип, рәшәткә аша кулын сузды.

– Яхшы гына әле, Маһинур апа, йөрибез әкертенләп, – дидем мин, аның рәшәткә аркылы сузылган кулын кысып.

Күрешкәннән соң ул, кесәсеннән ачкычлар бәйләме чыгарып, чалтыр-чолтыр итеп кирәклесен сайлый башлады һәм, аны табып, ат башы хәтле йозак тишегенә тыкты. Тик, нидер исенә төшкәндәй, шундук икеләнеп калды.

– Синең берәр дакуминтың бармы соң, энем? Чыннан да Сәлимҗан буласыңмы син?

– Сәлимҗан булмый, кем булыйм, Маһинур апа?! Әллә танымыйсыңмы?

– Тануын таныйм да... Алай да паспортыңа карап алсам, мишәйт итмәс. Хәзер әнә нинди заман!.. Адым саен үтереш, талаш. Туганың кыяфәтенә керергә дә күп алмыйлар... Парик-фәлән кию дисеңме...

– Әллә шаяртуыңмы, Маһинур апа? Син мине курчак хәтле чагымнан беләсең түгелме соң?!

– Шаяра торган заман түгел шул, Сәлимҗан энем. Әнә өченче көн күрше йортта ун карчыкны талап чыкканнар, ди! Йә, бармы дакуминтың, юкмы? Булмаса, кереп китәм. Хуш, сау бул!

– Туктале, Маһинур апа, ашыкма! Паспортым үзем белән...

– Күптән шулай диләр аны! Белмәгән кеше белән ләчтит сатып тора торган заманмыни?! Теге атнада күрше йортта... Килеп кергән ди шулай парик кигән бер ачәрвах. Керә-керешкә күрше карчыкны тотып ашамакчы икән, аждаһа! Ярый әле теше үтмәгән, тегесенең тиресе калын булып чыккан, рәхмәт төшкере.

Паспортымны рәшәткә аркылы Маһинур апага суздым. Ул, аны ачып, озак кына бер миңа, бер андагы сурәткә карап-карап алды.

– Чыннан да, син икәнсең шул, Сәлимҗан энем, – диде ул, тикшерә торгач. – Тик, бигайбә, ача алмыйм. Чит кешене фатирга кертү түгел, хәзер үз балаларыңнан да Алла сакласын! Теге атнада менә бу яктагы йортта, туңдырмага акча бирмәгән өчен, ике кечкенә бала әзмәвердәй этиләрен аунатa-аунатa тукмаган! Ике кабыргасын, бер кулын сындырганнар бичараның... Рәшәткә аркылы гына сөйләшеп торыйк. Хәзер Җиһангир абыең кайтырга тиеш, кибеткә генә чыгып китте...

Бер сәгать чамасы сөйләшә-сөйләшә басып торгач, лифттан Җиһангир җизни килеп чыкты.

– Әй-й, кунак бар икән ләбаса! – диде ул, кулларын җәеп. – Исәнме, энем! Нәрсә, кертмиләрме? Шулайдыр шул, шулайдыр. Заманасының асты өскә килде бит хәзер. Беркемгә дә ышана торган түгел. Әнә, ике генә атна элек, күрше урамдагы бер фатирга дүртәү килеп кергәннәр... Аяклары сыерныкы кебек ярык тояклы ди. Эз калдырмас өчен инде, ягъни мәсәлән. Әмма да ләкин йөнтәс койрыклары чалбар төпләрен күпертеп тора ди...

Шулай сөйләнә-сөйләнә, Җиһангир җизни, кесәсеннән ачкыч чыгарып, йозакны ачты. Әле монысы дүрт фатирга уртак рәшәткә икән, эчтә ике фатир өчен тагын бер кат рәшәткәләр бар. Анысын да үттек... Шалтыр-шолтыр килеп, башта тимер, аннан соң агач ишекләр ачылды. Фатирга кердек.

– Нигә үзегезне тимер рәшәткәләр белән әйләндереп алдыгыз?! Караклар кызыгырлык алтын хәзинәгез юктыр лабаса! – дим.

– Әйбер чепуха ул, энем. Баш кадерле, баш! Хәзерге явызлар элек үтерә, аннары гына карый әйберләреңне. Вәйт бит эш нәрсәдә! Әгәр дә шундый рәшәткәң булмаса?.. Әле әнә узган атнада гына Арча кырында...

Шулчак ишектән бик эшлекле кыяфәттә, кабалана-кабалана, күрше фатирда яшәүче туксан дүрт яшьлек Гарифулла бабай килеп керде.

– Карале, Җиһангир, чәнечкеле тимерчыбыкка дип акча җыялар анда. Шуның белән өйне урап алмакчылар. Бирәбезме? – диде ул, исәнләшеп тә тормыйча.

– Күпмешәр? – дип сорады Җиһангир җизни, эшлекле кыяфәт белән.

– Фатир башыннан кырыгар мең, диделәр...

– Җан хакына акча җәлләп булмас, күрше. Шушы көннәрдә пенсия дә алабыз, Алла боерса! Шуларны да кушып, ничек тә җыярга тырышырбыз. Ничек бирмисең? – дип куйды Маһинур апа.

– Дөрес, анасы! Бирмибезме соң! – дип җөпләде аны Җиһангир җизни. – Җан кадерле. Яшисе килә бит әле...

**Редакциядән:**

*Бу көннәрдә каләмдәшебез Әхәт Сафиуллинга 80 яшь тулды. Без Сезгә озын-озак иҗат гомере телибез. Гел шулай шат күңелле, үткен телле язучы булып калыгыз!*

# 2017 елда дини бәйрәмнәр
# һәм истәлекле көннәр

### МӨСЕЛМАН АЙ КАЛЕНДАРЕ БУЕНЧА 1438-1439 ҺИЖРИ ЕЛЛАР

**29 март** – мөселман календаренда изге саналган Рәҗәб аеның беренче көне. Бу айда Ибраһим пәйгамбәрнең, Гайсә пәйгамбәрнең туган көннәре һәм башка истәлекле көннәр билгеләп үтелә. Шулай ук кече хаҗ, гомрә хаҗы кылына.

**31 март** – Рәҗәб аеның беренче җомгасына каршы кич – Рәгаиб кичәсе дип атала. Мөхәммәд пәйгамбәрнең әти-әнисе Габдуллаһ һәм Әминәнең бергә кушылуын искә алу кичәсе дә.

**24 апрель** – Мигъраҗ кичәсе. Мөхәммәд пәйгамбәрнең Мәккә шәһәреннән Иерусалимга һәм аннан җиде кат күккә – Аллаһы Тәгаләнең тәхете янына кылган могҗизалы сәяхәте. Мигъраҗ уразасы 100 төн ураза тотуга тиңләнә.

**11 май** – Бәраәт кичәсе, ягъни «ләйләтул-Бәраәт». Бәхет һәм һәртөрле уңышлар, изгелекләр иңә торган изге көн. Нәкъ шушы төнне Аллаһы Тәгалә, һәркемнең изге гамәле һәм догаларында ялварып сораган үтенечләрен исәпкә алып, кешеләрнең язмышы турында карар кабул итә.

**21 май** – Идел Болгарстанында Ислам динен рәсми рәвештә кабул иткән көн (310нчы һижри, 922нче милади ел).

**27 май** – изге Рамазан ае һәм Ураза башланган көн. Рамазан аенда иң кадерле кичә – Кадер кичәсе (22 июнь).

**25, 26, 27 июнь** – Гайдел-фитыр. Ураза бәйрәме.

**31 август** – Гарәфә көне. Хаҗ кылучылар тарафыннан Мәккә янындагы Гарәфә тавына бару һәм тау итәгендә намаз уку көне.

**1 сентябрь** – Гайдел-Әдъхә, Корбан бәйрәме. Мөселманнарның иң зур бәйрәме. Ураза тәмамлангач, нәкъ 70 көннән соң башлана торган Корбан чалу бәйрәме, ул 3 көн дәвам итә. Бу көн Татарстан Җөмһүриятендәге барлык календарьларда кызыл төс белән билгеләнгән.

**2, 3, 4 сентябрь** – Тәшрикъ көннәре. Бу көннәрдә мөселманнар, фарыз намазларын укыганнан соң, Аллаһы Тәгаләне мактап махсус сүзләр әйтәләр.

**21 сентябрь** – 1439 ел, яңа мөселман елы һәм Мөхәррәм ае башланган көн. Бу айда күп итеп хәер (зәкят) бирелә, изге гамәлләр кылына.

**30 сентябрь** – Гашура бәйрәме. Сөнниләр – Аллаһы Тәгаләнең ун пәйгамбәренә күндерелгән изгелекләре хөрмәтенә, ә шигыйлар, Мөхәммәд пәйгамбәрнең оныгы Гали хәлифәнең улы Хөсәенне (626-680) җәзалап үтерү көнен мөбарәк, изге вә хөрмәтле санап, ураза тота.

**16 ноябрь** – Сәфәр ае башланган көн.

**1 декабрь** – Мәүлид бәйрәме. Иң зур бәйрәмнәрнең берсе – Мөхәммәд пәйгамбәрнең туган көне. Әлеге изге бәйрәм нәкъ бер ай дәвам итә. Бу вакытта мәчетләрдә вәгазьләр укыла, хәер, садака (зәкят) өләшенә. Күп кенә мөселман илләрендә факеллар һәм фонарьлар кабызып, тантаналы мәрасимнәр уздырыла.

*Төзүче-мөхәррир –*
**Хаҗи Абдулла ДУБИН.**

# 2016 елда «Казан утлары» журналында басылган әсәрләр исемлеге

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЛАРЫ**

2016 елда Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләрен бирү турында. №5

«Татарстан Республикасының Халык шагыйре» дигән мактаулы исем бирү турында. №7

«Татарстан Республикасының Халык язучысы» дигән мактаулы исем бирү турында. №7

**БАШ МӨХӘРРИР СҮЗЕ**

Ибраһимов И. Әдәбият елы дәвам итә... №1

**ГАМЬЛЕ ӘҢГӘМӘ**

Мәңгелек яшь кала *(Чаллы шәһәре башлыгы Н.Мәһдиев белән И.Ибраһимов әңгәмәсе).* №1

Яшәү матурлыгы – саулыкта *(Татарстанның һәм Россиянең атказанган табибы Р.Бакиров белән И.Ибраһимов әңгәмәсе).* №7

Театр – тылсымлы учак *(Оренбург рус драма театрының баш режиссёры Р.Исрафилов белән И.Ибраһимов әңгәмәсе).* №8

**ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Әмирханов М. Бибимәмдүдә. *Бәян.* №4

Әхмәтгалиева А. Ул югалмады. *Хикәя.* №1

Батталова Г. Саваплы сабак. *Хикәя.* №11

Батулла Р. Зәйтүнәкәй туташ. *Хикәя.* №4

Батулла Р. Аклы-каралы хикәятләр. №6

Вәлиев Р. Дөнья гаме. *Роман.* №№2-4

Галиев М. Тимә, яшәсен! *Роман-новелла.* №№10-12

Галиуллин Т. И, карак... *Бәян.* №10

Гәрәева А. Ни һоу! Яки нихәл? *Хикәя.* №8

Диндаров И. Боз өстендә. *Хикәя.* №6

Җамалетдинова Ф. Яратып китү. *Хикәя.* №3

Зарипов Ә. Әманәт. *Бәян.* №№7-8

Имамов В. Сөләйман солтан. *Тарихи роман.* №1

Имамов Ф. Мәхәббәт талисманы. *Фантастик бәян.* №9

Кәримова Р. Ташлы туфрак. *Документаль бәян.* №9

Моталлапов Ә. Йөзә торган арба. *Бәян.* №7

Мөхәммәтша Р. Җиктереп пар ат, Казанга... Гадәти бер кич иде. *Хикәяләр.* №7

Мулланурова Р. Гамәл дәфтәре. Әләк. *Хикәяләр.* №6

Низами Р. Блокада хатирәсе. *Хикәя.* №5

Нуриев В. Ни хәлең бар, балам?.. *Бәян.* №5

Сабирова Л. Бер уч борчак. *Бәян.* №7

Садриев Ф. Тургай. *Бәян.* №№3, 5, 6

Салихов Д. Чукрак. *Роман.* №№11-12

Харисова Н. Эссе җәйнең ун көне. *Бәян.* №7

Хафизов С. Тузгытылган күч. *Бәян.* №№1-2

Хәлим А. Исемсез малай. *Хикәя.* №1

Хәмзин А. Бармагыңнан үбәр идем... *Бәян.* №9

Хәсәнова Г. Ул. *Хикәя. (Р.Зәйдулла тәрҗемәсе).* №12

Хәсәнова Г. Кайту. *Хикәя.* №12

Шаһиев Р. Китмә, эти! *Хикәя.* №2

Якупова С. Ятим йорт. *Хикәя.* №8

Яһудин М. Миң. *Хикәя.* №1

**ШИГЪРИЯТ**

Әминева Ж. Җаным үзе зәңгәр күбәләк. *Шигырьләр.* №11

Әхмәдиев Н. Офык артларында офык бар. *Шигырьләр.* №12

Әхтәмова Г. Бирешмәс көчләр табам. *Шигырьләр.* №12

Бәйрәмова Г. Һәр сүзнең үз моңы, үз көе. *Шигырьләр.* №8

Булатова К. Шигъри көзләр әле дәвам итә. *Шигырьләр.* №3

Вәлиева Л. Мәңгелек бәхеткә ышанам. *Шигырьләр.* №7

Вәлиев Р. Без – мәңгелек туган җир беләән. *Шигырьләр.* №9

Гаташ Р. Тукай хозурында *(Гомер дастаныннан). Шигырь.* №4

Гаязов Ә. Урау юллар урау түгел. *Шигырьләр.* №6

Гыйбадуллина Л. Җанның кышка әзер түгел чагы. *Шигырьләр.* №1

Гыйләҗев И. Халкың гаме коткарыр. *Шигырьләр.* №1

Җамал Р. Үзем белән сөйләшәмен әле. *Шигырьләр.* №10

Җамалетдинова Ф. Җир шарына әйләнүләр теләә. *Шигырьләр.* №7

Җәлил М. Бер үгет. *Шигырь.* №2

Җәлилова Э. Күңелемнең күтәрелеш чоры. *Шигырьләр.* №3

Захарова З. Күңелдән шигырь тама. *Шигырьләр.* №3

Ибраһим Б. Кайнарлык бөркелсен рухыңнан. *Шигырьләр.* №8

Иделбикә. Кан тамыры кебек елгалар. *Шигырьләр.* №5

Идиятуллин Р. Бу заман нинди заман соң? *Шигырьләр.* №7

Иксанова И. Гомерем фасыллары. *Шигырьләр.* №2

Имаев Р. Минем җанда – үзгә кояш. *Шигырьләр.* №9

Кәримова Г. Кайгылыга кулым суздыммы? *Шигырьләр.* №7

Лерон Л. Бер яшисе иде кешечә. *Шигырьләр.* №8

Миңнуллин Р. Дәверләргә китеп барышы. *Шигырьләр.* №8

Мирза М. Хакны нахактан аерып... *Шигырьләр.* №11

Мөхәммәтшин Г. Яшьлегемнән мәңге китмәм. *Шигырьләр.* №10

Мөхияр Р. Күңелемнең төрле чагы була. *Шигырьләр.* №1

Низами Р. Туар идем җиргә яңадан. *Шигырьләр.* №10

Османов Д. Һәрбер сүзе җан назлаучы. *Шигырьләр.* №6

Рәхим Г. Язмышлар ул – безнең ялгышлар. *Шигырьләр.* №7

Рәшит Ә. Мөхәммәд. *Поэма.* №3

Садыйков М. Тамыр җәйдек туган туфракка. *Шигырьләр.* №5

Сафин Ф. Без – Тукайлы халык! *Сонет-такыя.* №4

Солтан Ф. Сулар ага – комнар кала... *Шигырьләр.* №11

Сөләйман Җ. Яңа халәт тоеп оча күңел... *Шигырьләр.* №11

Сөя халык үзенең Тукаен *(Х.Туфан, Н.Нәҗми, Ф.Җамалетдинова, Р.Рахман, Р.Аймәт, Р.Сүлти, Й.Миңнуллина шигырьләре).* №4

Таңчулпан. Гомер үтә шулай тоташтан. *Шигырьләр.* №12

Тукай Г. Туган тел. *Шигырьләр.* №4

Фәйзуллин Р. Яңа шигырьләр. №6

Харис Р. Аһ, үзгәрә дөнья!.. *Шигырьләр.* №5

Хафизов М. Шатланып туймый күңел. *Шигырьләр.* №9

Хәйруллин Д. Вакыт бит ул вакытлыча гына. *Шигырьләр.* №1

Шәрипов Р. Җомга. *Поэма.* №2

Якупова С. Тирбәлә шагыйрь җаны. *Шигырьләр.* №1

**ДРАМА ӘСӘРЛӘРЕ**

Хәким З. Ля бемоль. *Ике пәрдәле драма.* №9

**ПУБЛИЦИСТИКА**

Абдуллин Ф. «Җидегән чишмә»ләргә йөзек салдым... №9

Әхмәтгалиева А. «Син кояштан үрнәк алсаң...» *Очерк.* №6

Әхмәтгалиева А. Бу хыяллар нигә якты дисәң... *Очерк.* №9

Бәйрәмова Ф. Ерак Көнчыгышта татарлар. №№1-3

Даутов Г. Олуг максатка мәгариф аша килик. №5

**ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ**

Батулла Р. Күзен ачкач, Зөләйха нәрсә күрде икән? №2

Заһидуллина Д. Чаллы шагыйрьләре-нең иҗат үзенчәлекләре. №1

Заһидуллина Д. Кыска бәяннар конкурсы белән бәйле уйлар. №3

Кутлу Ф. Зәйтүнә – Тукай мәхәббәте дәвам итә... №4

Мансуров З. Шигырь белән ясак түләп... *(Шагыйрь И.Гыйләҗев иҗатына бер караш).* №3

Мансуров З. Укыйсың да уйлыйсың. №6

Мөбарәкшина А. Тукай турында «Кардәш каләмнәр». №7

Низами Р. Йолдызның серле дөньясы. №11

Рахман Р. Без хәтерлибез *(шагыйрь Г.Моратның иҗат портретына штрихлар).* №3

Рахман Р. Әдәбият елында – татар шигърияте. №4

Сверигин Р. Тургайларның туган ягы. №8

Турдыев Ш. Тукай һәм үзбәк әдәбияты *(Л.Хәмидуллин тәрҗемәсе).* №4

Ханнанов Р. Кеше язмышыннан – милләт язмышына. №4

Хатипов Ф. Ясалма трагедия. №5

Хәбетдинова М. «Без барыбыз да Тукай балалары...» №4

Хәбетдинова М. «Курилка-кухня-ларда»н – киң әдәби мәйданга. №11

Хәлим А. Бер сөйләшик, икәү калганда... №11

Хөснетдинова Л. Китап киштәсендә ниләр бар? №1

Шәрипов Ә. Шигъриятта Сирин стиле. №1

Юсупова Н. «Йөрәкләр турында язасы бар әле...» №7

Яхин Ф. Сикәлтәле юл кешесе. №11

**ТАРИХ**

Бәйрәмова Ф. Соңгы туранчы... *(Һади Атласиның тууына 140 ел).* №№8, 10, 11

Исхаков Д. Татар халкының этник тарихын яңадан барлау. №7

Фәйзуллин Р. Каләмне – микрофонга, микрофонны каләмгә тиңләп. №10

«Татар энциклопедиясе» битләреннән. №3

**МИЛЛИЯТ**

Таһиров И. Изге сөткә ни җитәр? №5

**СӘНГАТЬ**

Арсланов М. Татарның трагик артисты. №3

Бәйрәмова Г. Яратып китү. №5

Бәйрәмова Г. Көлүдә дә хикмәт бар. №10

Бәйрәмова Г. Чын безнеңчә – милли... *(Рушан Шәмсетдиновка 70 яшь).* №12

Галиев Р. Рәссам. №9

Галиева Ф. Гомер – бер мизгел. *(Миңгол Галиевкә 75 яшь).* №8

Закирова Э. Эльмира Кәлимуллина: «Мин – Түбән Кама кызы!» №9

Зарипов Ә. Минзәләм йолдызлыгы *(Сабир Өметбаев исемендәге Минзәлә татар дәүләт драма театрына 80 ел).* №1

Илялова И. Яшь шәһәрнең яшь театры. №9

Сафиуллин Ю. Сәхнәдән нур чәчеп. №8

Хәмзин А. Маэстро. №9

Шакиров Ә. Шәхесләр, язмышлар... *(Гөлсем Камскаяның тууына 115 ел).* №3

Юныс Р. Җаны-тәне тулы җыр-моң иде! *(Сара Садыйкованың тууына 110 ел).* №11

**ТУКАЙ БЕЛӘН ӘҢГӘМӘЛӘР**

Мансуров З. Һәр хыялдан татлыдыр милләт хыялы. №4

**ТУКАЙ ҺӘМ ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ**

Рахман Р. Тукай сулаган сулыш. №1

Рахман Р. Кол Гали һәм Тукай. №2

Рахман Р. Каләмнең милли асылы. №3

Рахман Р. Тукай очырган карлыгачлар: Хәдичә Шаммасова. №4

Рахман Р. Тукай очырган карлыгачлар: Гыйффәт туташ. №5

Рахман Р. Тукай очырган карлыгачлар: Зәйнәп Сәгыйдә. №6

Рахман Р. Тукай очырган карлыгачлар: Оркыя Ибраһимова. №7

Рахман Р. Тукай очырган карлыгачлар: «Бездә юк, булса да бик аздыр, беләм, тәнкыйтьчеләр». №8

Рахман Р. Тукайча көләм. №10

Рахман Р. «Шигырь тәсбихенең бисмилласы...» №11

Рахман Р. Тукай эзләреннән йөргән галим: Мөхәммәт Гали. №12

**100нче БИТ**

Газимҗанова Г. Бу – минем фикерем. №11

Исхаков Д. 1552 ел: хәтерләр яңару. №10

Корбан Р. Әдәбият милләтнең әхлакый йөзен билгеле. №1

Лерон Л. Әбиләр бәби тапмый. №3

Миңнегулов Х. Рухи мирасыбыз һәрчак юлдаш булсын! №5

Морат Г. Тукай җиләне. №4

Мөхәммәтша Р. Сәламәт тәндә... сәләмә рух? №2

Мөхәммәтша Р. Татарлыкта татар улы... кем? №7

Уразай Ф. Милләтне хәтер вә рух яшәтә. №8

Ханнанов Р. Яхшы атның нәселе калмый?.. №6

Хәким З. Янгын чыккач соң булыр. №9

Юныс Р. Явызлыкка һәйкәл кирәкме? №12

**ШӘХЕСЛӘРЕБЕЗ**

Галимуллин Ф. Исән калуы – әдәбият бәхетенә. №6

Хәлим А. Йөз елдан да эзле без, йөз елдан соң эзлибез. №6

**ӘДӘБИ ХӘЗИНӘЛӘРЕБЕЗ**

Шәрипов Ә. Сирин Батыршинның тууына 120 ел. №12

Батыршин С. Тормыш хатирәләре. *Автобиографик бәян-истәлек.* №12

**ӘДӘБИ БЕРЛӘШМӘЛӘРДӘ**

«Кама таңнары» әдәби берләшмәсе иҗат әһелләренең шигырьләре *(Ф.Абдуллинның кереш сүзе белән).* №9

**ТАТАР ХИКӘЯЛӘРЕ ХӘЗИНӘСЕННӘН**

Сабитов Г. Бизәкле чиләк. *Хикәя.* №10

Шамов А. Дустым кабере янында. *Хикәя.* №5

**ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫНЫҢ XVIII СЪЕЗДЫН КАРШЫЛАП**

Корбанов Р. Үткәннәргә хисап тотканда. №5

Татарстан Язучылар берлегенең XVIII корылтаеннан күренешләр. №7

**ЮБИЛЕЙЛАР**

ГАБДУЛЛА ТУКАЙНЫҢ ТУУЫНА – 130 ЕЛ

Шәймиев М. Үз Тукаебыз. №4

«Түгәрәк өстәл»: Тукай гасыры дәвам итә... *(З.Рәмиев, Р.Исламов, З.Мансуров, Җ.Миңнуллин, Т.Гыйләҗев, Г.Төхфәтова, А.Мөбарәкшина катнашында). Р.Ханнанов әзерләде.* №4

Тукай – истәлекләрдә. Галимҗан Әмирхан, Шәриф Байчура, Заһид Нуркин истәлекләре *(Р.Исламов, Җ.Миңнуллин кереш сүзе белән.)* №4

Юныс Р. Сер саклаучы фотолар. №4

ФАТИХ ӘМИРХАННЫҢ ТУУЫНА 130 ЕЛ

Вәлиев М. «Вакыт, әфәнделәр, вакыт!» №2

МУСА ҖӘЛИЛНЕҢ ТУУЫНА 110 ЕЛ

Бәдигый Х. Муса Җәлил әсәрләренең поэтик лингвистикасы. №2

Җыры белән җиңгән дошманын *(Р.Низами, М.Мирза, Ф.Мөслимова, Г.Морат, Л.Лерон, Р.Зәйдулла, Г.Корбанова, Р.Сәлахов, Ф.Гыйләҗев, Э.Һадиева, Р.Мөхәммәтша шигырьләре).* №2

Шамов А. Ике очрашу. №2

Шамова Ә. Бер фоторәсем тарихы. №2

ГАМИЛ АФЗАЛНЫҢ ТУУЫНА 95 ЕЛ

Мирза М. Гомерләр кичкәндә. №5

Афзал Г. Мәңгелек гамь. *Шигырьләр.* №5

САҖИДӘ СӨЛӘЙМАНОВАНЫҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ

Сәйфуллина Ф. Шигъри сүзнең шигъри көче. №10

Сөләйманова С. Сабыр канатлары. *Шигырьләр.* №10

РӘШИТ ӘХМӘТҖАНОВНЫҢ ТУУЫНА 75 ЕЛ

Вәлиев М. «Кыр казлары очып узарга...» №5

Әхмәтҗанов Р. Татар теле. *Шигырьләр.* №5

ТӘҮФИКЪ ӘЙДИНЕҢ ТУУЫНА 75 ЕЛ

Галиуллин Т., Галиуллин Р. Язмыш йөртә кешене. №5

ФИРДӘВЕС ГАРИПОВАНЫҢ ТУУЫНА 75 ЕЛ

Ханнанов Р. Туганкай. №12

МӨДӘРРИС ӘГЪЛӘМНЕҢ ТУУЫНА 70 ЕЛ

Морат Г. Әкә. №10

Әгъләм М. Китә алмыйм шуны белмичә. *Шигырьләр.* №10

ХАРРАС ӘЮПНЫҢ ТУУЫНА 70 ЕЛ

Хәсәнова Ф. Шигъри дога остасы иде ул... №8

Әюп Х. Авырткан җир. *Шигырьләр.* №8

РАФАЭЛЬ СИБАТНЫҢ ТУУЫНА 70 ЕЛ

Мостафин Ш. Үзебезнең «татар Шолоховы». №10

Сибат Р. Рухым елый сулкылдап... *Шигырьләр.* №10

**КОТЛЫЙБЫЗ!**

ХИСАМ КАМАЛОВКА 90 ЯШЬ

Галимуллин Ф. Сугышчы әдип – сафта. №5

ХӘНӘФИ БӘДИГЫЙГА 75 ЯШЬ

Галиуллин Т. Язмышка мәдхия. №1

ФОАТ ГАЛИМУЛЛИНГА 75 ЯШЬ

Әхмәдуллин А. Киң карашлы галим һәм җәмәгать эшлеклесе. №3

Галимуллин Ф. Яңа тормыш күпере. *Тормыш язган хикәя.* №3

РӘДИФ ГАТАШКА 75 ЯШЬ

Янсуар Л. Үзе булып кала алган шагыйрь. №3

РЕНАТ ХАРИСКА 75 ЯШЬ

Шәех Л. «Мин – мәңге тутыкмас алтын төрән!» №5

РАУЛЬ МИР-ХӘЙДӘРОВКА 75 ЯШЬ

Кәримов К. Батырларча иҗат. №12

ӘНВӘР ШӘРИПОВКА 75 ЯШЬ

Галимуллин Ф. «Мин дөньяны үзем иҗат итәм...» №10

РАВИЛ ШӘФИГУЛЛИНГА 75 ЯШЬ

Хәмидуллин Л. Күңел дәрьялары киң аның. №12

МАРСЕЛЬ ГАЛИЕВКӘ 70 ЯШЬ

Хәбетдинова М. «Без бу җиргә юкка килмәгән!» №10

НУР ӘХМӘДИЕВКӘ 70 ЯШЬ

Шәрәфиев Р. Мәҗнүнгә дә үз дәүләте кирәк. №12

СОЛТАН ШӘМСИГӘ 70 ЯШЬ

Сверигин Р. Күңелендә галәм чиксезлеге... №2

НӘБИРӘ ГЫЙМАТДИНОВАГА 60 ЯШЬ

Гайнуллина Г. Рухи камиллеккә омтылу. №10

РӘЗИНӘ МӨХИЯРГА 60 ЯШЬ

Хафизов С. Учларында утлы күмер... №5

ТАТАР ТЕАТР СӘНГАТЕНӘ 110 ЕЛ

«Халыкка дәрсе гыйбрәттер театр». №12

Илялова И. Театр – җәмгыятьнең барометры ул. №12

Ханнанов Р. Җилкәннәрне сыный чор җилләре. №12

Хәбетдинова М. Синең ничә нигезең бар? №12

ТҮБӘН КАМА ШӘҺӘРЕНӘ – 50 ЕЛ

Метшин А. Түбән Кама – туган йортыбыз. №9

ТР ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕНЕҢ
ЧАЛЛЫ БҮЛЕГЕНӘ 35 ЕЛ

Сафин Ф. Иҗат уты дөрләп яна. №1

ТҮБӘН КАМА
ПЕДАГОГИКА КӨЛЛИЯТЕНӘ – 35 ЕЛ

Галәветдинова Л. «Балаларны... башка заман өчен укытыгыз». №9

**ХӘТЕР**

Made in Schali. Кыймылдыйлар... №6

Юнысов М. Күк капусы. №6

**ДИН ҺӘМ ТОРМЫШ**

Гарипова Х. Шагыйрь дәһри була алмый! №4

**КИТАП КҮЗӘТҮ**

Сафиуллин Ә. Мөнбәрендә – шәхесләр, каләмендә – шәрехләр. №3

**ТОРМЫШ ЯЗГАН ХИКӘЯЛӘР**

Гайнанова Л. Берәү генә калды... №11

**ҖӘҺӘТ ӘҢГӘМӘ**

Җәлил елмаюы *(Ч.Җәлилова белән Г.Бәйрәмова әңгәмәсе).* №3

**ЯҢА ИСЕМНӘР**

Батталова Г. Ихласлыкка сусаган җан. *Шигырьләр.* №5

Сафина Э. Һич кимемәс шатлыгым. *Шигырьләр.* №6

Фәттахова Л. Җанымда илаһи тылсым. *Шигырьләр.* №12

Хафизова А. Язларымда кайтырсың. *Хикәя.* №10

**АК ҖИЛКӘН**

Әбрарова А. Мин сиңа гашыйкмын... *Шигырьләр.* №3

Газизуллина А. Җиңү көненә. *Шигырь.* №6

Гафурова Г. Телне саклыйк. *Шигырьләр.* №4

Гыйльметдинова А. Дустыбыз син, Тукай. №4

Давыдова К. Ни өчен икмәк агачта үсми? *Әкият.* №6

Зәкиева Э. Аның тәне дә көчле булган. №2

Кашапова И. Серле кунаклар. *Хикәя.* №8

Кәлимуллина Р. Бака-бакылдык. *Әкият.* №5

Муллагалиева Л. Бәхет тукталышы. *Хикәя.* №1

Муллагалиева Л. Әни җылысы булса... *Хикәя.* №4

Сунаев Р. Бүләккә тун. *Әкият.* №1

Ханнанов Р. Кәкре кадак. *Хикәя.* №6

Хәерова Л. Кояш халкы. *Хикәя.* №9

Хәкимуллин Б. Тукайга. *Шигырь.* №4

Шакиров К. Көтелмәгән очрашу. №2

Шәфиева Р. Тукайга. *Шигырь.* №4

Алинә Айдарова, Гүзәл Әмирова, Алсу Гыйниятуллина, Гөлүсә Нигъмәтҗанова, Ләйлә Хуҗина, Сөмбел Әхмәтҗанова, Нәзилә Сибгатуллина, Алия Корбанова шигырьләре. №1

«Хикәя яза аласызмы!» №№2, 3, 5, 6, 7, 8, 9

**БӘЛӘКӘЙЛӘР**

Ганиев Р. Бәләкәй Рөстәм. №9

Имашев М. Бәләкәй Мәсгут. №8

Сөләйманова Ф. Бәләкәй Флюра. №6

Хәким З. Бәләкәй Зөлфәт. №5

**ТАБИГАТЬ ҺӘМ МИН**

Кәримов К. Этюдлар. №6

Нуриев В. Җиңүче кем? №8

Юныс Р. Хатирәләр. №7

**ЮБИЛЕЙГА БАРЫШЛЫЙ**

Ахмеров З. АБ-225. *Очерк.* №8

Әпсәләмов Г. Көндәлек дәфтәремнән. №5

«Безнең юл» журналы турында. №6

Гыйләҗев А. Журналыбыз турында. №7

Даллин Г. Һади Такташ Кызыл Армиядә. №10

**СӘФӘРЛӘР, ОЧРАШУЛАР, ТӘЭСИРЛӘР...**

Тукай эзләре буйлап... №5

Әдипкә истәлек тактасы. №6

«Ак җилкән» конкурсы – Әлмәт төбәгендә. №6

**УКУЧЫЛАРЫБЫЗ ИҖАТЫ**

Аллабирде Р. Яшәрмен гел сезнең арада. *Шигырьләр.* №6

Гыйләҗева С. Хәтер. *Хикәя.* №3

Җиһангәрәева Р. Без кемнән ким? *Юмореска.* №3

Камалова З. Бәхетле. *Шигырьләр.* №3

Нигъмәтуллина Р. Ни чәчсәң... *Хикәя.* №3

Шәриф Х. Тормышчан хикәяләр. №10

**КАЙТАВАЗ**

Фәттахова Р. Театрга тарихи тема кирәкме? №1

Фәттахова Р. Үзем өчен яңа автор ачтым. №10

Хәйруллин И. Үз тарихын белмәгәннең киләчәге юк. №1

**ЮМОР**

Кашапов И. Аптырар дип уйлама. №9

Сафиуллин Ә. Шаян монологлар. №12

Хәйруллин И. Гаилә кризисы. №9

**ШАЯН СӘХИФӘ**

Уены-чыны бергә. *Сәхифәне М.Галиев әзерләде.* №№1-11

Мәкаль өмәсе дәвам итә. №2

«Танымыш» дәресе. №№2, 3, 6

2017 елда дини бәйрәмнәр һәм истәлекле көннәр. *Абдулла Дубин әзерләде.* №12

«Казан утлары» архивыннан. *Сәхифәне Р.Фәйзуллин әзерләде.* №№1-12

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. *Сәхифәне В.Нуриев әзерләде.* №№1-12

Яңа китаплар. №№2, 4

Хушлашу сүзе. Хисам Камалов. №12

## РӨСТӘМ МИҢНЕХАНОВНЫҢ АМЕРИКАДА ҺӘМ ФРАНЦИЯДӘ ТАТАР ҖӘМӘГАТЬЧЕЛЕГЕ БЕЛӘН ОЧРАШУЫ

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов АКШка эш сәфәре кысаларында Америка төрки-татар ассоциациясе җитәкчелеге һәм активистлары белән очрашты.

Берлингейм шәһәрендәге (Калифорния) Татар йорты залында булган очрашуга 50дән артык кеше килгән иде. Имам Абдул-Даяп Сафа дога укыды. Олуг кунакны Америка төрки-татар ассоциациясе президенты Туран Апакай сәламләде.

АКШтагы татар җәмгыяте эшчәнлеге белән Америка төрки-татар ассоциациясе әгъзалары Рукия Сафа, Адилә Сафа, Гүзәл һәм Илдус Әхмәдуллиннар таныштырды.

Рөстәм Миңнеханов Америка төрки-татар ассоциациясе активына тарихи ватаннан еракта үз халкыбызның йолаларын, гореф-гадәтләрен, телен саклап калу һәм үстерү эшенә керткән өлешләре өчен рәхмәт белдерде. «Сез бер-берегезне таба алгансыз, халкыбызның гореф-гадәтләрен, йолаларын, телен һәм мәдәниятен саклар өчен берләшкәнсез», – диде ул.

Аннары Татарстан Республикасы Президенты бөтен дөнья татарларын берләштерә торган проектлар, шул исәптән татар телен өйрәнү буенча «Ана теле» онлайн системасы, «ТНВ-Планета» иярченле телеканалы, «Tatarile» глобаль социаль челтәре һәм башка мөмкинлекләр турында сөйләде. Очрашу ахырында кунаклар Габдулла Тукай сүзләренә иҗат ителгән «Туган тел» җырын башкарды.

Рөстәм Миңнеханов эш сәфәре кысаларында Парижда Франциянең татар җәмәгатьчелеге белән дә очрашты. Очрашу Франциядә Россия Илчелеге территориясендә үткәрелде. Чарада татар җәмгыяте активистлары, «Франция Татарстан йорты» ассоциациясе вәкилләре катнашты.

Очрашуда Көнчыгыш телләре һәм цивилизацияләре институтының INALCO (Париж) татар һәм рус телләре укытучысы Ләйлә Садовинова татар телен укыту мәсьәләләре турында сөйләде, шушы вуз студенты Александр Казачевски татар телендә Габдулла Тукайның «Туган тел» шигырен укыды.

Россиянең Франциядәге Гадәттән тыш һәм тулы вәкаләтле вәкиле Александр Орлов Илчелекнең татар җәмгыятенә төрле чаралар, шул исәптән милли бәйрәмебез Сабан туен да уздырырга ярдәм итәргә әзер булуын әйтте.

## ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ ҺӘМ СӘНГАТЕ КӨННӘРЕ

Екатеринбургта һәм Свердловск өлкәсендә татар әдәбияты һәм сәнгате көннәре булып узды. Ул Екатеринбургта Татарстан сәнгать осталары концерты белән башланып китте. ТРның Урал төбәгендәге вәкиллегендә очрашу булды. Татарстан Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов, «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире Ләбиб Лерон, ТРның халык язучысы Нәбирә Гыйматдинова, язучы, галимә Рифә Рахман Урта Бугалыш, Сыскы, Рахмангол, Әртә-Шигер, Әҗегол, Уфа-Шигер, Үрмәкәй, Әрәкәй, Шәкүр һәм Төреш авылларында булып халык белән очраштылар.

## ТАНТАНА

Актанышта сәләтле балалар укый торган гуманитар гимназиянең торак-интернат бинасын ачу тантанасы булды. Бу чара әлеге уку йортының биш еллык тәүге юбилеена туры килде.

Актаныштагы механикалаштырылган күчмә колонна җитәкчесе Асыл Шәяхмәтов гимназия директоры Рамил Гарипов кулына символик ачкыч тапшырды. Кунаклар тулай торак бүлмәләрен карап чыкканнан соң, тантана район мәдәният йортында дәвам итте. Бәйрәмгә ТР Премьер-министр урынбасары – мәгариф һәм фән министры Энгель Фәттахов, Россия Дәүләт Думасының милләтара мөнәсәбәтләр комитеты рәисе Илдар Гыйльметдинов, Татарстан Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов, «Казан утлары», «Мәдәни җомга», «Безнең мирас» матбагаларының баш мөхәррирләре Илфак Ибраһимов, Вахит Имамов, Ләбиб Лерон һ.б. кайткан иде.

## КОНФЕРЕНЦИЯЛӘР

ТР Фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында татар әдәбияты классигы Фатих Әмирханның тууына 130 ел тулугa багышланган фәнни-гамәли конференция үткәрелде. Конференцияне институт директоры Ким Миңнуллин ачып җибәрде. ТР Фәннәр академиясе президенты Мәгъзүм Сәлахов, ТР Милли музее генераль директоры Гөлчәчәк Нәҗипова, ТР Диния нәзарәте рәисе урынбасары Рөстәм хәзрәт Хәйруллин, Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары Рәмис Аймәт котлау сүзе белән чыктылар. Конференциядә Фатих Әмирханның тормышы, иҗаты һәм мирасы турында докладлар ясалды, моңарчы басылмаган бүлекләре белән тулыландырылган «Хәят» әсәренең яңа басмасы тәкъдим ителде.

* * *

Шагыйрь Сириннең (Мөхәммәдсәйрин Хәниф улы Батыршин) тууына 120 ел тулу уңаеннан Ютазы урта мәктәбендә республикакүләм фәнни-гамәли конференция булып узды. Аны ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы, Чаллы педагогика университеты, Ютазы башкарма комитетының мәгариф бүлеге һәм Ютазы урта мәктәбе оештырды. Конференциядә катнашучыларны район башкарма комитетының мәгариф бүлеге җитәкчесе Г.Гыйләҗева, Ютазы мәктәбе директоры Ә.Ямалетдинов, Чаллы педагогика университеты профессоры Ә.Шәрипов

котлады. Аннары конференция эшен дүрт секциягә бүленеп дәвам иттерде. Сирин иҗаты турында язылган иң яхшы докладлар билгеләп үтелде. Конференция кысаларында Сирин шигырьләрен сәнгатьле уку буенча бәйге дә үткәрелде.

## ЮБИЛЕЙЛАР

ТР Милли музееның әдәби салонында ТРның халык язучысы, Г.Тукай исемендәге Дәүләт, Г.Державин исемендәге Бөтенроссия премияләре лауреаты Марсель Галиевкә 70 яшь тулу уңаеннан әдәби кичә булды. Кичәдә юбилярны ТРның халык шагыйре Разил Вәлиев, академик Индус Таһиров, каләмдәшләре Ркаил Зәйдулла, Газинур Морат, артистлар Әзһәр Шакиров, Дания Нурлы, Рөстәм Маликов һ.б. котлады. Кичәне салон хуҗабикәсе Флёра Дәминова алып барды.

* * *

Татарстан Язучылар берлегенең Г.Тукай клубында прозаик Нурислам Хәсәновка, шагыйрь, прозаик, галим Хәнәфи Бәдигыйга – 75, шагыйрь, галим Рифат Җамалга 65 яшь тулу уңаеннан әдәби-музыкаль кичәләр булып үтте. Юбилярларның иҗаты турында әдәбият галимнәре Тәлгат Галиуллин, Фоат Галимуллин, Хатыйп Миңнегулов, Рифат Сверигин сөйләде. Н.Хәсәновны – Татарстан Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов, каләмдәшләре Рашат Низами, Хәлим Җәләй, Х.Бәдигыйне – ТР Мәдәният министрлыгы вәкиле Айгөл Софийская, Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары Рәмис Аймәт, язучылар Камил Кәримов, Вакыйф Нуриев, Рифат Җамал, Казан федераль университеты, Казан дәүләт консерваториясе, Арча педагогика, Казан театр көллиятләре вәкилләре, Р.Җамалны ТР Дәүләт Советының Мәдәният, мәгариф, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Разил Вәлиев (ул Парламент Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин имзалаган Рәхмәт хатын да тапшырды), Татарстан Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов, каләмдәшләре Зиннур Мансуров, Ринат Мөхәммәдиев, Шаһинур Мостафин, Рифат Сәлах, элекке коллегалары – республика ветеринария хезмәте җитәкчеләре, Казан ветеринария академиясе галимнәре котлады. Бәйрәмдарларның якташлары – Теләче, Арча муниципаль районнары башкарма комитеты җитәкчеләре урынбасарлары Альфред Шәйдуллин, Рамил Гарифҗанов, авылдашлары да үзләренең ихлас котлауларын ирештерделәр. Кичәләрне Луара Шакирҗанова, Алмаз Хәмзин алып бардылар.

* * *

Чаллы шәһәренең «Энергетик» мәдәният сараенда «Мәйдан» әдәби-нәфис, иҗтимагый журналына 15 ел тулу уңаеннан тантаналы кичә үткәрелде. Редакция коллективын Чаллы шәһәре башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Рамил Хәлимов, Чаллы педагогика университеты ректоры Фәйрүзә Мостафина, Татарстан Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов, ТР матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе урынбасары Илдар Миргалимов, «Татмедиа» АҖнең генераль директоры урынбасары Сөмбел Таишева, «Казан утлары», «Безнең мирас», «Мәгариф», «Гаилә һәм мәктәп» журналлары, «Мәдәни җомга», «Шәһри Чаллы» газеталары, Чаллы Татар дәүләт драма театры вәкилләре, шәһәрнең мәгариф учреждениеләре, оешмалар җитәкчеләре, бер төркем язучылар котлады. Кичәдә «Мәйдан»ның беренче баш мөхәррире Факил Сафин, редакция белән байтак еллар җитәкчелек иткән Вахит Имамов истәлек-хатирәләре белән уртаклаштылар. Аларның чыгышын журналның бүгенге баш мөхәррире Фидаил Мәҗитов дәвам иттерде. Кичәне шагыйрә Зөләйхә Минһаҗева алып барды.

## «КАЗАН УТЛАРЫ» ИДАРӘСЕ УТЫРЫШЫ

«Казан утлары» журналы идарәсенең чираттагы утырышы булды. Аны журналның баш мөхәррире Илфак Ибраһимов алып барды.

Утырышның көн тәртибенә редакциянең 2016 елдагы эшчәнлеге һәм журналның ел дәвамында чыккан саннары турында фикер алышу, 2017 елга тематик планны карау һәм «Казан утлары»ның 95 еллыгы уңаеннан планлаштырылган чаралар турында сөйләшү кертелгән иде. Беренче көн тәртибе буенча басманың баш мөхәррир урынбасары Рамил Ханнанов чыгыш ясады. 2016 елда журналда 4 роман, 12 повесть, 21 хикәя, 42 шагыйрьнең поэмалары, шигырьләре, сонет-робагыйлары, тәнкыйтьче, галимнәребезнең 42 язмасы басылып чыкты. 2017 елга тематик планда да 6 роман, дистәләрчә бәян, хикәя бастырып чыгару күздә тотыла. Бүлек мөхәррире Рәзилә Хәйретдинова журналның яңартылган сайты турында сөйләде.

Утырышта ТР Дәүләт Советының Мәдәният, мәгариф, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе, Татарстанның халык шагыйре Разил Вәлиев, «Татмедиа» акционерлык җәмгыятенең генераль директоры киңәшчесе, Татарстанның халык шагыйре Равил Фәйзуллин, КФУның Л.Толстой исемендәге филология һәм мәдәниятара коммуникацияләр институты директоры Рәдиф Җамалетдинов, ТР Фәннәр академиясенең баш гыйльми сәркатибе, әдәбият галимәсе Дания Заһидуллина, Татарстан Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов, ТРның халык шагыйрьләре Рәдиф Гаташ, Зиннур Мансуров, галим тарихчы Дамир Исхаков, шагыйрь, әдәби тәнкыйтьче, галим Мөдәррис Вәлиев, ТР мәгарифне үстерү институтының милли мәгариф лабораториясе өлкән методисты Мингаян Мозаффарова һ.б. чыгыш ясады. Идарә әгъзалары редакция эшчәнлегенә һәм журналның эчтәлегенә, рәсми сайтына югары бәя бирде. Утырышта байтак кына киңәш-тәкъдимнәр дә әйтелде. Сүз нигездә традицион проза белән бергә экспериментал әсәрләрне дә бастырып чыгару, зур күләмле роман, бәяннарны кереш сүз белән бирү, публицистиканы көчәйтү, тарихи әсәрләргә һәм мәкаләләргә игътибарны арттыру, милли мәгариф проблемаларын даими яктырту һ.б. турында барды.

## КОТЛЫЙБЫЗ!

Татарстан Республикасы мәнфәгатьләрендә күпьеллык нәтиҗәле хезмәте, актив иҗади һәм җәмәгать эшчәнлеге өчен Балтач муниципаль районы сугыш һәм хезмәт ветераннары (пенсионерлары) советы президиумы әгъзасы, шагыйрь **Мөхәммәтшин Гарифҗан Садыйк улы** ТРның «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләнде.

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*«Проза и поэзия»: роман-новелла М.ГАЛИЕВА «Да пусть живёт!», роман Д.САЛИХОВА «Глухонемой», рассказы Г.ХАСАНОВОЙ; стихи Н.АХМАДИЕВА, Г.АХТЯМОВОЙ, ТАНЧУЛПАН.*
*«100-ая страница»: Р.ЮНУС. «Ставить ли памятник лютости?»*
*«Новые имена»: стихи Л.ФАТТАХОВОЙ.*
*«Наши юбиляры»: статьи Р.ШАРАФИЕВА, посвящённая 70-летию Н.Ахмадиева;*
*Г.БАЙРАМОВОЙ, посвящённая 70-летию Р.Шамсутдинова;*
*К.КАРИМОВА, посвящённая 75-летию Р.Мир-Хайдарова;*
*Л.ХАМИДУЛЛИНА, посвящённая 75-летию Р.Шафигуллина;*
*Р.ХАННАНОВА, посвящённая 75-летию со дня рождения Ф.Гариповой.*
*«Тукай и татарская литература»: рубрику ведёт Р.РАХМАН.*
*«Литературное наследие»: А.ШАРИПОВ. «120 лет со дня рождения С.Батыршина»; С.БАТЫРШИН. «Воспоминания жизни».*
*«Татарскому театральному искусству – 110 лет»: Р.ХАННАНОВ. «Без ветрил» на сцене академического театра; М.ХАБУТДИНОВА. «У тебя сколько отчих домов»; И.ИЛЯЛОВА. «Театр – это барометр общества».*
*«Юмор»: рассказы А.САФИУЛЛИНА.*
*Из фотоархива журнала.*
*Библиографический список произведений, опубликованных в 2016 году.*
*Дневник общественно-культурной жизни.*
*На наших обложках: Улица К.Насыри. Апанаевская мечеть.*
*Дом муллы Исанбаева и Шамсутдиновых – картина народного художника РТ Рушана Шамсутдинова; Казань. р.Казанка.*

## IN THIS ISSUE:

*«Prose and poetry»: romance-novel by M.GALIEV «Let him live!», novel by D.SALIHOV «Deaf-mute», stories by G.HASANOVA; poems by N.AHMADIEV, G.AHTYAMOVA, TANCHULPAN.*
*«100th page»: R.YUNUS. «Should we put up a monument to ferocity?»*
*«New names»: poems by L.FATTAKHOVA.*
*«Our anniversaries»: articles by R.SHARAFIEV dedicated to the 70th anniversary of N.Ahmadiev;*
*G.BAYRAMOVA dedicated to the 70th anniversary of R.Shamsutdinov;*
*K.KARIMOV dedicated to the 75th anniversary of R.Mir-Khaydarov;*
*L.HAMIDULLIN dedicated to the 75th anniversary of R.Shafigullin;*
*R.KHANNANOV dedicated to the 75th birth anniversary of F.Garipova;*
*«Tukay and Tatar literature»: section is conducted by R.RAHMAN.*
*«Literary heritage»: A.SHARIPOV. «120th birth anniversary of S.Batyrshin»; S.BATYRSHIN. «Memories of life».*
*«Tatar theatrical art is 110 years old»: R.KHANNANOV. «Without the sails» on the stage of the Academic theater; M.HABUTDINOVA. «You have so many folds»; I.ILYALOVA. «Theatre is a barometer of society».*
*«Humor»: stories by A.SAFIULLIN.*
*From the photo archives of the magazine.*
*Bibliography of works published in 2016.*
*Diary of the social-cultural life.*
*On our covers: Street K.Nasyri. Apanaevskaya mosque.*
*Mullah Isanbaev's and the Shamsutdinov's house – picture of the national artist of the Republic of Tatarstan Rushan Shamsutdinov; Kazan. the Kazanka river.*

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* К.Насыйри урамы. Апанай мәчете.
Мулла Исәнбаев һәм Шәмсетдиновлар йорты.
*ТР халык рәссамы Рушан Шәмсетдинов картинасы.*

*Тышлыкның дүртенче битендә:* Казан. Казансу елгасы.